www.kazanutlary.ru

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Флёра ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Мин фал ачам бүген киләчәккә... *Шигырьләр*. ...3
Рафис КОРБАН. Ватан. *Роман*. ...8
Җәүдәт СӨЛӘЙМАН. Аяктагы тышау әле коллык түгел... *Шигырьләр*. ...67
Чыңгыз АЙТМАТОВ. Чыңгызханның ак болыты. *«Бер көн – бер гомер» романына нисбәтле повесть. (Мөдәррис ВӘЛИЕВ тәрҗемәсе)*. ...71
Рашат НИЗАМИ. Кайда ялган, кайда дөреслек?.. *Шигырьләр*. ...102
Илдус ДИНДАРОВ. Каршылыклар кыры. *Повесть*. ...106

ЯҢА ИСЕМНӘР

Ринат АБЗАЛОВ. Һәр көн – ачыш... *Шигырьләр*. ...128
Чулпан ХАҖИЕВА. Әсәлем... *Хикәя*. ...131

*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ...139

«ШИФАЛЫ КУЛЛАР» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. «...кисмә безнең канатларны!» *Хикәя*. ...141

«ТАТАРСТАН. ТАРИХ. ШӘХЕСЛӘР» ӘДӘБИ ОЧЕРКЛАР КОНКУРСЫ

Зәлифә ӘХМӘТГАЛИЕВА. «Нәселемнең мин бер тәрәзәсе». *Очерк*. ...156

БАЛАЛАР КИТАПХАНӘСЕ

Роза ХАФИЗОВА. Әти кайткан көнне. *Хикәя*. ...163

ШИГЪРИ ХӘТЕР

Госман САДӘ. Һәр учакның җаны, үз теле бар... *Шигырьләр*. ...171

ФӘНЗАМАН БАТТАЛНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Рифә РАХМАН. Адашмаган каләм. ...174

ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

Лена ГАЙНАНОВА. Сәгадәт. ...177

ФӘН

Айрат СИТДЫЙКОВ, Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Хәзәр каһанлыгының башкаласы. ...184

*Котлыйбыз!* Рәфыйк Шәрәфиевкә 70 яшь. ...185

*Музейларыбыз*: сәхифәне Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН алып бара. ...186

*Шаян сәхифә*: Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде*. ...187

«Казан утлары» архивыннан. ...154
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ...190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Рамил Ханнанов.**

*Җаваплы сәркатип:* **Вакыйф Нуриев.**

*Бүлек мөхәррирләре:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**

*Мөхәррирләр:* **Лилия Вагыйзова, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева.**

*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).

*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип һәм проза бүлеге – 222-09-83 (өст. 1613)*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.01.2019, график буенча 30.01.2019.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-212. Тираж 4004.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2019 ел



Флёра
Гыйззәтуллина

# МИН ФАЛ АЧАМ БҮГЕН КИЛӘЧӘККӘ...

## Киләчәктән багам бакыйга

Мин – хакыйкать! –
Шигъри галәмнәнмен –
Ватанымның ваем даласы.
Җаным аша уза кешелекнең
Үлем белән яшәү арасы.

Мин, мөгаен, чыдам-түземлекнең
Мәрмәр кыяларга хасыдыр.
Назларымның барын кыядагы
Бөркет оясына ташыдым.

Шушы назлар рухи канат ярып
Гамен яктырталса халкымның,
Мин төннәрен иман кыйбласыннан
Тулган ай күк нурда балкырмын.

Сызылып таң атканда, таң сулары
Иелеп алырмын мин Иделдән...
Иман даулап татар җан атканда,
Иделләр дә тулып түгелгән.

Мин – хакыйкать!
Шигъри галәмнәнмен!
Киләчәктән багам бакыйга.
Мин сезне дә ияртермен, дуслар,
Күңелегез булса хак уйда.

---

Флёра ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА (1931) – *шагыйрә; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. «Йөрәгемдә шаулый карурман», «Күз нурларым», «Башкаемда дөнья исәпләре» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Бар да тыныч кебек

Ярсып-ярсып моңсу җилләр исә,
Ил кайгысы җилгә күчкәнме?
Җиргә кичке эңгер төшеп килә,
Кайтып килә халык эштәнме?

Эшсезләрме әллә төркем-төркем
Эш эзләргә чыккан кич кырлый?
Бар да тыныч кебек... Беркем туктап:
– Ачка үләм! – диеп кычкырмый.

Мин дә тыныч...
Төркемдәгеләргә
Юл бирәмен алга чыксалар –
Күзгә чалынып кала затлы туннар,
Шәп бүрекләр, чуклы букчалар.

Кайберәүләр кул арбасы тарткан,
Сыртлап төяп үтмәс тауарын.
– Күрсәт әле, – диеп, сорар идем –
Бәясенең беләм чыгарын.

Кичке эңгер төшеп килгән чакта,
Уйларымнан калмый бер адым,
Мин ияреп халык төркеменә
Урыйм икән базар урамын.

Төнгә кадәр кайный икән халык,
Сата... ала икән аласын.
Ни генә юк монда! Күзең ертып
Карыйсың да таңга каласың.

Тагын йөз мәртәбә, мең мәртәбә
Үзалдыңа уйлап аласың:
«Бүген болай... ә иртәгә нинди
Тәкъдир көтә адәм баласын?»

## Язмышларым әкияттәге төсле

Язмыш миңа ятимлеген биргән,
Хакимлеген биргән урманның.
Ылыс шавы, яфрак шыбырдавы –
Эшчәнлеге минем кулларның.

Язмыш миңа үги ана биргән,
Үгилекнең биргән баланын...
Үги: «Балам», – дисә, баланнарга
Таң тамчысы булып тамамын.

Язмыш миңа сөяр ярын биргән
Һәм сөюнең биргән бөеген:
Кыш аенда чыршы әйләнәли
Ай егете белән биедем.

Кыш өстеннән язлар йөгереп узды,
Кыңгыраулар гөлдә чыңлады...
Язмышларым әкияттәге төсле,
Әкиятләрнең азмы чыннары?!

***

Еллар уза...
Ә мин алга барам,
Яргаланам язмыш ярыдай.
Сөембикә алкасына охшап,
Баш очымда калка ярым ай.

Гомер уза...
Узган гомер өчен
Айлы кичләр – моңлы тамаша!
Айның яктыртуы – борынгыча,
Моңаюы гына яңача.

Чорлар уза...
Еллар аръягына
Аударыла гомер олавы.
Сөембикә елавына охшаш
Җилләрнең дә быел елавы...

## Бөре фалы

Яз хөрлеге бит ул җир-анага
Багышланып ачкан фалларда,
Җәйге таңда сары сандугачлар
Кунып сайрый торган талларда.

Ил кодрәте – кылган догабызда,
Кыйбла тарафына йөз тотып...
Изге дога! Намаз вакытында
Эри йөрәктәге мең котып.

Язгы якта һәр тереклек сакта!
Җан кояшка таба талпына.
...Мин фал ачам бүген кодрәт юллап,
Имин тормыш юллап халкыма.

Мин фал ачам бүген, киләчәккә
Учта тотып җирнең күчәрен...
Башым куйган намазлыкка тиеп,
Бәргәләнә бәгырь кисәгем.

Җир искәртә безгә яз килүен,
Назлап язның бөдрә бөресен.
Яздай эреп бер тыңлагыз әле,
Бөре фалы сөйли дөресен.

Бөре фалы: «Сөям... яратам...» – ди,
Яз түрендә дөрли-дөрли дә,
Мин фал ачам... ләкин үзем өчен
Кирәк түгел инде берни дә.

Мин бит инде Җир кешесе түгел! –
«Яратам!» – дип артык өзелмәм.
Еллар узгач, бер багармын язга,
Тамчы булып шигырь күзеннән.

## Ашыгыч ярдәм көткәндә

Ак ефәккә күз нурымны түктем,
Туй күлмәге тектем – йөзләгән...
Хак Тәгалә аклык өләшкәндә
Рәхмәтеннән мине өзмәгән.

Кара эштән дә бит кодрәт алдым:
Чуен юллар салдым Себердә.
Себердәге эшелоннар шавы
Озата мине гомер-гомергә.

Үз җырыма салып иҗат иттем,
Мәхәббәтнең шигъри аһәңен.
Көч-кодрәте сулмый, төсе уңмый
Мәхәббәттән алган бәһанең.

Ак ефәккә күз нурымны түктем –
Бөтен дөньям нурга күмелгән.
Үзем исә ашыгыч ярдәм көтәм,
Чыгар өчен кара үлемнән...

Гүя һаман эшелоннар көтәм,
Шигъри йөкләремне төяргә.
– Тырышлыгым артыбрак киткән,
Кичерегез мине! – дияргә.

## Төнге очрашу

Төн иде... Очрашып урамда
Атладың син минем көемә.
Сумкамны күтәрдең, үземне
Кунарга чакырдың өеңә.

Юк!.. Әле без гашыйк түгелләр.
Ирекле, чиста, пакь күңелләр.
Әйтерсең, тылсымлы каурыйдан:
Гәүдәләр шундый да җиңелләр.

Очасы көнебез – алдадыр:
Әлегә канатсыз – очмыйбыз.
Карандаш очлаган шикелле
Бары тик төн юлын очлыйбыз.

Менәбез баскычтан баскычка,
Шатлыгың чылтырый ачкычта.
Күзләрең күземә төбәлә:
Күренми күңелсез күләгә.

Без өйдә!
Бу синең ятактыр...
Әйбәтләп ак җәймә япкансың.
Үтенәм: кузгатма син аны! –
Хәтеремдә шул килеш саклансын...

Баш төртеп ятучы табылыр,
Синең бу ялгызак мендәргә.
Исемемне әйтмим дә, мин китим,
Сабырлык өстәргә төннәргә.

Мин китим озакка-озакка...
Кирәкми, син мине озатма.
Насыйп яр булалмам барыбер,
Минем бит йөрәгем – тозакта.

Көннәрем-төннәрем чуалган,
Мин күптән берәүнең әсире.
Җанымны «Ирек!» дип илертә,
Хурлыклы әсирлек тәэсире.

Әсирлек, коллыкка юлыккан
Мәхәббәт аяусыз, кызганыч!
Син мине, мин сине белмичә
Гомерләр заяга узган ич!

Очраштык...
Урамда – кара төн!
Төн минем бердәнбер сердәшем.
Ул шушы мизгелне күпсенеп,
Көндәшкә әверелә күрмәсен...

## Дога кыл, иркәм

Мәхәббәт – упкын! Упкыннан калка
Дөрлисе хисем, үрлисе кыям.
Мин синең өчен, тик синең өчен
Упкын төбеннән чәчәкләр җыям.

Кояш тирәли энҗе сибәли,
Чәчәккә төргән йөрәк серләрем.
Минем йөрәгем ничә ел инде
Сине чакырып елый төннәрен.

Мәгъруур кыялар боера миңа:
– Сөйгән ярыңны, чык, – дип, – эзләргә!
Упкын төсе бар, чәчәк төсе бар,
Кояш төсе бар минем күзләрдә.

Күземә карап һәр әйткән сүзең
Үзәкне өзә исемә төшеп.
Күзлисеңме син минем күзләрне,
Килмисеңме син упкынга күчеп?

Тоясыңмы син үз йөрәгеңдә
Кояш җылысын, кыя сулышын?
Кояшлы җырың артык мул, димә,
Бу – минем синнән алган бурычым.

Бу – сиңа булган кадер-хөрмәтем,
Кыя төсендә, кояш төсендә.
Исәнлек теләп дога кыл, иркәм,
Минем өчен дә, Кадер кичендә.

Мәхәббәт – дога... Мәхәббәт – упкын! –
Чор маңгаена чокып каелган.
Җир йөзендәге ошбу аерма:
Кемнедер аяп, безне аерган...

Рафис
Корбан

# ВАТАН

РОМАН

**Икенче бүлек**

**1**

Вустрауга әсирләрне китерә тордылар, милләтенә карап төрле легионнарга, батальоннарга бүлгәли тордылар. Кыска сроклы укулардан соң лагерьларга озата бардылар. «Идел-Урал» легионы батальоннары барысы да Едлино лагеренда оештырылган булып чыкты. Анда татарларны, башкортларны һәм чувашларны чүпләп җибәрделәр. Легионерларның бер өлешен Познань шәһәренә озаттылар. Татар эмигранты Искәндәр Яушев Шәфи Алмастан үзенең Германия армиясенең хәрби заказларын үти торган фабрикасында эшләүче поляклар өстеннән күзәтче булып торырга татар егетләрен җибәрүне сораган иде. Познаньга киткән утызлап легионер арасында, асылда, Гайнанның Демблин лагеренда оештырган яшерен оешмасындагы капут-команда егетләре булды. Аларга өстәп, Муса, авылдашы Назыйф Һадиев белән дусты Салих Ганиевне дә Яушев фабрикасына җибәртте. Егетләргә гаять җитди һәм җаваплы бурыч йөкләнде: фабрикада корткычлык эше алып бару. Муса аларга тагын бер мөһим эш йөкләде: поляк эшчеләре аркылы партизаннар белән элемтә урнаштыру. Монысы лагерьдан кача-нитә калганда, партизаннар отрядына чыгу өчен кирәк иде.

Яшерен оешманың штаб кебек төп җитәкчелек урыны булмаса да, бөтен оештыру эшләре Демблиннан, Гайнан Кормашев аркылы алып барылды. Һәм Җәлил белән килешенеп башкарылды. Оешманың пропаганда буенча җаваплы кешеләре Берлинда, «Идел-Урал» комитетында тупланды. Монда «Идел-Урал» гәзитен чыгару белән шөгыльләнүчеләр Алиш, Гариф Шабаев, Фоат Булатов, Зиннәт Хәсәнов легион тормышын кайнатты. Зиннәт күбрәк Берлин белән Радом арасында йөрде – Едлинога мөһим хәбәрләрне җиткереп торды, аннан гәзит һәм «Винета» радиостудиясенә татарча тапшыру өчен яңалыклар алып кайтты. «Винета»да тапшыруларны Әхмәт Симаев әзерли иде.

«Идел-Урал» комитетында татар легионын оештыру буенча янып йөргән тагын бер төркем милләтчеләр эшли иде. Алары – сугышка кадәр коммунистлар тарафыннан төрлечә кыерсытылган, җәбер күргән кешеләр – Шиһаб Нигъмәти, Гариф Солтанов, Сабит Кунафин, Рәис Самат һәм башкалар. Аларның да теләкләре изге – большевиклар тарафыннан милли азатлыгын югалткан татар

*Дәвамы. Башы беренче санда.*

милләтенә Гитлер ярдәме белән бәйсез дәүләт төзүгә ирешү. Ләкин Җәлил аларны «саташканнар» дип атады. Алар Әхмәтвәли Мәңгәр, Галимҗан Идриси, Казыйм Миршан кебек эмигрантлар йогынтысына бирелгән, шулай ук, СССР сугышта җиңелгәннән соң, татар дәүләтен төзергә мөмкин булыр, дип уйлаучылар иде. Сугышта әсирлеккә төшеп, татар легионына агитаторлар булып эшли башлаган Муса, Алиш, Симаев кебек комитетчыларны элекке коммунистлар буларак, өнәп бетермиләр иде. Аңнары белән дә коммунистларга карата нәфрәт, күрә алмау хисе идарә итте. Аларда болай да канлы террор нәтиҗәсендә җәфа күргән совет кешеләренең михнәтле тормышка күнеп яшәргә мәҗбүр булуларын аңлау дигән нәрсә җитеп бетми иде. Моннан егерме еллар элек кенә социалистик революция шаукымы кайнаган Германиядә дә властька Гитлер җитәкчелегендәге национал-социалистлар партиясе килде бит әнә. Аларның да СССРда Сталин алып барган сәясәттән бернинди дә аермалары юк. Германиядә коммунистлар белән шыплап тулган концлагерьларның исәбе-хисабы булмаган кебек, СССРдагы ГУЛАГ лагерьларында утырган «халык дошманнары»н кем санап бетергән?! Һәм менә шул фашистлар, коммунистларны юк итеп, СССР халыкларына нинди рәхәт тормыш алып килергә мөмкин? Эмигрант комитетчылар үз алларына шундый сорау биреп карадылар микән? Муса бик еш кына әнә шулар хакында уйлый иде.

Шөгыльләнсеннәр комитетчылар үз эшләре белән, ләкин һәрвакыт алар янында булырга, ни кылганнарын, нәрсә сөйләгәннәрен белеп торырга, бер үк вакытта легиончыларны дошманга каршы көрәшкә өндәүче яшерен эш алып барырга – Җәлилнең бөтен максаты шул булды.

Вустрауда татар легионерлары төркеменең җитәкчесе итеп Шиһабетдин Нигъмәтуллин дигән әсир билгеләнгән иде. Ул 1941 елның ноябрендә үк Волхов астында барган сугышларда чолганышта калып, фашистлар кулына төшкән. 1913 елда Себернең Омски өлкәсендәге Речник дигән татар авылында туган, мәктәптә укыткан, Кызыл Армиягә алынып, кече лейтенант дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән бу кешенең совет хакимиятенә нинди дәгъвасы булгандыр, ул белешмә кәгазьләрен тутырганда, «әсирлеккә үз теләгем белән төшәм», дип белдергән иде. Эш урынын да «мәктәп директоры» дип яздырган, хәрби дәрәҗәсен дә «өлкән лейтенант» дип күрсәткән. Әле хәтта шигырьләр дә яза икән. Монысы хакында Муса Җәлил белән беренче күрешкән көнне Рәхим Саттар әйтте.

Мусаны Саттар белән шул Шиһабетдин очраштырды. Шиһаб Нигъмәтуллин Вустрауга Муса Җәлил исемле шагыйрь китерелүен ишеткән көнне үк аның белән күрешеп, танышырга теләде. Татар әсирләре башлыгы буларак, үзенең дәрәҗәсен күрсәтәсе килде. Ләкин әсирләр арасында аның әллә ни абруе юк иде. Үзе дә кешеләргә куркыбрак, шикләнеп караучан, артык игътибар үзәгендә булырга теләми торганрак бер бәндә иде бугай. Ләкин тәкәбберлек дигән нәрсә бик көчле иде үзендә.

– Әйдәгез әле, Муса абый, мин сезне тагын бер үзебезнең кеше белән күрештерәм, – диде Шиһабетдин, Муса белән танышканнан соң. Ул аны лагерьның чәнечкеле тимер чыбыклар белән уратып алынган беренче, ябык зонасына алып чыгып, татар әсирләре өчен укулар бара торган баракка алып керде.

Баракта Гитлерның «Майн кампф» китабы буенча дәрес бара иде. Дәрес алып баручы Галимҗан хәзрәт Идриси, татар әсирләре башлыгы Шиһабетдин Нигъмәтуллин нindидер бер чит кеше ияртеп килеп кергәч, кулы белән ишарәләп, торып басарга әмер бирде.

– Утырыгыз, утырыгыз, – диде Шиһабетдин. Аннары, Галимҗан хәзрәткә

мөрәҗәгать итеп: – Рәхим Саттар әфәндене берничә минутка дәрестән җибәрмәссезме икән? – дип сорады.

Рәхим Мусаны шундук танып алды. Хәзрәтнең рөхсәт бирүен дә көтмичә, ул урыныннан торып, алар янына ашыкты.

Муса белән Рәхим кочаклашып күрештеләр. Казанда татар яшьләре гәзите редакциясендә журналист булып эшләгән Рәхим Саттар белән Муса яхшы танышлар иде.

Алар, хәзрәткә дәрес алып барырга комачауламас өчен, ишегалдына чыкты.

Уфа губернасының Чишмә районына караган Түбән Хәзрәт авылында Сөләйман мулла гаиләсендә туган Рәхим кечкенәдән куркусыз, кыю һәм үҗәт холыклы булып үсте. Мәктәптә укыганда, укытучы дәрес тыңламыйча тәртипсезләнеп утырганы өчен талчыбык белән сыйлаганнан соң, укуын ташлап, мәктәпкә барудан баш тарткач, әтисе аны, Уфага илтеп, шәһәр мәктәбенә урнаштырырга мәҗбүр булды. Алай да малай бик кызыксынучан иде, белемгә тартылды. Комсомол тормышы белән кызыксынып китте. Гәзитләргә хәбәрләр яза, шигырьләр чыгара башлады. Армиядә хезмәт итеп кайткач өйләнгән, һәм Казанда хатыны, Ил белән Алсу исемле балалары калган Рәхим Саттар, сугыш башлангач, үз теләге белән фронтка китте. Десант гаскәрләренә эләкте. 1942 елның 27 июнендә Вязьма районында дошман тылына ташланып, алар төркемнәре белән тулысынча әсирлеккә төштеләр. «Идел-Урал» легионы оештырылуы турында ишеткәч тә, ул, ике дә уйлап тормыйча, легионга язылды.

– Син дә мондамыни, Муса абый? – дип, иң якын кешесен күргәндәй кочып алды ул Җәлилне.

– Кемнәрне генә күрештермәде, табыштырмады Вустрау! – диде Шиһабетдин, ике дусның очрашуында үзенең дә өлеше бар кеше кебек.

– Нишләтәсең инде, тәкъдиреңә шулай язылган булгач, – диде Муса. – Калган дуслар белән туган илгә кайткач, Казанда күрешербез, язган булса.

– Ходай язган булса, диген.

– Ходайның монда бернинди катнашы да юк, Нигъмәтулин энекәш, – диде Рәхим үзеннән бер генә яшькә кече Шиһабка беркадәр мыскыллы тон белән.

– Алай көлмә әле син, Рәхим туган. Әле минем кебек җитәкчеләр булуына сөенеп туймассыз. Менә мин булмасам, күпме ятар идегез шушы базда казынып? Демблиннан Вустрауга чыгардым үзегезне. Моннан да Седльцега олактырмыйча, рәтлерәк бер эш табып бирергә дип ниятләп торган көнем.

– Рәхмәт инде. Карга карганың күзен чукымый, диләр бит. Син дә шагыйрь, без дә шагыйрьләр, бер-беребезне эт типкесендә йөртмәскә иде бит, кана.

– Үзем дә шул турыда әйтмәкче идем. Иртәгә лагерьга зур кешеләр киләчәк. Көнчыгыш территорияләр министры Розенбергның килүе дә көтелә. Аның артыннан ук сезне Берлинга озатырга исәпләп торам. «Идел-Урал» гәзите редакциясендә эшләрсез. Сезнең өчен бер дигән хезмәт урыны булачак. Муса абый, сезгә дә Берлинга китәргә күптән вакыт.

– Шәфи абзый күптән чакыра иде. Шулай итмичә булмас, ахры, – диде Муса. – Монда кадр да табылды гәзит өчен. Бик әйбәт булды әле бу! – дип, ул Рәхимнең иңеннән кочты.

– Менә яхшы, – диде Шиһабетдин. – Мин китим әле. Кайбер эшләрем дә бар. Сезнең документларны да әзерләп куярга кирәк. Каршы түгелсездер бит, Германиягә китеп эшләргә?

– Юк, әлбәттә! – диде Рәхим. – Һәй, онытып та торам икән. Шиһабетдин

әфәнде дә үзебезнең кеше. Шиһаб Нигъмәти дигән тәхәллүс белән милли гәзитләребездә шигырьләре дә чыккалап тора.

– Алай ук зур шагыйрь түгел инде. Үзем өчен язган булам шунда, – дип, тыйнаклык күрсәткәндәй итте Шиһабетдин. Аннары: – Ярар, мин китим. Сез сөйләшегез, киңәшегез. Күптән күрешмәгән дусларның сөйләшер сүзе күп була ул, – дип, үз казармасына юл алды.

– Рәхмәт, Шиһаб әфәнде, – диде Рәхим. Аннары, ярым пышылдап: – Алдыңнан артың хәерлерәк, – дип куйды. – Йә, сезнең хәлләр кай тирәдә, Муса абый? – дип, Җәлилгә сүз катты.

– Безнең хәлләр бертөсле булырга тиеш дип беләм. Күргәнеңчә, ятабыз шушында пыскып, яна алмыйча. Үзең соң, үзең нинди уйлар белән яшисең? – дип, Саттарның кылларын чиртеп карарга ашыкты Муса, үз планнарын ачып салырга теләмичә.

– Качарга иде бу козгыннар оясыннан, Муса абый. Беренче уңайлы очрак чыгуга качарга дигән ният белән легионга язылырга да булдым.

– Ә көрәшергә?.. Көрәшергә исәбең юкмыни?

– Кем белән, ничек?

– Фашистлар белән. Легионга шуның өчен языла бит халык.

– Алар да шул минем ише, күбесе качарга җай чыкмасмы, дип хыяллана.

– Качарга һәрвакыт җай чыгарга мөмкин. Ләкин көрәшергә кирәк, Рәхим дускай. Берлинда «Идел-Урал» комитетында «Идел-Урал» дигән гәзит чыга. Анда безнең егетләр эшли. Абдулла Алиш, Гариф Шабаев, Фоат Булатов... Син дә шушы командага кушылсаң, бер дигән йодрык булачакбыз. Гәзитнең мөмкинлекләрен сиңа аңлатып торасы юк. Гәзит язмалары аша легион солдатлары арасында коралларын фашистларга каршы борырга агитация алып барачакбыз. Планнар зур. Листовкалар язып тарату. Берлинда «Винета» дигән радиостанция бар. Көненә ярты сәгать кенә булса да татарча тапшырулар бирәләр. Әхмәт Симаев эшли. Гайнан Кормашны беләсеңдер, шагыйрь егет. Ул да безнең белән. Мин бөтен карталарны ачып салдым бугай инде. Әле тагын бар безнең арада ышанычлы егетләр. Бергә-бергә әллә ниләр эшли алыр идек.

– Кызык кына. Миңа нинди эш булыр икән соң?

– Шиһаб дустың, эш табам, диде бит. Редакция тирәсендә эш бетмәс. Материаллар язып торырсың. Гәзит бөтен әсирләргә таратыла. Астыртын эш йөртсәк, әсирләрне үз ягыбызга аударырга ничек тә җай табылыр дип уйлыйм. Тик бу хакта беркем белән дә сөйләшмәскә! Чит кешеләр алдында авыз да ачмаска. Оешмада кемнәр булуын оешма әгъзалары да белергә тиеш түгел, җитәкчелектән кала.

– Әлбәттә, конспирация булырга тиеш. Шунсыз эш барып чыкмас.

– Килештек алайса. Иртәгә, Шиһабның сүзе хак булса, безгә паспортлар бирерләр. Ирекле гражданнар булачакбыз. Германиянең теләсә кайсы җиренә барырга мөмкин аннары.

– Бирсен Ходай!

Иртәгесен лагерьда ниндидер үзгә бер җанлылык сизелә иде. Укыту баракларында да, казармаларда да кай арададыр диварларга немец һәм урыс телендә лозунглар язып элделәр. Юлларга ком китереп тараттылар. Ашыга-ашыга, кирпеч корылмаларны акшарларга тотындылар. Кайбер иске-москы, ертык-пыртык киемнәрдән йөргән әсирләргә кайсыдыр ил солдатларыннан салдырылган киемнәр кияртteләр, сәләмә сандалиларын салдырып, күн сандалилар бирделәр. Иртәнге аштан соң лагерьга ялтырап торган кап-кара

лимузиннарда хәрби башлыклар килгәне күренде. Машиналарның берсеннән озын гәүдәле, чигә турысы агара башлаган юка чәчле, озынча муенлы генерал төште. Аның тирәсендә йөгерешкән күпсанлы хәрбиләр тавык тирәсендә чабышкан чебиләрне хәтерләтә иде. Менә алар, берсен берсе узыша-узыша, генералның әле алдына, әле артына чыгып, әле бер, әле икенче казармага кереп, алардагы әсирләрнең хәлләре белән таныша башладылар. Казармаларны әйләнеп чыккач, генерал лагерь начальнигы оберштурмфюрер Френцель белән комендатура урнашкан бинага юнәлде. Ә бераздан кайбер легионерларны, рейхсминистр боерыгы буенча, аның белән аерым сөйләшү өчен, комендатурага чакырта башладылар. Исемлектә Муса да бар иде.

Рейхстагның иң зур түрәләренең берсе белән шәхси сөйләшү хәтта Гайнц Унгляубеның үзенә дә бик тәтемәгән бер чакта, үзе кебек гади бер әсирне кабул итүен Муса нәрсәгә дип юрарга да белмәде. Комендант бүлмәсенә килеп кергәч тә, иң беренче булып, аңа Розенберг сүз кушты. Аның: «Хәлләрегез ничек, Муса әфәнде?» – дип, татарча соравы Мусаны беркадәр каушатып та җибәрде. Ләкин Розенберг шул өч-дүрт сүздән башка татарча белми иде бугай, Мусаның, «Ярыйсы болай», дигәнен дә аңа тылмач тәрҗемә итеп бирде. Тылмач дигәне хатын-кыз иде. Аның татар хатыны булуы йөзенә чыккан. Татарча ягымлы, матур тел белән сөйли. Ул Розенберг авызыннан чыкмаган сүзләр дә әйткәләп алды. Муса немецчаны яхшы белә, тылмачның үзеннән дә кушып сөйләвен шундук чамалады. Шулай да рейхсминистр үзе белән сөйләшүгә татар шагыйрен чакырасыларын яхшы белә иде, бу очрашуга ул хәтта алдан әзерләнеп тә килде. Муса моны аның өстәлендә үзенең шигырь китапларын күрүгә аңлады. Розенбергка Мусаның китапларын үзе эшли торган институт китапханәсеннән фон Менде табып китергән иде. Розенберг, әлбәттә, аларны укымаган, ләкин татар әсиренең шундый китаплар авторы булуы аңа министр тарафыннан күпмедер хөрмәт белән карау өчен сәбәп иде. Розенберг үзе дә национал-социалистлар партиясенең идея юнәлешен билгели торган берничә китап авторы. Шул китаплары нигезендә ул «Өченче рейхның төп идеологы» дип саналды. Гитлерны нәкъ менә шул китаплары белән яһүдләргә каршы сугышка рухландырган кеше дә ул булды. Гитлер үзенең «Майн кампф» китабында Розенбергның шактый күп фикерләренә таянган иде.

– Күрәсезме, минем алда сезнең китаплар ята. Мин сезне иҗат кешесе буларак хөрмәт итәм, Гумеров әфәнде, – диде Розенберг, Мусага алдындагы китапларын күрсәтеп. – Ә сез исә минем китаплар белән танышсыздыр дип уйламыйм.

– Юк шул, кызганычка каршы, – диде Муса. – Нәрсә язасыз, поэзияме, прозамы?

– Мин – фәнни хезмәтләр авторы. Аларның төп темасы – идеология, фәлсәфә. Яһүдләр тарихын өйрәндем. Үземне сионизм идеологиясе буенча зур белгеч дип исәплим. Дөресен генә әйткәндә, мин – антисемит. Ә сез беләсезме, Россияне яһүдләр харап итте. Калмык-татар канлы Ленин, гөнаһ шомлыгына каршы, безнең ярдәм белән хакимлеккә килеп, Россиядә большевик яһүдләр диктатурасы урнаштырды. Без, арийлар, шуларга каршы көрәш алып барабыз. Шушы көрәштә безнең җиңүебез генә Россия халыкларына бәйсезлек китерәчәк.

– Сез үзегезнең тирән ялгышуыгызны аңламыйсыз, Россия тормышын белмичә сөйлисез, Розенберг әфәнде.

– Беләсезме, мин дә бит тумышым белән СССР составында булган Эстониядән, Таллин шәһәрендә туган кеше. Дөрес, әле 1893 елда ук туганмын. Атам – алман, гап-гади бер башмакчы булган. Анам – Петербург кызы, француз

гугенотлары нәселеннән. Таллинда, Ригада укыдым, архитектор белгечлегенә ия булдым. Аннары Мәскәү югары техник көллиятендә белем алдым. 1918 елга хәтле Мәскәүдә яшәдем. Россияне, Мәскәүне, андагы большевистик түнтәрелешне үз күзләрем белән күрдем. Россияне харап иткән түнтәрелеш башында яһүдләр торды. Яһүд большевиклар изүеннән качып котылуымны зур бәхетем дип саныйм.

– Сез, семитларны яхшы өйрәндем, дисез. Ә яһүдләр белән татарларның кардәшлеге хакында ни дә булса беләсезме?

– «Татар тугач, яһүд елаган», дигән шаяртуны гына ишеткән бар. Татар белән яһүд туганлыгы турында белмим. Бу да шундый ук бер шаяртудыр инде.

– Тарихчы галимнәр арасында төрле фикерләр яши. Татарларны хазарлардан килеп чыккан, диләр. Ә хазарлар борынгы яһүдләрнең варислары икән дигән версия дә бар. Алар шулкадәр болганып беткән ки, татарларның да, яһүдләрнең дә борынгы бабалары хазарлар булган дигән гипотеза да яшәп килә.

– Ха-ха-ха! Сезнең белән сөйләшеп утыруы шулкадәр кызык, Гумеров әфәнде. Хәтта мине дә уздырып җибәрәсез үзегезнең гипотезаларыгыз белән. Сез бик кыю, үз милләтегезне бик яратасыз бугай. Безгә менә шундый фикерли белә торган кешеләр кирәк тә. Шәфи Алмасның «Идел-Урал» гәзитенә редактор булырга бер дигән кандидат – сез!

– Рәхмәт, миңа биргән бәягез өчен. Ләкин мине ул эш кызыктырмый. Минем иректә буласым килә. Мин – иҗат кешесе. Шагыйрь кеше.

– Аңлыйм, аңлыйм. Шулай да сезнең кебек кешене монда яткыру – җинаять. – Розенберг шулай диде дә комендантка мөрәҗәгать итте: – Ишетәсезме, оберштурмфюрер Френцель?! Иртәгә үк Берлинга озатыгыз Гумеров әфәндене!

**2**

Әхмәт Тимерне Төркиягә матур гына озатып җибәргәч, Татар арадашчылыгына да, «Идел-Урал» комитетына да, «Идел-Урал» гәзитенә дә Шәфи Алмас баш булып калды. Шөһрәт ярата торган, тәкәббер, йөзендә масайган кыяфәте бер генә дә сүрелмичә балкып торган бу кешенең үз тормышыннан канәгать икәне бөтен килеш-килбәтеннән күренеп, сизелеп тора иде. Хәзер кая гына барса да, кем белән генә күрешсә дә, эредән кубып сөйләшә, үзен зур эшләр майтарган кеше кебек тота иде ул. Хактан да, кулыннан эш килә, дөньяны шактый болгата, тормыш дәрьясында чайкалган көймәне үзе теләгән якка бора алучан чын эшмәкәр иде Шәфи. Сәяси яктан сизгерлеге, белем чамасы әллә ни зур булмаса да, кешеләр арасында астыртын эш йөртү осталыгы, өстәгеләр алдында тәлинкә-табак тота белүе аңа зур уңыш китерде.

Муса Җәлил белән Рәхим Саттарның комитетка килүен дә ул үз мәнфәгатьләрендә файдаланып калырга омтылды. Бөтен татар дөньясында исемле кешеләр! Берсе – татар язучыларының башлыгы булып торган мөхтәрәм әдип! Икенчесе дә бөтен татар яшьләре яратып укыган яшьләр гәзитенең баш мөхәррир урынбасары, исеме дөньяга яңгыраган мәшһүр журналист. Әле җитмәсә, икесе дә шагыйрьләр. Муса Җәлил үзе Германиядә әсирлектә ята, ә Казанда зурлап, ул язган либретто буенча «Алтынчәч» дигән опера куйганнар ди. Аңламассың бу сәвитләрне. Әсирлеккә төшкән кешене «халык дошманы» дип игълан итәләр. Ә моның нинди зур театрда операсын куеп яталар. Әсирлеккә төшкәнен белмиләрдер, күрәсең. Хәер, эш анда түгел, операның авторы булуы зур дәрәҗә! Менә бит, нинди кош сайрап тора Шәфи Алмасның алтын читлегендә!

«Бүген үк иң кадерле кунакларны гына җыеп, зурлап аш мәҗлесе үткәрергә

кирәк. Белсеннәр кемнәр белән эш йөрткәнемне мондагы абзыйлар», – дип уйлады ул һәм тиз генә үз янына кабул итү бүлмәсендә утыручы Афзал Фәтхуллин атлы хезмәтчесен дәшеп кертте.

– Тыңлыйм сезне, – диде Афзал, ишектән керә-керешкә. – Ни йомыш, Шәфи абзый?

– Бер мөһим эш бар, Афзалетдин энем. Бар, хәзер өйгә йөгер. Әминә абыстаңа әйт, бүген абзый кунак җыя, диген. Аз-маз әзерләнсен. Мәфтухадан чәй ашлары, гөбәдия, кош теле кебек нәрсәләр пешертсен. Ике атла, бер бас, аннары, эшең бетүгә, монда йөгер. Тагын кайбер эшләр бар. Хәер, менә акча, кайтканда кибеткә кереп, бер өч шешә «төрек малаен» сатып алырсың.

Шәфи, кесәсеннән портмонет чыгарып, Афзалга акча санап бирде.

– Төрек аракысы гына димәсләр микән? Бер шешә виски да ал әле. Дәүрәк абзыйларны да дәшмичә булмас. Килештермәсләр. Аңладыңмы?

– Аңлашылды, Шәфи абзый. Йөгердем.

– Тукта, тукта! – дип, Шәфи ишектән чыга башлаган Афзалны тоткарлады. – Кире кайтышлый «Винета»га кереп, Шәмсия ханымны күрерсең. Аны мәҗлескә дәшәрсең. Идриси әфәндене телефоннан шалтыратып үзем чакырырмын. Шулай дип әйтерсең. Бар, йөгер.

Афзал чыгып киткәч, Шәфи башта, үзалдына сөйләнеп, бүлмә буйлап әрле-бирле йөренде.

– Тәк, кемнәрне дәшәргә соң? Унгляубены дәшәргә кирәк. Бу – бер. Аннан да зуррак Герхард фон Менде әфәнде бар бит әле! Иң кадерле кунаклар шушылар булыр. Парлашып йөрмәсләр инде, безнең татарлар кебек. Үзләре генә килерләр, Алла боерса, – дип сөйләнде Шәфи.

Фон Менде – Германиядә чит илләрне өйрәнү буенча зур белгеч, профессор. Аның тәкъдиме белән төрки-татар китапханәсе ачылган иде. Китапханә эше белән Әхмәт Тимер шөгыльләнде. «Нәфесе зур иде шул, дөньяны колачларга теләде. Шуның аркасында янды да», – дип уйлады Шәфи, көндәше турында искә төшереп.

«Галимҗан әфәнде Идрисигә шалтыратырга кирәк, – дип уйлады ул һәм шунда ук телефон трубкасын кулына алды. – Мусаларны озаттылар микән? Сорашырга кирәк. Бергә-бергә килсәләр дә начар булмас».

Телефоннан: «Ал-ло, Идриси әфәнде тыңлый», – дигән тавыш ишетелде.

– Исәнмесез, Галимҗан әфәнде! Комитеттан бу, Шәфи Алмас дустыгыз шалтырата.

– Тыңлыйм, Шәфи әфәнде.

– Бер зур нәстә пантамаллап[1] тора идек, Галимҗан әфәнде. Бүген Муса Җәлил белән Рәхим Саттар килү уңаеннан чәй мәҗлесе җыеп алмакчы идек. Сезнең дә урыныгыз түрдән булыр дип уйлаган идем. Килә алырсыз микән?

– Шулай зурдан купмасагыз да ярар иде.

– Бер сөйләшеп тә утырасы килә. Күптән очрашкан юк. Дөнья бит гел мәшәкатьтән генә торырга тиеш түгелдер. Әзрәк рәхәтен дә чигеп калырга кирәк. Мәңгегә килмәгәнбез лә.

– Ни бит, Шәмсия җиңгәгез... ул...

– Шәмсия абыстай турында борчылмагыз, Галимҗан әфәнде. Аңа хәбәр ителгән. Киләчәк, Алла боерса.

– Шулай укмы? Ярар, ярар, алайса. Сәгать ничәләр тирәсенә җыясыз?

[1] Нәстә пантамаллап *(диал.)* – нәрсә планлаштырып.

– Эш көненнән соң булыр инде. Фон Менде белән Унгляубе әфәнделәрне дә көтәбез.

– Шулай укмыни?

– Шулай, Галимҗан әфәнде. Җырлашып та утырырбыз. Төнлә туган нәстә дә булачак.

– Анысын үзегез карарсыз инде. Мин анысына үрелмәм. Әмма татар җырларына күңел сусады. Рәхәтләнеп тыңларбыз анысын.

– Галимҗан әфәнде, онытып та торам, безнең Муса белән Рәхим атлы егетләр ни хәлдә икән анда? Кичтән Шиһабетдин Нигъмәтуллин әфәнде, иртәгә кулларына паспорт тоттырып Берлинга озатабыз, дигән иде. Юлга кузгалмадылар микән әле? Кузгалмаган булсалар, алар белән бергәрәк килсәгез дә начар булмас иде.

– Шулаймы? Ярар, мин белешермен. Китеп өлгермәгән булсалар, машинамда урын табылыр, Алла боерса.

– Зур рәхмәт, Галимҗан әфәнде. Көтәбез.

Шәфи телефон трубкасын куйды да, тәрәзә янына барып, пәрдәләрен рәтләгәндәй итте. Тагын нинди олы кунак кала икән, дип уйлады.

– Вәт тити баш! – дип, маңгаена сугып алды. – Әхмәтвәли әфәнде каласы икән бит онытылып! Галимҗан әфәнденең якташы.

Әхмәтвәли Мәңгәр – Төркиянең иң зур байларыннан берсе. Галимҗан Идриси дә, Әхмәтвәли әфәнде дә Казакъстанның Кызылъяр каласында дөньяга килгәннәр. Әхмәтвәлинең ата-бабалары Казан артындагы Мәңгәр дигән авылдан чыккан. Шуңа күрә дә фамилияләре итеп Мәңгәрне алганнар. Галимҗан Идрисинең ата-бабалары исә – Буадан.

– Әхмәтвәли әфәнденең Германиягә килгән чагы булса ярар иде. «Ульрих Мейер» фирмасына шалтыратып карыйм әле. Ике көннең берендә шунда килә торган иде, – дип, Шәфи янә телефон трубкасына үрелде.

Әхмәтвәли Мәңгәр сугышка кадәр Маньчжурия, Монголия, Төркия, Германия кебек илләрдә яшәп һәм эшләп, зур капитал туплап, сугыш башлангач, Германиядәге «Мерседес» автомобильләре чыгара торган Мелчерс компаниясенең Швецариядәге Лузерн шәһәрендә урнашкан «Ульрих Мейер» фирмасы генераль директоры булып эшли иде. Германия концлагерьларында интегүче татар әсирләренә ярдәм кулы сузуны үзенең мөкатдәс бурычы итеп санаган Әхмәтвәли әфәнде «Идел-Урал» комитетының иң бай иганәчесенә әверелде. Комитет һәм «Кызыл хач» җәмгыяте аша татар әсирләренә һәртөрле ярдәм күрсәтте. Ул гына түгел, «Идел-Урал» комитетын оештыру өчен җан атып йөргән милләтпәрвәрләребезнең берсе булды.

Шушы мәртәбәле кешене Шәфи Алмас бүгенге мәҗлескә һич кенә дә чакырмыйча кала алмый иде. Бәхетенә каршы, Әхмәтвәли әфәнде бүген, чынлап та, Германиягә килергә тиеш икән. Шәфи фирма кәнсәләрендә телефон трубкасын алган кешегә үзенең кем булуы турында әйткәч, Мәңгәр әфәндегә гозерен җиткерүне үтенде. «Бик рәхәтләнеп!» – дигән җавап ишеткәч, шатлана-шатлана, трубканы урынына куйды.

Ул арада ишектә кулына шактый зур сумка тоткан һәм шул сумкадагы шешәләре шалтыр-шолтыр килгәне ишетелеп торган Афзал Фәтхуллин күренде.

– Нәрсә ул? – дип сорады Шәфи, хезмәтчесенең кулындагы сумкасына ишарәләп.

– Соң, үзегез куштыгыз бит, төрек аракысы белән виски.

– Вәт дивана! Мин бит аларны өйгә кайтышлый кереп ал, дидем. Өйгә алып кайтырга куштым. Алар белән ни эшлим мин монда?

Аптырап калган Афзал, сумканы бер кулыннан икенчесенә күчереп:

– Йә, кая куйыйм? – дип сорады.

– Менә монда куй! – дип җикерде Шәфи, ике бот арасына ымлап. – Өйгә кайтарып куй!

Афзал сүзсез генә ишекне ача башлаган иде, Шәфи: «Тукта! Кая барасың?!» – дип янә кычкырып җибәрде.

– Соң, өйгә кайтарырга кушасыз бит.

– Кайтарырсың. Көтеп тор. – Шәфи, өстәл артына утырып, кулына кәгазь-каләм алып, нидер язарга тотынды. – Фон Менде һәм Унгляубе әфәнделәрне күрергә кирәк. Министрлык белән институтка кереп, менә шушы кәгазьләрне кулларына тапшырырсың, – диде.

Ул аларның икесенә дә бүгенге чәй мәҗлесенә аерым-аерым чакырулар язган иде.

– Менә, тот. Чакырулар бу. Кулларына тоттыр. Бутама. Башта шешәләреңне өйгә кайтар. Алар белән шалтырап йөри күрмә тагын.

Кәгазьләрне Афзалга биреп, ишекне ачып, артыннан озатып калды. Аннары, үзе дә бүлмәсеннән чыгып, төрле бүлмәләрдә утыручы хезмәткәрләр янына юнәлде. Гариф Солтан, Кыям Галиев, Рәис Самат, Сабит Кунафинны да кич, эштән соң, үз өенә чәй мәҗлесенә чакырып чыкты. Рәисне, «Берничә минуттан минем янга кагылырсың әле, сүз бар», – дип, үз янына дәште.

Рәис Самат – комитетка Әхмәт Тимер урнаштырып калдырган кеше, аның ерак кардәше дә. Шәфи боларын ук белмәсә дә, элек Әхмәт Тимер белән вәс-вәс сөйләшеп йөргәне өчен аннан беркадәр шикләнә иде һәм үзеннәнерактарак тотарга тырышты, вак-төяк йомышларын үтәргә. Афзал юкта, гел аны йөгертә торган булды. Бүген дә кадерле кунакларының берсе – Искәндәр әфәнде Яушевны чәй мәҗлесенә чакырырга Рәис Саматны йөгертергә уйлады. Ул тиз генә Яушевларга, ирле-хатынлы парлашып килегез, дип, чакыру язды һәм Рәис керүгә, кулына тоттырып, өйләренә илтергә кушты.

Төшке ашны ашап, беркадәр вакыт узуга, Ноенбургштрассе урамының «Идел-Урал» комитеты һәм Татар арадашчылыгы урнашкан ундүртенче йорты ишегалдына ялтырап торган кап-кара «Хорьх» машинасы килеп туктады. Аның кабинасыннан хәрби киемле шофёр сикереп төште дә үз ягындагы арткы ишекне ачты. Аннан тәбәнәк кенә буйлы, соргылт-көрән төстәге кәчтүм-чалбар кигән, буй-буй аклы-каралы галстук таккан урта яшьләрдәге кеше төште. Машина килеп туктаган тавышны ишетеп, икенче каттагы эш бүлмәсе тәрәзәсеннән ишегалдына караган Шәфи Алмас Муса Җәлилне шундук таныды. Машинаның икенче ягыннан төшкән кешеләрнең беренчесе шулай ук аның өчен яхшы таныш Галимҗан әфәнде Идриси булып, икенчесен Шәфи: «Монысы Рәхим Саттардыр инде», дип уйлап куйды. Бу – утыз яшьләр чамасындагы, погоннары лейтенант икәнен күрсәтеп торган хәрби иде. Ул авыз ачып карап торганына үзен-үзе сүгеп, тиз генә урамга атылды. Кадерле кунакларны каршы алырга кирәк иде.

Гайнц Унгляубе белән лагерьлар буенча йөргәндә, Демблинда беренче мәртәбә очраткан Муса белән бүгенге Муса арасында шактый ук аерма күренде Шәфинең күзенә. Ул бераз тазарып, йөз-битләре алсуланып киткән. Киемне дә ул чакта кемнәндер салдырып киерткәннәр сыман, капчык шикелле асылынып тора иде. Бүген исә фырт иткән, кәчтүм-чалбардан, штиблет ботинкалар кигән,

кияү егетләренә охшап тора. Машина янында иң якын кешеләрен каршы алгандай, көлешә-көлешә куллар биреп күрешкәч, алар бинага кереп, гөр килеп сөйләшә-сөйләшә, икенче катка күтәрелделәр. Тавышларына бүлмә ишекләрен ачып куеп, комитет һәм редакция хезмәткәрләре коридорга чыккан иде. Муса һәм Рәхим исә Алиш, Гариф Шабай, Фоат Булатов белән күптәнге танышлар икәнен ачыктан-ачык күрсәтеп, кочаклашып күрештеләр. Муса Гариф Солтановны да таныды. Ләкин аның белән салкын гына исәнләште. Гариф үзе дә дәрәҗә саклап, ара калдырып кына кул бирде. Муса танымаган тагын берничә егет, күрешергә кул сузып, исемнәрен атадылар:

– Кыям Галиев булам, – диде беренчесе.

– Минем урынбасарым, гәзит буенча, – дип, якыннанрак таныштырды Шәфи Алмас, Кыямның Муса белән күрешкән кулын тотып калып. – Ә монысы – әдәби хезмәткәребез, тәрҗемәче Галимҗан Бахтиков, – дип, шулай ук Мусага кулын сузган икенче егет белән таныштырырга ашыкты.

Рәхим белән дә куллар биреп күрешеп чыктылар.

– Егетләр, бүген бездә бәйрәм, кадерле кешеләребез килде. Бу уңайдан мәҗлес ясап алсак та гөнаһ булмас дип уйлыйм. Барыгызны да эштән соң үземнең өемдә көтәм, – диде Шәфи, кулларын угалый-угалый. – Олы кунакларым белән кайта торабыз. Сез, эш сәгате бетүгә, Хафельштрассе урамына, минем өемә рәхим итегез.

– Без дәме? – дип сорады Фоат.

– Сез дә, – диде Шәфи, шаярткан булып. – Сезнең дә дусларыгыз килде ләбаса. Дус янына дус сыя ул. Күңелең иркен булсын. Минем кызларым күп, берегез дә артмас, яхшы кияүләр аунап ятмый ул!

– Алай булгач, Шәфи әфәнде, минем Берлинда комитет эше белән йөрүче тагын берничә дустым булырга тиеш. Аларны да дәшмәссез микән? – диде Муса.

– Әлбәттә! Килсеннәр. Үзегез оештырыгыз инде, егетләр. Бәйрәмнәр гел булып тормый. Ярый, без киттек. Әйдәгез, Галимҗан әфәнде, Муса энекәш, кайта торыйк.

Алар дүртәүләп кайтып киттеләр.

Калганнар бүлмәләренә таралышкач, Алиш, Гариф, Фоат, Кыям һәм Галим редакция хезмәткәрләре бүлмәсенә кереп киңәшләшергә булдылар.

– Егетләр, Шәфи карун юмартланган бүген. Бәйрәм итеп калырга кирәк безгә дә, – диде Гариф. – Телефоннан шалтыратып. «Винета»дан Әхмәтне дә чакырырга кирәк. Муса рөхсәт алды бит, Фәрит белән Зиннәтне дә дәшәргә иде. Кызганыч, Баттал белән Кормаш Берлинда түгел. Аларны чакырганда да начар булмас иде.

– Белгән булсак, кичә хәбәр иткәндә килеп җиткән булырлар иде, нишлисең инде, бәйрәмнәр алда тагын булыр әле, – диде Алиш.

**3**

Берлинның үзәк бер җирендә, Рихард Вагнер мәйданы тирәсендәге Хафельштрассе урамында, Шәфи Алмасның күпкатлы зур гына йорты бар иде. Дөрес булса, бу йортның 248 бүлмәсе булып, ул аның шактый өлешен табыш алу өчен файдалана ди. Байтак бүлмәсен Татар арадашчылыгы хезмәткәрләре өчен кунакханә итеп тотты. Арадашчылыкта, комитетта, гәзит-журналларда, радиостудиядә эшләүчеләрдән Шәфи Алмас казнасына ай саен зур гына суммада акча кереп торды. Үзе тулысынча диярлек өченче катта торып, анда да ул кайбер бүлмәләрдә шәхси хезмәтчеләрен яшәтте. Өченче катта шулай ук

кунак каршылау, күңел ачу, кәеф-сафа кору өчен зур гына залы, аш-су хәзерләү, йокы һәм ял бүлмәләре булып, үзе дә гаиләсе белән шунда көн күрде.

Галимҗан Идрисинең машинасы хуҗа белән кунакларын – Муса белән Рәхимне Шәфи йорты алдына китереп куйгач, Идриси үзенең «Винета» радиостудиясенә, җәмәгате Шәмсия ханымны барып алырга теләвен әйтте.

– Әлбәттә, әлбәттә, нинди сүз булырга мөмкин, – диде Шәфи, төчеләнеп. – Соңга калмагыз. Зур кунаклар булырга тиеш. Герхард фон Менде, Гайнц Унгляубе һәм Әхмәтвәли Мәңгәр әфәнделәр дә килергә вәгъдә бирделәр.

– О-о! Шулай укмыни?! Әхмәтвәли әфәнде үзе киләмени?! Бик шәп! Бик шәп! – дип төчеләнде Идриси дә. – Без хәзер, Шәмсия ханымның эш сәгате бетүгә, ялт, килеп тә җитәрбез. Борчылмагыз.

Машина китеп барды. Шәфи, Муса белән Рәхимгә борылып:

– Менә ничек күңелләрен күрергә туры килә юк кына бәндәләрнең, сезнең өчен тырышып йөреп, егетләр, – диде. – Шулай сөйләшмәсәң, төкереп тә бирмиләр. Эш барсын дип уйлап та караучы юк. Йә, ярый. Шулар күңелен күрәм, дип, үзебезне дә онытмыйк әле. Әйдәгез, керик. Әминә җиңгәгездән бигрәк, кызлар көтәдер әле анда. Берсеннән берсе чибәр өч кызым бар бит минем! Менә, күрерсез.

Ишектән килеп кергәч тә, Шәфи каршына өч-дүрт һәм ун яшьләр чамасындагы ике кыз йөгереп килеп, «Әти кайтты!» дип, кочагына ташландылар. Муса аларны күргәч аптырап китте. «Шактый олы гына, алтмыш яшьләр чамасындагы бу кешенең кызлары шулай бәләкәйләр микәнни?» дип уйлап куйды ул.

1922 елда, утыз җиде яшендә генә өйләнгән Шәфинең беренче кызы Нилүфәр 1927 елда гына туган икән. Ә бу ике кызы – Айсылу белән Гөлнар, әле чынлап та бәләкәйләр, Муса чамалаган дүрт һәм ун яшьләрдәге балалар гына иде.

– Бездән бигрәк, сезне сагынганнар болар, Шәфи әфәнде, – диде Муса.

– Шулайдыр шул. Әтиләрен бик яраталар шул алар, – дип, Шәфи бәләкәч кызын күтәреп кочагына алды. – Болар гына түгел, әле минем буй җиткән сылукаем да бар. – Ул, эчке бүлмә ишегенә борылып: – Нилүфәр, кызым, бире чык әле. Менә син китабын яратып укыган Муса Җәлил абыең килде! – дип, тагын бер кызын алгы якка чакырды.

Ишектә талчыбыктай сылу, әле буй үстереп кенә килә торган унҗиде яшьләр тирәсендәге тагын бер кыз күренде.

– Менә ул минем чибәрем, – дип, Шәфи, бәләкәй кызын идәнгә төшереп, олы кызының иңнәреннән кочты. – Кызым, таныш абыйларың белән, исәнләш.

Шәфи Алмасның гаилә җанлы булуы, балаларын сөюе әллә каян күренеп тора иде.

– Исәнмесез, – диде кыз.

– Нилүфәр исемле була бу кызым. Ә болары – Айсылу белән Гөлнар.

«Гөлнар», дигәч, ул бәләкәч кызының башыннан сыйпап алды.

– Йә, барыгыз, кызларым, бүлмәгезгә керегез.

Кызлар бүлмәләренә юнәлде. Шәфи кунакларны аш-су бүлмәсе ишегеннән килеп чыккан хатыны белән таныштырды:

– Таныш булыгыз, минем сөекле кызларымның әнисе Әминә ханым. Казан кызы. Нинди генә кызы әле!

– Ярар инде, Габдрахман, шапырынма артыгын. Исәнмесез, егетләр. Түрдән узыгыз. Габдрахман, кунак бүлмәсенә керт кунакларны.

– Шаулама син, әнисе. Ничек анда, аш-су әзерме? Тагын берәр сәгатьтән кунаклар килә башлый.

– Әзер, әзер. Афзалны эшенә җибәрмәдем инде, ачуланмассың. Өстәлләр корышырга кеше кирәк иде.

– Ярый, ярый, зыян юк. – Шәфи шулай диде дә егетләргә алгы бүлмәгә керергә ымлады. – Әйдәгез, егетләр, түрдән узыгыз. Өебез белән таныштырыйм үзегезне. Ә, юк, утырыгыз әле, өй белән танышырга өлгерерсез. Юлдан соң ял итеп алыгыз бераз.

Барысы дә кунак бүлмәсендәге затлы кәнәфиләргә барып утырдылар.

Өй, чынлап та, кеше алдында йөзне кызартырлык түгел иде. Шактый ук бай мебель, идәннәрдә, диварларда затлы келәмнәр. Күн тышлы диван-кәнәфиләр, кызыл агачтан кием шкафы, аяклары сырлап-сырлап эшләнгән өстәл, урындыклар.

– Казан бае кая китеп типтереп яшәп ята дип уйлыйсыздыр инде бу зиннәтләрне күреп, – дип башлады сүзен Шәфи. – Германиягә килеп урнашканда, әллә ни байлыгым юк иде минем. Эшләргә кирәк, егетләр, эшләргә. Кем эшләми, шул ашамый гына түгел, «Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш!» – дигән бөек Тукай. Ә сезнең ул сысысырыгызда эшләгән кешене атып үтерәләр. Баемаска кушалар. Хәерче яшәргә кушалар. Шулмы тормыш?! Шулай яшәргә тиешме кеше? Беләсездер, берара Казанның башлыгы да булып торган Габделхәмит Казаков дигән кешене. Менә шул Казаковның олы кызы – минем җәмәгатем Әминә. Һәй, сөйли башласаң, озынга китә. Сөйлисе дә килә. Нинди генә атаклы кешеләр белән бәйле түгел ул Казаковлар нәселе! Ләкин шул нәселгә бәйле кайбер нәрсәләрне, ай-һай, беләсез микән?!

– Сөйләгез, Шәфи әфәнде, – дип, моңа кадәр дәшми генә тыңлап утырган Рәхим Саттар сүзгә кушылды. – Мин өстән-өстән генә беләм дә кебек. Үзегездән ишетү кызыграк.

– Казаковлар нәселе Казанда бик зур байлар, сәүдәгәрләр нәселе була. Мин үзем бер ярлы-ябагай авыл малае идем. Дөбъяз якларыннан. Олы Солабаш дигән авылдан. Әти-әнием Ибәтулла белән Өммегөлсемнең биш кызы арасында бер малай булып үскәнмен. 1922 елда шул бай Казаковларның Әминә исемле кызларының кулын сораганда, очын-очка ялгап баручы бер эшмәкәр генә идем әле. Баеп китүем Әминәмнең туганнары ярдәме белән булды. Әминә миңа кияүгә чыкканда, мин инде утыз җиде яшемдә идем, ә ул – олы кызыбыз Нилүфәр кебек, унҗиде яше тулыр-тулмас бер үсмер бала. Мәскәүдә яшиләр иде. Ул чакта Мәскәүдә Төркия илчелегендә хезмәткәр идем. Ә Казаковларның хәле бик мөшкел чак. Мәрхүм әтисе Габделхәмит әфәндене «немец шпионы» дип гаепләп кулга алганнар. Утыз җиденче елда атып та үтергәннәр. Газиз Гобәйдуллин атлы кешене беләсез булыр. Казанда бик билгеле галим. Менә шуның җәмәгате Бибирабига Казакованың ике абыйсы Мөхәммәтрәхим һәм Мөхәммәтхәмит әле гаиләләре Әстерханда яшәгән елларда ук сәүдә эшенә керешеп китәләр. Әтиләре аларны Исхак Юнысов исемле сәүдәгәрнең ике бертуган Өммегөлсем һәм Фәхрибану исемле кызларына өйләндерә.

Исхакның кече улы Мөхәммәт 1910 елда Германиягә күченеп китә һәм шунда яшәп кала. Анда немец кызына өйләнеп, Мәхмүт һәм Мәрьям исемле балалары туа. Мәхмүт, үскәч, Төркиягә китеп, бүгенге көндә шунда яшәп ята. Үзенең сәүдә компаниясе бар. Мех һәм күн эше белән шөгыльләнә.

Әминәмнең әтисе Габделхәмит, Казанда укытучылар семинариясе төзү артыннан йөргәне өчен, әле патша заманында ук сөргенгә җибәрелгән була.

Мөхәммәтшакирның олы кызы Зөләйха сезгә мәгълүм кеше – Абдулла

Апанаевның хатыны иде. Аларның кызы Гайшә – сезнең каләмдәшегез Гали Рәхимнең хатыны. Мескен Галине дә Сталин ялчылары сөргенгә озатканнар. Исхак Казаков дигән бер туганнарын Татарстанда халык комиссарлары шурасы рәисе булып эшләгән җиреннән «халык дошманы» дип атып үтерделәр. Исхакның сеңлесе Өммегөлсем мәшһүр Мулланур Вахитовның әнисе иде. Әле ярый ул Мулланур Вахитовны унсигезенче елда ак чехлар атып үтергән. Югыйсә, башын Сталин лагерьларында череткән булырлар иде. Татарстан Республикасын төзү артыннан күпме йөргән кеше бит, мескен. Менә ул эшли алмаган эшне тормышка ашыру өчен тир түгеп йөргән көнебез бу «Идел-Урал» комитетында. Бергә-бергә башкарып чыгасы иде бит, егетләр.

Шәфи Алмасның кызып-кызып сөйләгәнен, гаепле кешеләрдәй, башларын аска иеп, тын гына тыңлап утырдылар Муса белән Рәхим. Шулвакыт ишектә кыңгырау тавышы яңгырады.

– Килделәр! – дип, Шәфи ишеккә юнәлде.

Ишектән, шаулашып, Әхмәтвәли Мәңгәр белән җәмәгате Гайшә ханым килеп керде.

– Әссәламегаләйкүм, мөхтәрәм Габдрахман әфәнде! Казан егетләре кунакта, дигәнне ишеткәч, фирмадагы бөтен эшләремне ташлап киләсе иттем.

– Вәгаләйкүмәссәлам, вә бәрәкәтүһү, вә мостафа сәл-әллаһу. Әйдүк, әйдүк, түрдән узыгыз. Узыгыз, уз, Гайшә ханым, – дип, Шәфи башта Мәңгәрнең хатыны өстеннән пәлтәсен салдырып, ишек буендагы шкафка элеп куйды. Аннары Мәңгәр әфәнденең пәлтәсен элгечкә урнаштырды да кунакларны алгы бүлмәгә, Мусалар янына дәште. Бүлмәгә ире генә керде, Гайшә ханым аш-су бүлмәсенә, хатын-кызлар ягына юнәлде.

– Саулармысыз, егетләр, – дип, кул биреп күреште Әхмәтвәли бәй Муса һәм Рәхим белән. – Ничек соң хәлләрегез? Бик кыерсытмыйлармы алман хәрбиләре? Үземнең бөтен ышаныч – алманнарда. Яңадан илгә әйләнеп кайтулар бары тик шулар тырышлыгы белән генә булыр, дип өметләнеп яшим.

Муса белән Рәхим, Әхмәтвәли әфәнденең сүзне алманнарны мактап башлавына нәрсә дип җавап бирергә дә белмичә, бераз аптырашта калдылар. Кунак алдында сер бирергә ярамый иде, сүзне Муса башлады.

– Алманнарның фронтта хәлләре бик шәптән түгел дигән хәбәрләр ишетелә бит әле, Әхмәтвәли әфәнде. Немецлар үзләре бик шапырынсалар да, Сталинградта Манштейн гаскәрләре тулысынча тар-мар ителгән, генерал-фельдмаршал Паулюс бөтен гаскәре белән чолганышта калып, әсирлеккә төшкән, дип ишеттек.

– Кышкы салкыннар комачаулый алманнарга. Кышкы салкыннарга хәтле Сталинград сугышын башкарып чыга алмадылар шул, – дип, немецларның җиңелүен үзенчә акларга ашыкты Мәңгәр.

– Алман гаскәре алай да көчле әлегә, – дип, кунагының кәефен күтәрергә теләп, сүзгә Шәфи Алмас кушылды. – Бер яңалык әйтергә телим, җәмәгать. Шушы көннәрдә Унгляубедан күрсәтмә килде. Февраль урталарында беренче батальонны фронтка җибәрәчәкләр. Гайнц әфәнде бүген монда киләчәк. Ул хакта үзе дә әйтер әле.

Яңалыкны ишетеп, Муса белән Рәхим бер-берсенә карашып алды.

Шулвакыт ишектә тагын кыңгырау чылтырады. Комитет егетләре Гариф Солтан, Сабит Кунафин, Рәис Самат, Кыям Галиев белән Галим Бахтиков килеп керделәр.

– Алишлар юкмыни? – диде Шәфи, алар арасында Алиш белән Гарифның күренмәвенә эче пошып. – Бергәрәк йөрергә дип әйттем бит, егетләр. Вакыт уза.

Ул арада ишек өстендәге кыңгырау янә үз вазифасын үтәп алды.

– Әһә, ишеттеләр, ахры, – дип, Шәфи ишекне ачты. Бу юлы Алишлар төркеме генә түгел, җәмәгате Шәмсия ханым белән Галимҗан хәзрәт Идриси дә килеп җиткәннәр иде.

– Әйдәгез, үтегез, – дип, Шәфи кунакларның барысын да зал бүлмәсенә дәште. – Залга керик. Үзебезнекеләр килеп бетте кебек. Фон Менде белән Унгляубе әфәнделәр үз җайлары белән килерләр.

Ул шулай диде дә тагын бер олы кунагы юклыгын исенә төшерде. Ни сәбәп беләндер Искәндәр Яушев әфәнде тоткарлана иде. Алай да, ул кунакларын, берсе артыннан берсенең исемен атап, табын тирәли утырта башлады. Түр башында ике урынны буш калдырып, алар янына Әхмәтвәли Мәңгәр әфәндедән утыруын сорады. Мәңгәр янына җәмәгате Гайшә ханым утырмакчы иде, шунда Шәфи, гафу үтенеп:

– Мөхтәрәм ханымнар, гафу итегез, без – ир-ат өммәтеннән булган кунаклар бер якка, хатын-кызлар каршы якка утырышсак, ничек булыр икән? – дигән тәкъдим ясады.

– Хуп мәйле! Бик әйбәт булыр, – диде Галимҗан хәзрәт.

– Ханымнар үзләре нәрсә дип әйтә бит әле, – диде Әхмәтвәли Мәңгәр әфәнде.

– Без разый, – диде аның җәмәгате Гайшә ханым. – Күптән күрешмәгән, сөйләшер серләребез дә җыелган. Мин менә монда утырам, – дип, җәмәгатенә каршы яктагы икенче урындыкка барып утырды. – Бу урынга Әминә ахирәтем утырыр.

– Менә рәхмәт. Ә сезнең янга Искәндәр әфәнденең немкасы утырыр. Яушевлар да килергә тиеш иде. Нишләптер соңга калалар, – диде Шәфи.

– Юк әле, утырмыйча торсын. Алдан килгән – урын өчен, дигәннәр. Килмәгән кешегә урын калдырганчы, үзем утырыйм әле, – дип, Әминә ханымнан соңгы буш урынга Галимҗан хәзрәтнең Шәмсиясе барып кунаклады.

– Искәндәр әлегә юк. Минем янга, Муса туган, син утырсаң, әйбәт булыр иде, – дип, Әхмәтвәли әфәнде Мусаны үз янына утырырга кыстады. Муса каршы килмәде. Аның янына Алиш, Рәхим һәм калган егетләр тезелеште.

Шәмсия ханымны Муса ишектән керә-керешкә үк таныды. Бу кичәге Альфред Розенбергның тәрҗемәчесе вазифасын башкарган хатын иде. Ә төп эш урыны – «Винета» радиостудиясендә, татарча тапшыруларның цензоры булып эшли икән.

Табын мул әзерләнгән иде. Әминә ханым үзенең бөтен осталыгын күрсәткән. Моңа, әлбәттә, хезмәтчеләре Мәфтуханың ярдәме зур.

Мәфтуха – Донбасс якларыннан Германиягә хезмәткә куып китерелгән хатын. Шәфи аны басып алынган җирләрдән куып китерелгән халыкны эшкә урнаштыру бюросыннан үзе барып, татар хатыннары арасыннан сайлап алып кайтты. Эшкә кулы бик ята, бигрәк тә аш-су әзерләүгә уңган хатын булып чыкты Мәфтуха. Ул Шәфи яраткан камыр ашларын бер дигән итеп пешереп куя. Шәфи гел: «Телеңне йотарлык булган бу!» – дип, мактый-мактый ашый. Бүген дә затлы кунаклар алдында йөзне кызартырлык түгел иде Мәфтуханың бәлешләре.

– Мөхтәрәм җәмәгать! Бүген безгә җыйналуның сәбәбе – ниһаять, комитетта бөтен татар дөньясында мәшһүр исеме билгеле күренекле шагыйрь Муса Җәлил әфәнденең пәйда булуы! Җәлил әфәнде Вустрауда инде айга якын эшләде. Бүгенге мәҗлесне мин шул уңайдан, әйтергә кирәк, махсус оештырдым.

Мәҗлеснең икенче сәбәбе дә бар: ул әле үзе дә бу хакта оныткандыр, мөгаен. Тагын берничә көннән, мөхтәрәм җәмәгать, Муса әфәнденең туган көне! Унбишенче февраль!

– Кит аннан! Чынлап тамы, Муса әфәнде? – дип, ышаныргамы, ышанмаскамы дигәндәй, Әхмәтвәли Мәңгәр урынында сикереп куйды. Шунда ук Мусаның кулын кысты. Шәфинең көтелмәгән хәбәреннән соң бераз аптырап калган Муса да, Әхмәтвәли бәйнең котлавын аягүрә кабул итәргә дип, торып басты. Кем әйтмешли, фил хәтле гәүдәле, йөз килоның аргы ягына чыккан, юан Әхмәтвәли әфәнде янында Муса аннан ике мәртәбә кечерәк һәм ябык кына бер чирләшкә кебек күренде.

– Котлыйбыз, Муса әфәнде! – дип, Мусаның каршында ук, өстәлнең теге ягында утырган Шәмсия ханым да торып басып, җәмәгать алдында төчеләнеп алды. – Муса әфәнде, китабыгыздагы рәсемгә караганда бик матур, таза булып күренә идегез. Әллә әсирлек начар тәэсир иттеме, нык ябыккансыз. Авырмый торгансыздыр бит? – диде ул, сүзен дәвам иттереп.

– Төрлесен күрергә туры килде инде бу ярты елда, – диде Муса. – Әле Вустрауга килер алдыннан гына, биш көн камерада тотып, ачка интектерделәр.

– Әйбәт булмаган. Бу хатаны кичекмәстән төзәтергә кирәк. Муса әфәнде, иртәгә үк Семпен пансионатына ял итәргә җибәрербез, – дип, Шәфи Алмас Муса алдында акланырга тотынды. – Сабит дускай, иртәгә үк Муса әфәндегә пансионатка юллама язып бирергә онытма, – дип, янында утырган егеткә мөрәҗәгать итте.

Бу егет комитетның кәнсәләр мөдире Сабит Кунафин атлы кеше иде.

– Эшкә килүгә язылган булыр, Шәфи абзый, – диде Сабит.

Шәфи шуннан соң торып басты да өстәлдәге өч урынга куелган аракы шешәләренең берсен кулына алды.

– Җәмәгать, гаеп итмәсәгез, бу истәлекле көнне менә шушы нәстә белән путалап куйсак, ничек булыр икән? – диде һәм җавап та көтмәстән, бөкесен ачып, касәләргә агыза да башлады.

– Үзегезгә карагыз, җәмәгать, мин тотмыйм, – диде Галимҗан хәзрәт.

– Рөхсәт бар, ачыгыз, егетләр, шешәләрне, – диде Шәфи.

Шуны гына көткәндәй, комитет егетләре озын муенлы төрек шешәләрен бөкеләреннән азат итеп, касәләрне «зәмзәм суы» белән тутырдылар. Шәфи шул арада үзенекен бушатып та куйды. Башкалар да аңа иярде.

– Котлы булсын туган көнегез, Муса әфәнде, – диде Әхмәтвәли Мәңгәр тагын бер тапкыр. – Сер булмаса, ничәнчесе инде бу?

– Хатын-кыздан гына яшен сорамыйлар. Сер түгел, тагын биш көннән утыз җиде тула. Тукайны узып, ун ел яшәдем, – диде Муса.

– Тукайның гомере кыска булган шул. Әмма үлгәннән соң мәңге яшәргә туган булган. Сезгә дә шундый гомер язсын, Муса әфәнде! Мәңге яшәгез! Үлгәннән соң да халкыбыз күңелендә мәңге яшәгез! – дип куйды дәшмитынмый гына карап утырган Галимҗан хәзрәт Идриси.

– Рәхмәт! Барыгызга да рәхмәт, – диде Муса. – Шәфи абзый, сезгә зур рәхмәт. Казанны, дусларны искә төшердегез. Барыбыз да монда түгел. Казанда да безне искә алалардыр әле, бәлки. Шәфи абзый, нишләптер арада бер кешене күрмим.

– Кемне, дисез?

– Әхмәт Тимерне. Мине легионга язылырга димләп бергә килгән идегез. Комитетның президенты иде шикелле. Кая юкка чыкты ул?

Мусаның соравыннан Шәфи Алмас югалып киткән кебек булды. Башта нәрсә әйтергә дә белмичә аптырап торганнан соң:

– Гаилә хәле белән Төркиягә кайтып киткән иде. Күптән түгел генә Төркия армиясенә хезмәткә алганнар икән, дип ишеттем.

– Шулай укмыни? – дип куйды Муса.

– Татар башын татар ашый монда, – дип өстәде Шәмсия ханым, тагын нәрсәдер әйтергә теләгәндәй.

Шунда Шәфи Алмас, сүзне икенчегә борып:

– Күңелле итеп утырыйк әле, җәмәгать. Әйдәле, Афзал, җырлап җибәр, булмаса, – дип, табынның бер башында утырган егеткә ымлады.

Муса, табындагыларның барысы белән дә танышып чыккан кебек булса да, әлеге егет белән танышмыйча калган икән. Афзал исемле бу егетне Шәфи хезмәтчесе итеп тота иде. Ул аны, гадәттә, үзе белән эшкә йөртә. Мөһим эшләр килеп чыкканда гына өйгә кайтара. Көндезләрен ул аның кабул итү бүлмәсендә утыра, Шәфинең вак-төяк йомышларын үти. Унгляубе белән лагерьларда әсирләрне легионга димләп йөргәндә, Шәфи аны Ченстохов лагеренда очратып, яхшы җырлаганына сокланып, үзе белән комитетта эшләргә алып кайткан иде. Шул чактан бирле Афзал Шәфинең кесә җырчысы булып, ул аны кая барса, шунда үзенә ияртеп йөрде, Көнчыгыш министрлыгы түрәләре, татар эмигрантлары белән очрашуларда җырлатып, үзенә кирәкле бәндәләрнең күңелләрен күрде. Соңга таба легионерлар өчен концертлар оештыра башлады. Аннары ул Афзалны Семпен пансионатында ял итүчеләр күңелен күрергә, шунда урнаштырды. Хәзер менә үз янында гына тота. Үз өендә яшәтә.

Афзал, «Була ул», дип, алдан ук хәзерләп куйган аккордеонын кулына алды да, «Су буйлап»ны сузып җибәрде.

Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул...

Җырның беренче аккордлары яңгырауга, Шәфинең күзләреннән яшь атылып чыкты. Аңа кушылып, Әхмәтвәли Мәңгәр дә, кесәсеннән кульяулыгын алып, күз төпләрен сөртештерде.

Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул.
Караңгы төн, болытлы көн –
Без аерылган көн бит ул.

Афзал җырлап бетерүгә, ишектә кыңгырау чылтырады. Шәфи, кульяулыгы белән күз төпләрен сөртә-сөртә, ашыгып барып ишекне ачты. Анда соңга калучылар – дүрт кунак – Искәндәр әфәнде белән Матильда Яушевлар, фон Менде һәм Унгляубе басып торалар иде.

– Willkommen, meine Herren[2] – дип, колачын җәйде хуҗа, мәртәбәле кунаклары алдында яхшатланып. – Рәхим итегез, түрдән узыгыз. Мактап йөрисез. Табынга утырышкан гына идек.

Шәфинең сораганын да көтеп тормыйча, Гариф Солтан ишек төбенә йөгереп килеп җиткән иде. Ул Шәфинең сүзләрен алманчага тәрҗемә итә башлады. Түрәләр, үз телләрендә нәрсәләрдер сөйләнә-сөйләнә, залга үтеп, Шәфи күрсәткән урыннарга кунакладылар.

[2] Рәхим итегез, әфәнделәр! *(нем.)*

– Ни хөрмәткә инде бу мәҗлес? – дип, сүзне үз телендә фон Менде башлады.

– Таныш булыгыз, хөрмәтле Герхард әфәнде, ниһаять, гәзитебездә эшләргә ике зур язучы таптык. Муса әфәнде Җәлил – татарның бөек шагыйре. Беренче татар операсының либретто авторы! – дип, әллә белмичә, әллә дәрәҗәсен күтәрер өчен, юри шыттырып, ул башта Муса белән таныштырды. Аннары Рәхимне тәкъдим итте: – Күренекле татар журналисты, шулай ук шагыйрь Рәхим Саттар әфәнде.

– Sehr schön[3] – дип, фон Менде кулларын чәбәкләп алды.

– Шәфи әфәнде арттырды бераз. Мин беренче опера авторы түгел. Беренче татар операсы «Сания» 1925 елда ук язылган. Аннары, гафу итегез, Шәфи әфәнде, минем гәзит эшләргә һич теләгем юк.

– Кистереп әйтмәгез әле, Муса әфәнде. Сөйләшербез. Бу бит соңгы сүз түгел. Мөхтәрәм әфәнделәр, тагын берничә көннән Муса әфәнденең туган көне. Шушы вакыйганы билгеләп үтәргә дип тә уйлаган идек.

– О-о! Gut, Gut[4]! За это можно выпить! – дип, фон Менде торып ук басты. – Ләкин мин беренче тостымны татар милләтенең чәчәк атуы, тиздән яуланачак җиңүдән соң төзеләчәк мөстәкыйль Идел-Урал дәүләте өчен күтәрергә телим!

Фон Менде Гитлерның сугыштан соң СССР территориясендә берничнди дә милли дәүләт булмаячак, дигән тәгълиматын бик яхшы белсә дә, бу минутта икейөзлеләнде. Аның тостын легиончылардан калганнар барысы да аягүрә торып басып хупладылар.

– Ә сез мөстәкыйль татар дәүләте булуын теләмисезмени?! – диде Шәфи, урыныннан кузгалмаган Мусага карап.

– Әлбәттә, телибез, – диде Муса. – Ләкин җиңүгә бик ышанып бетәсе килми. Булмас шикелле ул.

– Күңелегезне төшермәгез, Муса әфәнде. Әле төшенкелек өчен артык җитди сәбәпләр күренми.

Тагын тостлар әйтелде. Афзал Фәтхуллин тагын җырлап алды. Татар җырын немецлар дә яратып тыңлады. Бераздан табын артыннан торып, кайсы дивар тирәли куелган кәнәфиләргә чүмәште, кайсылары алгы яктагы бүлмәләргә таралышты. Фон Менде исә халык алдында гафу үтенеп, кайтып китте. Ул киткәч, барысы да иркен сулыш алган кебек булдылар. Сөйләшү тулысынча татарчага күчте. Унгляубе дә каршы түгел иде бугай, үз янына Гариф Солтанны чакырып алды да бөтен сөйләшүләрне алманчага тәрҗемә иттерде. Унгляубе комитет хезмәткәрләрен болай да яхшы белә иде. Шуңа күрә бугай, ул күбрәк Муса белән Рәхим янында булды. Әхмәтвәли Мәңгәрнең дә Муса белән якынанрак танышасы килә иде. Табын артыннан таралышкач, ул да Мусалар әңгәмәсенә кушылды.

– Сугышка ничек эләктегез, Муса әфәнде, үз теләгегез белән киттегезме фронтка? – диде ул.

– Әлбәттә, – диде Муса.

Әхмәтвәли Мәңгәр аннан һич кенә дә мондый җавап көтми иде.

– Без татар язучылары барыбыз да үз теләгебез белән киттек. Язучылар берлегендә, «Совет әдәбияты» журналында һәм радиокомитетта эшләүче берничә язучыдан кала.

– Ничек инде алай? Һаман да шул вәхши большевиклар астында изелеп яшисегез киләмени?

[3] Бик яхшы! *(нем.)*
[4] Яхшы. *(нем.)*

– Аңлап бетермисез сез безнең тормышны, Әхмәтвәли әфәнде. Революциядән соң чирек гасыр вакыт узды бит инде. Гражданнар сугышы тынганга да ике дистә ел. Дөньялар тынычланды. Тормыш көйләнә башлады. Яңа тормыш төзи башладык.

– Сөйләмә инде, Муса дус, – дип куйды Рәхим, Җәлилнең сүзләре белән килешеп бетмичә.

– Милләтнең асыл уллары, ул инкыйлабны кабул итмичә, Төркиядә, Германиядә, Франциядә яшәп ята. Россия бит аларның да ватаны. Аларга ватанга кайтырга юл бикле. Ни өчен?! Милләтнең генә түгел, урысның да асыл ир-егетләрен большевиклар зинданнарда яткыра. ГУЛАГта күпме каләмдәшегез иза чигә. Галимҗан Ибраһимов, Тинчурин, Бурнаш, Туфан, Гомәр Гали, Гомәр Толымбай... Саный китсәң, исең китәрлек бит. Нинди гаепләре бар соң ул әдипләрнең? Галимҗан Ибраһимов – Татарстан Республикасын төзү өчен җан аткан кеше. Менә сез, Муса әфәнде, Язучылар берлеге рәисе дә булгансыз, һич кенә дә саклап калып булмый идемени соң ул Галимҗан Ибраһимовны? – диде Галимҗан Идриси, Әхмәтвәли әфәнде белән Муса арасындагы сөйләшүгә кушылып.

– Ул инде мин рәис булганчы ук үлгән иде.

– Үтергәннәр иде, диген инде, – дип, Мусага каршы чыкты Рәхим.

– Аны бит эсэрлар партиясе әгъзасы булган өчен, буржуаз милләтчелектә гаепләп утырткannар. Уфада оештырылган Милли мәҗлес эшендә актив катнашкан өчен. Яңалифкә кучүгә каршы булганы өчен. Сталин теләмәгән «Идел-Урал» штатын төзергә теләүчеләрнең берсе булганы өчен.

– Соң, менә безнең дә шул дәүләтне төзү өчен тырышып йөргән көнебез бит инде. Легионны да шуның өчен оештырдык. Әсирләрне легионга керергә үгетләп йөреп, үзегезгә үзегез каршы киләсез түгелме соң?

– Сезнең арада да бит бердәмлек юк, Әхмәтвәли әфәнде. Бая гына Шәмсия ханым әйтеп ташлады, татар башын татар ашый, дип. Шул инде бездә, татар башын татар ашый. Әхмәт Тимерне дә юкка чыгаргансыз әнә. Язучылар берлегендә эшләгәндә, минем өстән дә ниләр генә язмадылар. Мәскәүгә баргач, шулай, Фадеев алдыма бер кочак хат китереп салды. Укып кара әле, ди. Укысам, исләр китте. Союз тирәсендә, минем белән кулга-кул тотышып эшләп йөргән бәндәләр нәрсәләр генә язмаганнар минем турыда, нинди генә гаепләр тагып бетермәгәннәр. Миннән соң рәис булып калган бер драматург кисәге хәтта мине «халык дошманы» дип атаган, хәерсез. Ярый әле Фадеев акыллы кеше. Ул доносларның берсен дә өскә җибәрмәгән, өстәл тартмасына гына салып барган.

– Татар арасында бердәмлек юк инде ул. Муса дөрес әйтә. Үзебезнең комитетта гына, әнә, Гаяз Исхакыйга мөнәсәбәт нинди, – дип, сүзгә Алиш кушылды.

– Нинди, нинди?! – дип чәчрәп чыкты шулвакыт Шәфи Алмас.

Алиш сүзне озынга җибәрмәскә булды, Исхакыйны ялгыш искә алуын аңлады һәм: «Бернинди дә түгел», – дип, сүзен түгәрәкләде.

Алиш редакциядә эшли башлаганда, аның бүлмәсендә диварда Гаяз Исхакый портреты эленеп тора иде. Комитет әгъзалары арасында кайсыдыр «Идел-Урал»га президент итеп Гаяз Исхакыйны куярга кирәк», дигән сүз ычкындырган. Бу сүз биш тапкыр күпереп, Шәфи Алмас колагына барып ирешкән. Ул, дулап китеп, портретны ертып ташлаган. Хәтта комитетның исемен дә алмаштырырга кирәк, дип йөри башлаган. Алиш шул хакта искә

төшермәкче иде. Аннан соң тыелып калуны хуп күрде. Ярар инде, бүген көне ул түгел, дип уйлады.

– Әшулай да, нишләргә соң инде безгә? – дип көрсенеп куйды Әхмәтвәли Мәңгәр.

– Ничек инде «нишләргә»?! Эш бара бит, әфәнделәр! Муса белән Рәхим әфәнделәрне дә җитди кешеләр дип беләм. Бергә-бергә батальоннарны әзерләсәк, алман армиясенә олы ярдәмебез булыр, шәт иншалла! – диде Шәфи. – Әйдәгез әле, төшенкелеккә бирелеп утырмыйк. Табын артына рәхим итегез. Мәҗлесне дәвам иттерик.

Барысы да яңадан үз урыннарына кереп утырдылар. Унгляубе китеп барды. Бу юлы мәҗлескә җитәкчелек итүче булмады. Бер тирәдә утырганнар төркем-төркем булып үзара гәпләшүгә күчтеләр. Әхмәтвәли Мәңгәр кабат Муса белән сөйләшүен дәвам итте.

– Сезне зур шагыйрь диде Шәфи әфәнде, Муса туганкай. Берәр шигырегезне укып, кәефләрне күтәреп җибәрмәссез микән? Монда шигырь язарга мөмкинлек тә юктыр инде.

– Нишләп булмасын. Әле менә Вустрауга килер алдыннан гына биш көн камерада тоттылар. Комачаулаучы булмады. Берничә шигырь язарга өлгердем.

– Сезне алайса камерада гына тотарга икән. Ник болай паспортлар биреп, иркле тормышка чыгарганнар, – дип, үзенчә шаярткан булды Гариф Солтан.

– Көлмә кешедән, борының өшегән! – диде Шәфи Алмас. – Сезне ул монда бераз камерага ябып тотарга иде. Дөнья бутап йөрисез.

Шәфи комитетка Әхмәт Тимер урнаштырып калдырган Гарифны бик өнәп бетерми. Шымчылары аша ишетеп, Гаяз Исхакыйны президент итәргә кирәк дигән сүз дә Гариф авызыннан чыккан булырга тиеш, дип шикләнеп йөри иде.

– Бүгеннән үз өемдә яшәрсез, Муса әфәнде, – диде ул. – Шигырь язарга да мөмкинлегегез күп булыр. Бөтен уңайлыкларны да тудырырбыз. Беренче көннәрдә Галим бүлмәсендә яшәп торырсыз. Аннары, пансионатта ял итеп кайткач, үзегезгә аерым бүлмә әзерләп куярбыз.

Галим дигәне редакция хезмәткәре Бахтиков иде. Шәфи аның исемен атауга, ул, торып басып, Мусага: «Мин булам ул», – диде.

– Ә Рәхим әфәндене беренче төнгә Алиш әфәнде сыендырыр, бәлки... Сез ризамы, Алиш әфәнде?

Алиш ризалыгын белдереп баш какты.

– Беренче төндә йокламыйча сөйләшеп чыгарга да риза без, – диде Рәхим. – Алиш та шулай уйлыйдыр, дип беләм.

– Сездән шигырь, Муса әфәнде. Сорыйбыз, – диде Әхмәтвәли Мәңгәрнең җәмәгате Гайшә ханым.

– Шигырь икән, шигырь. Укыйбыз аны, – диде дә, Муса куен кесәсеннән кулъязма кенәгәсен чыгарып, битләрен актара башлады. – Менә, әле кичә генә язган өр-яңа бер шигырь. «Хәдичә».

Күрше кызы Хәдичә,  
Шулай гадәттәгечә,  
Озак йөреп бакчада,  
Кичегеп кайтты кичә.  
Каравылчы карт аның  
Ишетмәгән кайтканын.  
Шуңа күрә ачмаган  
Хәдичәгә капканы.

Барысы да Мусаның шигырь укыганын тын да алмыйча тыңладылар. Укып бетерүгә, Әхмәтвәли, кул чабып:

– Афәрин! – диде. – Менә бит нинди кеше! Дөньяда сугыш бара. Ә ул шаян шигырь яза. Афәрин, Муса! Каян килә ул башыңа шундый шаян шигырьләр?! Кирәк бит, ә! «Кызлар, төнлә йөрмәгез, Коймадан сикермәгез! Тагын әллә ни ертып: «Мода», дия күрмәгез». Талант!

Муса тагын берничә шигырь укыды. Ахырдан «Тик булса иде ирек» дигән шигырь битен ачты да, укыргамы, юкмы икән, дип уйланып калды.

– Укыгыз инде, Муса әфәнде. Тагын берне укыгыз инде, – диде аның икеләнеп калганын күреп Шәмсия ханым.

– Ярар, укыйм булмаса. Монысы мәҗлестә укый торган түгел дә... Бик кыстагач, укыйм инде. «Тик булса иде ирек».

Бу шигырьне дә бер тавыш-тынсыз тыңладылар.

Юк, барыннан да элек,
Тик булса иде ирек;
Кылычым булса кынымда,
Карабиным кулымда,
Сине саклап, туган җирем,
Мин ирләрчә үләр идем
Данлы сугыш кырында.

Муса укып бетерде дә «Йә, ничек?» дип сорап куйды.

– Монысы да әйбәт, – диде Әхмәтвәли Мәңгәр. – Ләкин сездән мондый шигырь көтмәгән идем. Чынлап та шулай уйлыйсызмыни, Муса әфәнде?

– Ә сез, Әхмәтвәли әфәнде, Гитлерны шулкадәр изге кеше дип саныйсызмыни? Мин тоткынлыкта булган Демблин лагеренда узган ел 17 мең әсирнең 15 меңе ачлыктан интегеп, суыкта өшеп-туңып үлгән. Сез бу хакта яхшы беләсез. Башка лагерьларда да шул ук хәл. Ә сугыш әле дәвам итә. Кайчан туктаячагы да билгесез. Күпме кеше кырыла. Бер гаепсез халык харап була. Безнең илдә бит Молотов белән Риббентроп килешүеннән соң, сугыш булмаячак, дип, ышанып яши башлаганнар иде. Халык немецларга хөрмәт белән карый, мәктәпләрдә нимес телен өйрәтәләр. Большевиклар һәм яһүдләр ошамый, дип, бөтен халыкны кырып бетерсеннәрмени инде? Ул Гитлерның үзен дә яһүд икән, дип сөйлиләр. Әйе, без легионга язылган илдәшләрне сугышка барырга өндәп йөрибез. Ләкин алар арасында да төрле кеше бар. Иманлылары бар. Иманы нык кешене бернинди үгет-нәсихәт тә сындыра алмый. Легионга да лагерьларда ачлыктан интегеп үләсе килмичә язылган аларның күбесе. Шуны аңлыйсызмы, Әхмәтвәли әфәнде? Совет иле – аларның ватаны. Ватан ул әле дәүләт башында утырган хакимнәр генә дигән сүз түгел. Хакимияттә бүген большевиклар, иртәгә капиталистлар булырга мөмкин. Гитлер җиңсә, национал-социалистлар киләчәк. Аларга ышаныч бармы? Егерме еллар элек кенә революция шаукымы белән яшәгән немец коммунистлары интекмимени ул Дахау кебек лагерьларда? Бер урыслар, татарлар гына түгел, алманнар, чехлар, венгрлар, шул ук испаннар, итальяннар, французлар интегә безнең белән немец тоткынлыгында.

– У-у, озынга китте бу чыгышыгыз, Муса әфәнде, – дип, аның сүзен бүлдерде Шәфи Алмас.

Муса үзе дә туктарга җыена иде инде.

– Мин бернинди дә үгет-нәсихәт укымыйм, әфәнделәр. Бары тик әсирләрнең

күңелендә йөргән нәрсәләрне генә сөйлим. Аек акыл белән карарга кирәк тормышка. Шул хакта искә төшермәкче булам.

– Сез хаклы, Муса әфәнде. Ләкин инде артка юл юк, – диде Әхмәтвәли Мәңгәр.

– Мин дә легионерлар сугышка бармасын, димим. Ләкин безнең үгетләп йөрүдән генә аларның күңелендәге уй-фикерләре үзгәрмәскә дә мөмкин. Шул турыда әйтергә телим.

– Ә шигырегез куркыныч, Муса әфәнде, – диде Шәфи Алмас.

– Сез сорадыгыз, мин укыдым. Күңелемдәгесен яздым. Хәзер инде анда язылганнар барысы да хыял гына. Чынга ашмас хыял. Берни эшләр хәл дә юк.

– Ә сез ни уйлыйсыз, мөхтәрәм Искәндәр әфәнде? – диде Әхмәтвәли Мәңгәр, үз янында Унгляубе урынына кереп кунаклаган Яушевка карап. – Нишләптер, килгәннән бирле дәшми-тынмый утырасыз.

– Кәеф юк бүген, Әхмәтвәли туганкай. Бер килмәскә дә уйлаган идем. Заводта поляк эшчеләре корткычлык эшләгәннәр.

– Нинди корткычлык инде ул тагын? Җитдиме?

– Кемнәрдер эшчеләр арасында листовка тараткан. Совинформбюро хәбәрләре. Сталинградта алман армиясенең тулысынча тар-мар ителүе турында. Шәфи әфәнде җибәргән күзәтчеләрнең дә бер файдасы юк.

– Нишләп булмасын, Искәндәр әфәнде, ялгыш сүз сөйләмәгез. Иң турылыклы егетләремне генә туплап җибәрдем. Сезгә ышанган кебек ышанган егетләремне.

– Белмим инде. Ул полякларга да бер дә ышаныч юк.

Шунда Муса торып басты да:

– Бүген нык ардырды. Рөхсәт итсәгез, бераз ял итәр идек. Шәфи әфәнде, мөмкин булса, Бахтиков миңа үзенең бүлмәсен күрсәтсен иде, – диде.

– Әлбәттә, әлбәттә, – диде Шәфи. – Барыгыз, бар, ял итегез.

Муса белән Галим Бахтиков артыннан Алиш белән Рәхим Саттар һәм арадашчылык хезмәткәрләреннән кала башка егетләр дә кузгалды.

– Ә сез ашыкмагыз әле, Әхмәтвәли кордаш, Галимҗан хәзрәт, Искәндәр әфәнде, утырыйк бераз. Һаман-һаман очрашып тормыйбыз. Егетләр, сез дә ашыкмагыз. Афзал, син җырлап җибәр, булмаса, – дип, Шәфи Алмас кунакларын табын артында калырга кыстады.

**4**

Галим Бахтиков Шәфи Алмаз йортының икенче катында яши икән. Мусага ияреп, аның янына Алиш белән Рәхим дә керделәр. Бүлмәдә ике карават, өстәл, тумба һәм ике урындык бар иде. Ике кешелек бу фатирда Галим үзе генә яшәсә дә, Шәфи анда әледән-әле кемне дә булса кундырып чыгара торган булды. Баштарак анда Алиш та яшәп алды. Өч көннән соң Шәфи үзенә аерым бүлмә бирде. Бүлмәсе Галимнеке шикелле үк ике кеше яшәрлек итеп җиһазланган иде.

– Галим дускай, сез ял итә торыгыз, мин Алиш торган җирне дә күреп чыгыйм инде, – диде Муса, һәм алар өчәүләп чыгып киттеләр.

Алиш бүлмәсе дә икенче катта, Галимнекеннән өч ишек аралаш кына булып чыкты.

– Башка егетләрне дә дәшеп керегез әле, – диде Муса Алишка, мәҗлестән үзләре белән бергә чыгып киткән Әхмәт Симаев, Гариф Шабаев, Фоат Булатов, Зиннәт Хәсәновны күз алдында тотып. – Ә-ә, Абдулла, карале, Кормаш кайда соң безнең? Бүген күренмәде.

– Кормашны бит Шәфи Алмас кире Демблинга җибәрде. Музыкаль рота оештырырга булган. Бу эш өчен Гайнаннан да кулай кеше тапмаган.

– Шулаймыни? Кызык. Әйбәт булды әле бу мәҗлес, – диде Муса. – Вустраудан сез киткәннән бирле болай барыбызга да бергә очрашырга туры килгәне юк иде.

– Мин хәзер киләм, сез гәзитнең соңгы санын карый торыгыз, – дип, Алиш, Муса белән Рәхимгә таныша торырга тумба тартмасыннан гәзитләр чыгарып өстәлгә куйды да ашыгып чыгып китте.

– Мондый шартларда яшәргә була, – диде Муса. – Язам дигән кеше өчен дә мөмкинлекләр җитәрлек.

Ул «Идел-Урал» гәзитенең соңгы санын караштыра башлады. Гәзит бәләкәй форматта, укыр өчен дә, кесәгә тыгып йөртер өчен дә бик уңайлы. Вустраудa чакта Муса аның бөтен саннарын да диярлек укып чыккан иде. Монысын, яңа сан булганга, ниләр турында яздылар икән, дигән кызыксыну аша кулына алды. Беренче битендә үк Алишның ниндидер язмасы бар иде. Икенче, өченче битләрдә дә Әхмәт Симаев, Галим Бахтиков, Кыям Галиев фамилияләрен күрде. Икенче биттә Муса Гайнц Унгляубе исеме белән имзаланган «Хәерле юлга!» дигән язмага игътибар итте. Бүгенге мәҗлес башында Шәфи Алмас әйтә башлаган хәбәр иде ул. «Февральнең ундүрте көнне беренче татар батальонын тантаналы рәвештә фронтка озату була», – диелгән иде ул язмада. Ни өчендер бу хакта Унгляубе да, Розенберг үзе дә ләм-мим, берни дә әйтмәделәр, әллә оныттылар, әллә сер итеп калдырдылармы? Сер дисәң, гәзиткә язмаслар иде. Муса шул язманы укыган арада ишектә егетләр дә күренде.

– Йә, егетләр, утырышыгыз әле. Тагын дүрт көннән беренче батальонны тантаналы шартларда фронтка озатырга җыеналар икән бит. Тәкъдир бүген безгә шундый форсат бирде: оешманың чираттагы утырышын уздыру мөмкинлеге. Шәфи Алмасның үз йортында. Сүзне озын-озакка сузарга ярамый, үзе килеп керүе дә бар. Вакыт аз калган – өч көн. Фронтка китәчәк батальон солдатлары белән очрашып, сөйләшеп калырга кирәк. Һәрберсе белән аерым сөйләшергә. Бөтен игътибарны шушы эшкә тупларга.

– Эш бара, Муса абый, – дип сүзгә кушылды Әхмәт Симаев. – Әле бүген дә Солтанбәков белән Газиев бер чемодан листовка алып киттеләр Радомга. Бүген-иртәгә Едлинодагы бөтен дүрт батальонга да таратылачак. Листовкаларны «Винета»да үзем бастырам.

– Ничек шулай курыкмыйча бер чемодан листовка җибәрдегез?

– Чемодан ике катлы. Листовкалар аста. Өскә «Идел-Урал» гәзитенең соңгы санын тутырдык.

– Кем соң ул Газиев?

– Ышанычлы кеше, Муса абый. Бергә эшлибез. Инде берничә мәртәбә листовка бастырып, Едлинога илттек без аның белән.

– Листовкалар бастыруны очрактан очракка гына түгел, тәртипкә салырга кирәк. Бу эш белән, Гариф, син шөгыльләнсәң әйбәтрәк булыр. Әхмәт, синең Совинформбюро хәбәрләрен табуны җайга салырга мөмкинлегең бар. Листовкаларны язу машинкасында бастырып, гектографта йә ротаторда ишәйтергә кирәк. Бу эшне дә гәзит редакциясендә түгел, «Винета» редакциясендә башкару куркынычсызрак түгелме икән?

– Мин типографиядә эшләүче болгар студентлары белән таныштым. Чын антифашистлар, ышанырга була. Бәлки, шулар аркылы ишәйтергәдер, – диде Алиш.

– Бәлки. Карап кара. Гайнан белән күрешкәнегез бармы? Эшләре ничек бара?

– Гайнан капелла оештыру белән мәшгуль. Тугыз кешелек төркем туплады инде. Музыка коралларында да уйныйлар, хор белән дә җырлыйлар. Инде берничә концерт та куйдылар. Капелланы ишетәселәре килә.

– Бу Шәфинең бүгенге артисты Афзал Фәтхуллин бик матур гына җырлый. Шунда җибәрергә кирәк. Аккордеонда да әйбәт уйный.

– Без анда өчебез скрипкада, икебез гармунда, икәү мандолинада, икәү гитарада уйныйбыз. Гарәф Фәхретдинов – җырчы-солист. Калганнар кушылып җырлый. Халык яратып кабул итә концертларны. Гайнан үзе алып бара. Концерт вакытында безнең егетләр халык арасында йөри, листовка тарата.

– Әйбәт. Гарәф әйбәт җырчы. Гайнан урынына аны җигәргә кирәк бу эшкә. Гайнан режиссёр булсын. Иртәгә үземә дә, танышырга форсат чыкты, дип, Едлинога барып кайтасы булыр. Батальон командирлары арасында безнең егетләр бармы соң?

– Батальонда чама белән тугыз йөз кеше. Шуларның сигез йөз кырыклабы – әсир-солдатлар. Алтмышлап немец – командный составта. Хөсәен Мөхәммәтов, Таҗиев, Рәхимов атлы егетләрне махсус әзерләдек, восстание оештыру өчен. Батальон немец командирларны юк итеп, восстаниене башлауга, командалык итүне алар үз кулларына алырга тиеш.

– Партизаннар белән элемтә урнаштырганда да начар булмас иде. Монысы иң катлаулысы, әлбәттә. Шул ук вакытта иң кирәклесе дә. Партизаннар алдан белеп тормаса, немец киемендәге тулы бер батальон солдатны юкка чыгарып ташлаулары бар.

– Әлегә батальонны кая җибәрәселәре төгәл генә билгеле түгел. Шушы араларда ачыкланыр инде, бәлки. Партизаннар белән элемтәгә, һичшиксез, керергә тырышырбыз.

– Абдулла, син бу Бахтиков дигән егетне беләсеңдер, ышанычлымы икән ул? Аның алдында ачылырга ярыймы?

– Мин үзем бик ачылганым юк. Болай кылларын чирткәләп караган бар. Зыянлы кешегә охшамаган кебек. Белмим тагын.

– Ярар алайса, күз күрер. Сөйләштереп карармын кайткач. Ә хәзер, егетләр, бер мөһим эш бар.

Муса шулай диде дә кесәсеннән дүрткә бөкләнгән бер бит кәгазь чыгарды.

– Егетләр, без бик җитди эшкә керештек. Куркыныч эшкә. Монда саклык, саклык һәм тагын бер тапкыр саклык сорала. Мин кичә бер текст әзерләдем. Беләсезме, безгә хыянәттән куркырга кирәк. Иң куркыныч нәрсә – хыянәт. Әгәр дә бер-беребезгә хыянәт итәбез икән, безнең бер эшебез дә чынга ашмас. Башыбызны куркыныч астына куеп шөгыльләнгән бөтен хезмәтебез юкка чыгачак. Бер куркак, мескен шкурникның хыянәте аркасында бөтен эш харап булачак. Шуның өчен бер-беребез алдында изге ант бирергә тиешбез. Моны малайлык дип уйламагыз. Изге ант – ул җитди нәрсә! Мин кичә төнлә шушы антның текстын яздым. Менә, тыңлагыз әле.

Муса, кәгазен ачып, ишек ягына карап алды да, ярым пышылдап, язуны укый башлады.

– «Изге ант. Мин, Муса Җәлил, үз теләгем белән фашистларга каршы көрәшүче «Идел-Урал» яшерен оешмасы әгъзасы булырга карар кылдым. Нинди генә шартларда да, оешма эшенә зыян китермәскә, хыянәт юлына басмаска, туган илгә каршы корал күтәрмәскә ант бирәм! Илгә каршы корал күтәрү – ул нәселеңне, ата-анаңны, балаңны, үзеңнең кешелек сыйфатларыңны юк итү дигән сүз. Әгәр шушы изге антымны бозсам, оешмадагы көрәштәшләремнең рәхимсез нәфрәте мине һәлак итсен!»

Йә, ничек? Кемдә нинди фикерләр бар?

Мусаны тын да алмыйча тыңлаган егетләр башта сүзсез тордылар.

– Булган бу! – дип куйды шунда Рәхим Саттар, һәркайсының уртак фикерен белдергәндәй.

– Кыска һәм ачык, – дип куйды Алиш һәм, – кушылабыз! – дип өстәде.

– Юк, егетләр, кушылабыз гына түгел. Бу антны оешманың һәр кешесе шәхсән үзе укып чыксын. Мин шулай дип уйлыйм. Аннары, оешма зур булырга тиеш түгел. Без намуслы, ышанычлы санаган очракта да, бөтен кешене дә оешма әгъзасы дип атарга ярамый. Менә бүген без монда бишәү. Димәк, оешмабызда әлегә шушы биш кенә кеше бар, дип саныйк. Аннары бу ант сүзләрен укытып, тагын берничә кешене алырга мөмкин булыр, – диде Муса.

– Ә элек яшерен оешма әгъзалары дип йөргәннәр белән нишләргә? Гайнанның үз командасы бар.

– Булсын, Гариф туганкай, ләкин безнең оешмада Гайнан үзе генә булырга тиеш. Аның безнең оешмада икәнен командасындагылар да белергә тиеш түгел. Командалар күп булырга мөмкин. Ләкин һәр төркемнең җитәкчесе берәү, һәм бары тик аны гына үз оешмабызга алачакбыз. Шулай эшләгәндә генә оешмабызны чын мәгънәсендә яшерен дип атап булачак. Шунда гына хыянәткә юл калмаячак.

Мусаның сүзләре белән барысы да килештеләр. Шунда Муса Алиштан пычак сорады. Алиш, «Нәрсәгә ул?» дип сорап, соравына җавап көтеп тормыйча, кесәсендә йөрткән үзе ясаган пәкесен чыгарып бирде. Муса пәке белән сул кулының учын кисеп җибәрде. Аннан тамчылап кып-кызыл кан саркып чыкты. Муса шуннан соң яңабаштан «Изге ант» текстын укыды һәм учындагы кан тамчысын йотты да, җәрәхәтен кысып, янәдән кан тамчыларын сытып чыгарды һәм учын Алишка сузды:

– Каннарыбыз белән ант итәбез, егетләр...

Башта Алиш, аның артыннан башкалар да шулай иптәшләре алдында изге антларын ныгыттылар.

– Ә хәзер таралыштык. Иртәгәгә кадәр, сау булыгыз. Хәерле төн. Татлы йокы, тәмле төш, кем әйтмешли. Онытмагыз бу төнне, егетләр. Оешмага алынган һәр кешедән шундый ант бирдерәчәкбез, – диде Муса һәм, башкаларга бераз көтеп торырга кушып, беренче булып коридорга чыкты.

Өченче катта җырлаган тавышлар ишетелде. Афзалга башкалар да кушылган булырга тиеш, аның тавышы хәтта башкалар арасында әллә ни аерылмый да иде. Муса беркадәр тыңлап торды да Бахтиков бүлмәсенең ишеген шакыды. Бахтиков әле ятмаган, бүлмәдәшен көткән, күрәсең, аның өчен икенче койкага урын җәеп куйган, ә үзе тумба янына чүмәшеп, нидер язып утыра иде.

– Без җүнләп танышмадык та, – диде Муса, аңа кулын сузып: – Муса Гумеров.

– Мин сезнең иҗат белән яхшы таныш, Муса абый. Җәлил икәнегезне дә беләм.

– Мине немецлар Гумеров дип белә. Шуңа күрә алар арасында Җәлил дип әйтмәвең яхшы булыр иде.

– «Алтынчәч» операсының либреттосын язуыгызны да беләбез. Мин укытучы булырга укыган идем. Укып бетергәч үк армиягә алдылар, эшләргә өлгерми калдым. Сугышның беренче көннәрендә үк әсирлеккә төштем.

– Коммунист идегезме?

– Комсомолец.

– «Идел-Урал» гәзитенә ничек килеп эләктегез?

– Башта Көнчыгыш Пруссиядәге Тильзит лагерена эләктем. Анда анкета тутырганда, минем югары белемле икәнемне белделәр дә ниндидер махсус мәктәпкә укытырга җибәрергә үгетли башладылар. Ачлыктан бик интеккәч, өч тапкыр ашату була, дигәч, ризалаштым. Берлин астындагы Вульгайде лагерена җибәрделәр. Берзаман лагерьга Әхмәт Тимер белән Шәфи Алмас дигән эмигрантлар килде. Татар легионы төзелә, диләр, әсирләрне легионга язылырга үгетләү өчен пропагандистлар эзлиләр икән. Һәр әсир белән әңгәмә үткәрделәр. Мине «Идел-Урал» гәзите редакциясендә тәрҗемәче эшенә кыстый башладылар. Башта барырга теләмәгән идем дә, Әхмәт Тимер бик хәйләкәр булып чыкты. Минем немецча белү-белмәвемне тикшерәм дигән булып, бер әшәке фашистик текстны татарчага тәрҗемә итәргә бирде. Тәрҗемәләп бетергәч, астына, «тәрҗемәче Галим Бахтиков», дип яздырды. Язуны алды да, «Менә хәзер эштән баш тарта алмыйсың инде, – ди. – Каршы килсәң, немецлар коммунистларга фамилияң язылган шушы язуны гына күрсәтәчәкләр. Алар моның өчен сине гафу итмәячәк», – дигәч, ризалашырга туры килде.

– Алай икән, – дип куйды Муса. – Мине дә бик кыстыйлар ул гәзиттә эшләргә. Шәфи Алмас урынына редактор итеп куярга телиләр хәтта.

– Булыгыз, Муса абый. Ул Шәфи Алмас бик йомшак кеше. Үзенең белеме гел шул коммерция тирәсендә генә. Дан-дәрәҗә ярата. Идел-Урал дәүләте төзү турында сөйли, үзенең Гаяз Исхакыйның «Идел-Урал» китабын кулына да алып караганы юк. Укырга иренә. Аның ялкаулыгының безнең өчен уңай ягы да бар. Гәзиткә нәрсә язсалар да үтеп китә. Аннары немец нәчәлникләре чакырып сүгәләр үзен. Аңа да исе китми, кайта да безне орыша. Гел гаепне бездән эзли.

– Мин редактор булсам, гәзиттә теләсә нәрсә бастырмаячакмын бит. Контроль нык булачак.

Мусаның сүзләреннән Галим беркадәр югалып калды.

– Һым-м... Шулай укмы? – диде.

– Ә син редактор булсаң нишләр идең? Мин, мәсәлән, үземә тапшырылган эшкә бик җаваплы карый торган кеше. Беләсең килсә, «Идел-Урал»да Шәфи Алмасның редактор булуы бик әйбәт. Безнең өчен нәкъ менә шундый кеше кирәк тә.

Муса Галимнең гәзиттә фашистик рухтагы язмаларның йомшартып бирелүенә карашы нинди булуы хакында сорамакчы иде дә, Алишларның аның белән артык ачылып бетмәүләре турында әйткәнен искә төшереп, дәшмичә калырга уйлады. Аңа тыныч йокы теләп, ятагына барып ауды.

## 5

Икенче көнне иртән Мусаны бүлмәсеннән Шәфи Алмас үзе кереп алды. Алар инде юынып, кырынып, чәйләр эчеп куйганнар иде. «Винета» радиостанциясенең башта немец, аннары татар телендәге соңгы хәбәрләрен тыңладылар. Радио «Винета» радиостанциясе дулкыннарына көйләнеп куелган иде бугай, Мусага аны эзләп табасы да булмады. Шәфи аларның ишеген соңгы хәбәрләр бетеп, ниндидер музыка яңгырый башлагач шакыды.

– Нәрсә, егетләр, туйдымы йокыгыз? Башыгыз авыртмыймы? – дип килеп керде Шәфи алар бүлмәсенә.

– Йокы да туйды, баш та авыртмый, – диде Муса.

– Алайса, эшкә! Безне алда яңа җиңүләр көтә!

– Кемне нәрсә көткәнен белгән юк инде монда, Шәфи әфәнде.

– Нишләп алай дисез, Муса туганкай?

– Тыңламадыгызмыни, радиодан әле генә немецларның Сталинград сугышында җиңелүе турында хәбәр иттеләр.

– Ул хакта кичә дә сүз булган иде инде. Ләкин Германиянең көче бетмәс-төкәнмәс, Муса туганкай. Менә тиздән татар батальоннары Германиянең җиңүе өчен сугышка кушылачак. Сез «Идел-Урал» гәзитендә эшләргә теләмим, дидегез бугай. Мин сезгә тагын да җаваплырак эш тәкъдим итәм: комитетның мәдәни-агарту эшләре өчен җаваплы вазифаны башкарырсыз. Бу инде комитетта миннән кала икенче урында торган вазифа булачак. Сез разыймы?

– Минем турында шулай югары фикердә булырсыз дип һич башыма да китермәгән идем. Рәхмәт инде, Шәфи әфәнде, бик рәхәтләнеп башкарырмын бу эшне, – диде Муса, сүзләренең интонациясенә беркадәр киная кертеп. Шәфи моны аңладымы, аңламадымы, аңа җавап итеп:

– Бик әйбәт! – дип куйды. – Алайса, кузгалдык. Бүген икәү бергә Едлинога барып кайтыйк. 14 февральдә беренче батальонны фронтка озатабыз. Зур абзыйлар катнашырга тиеш озатуга багышланган митингта. Мәдәни программасы турында да уйларга кирәк. Бу эш бүгеннән сезнең өстә.

– Кайсы фронтка җибәреләчәк беренче батальон, Шәфи әфәнде, сер булмаса?

– Сер түгел. Белоруссиянең Витебск шәһәренә җибәреләчәк. Шул тирәдәге партизаннарга каршы сугышырга.

Муса ничек итеп бу хәбәрне Алишка йә Симаевка җиткерергә икән дип уйлап куйды. Кичтән сөйләшкәнчә, партизаннар белән элемтәгә керү хәстәрен күрергә кирәк.

– Бу хакта «Идел-Урал» гәзитенә язма әзерләгәндә начар булмас иде. Ничек уйлыйсыз, Шәфи әфәнде? – дип сорады ул.

– Дөрес фикер, – дип куйды Шәфи. Аннан, Бахтиковка карап: – Галим туганкай, эшкә баргач, Кыямга шушы хакта әйт. Мин кушты, диген. Материал әзерләсеннәр, – диде.

Кыям дигәне – Шәфи Алмасның урынбасары Кыям Галиев иде. Баштарак, Шәфи әле редактор итеп билгеләнгәнче, ул вакытлыча редактор вазифаларын башкаручы булып та торды.

Шәфи, Мусаны да машинасына утыртып, туп-туры Радомга, беренче татар батальоны урнашкан Едлино лагерена юл тотты.

...«Идел-Урал» комитетында «Идел-татар» легионын оештыру эшләре узган елның 21 августында башланган иде. Лагерь өчен Польшаның Радом шәһәре янындагы Едлино лагере сайланды. Милли легионнар оештырылачагы турында сүз чыккач, татар әсирләрен башта Едлино белән бер рәттәге Седльце лагерена тупладылар. Алиш та шушы лагерьга китерелгән иде. Мусалар яшәгән Демблин да төрки әсирләрне легионга әзерләү лагере булып торды. Соңыннан барысын да берләштереп, Вустраугa җыйнадылар һәм, милләтләр буенча аерып, батальоннарга озаттылар. Төп татар батальоннары дүртәү, ә әсирләр күп булгач, аларга өстәп тагын ике батальон оештырылды. 25 ноябрьдә төзелгән беренче татар батальонына немецлар 825нче теркәү номеры бирделәр. Ике ай ярым эчендә бөтен әзерлек эшләре башкарылып, солдатлар махсус өйрәтү курслары үтеп, аларны 14 февральдә инде фронтка җибәрергә дигән карар да кабул ителгән иде.

– Ашыга алманнар, – диде Шәфи, үзалдына сөйләнгәндәй. – Күрәсең, эшләре чынлап та хөртидер, ахры.

– Хөртидер, әлбәттә. Алай бик көчле гаскәр булгач, әсирләр ярдәменә

калырга тиеш түгелләр инде, бер караганда, – дип, Муса Шәфинең күңелендә барлыкка килгән шомны көчәйтеп куйды.

– Без бит аларга ярдәмебезне үзебез тәкъдим иттек.

– Мескен әсирләрне сугышка җибәрергә хакыбыз бар, дип уйладыгыз инде алайса?

– Юк та инде анысы. Легионга бит алар үз теләкләре белән язылдылар.

– Язылырсың да, ачтан интектерсәләр, кышкы салкыннарда катырып үтерсәләр.

– Сез, Муса әфәнде, бик көчле үгетче бугай. Үз ихтыярыгызга буйсындыру сәләтенә ия кеше. Кем диләр әле, әйе, гипнозчы. Монда хәтта мине дә юлдан яздырып барасыз үзегезнең коммунистик демагогиягез белән. Бу сөйләшүне ишетә күрмәсеннәр тагын алман дуслар. Икебезнең дә кирәкне бирерләр. Менә барыйк, күрик. Легионерлар белән сөйләшерсең. Кем җибәрә аларны сугышка? Безме? Үз теләкләре белән китәләрме?

Шәфи Алмасның юлдагы икеләнүләре лагерьга барып җиткәч, Идел-татар легионы командиры майор Оскар фон Зеккендорф белән сөйләшү вакытында тагын да көчәйде.

Фон Зеккендорф үз башыннан күпне кичергән, әле Беренче Бөтендөнья сугышында ук инде кырык яшьләрендә булган тәҗрибәле командир иде.

– Батальонның сугышка әзерлеге канәгатьләнерлек түгел, мөхтәрәм Шәфи әфәнде, – диде ул.

– Нишләп алай дисез?

– Легионерларның корал белән эш итә белүенә шигем юк. Кулларына мылтык тотып карамаганнар дип әйтеп булмый. Ләкин командирларның идея-сәяси әзерлеге ташка үлчим. Гитлер партиясенең җиңүе өчен атлыгып тормыйлар.

– Ә нигә, командирлар барысы да немецлар бит.

– Немецлар булуы начар да. Легионер солдатлар командирларның нәрсә әйткәнен аңламый, немец телен начар беләләр. Ә командирлар татарча белми. Менә бәла кайда! Тәрҗемәчеләр, нигездә, черек совет интеллигентлары. Бер дә ышанычлы кешеләр түгел. Әле җитмәсә әледән-әле солдатлар арасында листовкалар таратып торалар. Менә, кара әле, нәрсә язалар!

Фон Зеккендорф Шәфигә өстәл өстендә яткан кәгазьләр арасыннан бер бит алып бирде. Кәгазьне кулына алып, язуына күз төшерүгә, Шәфинең йөзе агарып китте.

«Ватандашлар! Кызыл Армия солдатлары! Фашистлар сезне, төрлечә алдап легионга язылырга мәҗбүр иттеләр. Кулларыгызга мылтык тотып, эти-әниләрегезгә, хатыннарыгызга, балаларыгызга каршы барырга кушалар. Коралларыгызны фашистларга каршы юнәлтегез! Фашистларның көне санаулы. Кызыл Армиянең Сталинград сугышындагы җиңүе сезне дошманга каршы изге көрәшкә рухландырсын! 4нче комитет».

Листовканы укып чыккач, ул, ни әйтергә дә белмичә, беркавым сүзсез торды. Әле генә кулындагы кәгазь кебек ап-ак булган шадра йөзе кызарып, бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты. Аннары исенә килеп, әйтеп куйды:

– Болай булгач, безнең комитетның эше барып чыкмаска мөмкин?

– Монда сезнең гаеп юк. Бөтен гаеп үзебездә. Гитлерның ярдәмчеләрендә, көрәштәшләрендә. Алар аңламыйлар ситуацияне. Алар китерәчәк илне һәлакәткә. Гитлер бик дөрес әйткән иде: «Большевикларга каршы сугышта немец булмаган бер генә солдат кулына да мылтык тоттырмаска!» – дип.

...Фон Зеккендорф яныннан Шәфи Алмас бөтендәй кәефсезләнеп чыкты. Аның артыннан ук ул Мусаны беренче батальон командиры майор Цек янына алып барды. Майорның, киресенчә, кәефе күтәренке иде. Фон Зеккендорфның шикләнүләре турында әйткәч, ул:

– Бездә гел шулай, җитмешнең аргы ягына чыккан маразматикларның җылы урыннарын яшьләргә бирәсе килми. Нәрсә сөйләмәс картлык маразмы белән чирләгән кеше, – дип, кычкырып көлде. – 70 яшь бит инде аңа! Күптән Инҗилне укып, өйдә генә утырырга, гонаһларын юар өчен көн дә чиркәүгә йөрергә тиешле мәлҗерәгән карт. Командирларыбыз барысы да ут-су кичкән. Витебск партизаннарына каршы үткәрелә торган «Kugelblitz» (Шарлы яшен) операциясендә катнашачак 825нче батальон. Операциягә генерал-майорлар Якоби белән фон Вартенберглар җитәкчелек итәчәк. Легионерлар яхшы коралланган. Танкка каршы ата торган өч пушкабыз бар, дистәләп пулемёт, кул пулемёты, һәр сугышчыда автомат, пистолет, башка сугыш кирәк-яраклары!

«Болар арасында да таркаулык икән, – дип уйлап куйды Муса майор Цекның легион командиры турындагы сүзләреннән соң. – Бер караганда, дөрес әйтә ул, сугыш картлар эше түгел. Өендә үзе шикелле үк мәлҗерәгән карчыгы ут йотып, карты өчен кайгырып ятадыр. Ә бу җүләр һаман ут эченә керергә ашкынып йөри. Гитлер идеяләре белән агуланган тиленең озак яшисе калмагандыр болай булгач, тагын, күп дигәндә, атна-ун көн». Муса үзе дә татар батальонының, һичшиксез, партизаннар ягына чыгасына, мылтыкларын дошманга каршы төбисенә чын күңеле белән ышана иде. Лагерьда күпме кеше белән сөйләшкәне булды, һәммәсе дә диярлек фашистларга нәфрәт белән карыйлар иде. «Эшләре генә барып чыксын да, фашистларны җиңеп, туган илгә исән-сау әйләнеп кайтырга насыйп булсын. Сталин җиңүдән соң үзенең «әсирлеккә төшкән солдат – халык дошманы» дигән сүзеннән, һичшиксез, ваз кичәр, ялгышуын аңлар, безнең гаскәрләр ягына чыккан легионерларны кичермичә калмас».

**6**

Беренче батальонны сугышка озату тантаналы шартларда узды. Едлинодан кәефе нык кырылып кайтканнан соң, ике көн буе сөмсере коелып, кара көеп йөргән Шәфи Алмасның да күңеле тынычланып калды. Озатуга Берлинның Альфред Розенберг министрлыгыннан дәрәҗәле кешеләр, министрлыкның махсус бүлек мөдире, профессор фон Менде әфәнде килгән иде. Шәфигә иң нык тәэсир иткәне Өченче рейх һәм нацистлар партиясенең иң зур эшлеклеләреннән берсе, СС рейхсфюреры Һенрих Гиммлерның төп киңәшчесе, СС гауптштурмфюреры Райнер Ольцшаның килүе һәм чыгыш ясавы булды. Ольцша Гитлерның сугыштан соң бернинди дә милли дәүләтләр булмаячак, дигән күрсәтмәсен яхшы белсә дә, легионерлар алдында икейөзлеләнеп, аларга: «Германиянең бөек җиңүеннән соң татарларның үз дәүләтләре төзеләчәк», диде. Шул җиңүне якынайту өчен сугышка барган легионерларга рәхмәт белдерде.

Гайнан Кормашның музыкаль капелласы концерты да Шәфи Алмасның күңеленә сары май булып ягылды.

Концертны Гайнан үзе алып барды. Гарәф Фәхретдинов белән Афзал Фәтхуллиннарның җырлавы болай да нечкә күңелле Шәфине тәмам җебетте. Алар башкарган «Су буйлап», «Шахта», «Уел» җырлары бәгырен айкап-айкап алгандай итте. Бигрәк тә туган авылы Солабашта гына җырлана торган «Өнсә» көе үзәген өзде.

Безнең авыл өсләрендә
Йолдыз яна яктырак.
Айга да йолдыз бик якын,
Син генә миннән ерак.

Егет чакларында җырлап йөргән җырлары иде бит ул. Шактый ук олыгаеп өйләнсә дә (нишлисең, заманы бик болгавыр, өйләнү, тормыш кору турында уйларга вакыт булдымы соң?), аның да кызларга күз атып йөргән яшь вакытлары бар иде.

Капелла оештыру идеясе дә Шәфинең үзеннән чыккан нәрсә булды. Афзал Фәтхуллинны легионерлар белән очрашуларга барганда үзе белән ияртеп җырлатып йөреп, шундый уйга килгән иде ул. Гайнан Шәфинең музыкаль капелла оештырырга теләве турында ишетеп, бу хакта Муса белән киңәшләшергә булды. Ул исә бу эшне Кормашка үз кулына алырга киңәш бирде. Концертлар куеп йөреп, әсирләр белән якыннанрак аралашу мөмкинлеге барлыгын әйтте. Ә Гайнан Демблин лагерендагы һәр татар әсире белән яхшы таныш, кемнең нәрсәгә сәләтле икәнен әйбәт белә. Ул үзе дә студент елларында, мәктәптә эшләгәндә, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша иде. Абдулла Баттал да бер дигән конферансье, теле телгә йокмый торган юмор остасы. Яттан әллә никадәр шигырь белә. Зиннәт тә көчле ягымлы тавышка ия, бер дигән җырчы. Шулар өстенә нәфис сүз остасы да. Шигырьләрне йөрәккә үткәзерлек итеп сөйли. Гайнан әсирләр арасыннан махсус музыкаль белеме булмаса да, бер дигән итеп гармунда, скрипкада, мадолинада уйный торган осталар тапты. Гариф Маликов, Иван Скоболев, Гали Корбанов, Фәрит Солтанбәков, Фәрит Сәйфелмөлеков – барысы да музыкантлар, җырчылар булып киттеләр. Сугышка кадәр Башкортстан опера театрында эшләгән Гарәф Фәхретдинов белән Одессада опера җырчысына укып йөргән Барый Кәримов исә Гайнанның уң кулы, иң якын ярдәмчеләре. Барый Кәримов – яһүд егете. Чын исем-фамилиясе – Борис Крамов. Легионга язылганда, медицина тикшерүе үткәндә, сөннәтләнгән булуын күргәч, аның татарлыгына шикләнмәделәр. Гайнаннар белән капут-командада йөргәндә, беркадәр татар сүзләрен дә өйрәнгән иде. Тора-бара татар җырларын да өйрәнеп алды, вокал осталыгы турында инде әйткән дә юк. Кыскасы, бер дигән хор-музыка капелласы тупланды. Шәфи Алмас кына түгел, туган җирләрен сагынып яшәүче күпләгән әсирләрнең нечкә күңелләреннән балавыз сыктыра торган концертларны әсирләр көтеп ала торган булдылар. Капелла татарлар гына түгел, башка милләт батальоннары алдында да чыгышлар ясый башлады. Бу, бердән, Шәфинең абруен күтәрсә, икенчедән, татар егетләренә карата ихтирамны үстерде. Бигрәк тә үзбәкләр, казакълар, азәрбайҗаннар, әрмәннәр, балкарлар арасында дуслары күбәйде. Концертлар вакытында бу милләт егетләре дә сикереп чыгып, үз җырларын, биюләрен башкара торган булып киттеләр. Татарларның дәрәҗәсе үсте.

Беренче татар батальонын фронтка озату тантанасына Вустраудан легионерларга Гитлернең «Майн кампф», Гаяз Исхакыйның «Идел-Урал» китаплары буенча лекцияләр укучы һәм ислам нигезләрен өйрәтүче Галимҗан хәзрәт Идриси дә килгән иде. Вустрауда чакта да, Шәфи Алмас өендә кунакта чакта да Мусага Галимҗан хәзрәт белән артык ачылып китеп сөйләшеп утырырга туры килмәгән иде. Батальон солдатларына хәерле юл теләп, вәгазь сөйләп, Коръәннән «Фатиха» сүрәсен укыганнан соң бушап калган хәзрәт, үзе

Муса янына килеп, аның белән әңгәмәләшеп алырга ният итте. Муса хәзрәт турында әллә ни хәбәрдар булмаса да, Галимҗан Идриси Муса турында шактый ук ишеткән кеше иде. Ул, гомумән, эмиграциядә совет илендә калган газиз туган җирләре, андагы тормыш, кешеләр турында һәрдаим кызыксынып яшәде, гәзит-журналлар алдыра иде. Гаяз Исхакый чыгарган «Милли юл» гәзитенең, «Милли байрак» журналының өтеренә кадәр карап, укып барды. Алар ябылганнан соң да Төркиядән татар тормышына багланышлы төрле басмалар, китаплар кайтартып, җентекләп танышып бара торган булды.

– Киттеләр. Исән-имин генә барып җитсеннәр дә җиңүгә үз өлешләрен кертсеннәр инде, газиз милләттәшләр, – диде Галимҗан хәзрәт, Муса янына килеп баскач.

– Хәзрәт, менә сез тәкъва кеше. Үз ватанына каршы сугышка киткән бу кешеләргә, юлыгыз уң булсын, дип, фатиха бирдегез. Үзегезне Аллаһы Тәгалә каршында гөнаһ кылдым дип исәпләмисезме?

– Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла. Ниткән гөнаһ булсын?! Үз ватаннарын һәртөрле шайтаннардан азат итәр өчен изге юлга иңдерелгән бәндәләргә фатиха бирүнең нинди гөнаһысы булсын?! Һич кенә дә алай дип исәпләмим.

– Әгәр дә алар бу эшкә ихтыяри бармаган булсалар? Әгәр дә алар, чикне узганнан соң, коралларын үзләрен шушы эшкә мәҗбүр итүчеләргә каршы борсалар?

– Бер кешене үз ихтыярына каршы барырга мәҗбүр итәргә мөмкин, ике, өч кешене. Монда бит олы бер гаскәр турында сүз бара.

– Олы бер гаскәр генә түгел, олы бер илне ялгыш юлга кертеп җибәргән шайтан вәсвәсәсе нәтиҗәсе бу, дип уйламыйсызмы, хәзрәт?

– Ягъни мәсәлән?

– Ягъни мәсәлән – алман халкын, без башкаларга караганда өстен милләт, шуңа башка милләтләр өстеннән идарә итәргә тиешбез, дип өйрәтә торган тәгълимат тудыручылар фәлсәфәсе.

– Ә соң большевиклар шундый ук тәгълиматны алга сөрүчеләр түгелме?

– Ләкин бит СССРда бер урыс кына түгел, йөзләрчә милләт үзара дус гаиләдә, тыныч, матур тормыш корып яшәп ята иде.

– Татарлар дамы?

– Татарлар да. Үзләренең Татарстан дигән автономияле Совет Социалистик Республикасында.

– Татарлар бер Татарстанда гына яшәми бит, тәкъсир. Социалистик инкыйлабка кадәр Рәсәйдә унбиш миллион татар бар иде. Ә Татарстан дигән республикада ничә милләттәшебез яши дип беләбез? Ике миллион. Унбиш миллион татар яшәгән Рәсәйне унбиш республикага бүлеп, татарларның санын бер киметтеләр. Шул унбиш республикада төп милләтләргә генә өстенлек биреп, мәдәнияте, әдәбияты, сәнгате, сәнәгате ул республикалардагы төп милләт булган халыкларныкыннан бер баскычка югарырак торган татарны икенче сортлы итеп калдырып, икенче кимсеттеләр. Гаяз әфәнде Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дигән әсәрен укыганыгыз бармы?

– Юк.

– Юктыр шул. Укырга иде. Башка милләттәшләргә дә укытырга иде.

– Алай дисәң, хәзрәт, ике йөз елда татар гына түгел, урысың да, алманың да, Тукай әйтмешли, җир йөзендә бер дә яшәмәгән кебек юкка чыгып бетәргә мөмкин дип уйламыйсызмы?

– Уйламыйм. Ә менә татар бетәчәк, болай барса. Ул СССРда милли кысу

гына түгел, гомумән, кешенең шәхесен кысу бара, диләр. Сездә бит хәерчелек, ә хәерче булып яшәү өстен күрелә. Эшләгән кешене сыйнфый дошман итеп саныйлар. Эшләгән кеше, һичшиксез, байый. Ә бай кеше – дошман. Шулмы дөреслек? Шулмы гаделлек? Кем хәерче? Ялкау – хәерче. Ялкаулыкка юл куелган илдә беркайчан да рәхәт, матур тормыш төзеп булмаячак. Хакимият башында ялагайлар, яла ягучылар, тәлинкә тотучылар, демагоглар утырганда, һәрвакыт дошман табылып торачак. Кеше гомер бакый изелүдә яшәячәк. Йә, әйтсәгезче, әфәндем, мин дөрес сөйләмимме?

– Сез мине тупикка куясыз, Галимҗан хәзрәт. Ләкин бит ватан дигән нәрсә хакимият башында кем утырганга карап ватан булудан туктамый. Ватан ул – туган җир, ата-бабаң, нәсел-нәсәбең, балаң, йортың. Гомер бакый шулай булган, илдә бер хакимиятне икенчесе алыштырган. Хакимнәр килгән, киткән. Аларның кеше хокукларына мөнәсәбәте үзгәреп торган. Аңа карап ватан ватан булудан туктамаган. Һәр кеше җиргә бер генә мәртәбә туа, бер генә тапкыр яшәргә килә. Туган икән, кешенең яшәргә хокукы бар. Шул хокукны юк итәргә теләүчеләргә каршы көрәшергә дә хокукы бар.

– Менә шул шул. Үзегезгә үзегез каршы киләсез, Муса әфәнде. Ни өчен әле мин бай, рәхәт матур тормышта яшәргә теләгән өчен генә илдә дошман булып саналырга тиеш?

– Ватанын саклап көрәшергә дә хокукы бар кешенең. Бу очракта без үз ватаныбызны саклап көрәшәбез, Галимҗан хәзрәт. Ә ватаныбызда нинди хакимият урнаштыру – анысы безнең эчке эшебез. Бер илнең дә, бер халыкның да ул эшкә тыгылырга хакы юк. Алманнарның да.

– Анысы шулай.

– Шулай булгач, нигә дип шушы сугышны алып баручыларны хуплап, аларга хезмәт итәргә алындыгыз?

– Мин үзебезне алманнарга хезмәт итәбез, дип санамыйм, Муса әфәнде. Без бары тик форсаттан файдаланып калырга гына уйладык. Гитлерны сугышка без котыртмадык, без өндәмәдек. Аның җиңүеннән файдаланып, большевиклар изүе астында калган милләтебезне азат итәргә, күп гасырлар буе үз дәүләтчелеге булган халкыбызның кабаттан мөстәкыйль дәүләтен төзергә, дигән ният белән генә шушы эшкә алындык.

– Ә сез Гитлер СССРны җиңгәннән соң, анда яшәүче йөзләгән милләтләрнең һәрберсенә үз мөстәкыйль дәүләтләрен төзергә юл куяр, дип уйлап ялгышмыйсызмы соң?

– Бәлки, ялгышабыздыр да.

– Һичшиксез ялгышасыз. Андый хәлнең әле моңа кадәр тарихта булганы юк. Татарлар өчен генә шундый нәрсәгә юл куелыр дип уйласагыз, бу – татарларны үзләрен барлык милләтләрдән дә өстенлеккә чыгу өчен фашистик юлга баскан алманнар белән тиңләү булыр иде.

– Сез Ходайга ышанасызмы, Муса әфәнде?

– Ходайның монда ни катышы бар? Ышанаммы, ышанмыйммы, анысы һәркемнең үз эше. Аны, әйе, мин ышанам, дип кычкырып йөрмиләр, дип беләм.

– Юк, мин сезне гаепләргә җыенмыйм. Ялгыш уйлый күрмәгез. Сез, һичшиксез, коммунисттыр. Шул ук вакытта коммунистлар – алласызлар дигән нәрсәне дә беләм. Ләкин, сезнең белән бу сөйләшүдән соң, күңелдә Аллага ышанасыздыр дигән тәэсир кала. Мантыйгыгыз дөрес. Сез мине дә үз мантыйгыгызга ышандырдыгыз.

Хәзрәт белән сөйләшү шушы урында өзелде. Алар янына Шәфи Алмас

килеп басты. Аның әле бая гына балкып торган, бүгенге тамашадан канәгать шат чырае караңгыланган иде.

– Ни булды, Шәфи әфәнде? Йөзегез борчулы? – дип сорады аннан Галимҗан хәзрәт.

– Бәйрәмнең ямен җибәрделәр. Халык арасында листовка таратканнар. Шундый көндә бит. Шундый көндә...

**7**

Февраль аенда Едлино лагеренда урнашкан батальоннарны фронтка озату эшен ашыктыра башладылар. Белоруссия партизаннарына каршы оештырылачак «Шарлы яшен» операциясе уңышлы барып чыккан очракта, икенче батальонны да февраль аенда ук партизаннарга каршы яңа операциягә җибәрергә, дигән күрсәтмә булды. Шуңа да Мусалар яшерен оешманың эшчәнлеген кичекмәстән активлаштырырга кирәк, дигән фикергә килделәр. Чөнки беренче батальон легиончылары белән эшләүгә күбрәк игътибар биреп, икенчесе белән беркадәр сүлпәнрәк эш алып барылган иде. Солдатларның күңелен күтәрү өчен, иртәгә үк музыкаль капелланың концертын оештырырга кирәк дип тә фикерләштеләр. Концерт вакытында таратырга бүгеннән үк листовка әзерләргә кирәк иде. Моның өчен фронттагы хәлләр турында дөрес мәгълүмат табу мөһим. Муса, Шәфи Алмас янына кереп, «Идел-Урал» гәзитенә мәгълүматлар табу өчен берәр китапханәгә барып, соңгы көннәрдәге матбугат басмалары белән танышырга уйлады.

– Шәфи әфәнде, гәзитнең соңгы саннары белән танышып чыккач, оператив мәгълүматларның аз булуы күзгә ташланды. Легионерлар немец гаскәрләренең соңгы айлардагы уңышлары хакында бөтенләй дә белмиләр диярлек. Алар арасында таратылган листовкаларда, киресенчә, алман армиясенең уңышсызлыклары турында гына сөйләнә. Шуңа күрә берәр китапханәгә барып утырып, гәзит тупланмаларын караштырырга иде.

– Әйбәт идея! – диде Шәфи. – Урыс әсирләре өчен «Заря» дигән гәзит чыгарыла. Менә шул гәзит редакциясенең бик бай китапханәсе бар. Алла үзе биргән хәзинә безнең өчен. Гәзитнең редакторы Зыков дигән кеше. Шуннан рөхсәт алып, китапханәдә бераз утырсаң, «Идел-Урал» өчен бер дигән мәкаләләр язарга мөмкин.

– Кайда урнашкан соң ул редакция? Мин сорап кына рөхсәт бирерме ул Зыков?

– Мин сиңа үтенеч язуы сырлап бирермен. Редакция Викторияштрассе, 10 адресы буенча урнашкан. Китапханәсе дә шул йортның подвалында ук. Хәзер, шофёрга әйтермен, илтеп куяр.

Зыков язып биргән рөхсәт кәгазен тотып, «Заря» гәзите китапханәсенә барып кергәч, Муса анда идәндә тау-тау өелеп яткан китаплар, гәзит-журнал тупланмалары арасында утыручы бер унтерофицерны күрде. «Урыс китапларына күмелгән бу майор берничек тә немец булырга тиеш түгел», – дип уйлап куйды ул, һәм аның кергәнен сизмәгән офицерга:

– Бу биләмәләрнең патшасы сез буласызмы? – дип мөрәҗәгать итте.

Хәрби сискәнеп куйды һәм, хәрбиләрчә кыска итеп:

– Мин! – диде. – Ә сезгә нәрсә кирәк?

– Мине дә шушы хәзинәләрнең эчтәлеге кызыксындыра иде.

– Начальство рөхсәтеннән башка аларны беркемгә дә бирергә ярамый.

– Миңа рөхсәт иттеләр, – диде Муса һәм кесәсеннән Зыков язып биргән кәгазьне чыгарып күрсәтте.

– Ул чакта, рәхим итегез. Сезне нәрсә кызыксындыра?

– Нишләп шулкадәрле кыйммәтле бу хәзинә шулай аяк астында аунап ята? Китапка карата мондый мөнәсәбәтне беренче тапкыр күрәм.

– Бу мәсьәлә буенча миңа дәгъва белдерү дөрес булмас.

Муса идәндә яткан китапларның берсен кулына алып, ачып карады. Аңа Минск шәһәре үзәк китапханәсе мөһере сугылган иде.

– Кемгә кирәк соң хәзер бу байлык? Күп тә үтмәс, самолётлар килеп, бомба ташлап китәрләр дә бөтенләй юкка чыгарырлар. Ә сез дәгъва белдерәсез. Үзегезгә кирәкләрен сайлагыз да алып китегез. Иң яхшысы шул булыр.

– Китаплар беркемгә дә бирелми. Шушында утырып кына танышырга, диделәр бит.

– Димәсәләр тагын. Монда нәрсә барын каян белсен ул немецлар. Менә миңа аунап яткан бу гәзитләрне тупланмаларга тегәргә куштылар. Һәр гәзит унбишәр данә. Бары тик бер данәсен тегеп, калганнарын яндырырга. Менә, кара, үзеңә кирәкләрен сайлап ал. Мин беркемгә дә әйтмәм.

Муса гәзитләрне күреп исе китте: «Правда», «Известия», «Комсомольская правда», «Красная звезда»... Ниләр генә юк! Аңа хәтта туган илгә кайтып, үз китапханәбезгә кереп утыргандай тоелып китте. Ул, ашыга-ашыга, үзе өчен гәзитләрне аерырга кереште. Аларның иң соңгы саннары моннан ике атна чамасы элек кенә чыккан, чагыштырмача өр-яңа саннар иде. Никадәрле байлык, мөһим мәгълүмат ласа!

– Карале, без бит танышмадык та. Сезне кем дип белергә соң? – диде Муса китапханә хуҗасына.

– Мин – Рус Азатлык армиясе штабының пропаганда бүлеге башлыгы, майор Рыбальченко. Исемем – Андрей.

– Рус армиясе солдаты, үзегез фриц формасында.

– Нишлисең, Кызыл Армия солдаты формасында йөреп булмый.

Рыбальченко асылда рус коммунист әсирләре оештырган яшерен оешманың пропагандисты иде. Аны Власов оештырган Азатлык армиясендә таркату эшләре алып бару өчен армия штабының пропаганда бүлегенә эшкә урнаштырганнар иде. Ләкин ул бу хакта Мусага белдерергә ашыкмады. Муса да үзен «Татар легионы пропагандисты» дип таныштырды. Рыбальченконың күңелендә коммунистик басмалар белән кызыксынган Мусага карата «татарлар оештырган яшерен оешма кешесе түгел микән» дигән шик туды тууын, ләкин ул да бу хакта шиген белдермәде.

– Исемең белән кем дип дәшәргә инде сиңа?

– Муса Гумеров. Ярый, мин китим әле. Ашыгыч эшләрем бар. Иртәгә тагын килермен, – дип, Муса китапханәдән чыгарга ашыкты.

– Әлбәттә. Килегез, нәрсә кирәк, ярдәм итәрмен, – диде Рыбальченко.

Муса, беркадәр, ниндидер парк буенча барды. Парк аллеясе аны Берлинның үзәгендә үк диярлек урнашкан Азатлык статуясы янына китерде. Ул Шәфи Алмас йортына барган чакта бу статуяны күргән иде. Димәк, Шәфинең йорты моннан ерак булырга тиеш түгел. Ул, чынлап та, беркадәр баргач, Хафельштрассе урамына килеп чыкты. Өйгә кайткач, Муса чәй эчте дә алып кайткан гәзитләрен өйрәнергә кереште. Листовка өчен бер дигән материал иде гәзитләрдә. Кәгазь-каләм алып, мәгълүматларны тематикасына карап төрле бүлекләргә таратты. Аннары бер исем астына туплап, кыска гына, машинкада җыйганда төп-төгәл бер битлек булырлык язма әзерләде. Симаев эштән кайтып киткәнче, аның янына барып өлгерергә кирәк иде.

Муса Әхмәтнең эш сәгате бетәргә санаулы минутлар калганда гына аның белән күрешә алды.

– Бер бит чамасы татарча текст бастырасы бар. Татар шрифтлы машинка табыйк, – диде ул аңа.

– Халыкның эштән кайтып киткәнен көтәргә кирәк. Машинка тәрҗемәче бүлмәсендә. Ул ишеген бикләп китә. Коридорда халык йөрми башлагач кына ачкыч ятатып ачып керербез. Кая, бир текстыңны. Монда көтеп утырма вакыт үткәреп. Мин әзерләп куярмын. Ничә данә кирәк булачак?

– Икенче батальон өчен. Анда да шул дүрт рота чамасы булыр. Матрицаларга салып, тиражын да әзерләсәң, иртәгә музвзвод аша биреп җибәрер идек. Гайнан егетләре концерт белән барачак.

Муса Рыбальченко янына икенче көнне дә барды. Алар күчләрдә нинди китаплар барын озак кына тикшерделәр, авторлары буенча каталоглар ясап, киштәләргә урнаштырдылар.

– Син күбрәк сәяси китаплар карыйсың. Политрук идеңме әллә? – диде Рыбальченко, Мусаның Ленин томнарын актарып утыруын күреп.

– Шулайрак. Ә син үзең?

– Кем булыйм инде тагын.

– Димәк, икебез дә бер эш белән шөгыльләнәбез?

– Власовның Азатлык армиясендә яшерен оешма бар, дип сөйлиләр. Чын сүз, димәк?

– Утсыз төтен чыкмый. Безгә бергә эшләргә иде. Сине дә татар легионының яшерен оешмасы кешесе дип уйларга кирәк.

– Дөрес гөманлыйсыз.

– Менә бу листовкаларны ал әле. Үзегезнекеләргә таратырсыз, – дип, Рыбальченко, өстәл тартмасыннан алып, Мусага бер төргәк тоттырды.

– Сезнең оешма кайда урнашкан соң? Җитәкчеләрегез белән очрашып буламы?

– Нигә җитәкчеләр? Мин булгач җиткән инде.

– Мәскәү белән элемтәләрегез бармы соң?

– Әлегә юк. Ләкин кайбер чаралар күрелә. Киләчәктә урнаштыра алырбыз, дип өметләнәбез.

– Бүгеннән безнең «Идел-Урал» легионы белән Рус Азатлык армиясе яшерен оешмалары арасында элемтә урнаштырылды, дип исәпләргә була, димәк?

– Була. Ләкин безгә сак эш итәргә иде. Монда еш күренүең синең өчен куркыныч тудыра. «Заря» гәзите немецларның даими күзәтүе астында чыгарыла. Китапханәдә аеруча мөһим очракларда гына очрашырга кирәк. Без Потсдаммерплац, Фридрихштрассе метро станцияләрендә очраша алабыз.

– Яхшы.

Муса, чынлап та, башка көннәрдә Андрей Рыбальченко белән ул әйткән метро станцияләрендә очраша торган булып китте. Ул аңа рус телендә үзләре чыгарган листовкаларны алып килде. Муса аларны, татарчага тәрҗемә итеп, Симаевка илтә барды. Ләкин көннәрнең берендә Рыбальченконы китапханәдә эшләүдән читләштерделәр. Власов армиясе генералларының шымчылары нәрсәдер сизенделәр булса кирәк. Җитмәсә, кемнәрдер аның сугышта политрук булганын җиткергән иде. Андрейны штабта утырудан бөтенләй азат итеп, резервтагы ротага күчерделәр. Ул, моннан соң ике оешма арасындагы элемтәләрне дәвам иттерү өчен, Мусаны «Заря» гәзитендә эшләүче Виктор Харчёв исемле хезмәткәр белән таныштырды. Анысы да яшерен оешма әгъзасы икән.

Февраль ахырларында Белоруссия партизаннарына каршы сугышка китәргә тиешле икенче татар батальонын Франциягә җибәрергә җыенулары хакында хәбәр таралды. Яшерен оешма алып барган пропаганда нәтиҗәсендә, фронтка барып җитүгә, командирларны юк итеп, Кызыл Армия яки партизаннар ягына чыгарга ниятләп йөргән легионерларның кәефләрен нык кырды бу хәбәр. Ничек инде, дөньяның бөтенләй башка ягына, каядыр Франция чикләренә барып чык та, Советлар Союзы шикелле үк, фашистлар белән көрәшеп ятучы бер гаепсез француз солдатларына каршы сугышка кер, имеш. Ә саташкан пуля килеп эләгеп, бөтенләй чит-ят җирдә мәңгегә ятып калсаң нишләрсең? Кем белер синең кабереңне? Кем белер кадереңне, дигән шикелле. Бөтенләй мәгънәсез үлем көтә булып чыга түгелме?

Яшерен оешма алдында яңа мәсьәлә килеп туды – легионерлар арасында агитация эшләренең эчтәлеген үзгәртү. Ул арада батальонны Голландиягә җибәрәчәкләр икән, дигән сүзләр дә йөри башлады. Муса, егетләр белән яшерен сөйләшү өчен, комитетта эшләүчеләргә Берлин зоопаркына культпоход оештырырга, дигән нәрсә уйлап тапты.

Ниятен әйтергә дип, ул Шәфи Алмас эш бүлмәсенең ишеген шакыды. Кабул итү бүлмәсендә утыручы Сабит Кунафин, Мусаны күрүгә, аңа каршы чыкты.

– Муса абый, сезгә Семпен пансионатына юллама язылган килеш ята. Менә, Шәфи абзыйдан кул куйдырып алып чыгыгыз әле, – диде Сабит.

– Шулаймыни? Мин оныткан да идем инде ул хакта. Рәхмәт, әйбәт булган, – дип, Муса Сабиттан юллама кәгазен алды да ишек тоткасына үрелде.

Шәфи Алмас бүлмә түрендәге озын өстәленең урта бер турысына куелган күн терәкле урындыгына чумып, хәсрәтле кеше кебек тирән уйга батып утыра иде.

– Ә-ә, әйдә, Муса әфәнде, түрдән уз, – диде ул һәм үзенә каршы яктагы урындыкка утырырга ым какты.

– Кәефегез юк чакка туры килдем, ахры, Шәфи әфәнде?

– Кәефне кырып кына торалар бу Кызыл Армия солдатлары.

– Тагын нинди җиңү яулаганнар инде, рәхмәт яугырлары.

– Беренче батальон партизаннар ягына чыккан.

Шәфи Алмасның хәбәре Муса өчен алтын кош тоткан кебек тәэсир итте.

– Чынмы? – диде ул, сөенечен яшермичә.

– Күрәм, сез дә кош булып очып китәргә җыенасыз бугай, Муса әфәнде.

– Яшермим, Шәфи әфәнде, шул батальон солдаты булсам, үземне бик бәхетле санар идем. Ә болай, нәрсәсенә сөеним инде? Шулай да кызыксындыра: чынлап та шундый хәлме?

– Бөтен алман командирларын үтереп бетереп, пушкаларын, пулемётларын, автоматларын үзләре белән алып, биш йөз дә илле җиде солдат партизаннар ягына чыккан. Калганнарының яртысы һәлак булган, яртысы безнең якта калган. Аларын алманнар, кире алып кайтып, лагерьларга озатканнар. Җитмешләп легионер ди бугай.

– Кайчан булган соң әле бу хәл?

– Егерме сигезенче февраль көнне булган, ди.

– Нәрсә дип әйтим инде, Шәфи әфәнде? Майор фон Зеккендорфның легионерлар белән сәяси тәрбия эше начар алып барыла, дигән сүзләренең шаһиты үзегез бит.

– Шулай дигән иде дә. Ә менә аның сүзләреннән көлгән батальон командиры майор Цек легионерлар белән сугышта үлгән, ди. Урыны

җәннәттә булсын, мәрхүмкәйнең. Нинди эш белән йөрисез соң әле болай, Муса әфәнде?

– Бу хәбәрдән соң әйтергә дә уңайсызланып торам инде, Шәфи әфәнде. Беренчесе, менә бу юлламага кул куйдырырга дип кергән идем. – Муса шулай диде дә Сабит Кунафин биргән кәгазьне аның өстәленә салды.

Шәфи язуны укып чыкты да, каләмен алып, кәгазьнең өске почмагына карарын сырлап, имзасын куйды.

– Үзем тәкъдим иткән идем, рәхәтләнеп ял итеп, тәнегезгә ит кундырып кайтыгыз. Югыйсә сезнең кебек кешене болай йөртү бер дә килешә торган эш түгел. Сугыш сугыш инде ул. Анда үләләр дә... Ә икенче йомышыгыз нидә?

– Икенчесе, комитет егетләре белән Берлин зоопаркына сәяхәт ясап кайтсак, дигән идек.

– Бусы да начар эш түгел. Гел эш тә эш булмый, андый ял да кирәк. Бик бай зоопарк! Карап кайтыгыз. Рөхсәт, Муса әфәнде. Икенче көнне икеләтә егәр белән эшкә керешерсез.

– Рәхмәт сезгә, Шәфи әфәнде. Үзегез дә коллектив белән культпоход ясап кайтсагыз, дисәм инде...

– Рәхмәт, Муса туганкай. Мин ул зоопаркта берничә кат булганым бар. Бик әйбәт зоопарк. Үзегез генә йөреп кайтыгыз әле.

Зоопарк, чыннан да, бик әйбәт, бик бай иде. Сугыш заманы димәссең, читлекләр чиста, каралган. Хайваннарның, җәнлекләрнең ризыклары алларында, тамаклары тук икәне күренеп тора. Әсирләргә караганда, күп тапкырлар әйбәтрәк шартларда яшиләр кебек. Җәнлекләрнең күплеге һәм төрлелеге дә күзгә ташланып тора. Ләкин Мусаны, хайваннар карап йөрүдән бигрәк, оешма әгъзалары белән сөйләшү кызыксындырды. Культпоходта татар арадашчылыгының барлык хезмәткәрләре дә диярлек катнашканлыктан, ул кирәкле кешеләр белән аерым-аерым, башкаларга сиздермичә генә сөйләшергә тырышты.

Алар төркем-төркем булып та, аерым гына да, төрле аллеялар буйлап таралышканнар иде. Муса башта ялгызы гына бүреләр читлеге янәшәсендә басып торган Алиш янына килде. Алиш читлек өстенә беркетелгән рамкадагы немец телендә язылган белешмәне укый иде. «Бүре – этләр семьялыгына карый торган ерткыч, имезүче җәнлек, йорт этләренең борынгы бабасы булып тора. Бу семьялыктагы иң эре гәүдәле ерткыч: гәүдәсенең озынлыгы 160 см, койрык озынлыгы 52 см, биеклеге 90 смга, авырлыгы 80 кгга җитә...»

– Татарларның милли символы булып тора, дип тә язмаганнармы? – диде Муса, Алишны укуыннан аерып.

– Мифологияләр белән бәйле нindidер сүзләр бар бугай, катлаулы итеп, фәнни телдә язганнар. Аңларга авыррак, озак укыла, – диде Алиш.

– Шатлыклы бер хәбәр бар! – диде Муса, Алишның үзенә генә ишетелерлек итеп пышылдап.

– Нинди?

– Беренче батальон партизаннар ягына чыккан.

– Кит аннан! Каян белдең?

– Шәфи Алмастан. Тәмам төсен җуйган мескен, кара янып, кулларын салындырып, бүлмәсендә утыра. Икенче батальонны Франциягә җибәрергә теләүләренең сәбәбе шул икән. Аптыраган идем аны.

– Саграк эш итәргә кирәк болай булгач, шикләнеп, эзәрлекләүләр башланырга мөмкин.

– Анысы да бар. Кичекмәстән икенче батальон солдатлары арасында пропаганда эшләренең эчтәлеген үзгәртергә кирәк. Листовкаларның эчтәлеген үзгәртергә. Кая гына җибәрсәләр дә, шул ил партизаннары ягына чыгарга үгетләргә. Фашистларга каршы көрәш беркайчан да тукталмаска тиеш. Аннары Германия заводларында эшләүче гастарбайтерлар арасында эшне активлаштырырга. Искәндәр Яушев заводында эшләүчеләр белән элемтәгә керергә, завод чыгара торган продукциягә зыян китерә торган эшләрне киң җәелдерү турында сөйләшергә. Мин хәзер Симаев белән сөйләшермен. Бүген үк листовка бастырып алырга кирәк. Листовкаларны биреп, Батталны иртәгә Познаньга җибәрергә. Син гәзит өчен бирәр материал әзерләсәң дә начар булмас иде. Баттал янына барып, шул хакта сөйләш әле. Ул әнә аюлар читлеге янында йөри бугай. Аннан соң Зиннәт белән киңәшләшерсең. Мин – Фоат белән. Бер-беребез белән ике тапкыр очрашмыйбыз. Монда Шәфинең шымчылары иснәнеп йөри. Сак булырга кирәк. Иртәгә кем нәрсә эшләргә тиешлеген исендә калдырсын һәм, һичшиксез, эшләсеннәр. Мин иртәгә Семпен пансионатына китәм. Бер атна чамасы, сәламәтлекне ныгытып алырга кирәк. Югыйсә чынлап та какшады. Бер чирләшкәгә әйләнеп барам.

– Барып кайт шул. Без монда үзебез оештырырбыз барысын да.

– Тагын бер нәрсәне онытканмын. Зоопарктан чыккач, кешегә бик сиздермичә генә минем янга килерсең. Әхмәт һәм сине бер кеше белән таныштырырга иде.

Алар шунда аерылыштылар: Муса Әхмәт Симаевны эзләп китте, ә Алиш аюлар читлеге ягына таба атлады. Симаевны эзләп барганда, аңа маймыллар читлеге янында Рушат Хисаметдинов очрады.

– Бабаларыңны таныдыңмы әллә? – дип шаяртты Муса.

– Үзем дә аптырап карап тора идем менә. Чынлап та, дөрес микән ул Дарвин бабайның теориясе? Дөрес булса, койрыгыбыз кая киткән соң?

– Нәрсәсенә аптырыйсың аның, койрык болгап йөрүчеләр кешеләр арасында да җитәрлек. Әнә, берсе килә, – дип, Муса аларга таба якынаючы Рәис Саматны күрсәтте.

Рәис, Мусаның үзенә игътибар иткәнен сизенде булса кирәк, маймыллар читлегенә җитәрәк туктап калды, күз кыры белән генә аларга карап, ниндидер җәнлекне күзәтә башлаган кыяфәт чыгарды.

– Туктады, ә локаторы безне тыңлый, – диде Рушат.

– Күрмәмешкә салышып, маймылларны күзәтүеңне дәвам ит, – диде Муса, пышылдап. Үзе юри, тавышын күтәреп, концерт программасы турында сөйли башлады: – Мин иртәгә ял йортына китәм. Син алдагы концертта халык җырларына күбрәк басым ясa әле. Афзал да, Гарәф тә, Барый Кәримов та халык җырларын башкарсыннар. Солдатлар халык көйләрен яратыбрак кабул итә.

Рушат та, Рәискә яхшырак ишетелсен өчен, кычкырыбрак сөйләшә башлады.

– Үзем дә шундыйрак фикердә торам.

Рәис, боларның сөйләшүендә Шәфи Алмас өчен кыйммәтле мәгълүмат юк бугай, дип, башка төркемнәр ягына юнәлде.

– Рушат, сине күптән карап йөрим, ышанычлы егет дигән нәтиҗәгә килдем. Гайнан да ышана үзеңә. Сизенәсеңдер инде безнең яшерен оешма турында. Кушкан эшләрне дә төгәл үтәп барасың. Рәхмәт. Яшерен оешма чынлап та бар. Сине шуның әгъзасы итеп алырга булдык. Гайнан бик яхшы рекомендация бирде.

– Мин әлегә хәтле дә үземне яшерен оешма әгъзасы дип уйлап йөридер идем. Менә сиңа мә! Юкәдә икән чикләвек!

– Алла сакланганны саклармын, дигән. Шуңа күрә моңа кадәр белдермичәрәк йөрдек. Үзең әйтмешли, болай да бер эшне башкардык. Оешманың җитәкче органы бар. Без аны «Дүртенче комитет» дип атадык. Комитетта кемнәр барын бөтен кеше дә белергә тиеш түгел. Шуңа күрә үпкәләмә. Сиңа заданиеләрне Гайнан биреп барыр. Моннан ары кем генә эш кушса да, Гайнан белән киңәшмичә тотынма. Тагын бер нәрсә бар: яшерен оешмага керүчеләрне «Изге ант» бирдереп алабыз. Риза булсаң, тыңла һәм кабатла.

– Риза, әлбәттә.

– Алайса тыңла: «Изге ант. Мин, Рушат Хисаметдинов... Кабатла.

– Изге ант. Мин, Рушат Хисаметдинов...

Муса Рушатка «Изге ант»ны шулай җөмләләп үз артыннан кабатлатып чыкты. Аннары кесәсеннән пәке чыгарып, аның сул кулының учын кисеп җибәрде дә кан тамчыларын ялатты. Аннары үзе ялап алды.

– Менә, чын хәрбиләрчә изге ант булды бу, – диде.

Муса аннары Рушатка да беренче батальон турындагы шатлыклы хәбәрне әйтте.

– Бу хакта имеш-мимеш кенә дигән булып, легионерлар арасында да хәбәр таратырга кирәк. Иң яхшысы – листовка язып тарату. Бу эшне Симаев белән Алишка әйттем. Демблинга алып кайтып тарату сезнең өстә. Гайнан белән киңәшегез, – диде ул.

Зоопаркта ике сәгатьләр чамасы йөргәч, алар кайтырга булдылар. Арадашчылык хезмәткәрләре хайваннарны карап йөрүдән алган тәэсирләре белән уртаклаша-уртаклаша, капкага таба атладылар. Капка янында бер хатын, бәләкәйрәк кенә суыткыч-тумба куеп, туңдырма сатып тора иде. Муса, башкалардан арттарак калу өчен, Алиш белән Симаевка туңдырма сатып алырга тәкъдим итте дә, үзе кесәсеннән акча чыгарып, өч пломбир сорады.

Муса егетләрне «Заря» гәзите китапханәчесе Рыбальченко дусты белән таныштырырга сөйләшкән иде. Андрей белән алар кичке сәгать бишләр тирәсендә Мариенфельде урамы чатындагы сыраханәдә очрашырга килештеләр. Туңдырма ялый-ялый, шул якка юл тоттылар. Сыраханә янына җитәрәк, Муса егетләргә туктап калырга кушты. Ул ялгызы гына сыраханә ишеге төбендә Андрей белән очрашырга тиеш, ә егетләр аларның очрашуыннан соң, шул кеше янына килеп, аның белән танышырга һәм сөйләшеп алырга тиешләр иде. Муса, бүген шулай итеп аерылышабыз, тиз генә күрешеп булмас, дип, алар белән хушлашып, сыраханәгә юнәлде. Рыбальченко әле күренми иде. Муса сыраханәгә якынаюга, чаттан ике кеше борылганын күрде. Аларның берсе – Андрей, ә икенчесе – китапханәдә аны алмаштырган Виктор Харчёв иде.

Андрей Мусаларны читтән күзәтеп торган, ахрысы, килеп җитүгә:

– Кемнәр белән син анда? – дип сорады.

– Курыкмагыз, ышанычлы егетләр, – диде Муса. – Мин иртәгәдән Берлинда булмыйм, ял итәргә китәм. Безнең кичектергесез эшләр килеп чыкты. Егетләр барысын да сөйләр.

Ул шулай диде дә ашыгып китеп тә барды. Андрей белән Виктор Харчёв сыраханәгә керделәр. Муса күздән югалуга, Алиш белән Әхмәт тә сыраханәгә таба атладылар.

## 8

Семпен пансионаты дигәннәре Балтыйк диңгезендәге Узедом утравына урнашкан бер шәһәрчектәге, шундагы «Инзельхоф» дип аталган ял йорты булып чыкты. Аны «Идел-Урал» легионерлары ял итү өчен махсус сатып алганнар икән. Муса биредә бер атна ял итте. Дөрес, ялы ял булмады, йөрәге гел борчулы, гел оешма эшләре турында кайгырды. Шулай да ике шигырь яза алды. Берсе, «Томаулы гыйшык» дигәне, әле күптән түгел генә язган «Хәдичә» шигыре рухында шаянрак булып чыкты. Икенчесен язу уе зоопаркта Алиш карап торган бүре читлеге янында чакта туды. Исемен дә «Бүреләр» дип куйды.

Бүре – кыргый ерткыч. Безнең яклардагы кыргый җәнлекләрнең иң күп таралган һәм иң куркыныч төре. Ничек кенә куркыныч һәм явыз булса да, борынгы кеше аны кулга ияләштергән һәм үзенең тугры дустына әверелдергән. Әйе, ат белән эт – хайваннар арасында кешенең иң якын һәм тугры дуслары. Иң авыр чакларда да беркайчан да хуҗасына хыянәт итмиләр, ташлап китмиләр. Бүреләр ялгыз гына яшәмиләр, алар – куч, гаилә белән яшәүче, бердәм ерткычлар. Һәрвакытта да үзләренең юлбашчыларына, ата бүрегә буйсыналар. Төрле халыкларның мифларында, фольклорында бүреләр хакында кызыклы әкиятләр, легендалар яши. Рим шәһәренә нигез салучы Рем һәм Ромул исемле игезәкләрне имезеп үстергән ана бүре хакындагы легенданы дөньяда белмәгән кеше юктыр. Римдагы Капитолий музеенда ана бүрегә куелган һәйкәл дә бар. Тарихчы галимнәр ул һәйкәлне Римның борынгы халкы булган этрусклар ясаган, диләр. Ә ул этрусклар төркиләр булган. Унынчы-уникенче гасырларда яшәгән угыз-кыпчаклар ак бүрегә табынганнар. Төрки ханнарның байрагында бүре башы сурәтләнгән булган. Галимнәр язуынча, имеш, кытайлар түркетләрне бүреләр дип атап йөрткәннәр.

Муса шигыренең исемен язды да бүре турында әнә шуларны уйлап утырды. Аннары:

Кешеләр сугыша, кан коя,  
Киселә меңнәрчә гомерләр.  
Төн буе улашып якында  
Иснәнеп йөриләр бүреләр,

– дип язып куйды.

Борынгы бабаларыбыз тиккә генә бүрене кулга ияләштереп, тугры дустына әверелдермәгәндер. Бүре – ул кадәр үк ерткыч түгел. Ул беркайчан да үләксә ашамый. Бик сирәк очракларда, ашарына азык табарга бернинди җай чыкмаганда гына кешегә һөҗүм итә.

Муса шулар хакында уйлый-уйлый, авыр яраланган солдат янына килеп чыккан, аңа тимичә китеп барган бүре турында шигырен дәвам итте. Бүре калдырып киткән яралы егетне, фашистлар килеп җәзалап, ак каенга асып үтерәләр. Аның соңгы юлларын ул:

Бүреләр, аһ... ләкин бүреләр  
Бу кадәр үк ерткыч түгелләр,

– дип бетерде. Фашистларның ерткычлыкларын үз күзләре белән күргән Муса бу шигырьдә аларның никадәр кешелексез, вәхши зат икәнен күңелләрне тетрәндерерлек итеп сурәтли алды.

Уздомнан кайтуга, Шәфи Мусага легионерлар арасыннан Комитетта һәм Татар арадашчылыгында эшләргә, җитәкче кадрлар эзләү өчен лагерьларга чыгарга җыенулары, комиссия составына Мусаның да кертелүе хакында әйтте. Алар икенче көнне үк Берлин – Варшава поездында юлга кузгалдылар.

Муса вокзалга төшеп, Шәфи Алмас биргән билетта күрсәтелгән вагонга керде, купе ишеген ачты. Астагы ятакларда ишек янында Сабит Кунафин белән җырчы Афзал Фәхретдинов, түрдә, тәрәзә буенда Гариф Солтан утыралар иде. Ул: «Ишек янында утыручылар өстәге ятакларга үрмәләргә тиеш, димәк», – дип уйлап куйды. Пәлтәсен салып элгечкә урнаштыргач, аны түргә, тәрәзә буендагы буш урынга үткәрделәр. СВ купега урнашкан булса кирәк, Шәфи Алмас үзе күренми иде. Афзалны ул әсирләр алдында җырлатыр өчен алган булырга тиеш, Сабит – шымчы, Мусадан бер адым да калмыйча күзәтеп йөрер инде. Гариф Солтан – немецча чыгыш ясаучылар булса, тәрҗемәче. Ә Муса әсирләр арасында абруен күтәрер өчен кирәк. Ул аннан, һичшиксез, шигырь сөйләтәчәк.

Бераздан поезд кузгалды. Алар купесында урыннар тулы, ә Шәфи Алмас күренми иде.

– Шәфи абзый кайда йөри? – дип сорады Муса комитетчылардан.

– Ул СВ купеда. Кәефе юк. Безнең белән дорфа гына сөйләште. Салып та алган бугай, – диде Гариф Солтан.

– Нәрсә булган соң шулай кәеф кырылырлык?

– Өченче көн Яушев заводында янгын чыккан. Кайбер цехлары шартлаган ди бугай. Шуннан бирле абзыйның кәефе юк.

– Батальоннарда солдатлар арасында татар һәм урыс телләрендә листовка таратканнар. Урыс Азатлык армиясенә каршы листовкалар, ди. Шулай да безнең комитет хезмәткәрләреннән шикләнәләр.

– Кемнәр кулы уйнавын мин төгәл чамалыйм, – дип, сүзгә Сабит Кунафин кушылды.

«Ярый әле мин Семпендә чакта булган. Миннән шикләнерлек урын юк», – дип уйлап куйды Муса. Алай да ул Унгляубе шымчысының кылларын чиртеп карарга булды:

– Кемнәр дип уйлыйсыз? – дип сорады.

– Борчылмагыз, сез түгел, – диде Кунафин. Шулай да төгәл исемнәр әйтүдән тыелып калды.

Муса юл кирәк-яраклары салынган сумкасыннан «Идел-Урал» гәзитенең үзе ял иткән чакта чыккан соңгы санын алып караштыра башлады. Гариф белән Сабит карта сугарга тотындылар. Афзал, бер сүз дә дәшмичә, тын гына аларны карап утырды, тәрәзәдән Германиянең гүзәл табигатенә сокланып барды. Калкулыклар арасында ара-тирә очраштыргалаган төз буйлы чыршылар аңа туган якларындагы матур урыннарны хәтерләтте. Берәр сәгать чамасы шулай баргач, алар купесының ишеген шакыдылар. Вагон озатучысы икән. Ул билетларны тикшерде һәм Мусага мөрәҗәгать итте:

– Herr Gumerov, Herr Shafi Almas aus dem ersten Abteil lädt Sie zu sich selbst ein.

Муса озатучының аны үзенә Шәфи Алмас чакыруы турында әйтүен аңлады. Гариф Солтан шунда ук татарчага тәрҗемә итеп бирде:

– Һерр Гумеров, сезне беренче купеда баручы Шәфи Алмас әфәнде үзенә дәшә, дип әйтә, – диде.

– Кайсы купеда? – дип сорады Муса Гарифтан.

– Беренче, СВ купеда бара Шәфи абзый, – диде Гариф, озатучыга мөрәҗәгать итеп тормыйча.

– Яхшы, – диде Муса һәм, җыенып, ишектәге көзгедән карап чәч-башын тәртипкә китереп, чыгып китте.

Шәфи Алмасны ялгызлык ялыктырган булса кирәк, ул Муса белән бераз сөйләшеп, аралашып барырга уйлаган иде. Бу хакта алдан ук хәзерләнгән, күрәсең, өстәл өстенә затлы виски, төрле консерва-закускалар чыгарып тезгән, үзе эчемлектән авыз итеп алырга да өлгергән – шешәсе ачылган һәм ике касәнең берсендәге хәмернең яртылаш эчеп куелганлыгы күренеп тора иде. Ләкин Шәфи сүзне Мусага дәгъва белдерүдән башлады.

– Сезгә билетны баштан ук үзем белән бер купедан аласы калган. Әйдүк, узыгыз, Муса әфәнде, – дип каршы алды ул аны.

– Зыян юк, Шәфи әфәнде, үзегез генә булгач, борчучы да юктыр, рәхәтләнеп ял итеп барасыз.

– Сөйләгез, үзегез ничек ял иттегез. Матураеп, түгәрәкләнеп киткәнсез, ял килешкән бугай, күренеп тора, – диде Шәфи, Мусаның Семпеннан кайтып төшүенә ишарә ясап.

– Зур рәхмәт, ярады, ярады. Ял ял инде ул.

– Безгә генә монда рәхәтләнеп яшәргә бирмиләр, корт чаккырлары. Ул Әхмәт Симаев дигән кемсә сәвит разведчигы, ахрысы. Диверсия оештырыр өчен монда махсус ташланган, дигән фараз бар. Бик матур гына кереп утырган җылы урынга. Сәвитинформ хәбәрләрен тыңлап ята, шуларны татарчалаштырып, «Винета»да легионерларга тапшырып тора.

– Кит аннан. Булмас, ул бит рейхсминистр Розенбергның ышанычлысы, яраткан журналисты. Ул үткәргән пресс-конференцияләрдә даими катнаша.

– Шуннан файдалана да инде. Легионерлар арасында таратылган листовканың Гиббельсның борын астында эшләп яткан «Винета» радиостанциясе тәрҗемәчесе машинкасында басылганлыгы ачыкланды. Моны бары тик Симаев эше дип кенә уйларга була!

– Бу бит батырлык! Шәфи әфәнде!

– Көлмәгез, Муса туганкай! Көлмәгез. Баш китәрлек эшләр бу! Берочтан Симаевның эшчәнлеген сезнең персона белән дә бәйләргә бик мөмкин!

– Ничек алай? Минем аны күргәнем дә юк.

– Күргәнсең шул. Зоопаркта икегез бергә крокодиллар бассейны янында озак кына сөйләшеп басып торгансыз.

– Соң, анда бит комитетның барлык хезмәткәрләре дә бар иде. Барыбыз да бергә йөрдек.

– Кемнең нәрсә уйлаганын, нәрсә сөйләшкәнен кем белгән анда.

– Аннары, мин икенче көнне үк ял йортына китеп бардым.

– Рәхим Саттар дустың да бик шикле кеше булып чыкты. Минем лояльлектән файдаланып, гәзиттә «Вакытлыча дуңгыз да кияү була ала» дигән мәзәк бастырган. Гитлерны мыскыл иткән. Алиш дустың төрле милләт легионерларына «уртак дошманга каршы берләшергә» чакыру белән мәкалә язып чыгарган. Нинди дошман турында сүз бара торгандыр? Барысын да эштән куарга! Урыннарына яңа хезмәткәрләр алырга. Сезнең белән бу сәфәргә чыгуыбызның төп максаты менә шул, Муса әфәнде, белмәсәгез, белегез! Унгляубе миннән әнә шуны таләп итә. Үземне кыен хәлдә калдыручыларны яклап маташырга һич теләгем юк. Китсеннәр, әнә, батальоннарда хезмәт итсеннәр. Франциягә, Голландиягә барып сугышып ятсыннар, кадеремне белмәсәләр!

– Җиңел генә әйтәсез, Шәфи әфәнде. Андый белгечләрне табуы ансат булмаячак. Аяк астында аунап ятмый андыйлар.

– Ятмасалар, аларны үзең алмаштыра аласың. Иртәгә үк легионерлар алдында чыгыш ясарсың. Лагерьларга да барачакбыз. Әсирләр алдында легионга язылырга чакырып та чыгышлар ясарсың. Ышанычны акларга кирәк, Муса әфәнде!

– Минем ораторлык сәләтем юк. Шигырь укый алам. Афзал җырларымны башкарыр. Шуннан артыгын көтмәгез. Нәрсә булдырсам, шуны эшләрмен.

– Ярар. Карарбыз. Мондый сөйләшүгә дип чакырмаган идем. Канның кызган чагы, гафу ит. Әйдә, берәр чәркә җибәрик булмаса.

– Гафу итегез, Шәфи әфәнде, бер дә теләгем юк. Кәефемне дә кырдыгыз. Купега кайтып ял итим.

Муса шулай диде дә, Шәфинең үгетләүләренә карамыйча, үз купесына чыгып китте.

– Иртәгә чыгыш ясарга әзерлән! – дип калды аның артыннан Шәфи, монда әле үзенең хуҗа икәнлеген күрсәтергә теләгәндәй.

Муса Шәфи яныннан, чынлап та, шактый кәефсезләнеп чыкты. Ул шикләнеп кенә йөргән күп нәрсәләрнең чын икәнен ачты президент. Алар артыннан күзәтәләр дә икән. Һәм эшләре шактый ук куркыныч та икән. Симай белән Саттарның хәлләре аеруча кыл өстендә, болай булгач. Бу карт, үз тиресен кайгыртып, эшне сүздә генә калдырмаска да мөмкин. Әхмәт Тимер белән дә нинди мәкерле хут ясап атты.

Купедагылар Мусаны шулай тиз генә әйләнеп кайтыр дип көтмәгәннәр иде бугай.

– Нәрсә булды? – дигән сорау ташлады Гариф Солтан, ишектән керә-керешенә.

– Нәрсә булсын, тилергән президентыбыз. Теленә тилчә чыккан, ни теләсә, шуны сөйли.

– Президентлыгын әйтер идем инде, – диде Гариф, Мусага теләктәшлек белдергән чырай чыгарып. Кем белән, кайда гына сөйләшсә дә, Шәфи Алмас турында сүз чыкса, аны каралтмыйча калмый. Гел булдыксызлыкта, наданлыкта гаепли. – Башка комитетларның президентлары легионерлар өчен барысын да эшлиләр. Ә безнеке бары тик үзенең сәүдә эшләре турында гына кайгыртып, үз кесәсен калынайту турында гына уйлап йөри. Күптән алыштырырга кирәк инде.

Гарифның нәрсә уйлаганын барысы да яхшы белә. Аның белән килешәләр дә иде бугай. Ләкин бу хакта берсе дә кычкырып сүз әйтми, дәшмәүне мәгъкульрәк күрәләр. Чөнки Гарифның үзенең дә бу вазифаны башкарырга әле башы яшь, борын асты кипмәгән. Нибары унтугыз яшь кенә тулып узган.

Мусаның Шәфи белән булган сөйләшүен купедашларына җиткерергә бернинди теләге дә юк иде. Ул яңадан үз урынына утырып, тыныч кына «Идел-Урал» гәзитен карый башлады.

Кичкә таба поезд аларны Варшава тимер юл вокзалына алып килеп җиткерде. Муса кунакханәгә Афзал белән бер номерга урнашты. Мусаның зур кара сумкасы «Идел-Урал» гәзитләре белән шыплап тулган иде. Алдагы көнне ул, ике атналык сәфәргә чыгасы, дигәч, Седльце, Демблин, Вустрау, Узедом, Радом, Крушино, Дрезден кебек шәһәрләр тирәсендәге лагерьларда булырга туры киләчәк, дип чамалап, Алиштан йөз данәләп листовка алырга да

өлгергән иде. Хәзер шул листовкаларны, Афзалга сиздермичә генә, төргәкләп бүлгәләп куясы. Гәзит битләре арасына кыстырып таратуы да куркыныч; аерым, ышанычлы кешеләргә биреп калдырырга кирәк. Седльцедә аның килүен дүрт күз белән Абдулла Баттал көтә. Радомда – Зиннәт Хәсәнов, Едлинода – Кормаш егетләре, Крушинода – Ян Габдуллин...

Икенче көнне Седльце лагерена алып килделәр. Аларның киләсен биредә көткәннәр. Татар һәм башкорт әсирләрен лагерь уртасындагы тузанлы мәйданга чыгарып тезгәннәр иде. Кунакларны лагерь коменданты һәм Татар арадашчылыгының башлыгы Гайнц Унгляубе үзе каршы алды. Әсирләр алдында комендантның кыска гына чыгышыннан соң Унгляубе сүз алды. Аның сөйләгәннәрен Гариф Солтан татарчага тәрҗемә итеп барды.

Унгляубе әсирләрнең легионнарга язылып, Германия мәнфәгатьләрендә хезмәт итүен патриотизм дип бәһаләде.

– Чөнки сез, туган илегезне большевистик чумадан азат итү өчен, үз милли дәүләтегезне төзү өчен көрәшәчәксез, – диде ул. – Легионерларның көнкүреше гади әсирләрнеке белән чагыштырганда, күпкә яхшырак. Алар көнгә өч тапкыр кайнар аш белән тәэмин ителә. Яхшы киенеп йөри. Хезмәт хакы ала. Без СССРда сезнең хезмәт хакы алмыйча эшләгәнегезне төгәл беләбез. Легионда хезмәт итеп, сез туган илегезгә тулы янчык белән, баеп кайтачаксыз.

Унгляубеның чыгышын татарчага аударып барган Гариф Солтан аның артыннан үзе дә татар телендә нотык тотты. Ул шулай ук легионерларның хәрби әсирләргә караганда яхшырак шартларда яшәүләре белән кызыктырырга тырышты. Моның өчен Татар комитеты зур эш башкара, дип, комитетның дәрәҗәсен күтәрергә маташты. Татар комитетының, башка комитетлар белән чагыштырганда, абруе зурлыгын билгеләп үтте.

Гариф үзенең сүзләрен: «Ә хәзер сезнең алда күренекле татар шагыйре Муса Җәлил чыгыш ясый», – дип тәмамлады.

«Муса Җәлилгә сүз бирелә», дигәч, әсирләр гөрләшеп алдылар. Муса Гумеровка, дисә, мондый хәл булмас иде, әлбәттә. Ә Җәлилне халык яхшы белә иде.

– Исәнмесез, Ватандашлар! – дип башлады сүзен Муса. – Мин оратор түгел, андый осталыгым юк. Сезне, легионга язылыгыз, дип үгетләп, кайнар чыгыш ясый алмам. Ләкин, чынлап та, легионга язылыгыз, дип чакырырга телим. Алда әйтелгәннәргә кушылып, чынлап та, легионда сезнең хәлегез күпкә яхшырачак, ачтан интегүләрегез бетәчәк, дип әйтәсем килә. Ә хәзер мин сезгә үземнең берничә шаян шигыремне укып китмәкче булам.

Муса әсирләргә үзенең «Хәдичә» һәм «Томаулы гыйшык» дигән шигырьләрен укыды. Ул тоткынлыкта дошманга үч һәм нәфрәт белән язылган башка шигырьләрен укудан тыелып торды. Арада, нәрсә сөйләр, кайсы шигырьләрен укыр икән, дип, аның һәр әйткән сүзен җиз иләк аша үткәрүче кешеләр бар иде.

Мусадан соң чыгыш ясарга Афзал Фәтхуллинны игълан иттеләр.

– «Сагыну». – Муса Җәлил сүзләре, Заһид Хәбибуллин музыкасы.

Афзал аккордеонда көйнең беренче аккордларын алды һәм көчле, моңлы тавышы белән җырлый башлады.

Гөл чәчәкләрен өзәм мин,
Юлларыңа тезәм мин.
Бик сагындым, бәгърем,

Бик сагындым сине,
Әле дә ничек түзәм мин...

Җырны әсирләр тын да алмыйча тыңладылар һәм ахырдан көчле алкышларга күмделәр.

Афзалның «Җавап хаты» дигән икенче җыры да Җәлил сүзләренә иде. Аннан соң ул татар һәм башкорт халык җырларын башкарды.

Концерттан соң, Муса, Шәфи Алмастан әсирләр өчен аерым сөйләшүләр үткәрергә, аларга «Идел-Урал» гәзитен таратырга дип сорап, бараклар буйлап йөрергә китте. Шәфи Мусаны бер минутка да күз уңыннан ычкындырмый иде. Үзе булмаса, бу эшне Сабит Кунафинга тапшырып, гел аның артыннан ияртеп йөртте. Муса моннан оста файдаланды. Гәзитләрнең бер өлешен Сабитка тоттырды, ә икенче өлешен үзе алды. Икенче төргәктәге бер гәзиткә сизелмәслек итеп листовкаларны кыстырган иде. Мусаның Сабиттан аерылуын көтеп кенә торган Абдулла Баттал, кеше-карага сиздермәслек итеп, Муса белән күз карашлары аша гына исәнләшеп, листовкалы гәзитне алып куенына кыстырды да әсирләр арасында юк булды. Муса җиңел сулап куйды. Аның гәзитләре дә тиз арада таралып бетте.

Икенче көнне инспекция Демблин лагеренда әсирләр белән очрашты. Алар лагерьлар буйлап йөргән ике атнаның һәр көнендә диярлек, әле анда, әле монда әсирләр, легионерлар арасында листовкалар таратылуы, төрле диверсия эшләре турында хәбәрләр килеп торды. Ул яңалыклар Шәфи Алмасны чыгырыннан чыгарса, Мусаның кәефен күтәрә, эшкә дәртләндерә иде.

**9**

Муса Семпен пансионатында ял иткәндә, Яушевның Познаньдагы радиоприборлар заводында, чынлап та, зур янгын чыкты.

Алиш белән Симаев, Муса пансионатка китәр алдыннан сыраханәдә аның танышлары Андрей Рыбальченко һәм Виктор Харчёв белән очрашып, Германиядә һәм Польшада төрле завод-фабрикаларда Гитлер армиясе өчен эшләүче гастарбайтерлар, алар арасында фашистларга каршы төрле диверсия эшләре алып баручы яшерен оешмалар турында күп кенә белешмәләр алдылар. Власовның Урыс Азатлык армиясенә үтеп кергән яшерен оешма әгъзалары башкарган гамәлләр аларны да активрак эшләргә рухландырып җибәрде. Икенче көнне үк Мусаның зоопаркта искә төшергән Яушев заводында поляк гастарбайтерларына күзәтчеләр булып урнашкан Гайнан төркеме егетләре белән элемтәгә керделәр. Заводта алардан башка да Мусадан йөкләмә алып киткән Салих Ганиев, авылдашы Назыйф Һадиев поляк эшчеләре арасында төрле аңлату эшләре алып бара, листовкалар тарату белән шөгыльләнә иде.

Алиш, Муса әйткәнчә, Яушев заводының Гитлер Германиясе басып алган илләрнең халыкларына никадәрле әшәкелекләр эшләве хакында листовка язып, Симаев аны радиостанция машинкаларында бастырып һәм ротаторда ишәйтеп, икенче көнне Баттал Познаньга, Салих белән Назыйфка илтеп тапшырды.

Салих белән Назыйфны Польшаның Познань шәһәренә, татар эмигранты Искәндәр Яушевның радиоприбор заводына, Вустраугa китерелгәннең өченчеме, дүртенчеме көнендә үк егерме кешелек зур төркем белән бергә җибәрделәр. Аларны завод идарәсе урнашкан бинада Яушев үзе каршы алды. Ул татар егетләренә зур ышаныч баглый, эштә гел зыян салырга гына торган поляк эшчеләрен күзәтү астында тотар өчен, үзенә бер дигән ярдәмчеләр

булырлар, дип өметләнә иде. Аларның барысын да завод эшчеләре артыннан күзәтчеләр итеп билгеләде. Заводта эшләүче polякларның нинди дә булса оешмалары юк. Ләкин алар шулай ук немецларны күрә алмыйлар, адым саен этлек эшләргә генә торалар. Шуңа күрә татар күзәтчеләре поляклар белән бик тиз уртак тел тапты. Ике якның да максаты бер үк – фашистларга эшләүче фабрикантның бизнесын туздыру. Җитмәсә, татарларны поляклар белән бер лагерьга урнаштырдылар. Эштән соң да аралашырга, уртак планнар корырга мөмкинлек зурайды.

Салихларга хәтле дә, ышанычлы кешеләр дип, Шәфи Алмас Татар комитетыннан биш-алты кешене монда юллаган иде. Муса бу хакта белә. Салихка да, Назыйфка да ул Шәфи Алмас җибәргән әлеге кешеләрдән саграк булырга кушты. Ләкин бу бишәү арасында Шәфи үзе дә шикләнмәгән коммунист Гәрәй Гыймранов дигән кеше бар иде. Гыймранов Гайнан Кормаш әле Демблинда чакта ук оештырган яшерен оешмада тора иде. Үз бәхетсезлегенә каршы, Яушев Гыймрановны проходнойга каравылчы итеп куйдырды. Каравылчы – заводта иң мөһим вазифа. Ул хәтта һәрнәрсәне күзәтү астында тоткан цех башлыкларыннан да күбрәк мөмкинлекләргә ия.

Заводта яшерен оешма белән Идрис Кәлимуллин җитәкчелек итте. Идрис – шулай ук Гайнан командасыннан. Гайнан үзе кан белән изге ант биргән кеше булса да, Кәлимуллин андый ук дәрәҗәдәге җитәкче түгел иде.

Заводка Познаньнан яңа эшчеләр төркеме китерелгән көнне лагерьда листовкалар барлыкка килде. Ике телдә – полякча һәм урысча язылган бу листовкаларда СССРда фашистларга каршы сугышу өчен поляк дивизияләре оештырыла, дип язылган иде. Бу хәбәр поляк эшчеләренең рухын күтәреп җибәрде. Кәлимуллин polякларның мондый күтәренкелегеннән файдаланып калырга кирәк, дигән фикергә килде. Аның күңелендә бер план туды. Ул Салихны, Назыйфны, Гәрәй Гыймрановны бытовкага чакырып, шул планы белән уртаклашырга булды.

– Егетләр, миндә бер уй туды, – диде Идрис. – Бүгенге листовка хәбәреннән соң, фашистларга каршы көрәш алып баручы поляк партизаннарына бүләк ясарга кирәктер?

– Нинди бүләк? Ничек? – диде Салих.

– Кул пулемёты бүләк итү мөмкинлеге бар.

– Ничек итеп? Аны заводтан ничек алып чыгасың?

– Частьлап. Егерменче цехта пулемёт җыялар бит. Эш сәгате беткәч, һәр эшче, куенына яшереп, бер пулемёт часте алып чыга. Проходнойда каравылчы үзебезнеке – Гыймранов. Ничек, Гәрәй, мөмкинме шул эш?

Гәрәй башта Идриснең бу идеясеннән телсез калып, дәшмичә торды. Аннары:

– Ну малай! Баш та соң үзеңдә! Баш түгел, ә политбюро! Каян килде синә мондый идея! Шәп бит бу! – диде, аны мактап. – Бер авырлыгы бар барын.

– Нинди?

– Проходнойда металлны сизә торган сигнализация куелган. Шуны сүндереп торганда гына башкарып була бу эшне.

– Соң, сүндерербез.

– Сизмәсләрме соң? Арада шымчылар да булуы мөмкин.

– Аларның кемнәр икәнен чамалыйбыз бит. Игътибарларын читкә юнәлтеп торырбыз.

– Шулай итсәк кенә инде.

– Алайса, килештек. Егерменче цех хатыннары белән сөйләшергә кирәк, эш ахырына таба соңгы пулемётны җыймасыннар. Частьларын иң ышанычлы егетләр, эштән соң кереп, куеннарында тышка алып чыгуны оештырырга кирәк. Бу эшне, Салих, Назыйф, сезгә тапшырсак, ерып чыга алырсызмы?

– Әлбәттә.

Операция уңышлы үткән кебек булды. Егетләр, алдан сөйләшенгәнчә, куеннарында кыстырып чыккан пулемёт частьларын, лагерьга кайту юлындагы бомба төшеп җимерелгән йортның подвал тәрәзәсеннән, аларны алырга дип килгән партизан отряды егетләренә биреп калдырдылар. Ләкин кайсыдыр сизгән, саткан булып чыкты. Икенче көнне үк Гәрәй Гыймрановны кулга алдылар. Хәрби трибунал буенча хөкем итеп, атып та үтерделәр.

Егетләр сатлыкҗанны тиз таптылар. Гәрәй үтерелгән көнне үк Шәфи шымчы итеп җибәргән егетләрнең берсе серне үзе үк ачты. Көндезге аш вакытында егерменче цех башлыгына бер коммунистны теге дөньяга олактырдым, дип мактанып утырган. Икенче көнне иртән эшкә килүчеләр, завод проходноеннан үтеп, бытовка ишеген ачып керсәләр, бүлмә уртасындагы электр лампасы чыбыгына асылынып торган надзирательне күрәләр һәм смена начальнигына йөгерәләр.

Гомере кыска булды Гәрәй Гыймрановның. Бер кул пулемёты өчен мөртәт сатлыкҗанның хыянәте аркасында япь-яшь килеш көтмәгәндә-уйламаганда өзелде. Ләкин, ул пулемёт җиңүне якынайту өчен бер генә фашистның башына җитмәгәндер, дип уйлап юанды Яушев заводында эшләүче татар егетләре, көрәштәшләренең якты истәлеге турында уйлап.

1943 елның язы җитте. Дөньяда сугыш бара. Икенче Бөтендөнья сугышы. Совинформбюро хәбәрләрен тыңлап, Яушев заводы эшчеләре СССРда хәлләрнең кай тирәдә булуын чамалыйлар иде. Сталинградта мәсхәрәле җиңелүгә тарган немец гаскәрләре исә, бөтен уңышсызлыкларын кышкы салкыннарга сылтап, җәй килүен түземсезлек белән көтәләр иде.

Көннәр язга авышкач, Познань өстендә, каяндыр самолётлар күренгәли башлады. Самолёт тавышы ишетелүгә, һава һөҗүме дигән тревога игълан ителә, һәм эшчеләрне завод территориясендәге бомбадан саклану өчен корылган подвалларга куалыйлар. Шундый һава һөҗүмнәренең берсендә Идрис Кәлимуллинның башында янә бер идея туды. Монысы тагын да хәтәррәк. Ул, егетләрен җыеп, чираттагы планы белән уртаклашты.

– Егетләр, тагын бер план бар.

– Тик бу юлы саграк кыланырга иде, – диде Салих, Идриснең буш хыяллар белән йөрмәвенә ышанган хәлдә.

– Бу юлы беркем дә сизмәячәк.

– Нинди эш инде ул, сөйлә тизрәк.

– Күреп торасыз, ике көннең берендә самолётлар бомба ташлап китә. Завод өстенә төшкәне юк югын. Ләкин төшертергә кирәк.

– Ничек итеп? Алар белән элемтәбез юк бит.

– Булмас та. Ләкин һава һөҗүме тревогасы вакытында, бөтен халык подвалга качып беткәч, заводны шартлатырга. Мөмкин эшме шул?..

– Мөмкин. Ничек синең башыңа гына килеп тора ул, ә?

– Мин, дуслар, гел шул турыда гына уйлап йөрим. Ничек итеп көлен күккә очырасы иде бу заводның, дип.

– Көлен үк очырып булмас, шулай да берәр цехын очырырга мөмкиндер.

– Моның өчен бары шартлаткыч табарга кирәк. Сиздермичә генә алдан

хәзерләп куярга да, һава тревогасы булганда, эшне башкарырга. Бетте-китте, вәссәлам!

– Шартлаткычын да әллә каян эзлисе юк. Заводта ук бар. Хәрби завод бит. Егерме бишенче цехта снарядлар ясыйлар. Шул цехның үзен күккә очырырга була. Цех кына түгел, заводның да исән калмавы мөмкин.

– Безнең ул цехта кем надзиратель соң әле?

– Мулланур Гәрәев.

– Анда сәгатьле механизм гына куярга кирәк, бернинди тротиллар да эзләп торасы юк. Тревога игълан ителүгә, биш минутка куярга да, биш минут эчендә заводта бер кеше дә калмый. Кая, кем шартлатканын да абайламый калачаклар, бомба төшкән дип уйлаячаклар. Шуның белән шул.

– Килештек, егетләр. Поляк партизаннары белән элемтәгә кереп, шартлаткыч механизм табарга кирәк. Бу эшне үз өстемә алам. Таралыштык, – диде Идрис, шымчылар игътибарын җәлеп иттермәс өчен, сүзне озынга сузмыйча.

Партизаннар шартлаткыч сәгатьле механизмны икенче көнне үк китереп бирделәр. Шул көнне үк һава һөҗүме дә булды. Мулланур Гәрәев каравыллаган егерме бишенче цех һәм аның күршесендәге тагын өч цех җимерелеп, ярты сәгать буе күккә фейерверклар атты ул көнне. Чынлап та, барысы да самолётлардан ташланган бомба шартлауга сылтадылар бу фейерверкларны. Яушев заводының снарядлар эшләүгә көйләнгән ярты өлеше сафтан чыкты.

Радиоприбор заводы дип йөртелгән бу завод Германиянең оккупацияләнгән Польша җирендә Гитлер армиясе өчен иң зур күләмдә корал җитештерә торган хәрби предприятие иде. Татар надзирательләре килгәч, эшкә әледән-әле зыян китереп торучы поляк гастарбайтерларының корткычлыкларына чик куелыр дип өметләнгән Яушевның эшләре тагын да зуррак колач белән киресә таба китте.

Снаряд цехлары шартлауны баштарак һава һөҗүме нәтиҗәсе, дип йөрсә дә, заводта килеп чыккан тагын да бер зур янгыннан соң, ул бу корткычлыкларны татар әсирләре эшләвенә төшенә башлады.

Көннәрнең берендә заводта янгын сүндерүчеләр частенда һәм Идрис Кәлимуллин утырган бүлмәдә янгын чыкты. Бу юлысында яшерен оешма егетләре әлеге янгынга үзләре дә аптыраушта калды. Корткычлыкны поляклардан күрделәр. Ләкин моны Идрис Кәлимуллин үзе эшләде. Җае килеп чыкты да, бу операция турында иптәшләре белән алдан киңәшләшергә вакыт та калмады. Ә янгыннан соң ул аны беркемгә дә сөйләп тормады.

Эш болай булды. Заводның янгын сүндерү часте урнашкан бүлмә яныннан узып барганда, ул аларның ниндидер сәбәп табып бәйрәм итеп, хәмер эчеп утыруларын күрде. Эш урынына кайтып, үзенең бүлмәсендәге кәгазьләрне җыеп ут төртте дә ишеген бикләп чыгып китте һәм, тиз генә барып, янгын сүндерүчеләр утырган бүлмә ишеген дә бикләп алды. Бүлмәләргә ут кабып, ялкын шактый тарала башлагач кына заводта янгын чыгуын сизделәр. Ә янгын сүндерүчеләр бикле бүлмәләренең ишеген ватып чыкканда, ут инде шактый көчәеп, түбәләргә хәтле үрләгән иде. Нәтиҗәдә, заводта дүрт көнгә эш тукталып торды.

Тикшерүчеләр янгын сәбәпләрен тиз ачыклады. Идрис Кәлимуллинны кулга алдылар һәм Моабит төрмәсенә утыртып куйдылар. Яушев барлык татар надзирательләрен эштән куып, концлагерьларга озаттырды.

Бу хәлләрдән соң Искәндәр Яушев күз яшьләре белән елады.

Соңгы янгыннан соң, түзәр хәле калмаган фабрикант, зарын түгәр өчен,

Шәфи Алмас белән көрешергә «Идел-Урал» комитетына килде. Шәфи, Яушевның хәсрәтләрен уртаклашыр өчен, дигән булып, очрашуга Галимҗан хәзрәт Идриси белән Швейцариядән Әхмәтвәли Мәңгәр әфәндене дә дәште. Аларның очрашулары Шәфи Алмасның өендә, чәй табыны артында узды. Хуҗа бу юлы да хезмәтчеләре Мәфтухадан мул гына чәй ашлары пешерттерде. Кунаклар җәмәгатьләреннән башка гына, ирләрчә эшлекле сөйләшүгә дип килгәннәр иде.

– Германиянең Советлар Союзына күрсәткән бөтен золымнарын миннән күрәләр бугай бу синең кәмититчеләрең, Шәфи агай, – дип башлады сөйләшүне Искәндәр Яушев. – Шулар килеп эшли башлаганнан бирле эшем артка тәгәри бит, кана. Әле шартлау, әле янгын, әле кеше асып үтерү. Түзеп кенә тор. Бер көн килеп, үземне дә асып куярлар шикелле куркып йөри башладым.

– Аңлыйм, аңлыйм хәлеңне, Искәндәр әфәнде. Үземдә дә шул ук хәл. Әле монда листовка тараталар, әле тегендә листовка бастырганнар, дип теңкәгә тияләр. Беркөнне Унгляубе әфәнде җиде кат тиремне тунады шул листовкалар мәсьәләсендә. Гитлерның тугры дусты Геббельсның борын төбендә, «Винета» радиостанциясе редакциясе машинкасында листовка бастырганнар бит, каһәр. Бу шымчыларымнан да рәт юк. Әллә шул шымчы дип йөргән мәлгуньнәр үзләре үк бастырып ята инде?.. Кулларыннан барып тотмагач, кемгә дә бәйләнергә белгән юк.

– Әйе, эшегез бер дә көнләшерлек түгел, Шәфи туган, – дип, сүз кыстырды дусларының зарын тыңлап утырган Әхмәтвәли Мәңгәр.

– Кайчакта ташлап качыйм микән әллә бу комитетны дигән уйлар да килә башка. Шайтаныма кирәкме соң бу татарга дәүләт?! 1919 елда инде төзеп бетергән җиреннән җимереп атканнар бит ул Идел-Урал республикасын. Исхакый белән Вәлиди, әнә, бүгенгә кадәр кан дошманнар булып, уртак тел таба алмыйча, Алманиядән Төркиягә качып киттеләр. Исхакый әфәнденең «Идел-Урал» комитетына килеп тә караганы юк. Гәзит чыгарып ятабыз. Мәкалә язып китерер иде берәү булса.

– Син, Габдрахман туган, үзең дә гаепле бугай инде Исхакыйның бездән читләшүенә. Редакцияңдәге портретын да ертып ыргыткансың дип ишеттем, дөрес булса.

– Булды андый хәл, Әхмәтвәли кордаш. Бездә бит, татарда, берәү түрә булса, икенчесе аны урыныннан төртеп төшерергә маташа башлый. Исхакый абзый да «Идел-Урал»ның президенты булырга йөри икән дигән сүз чыкты. Шуны ишеткәч, кызып китеп эшләнгән эш булды ул.

– Ә син кызма, кордаш. Бу эштә уйлап эш итәргә кирәк. Исхакый агай ни житте кеше генә түгел ул. Кирәк булды микән аңа синең ул президентлыгың? Юри үз шымчыларың араны бозар өчен уйлап чыгарган сүз булмады микән? Вәлиди, дисәләр инде, ышаныр идең. Ул анда – әле Колчакка хезмәт итеп, әле сәвитләр ягына чыгып, әле басмачлар башлыгы булып, җылы урын, кәнәфи эзләп йөрүче саташкан бәндә. Бер мактарлык эше бар: башкортларга республика ясап калдырды. Әле менә күрерсез, коммунистларны җирдән себереп түккәч, башкортлар күтәреп кенә йөртерләр үзен. Ул көннәрне үзе күрә алса инде. Ә Исхакыйны белүче дә булмаячак. Коммунистлар гына түгел, монда да шундый мөнәсәбәт икән, сез президенты булган ул илдә аңа, ай-һай, рәт чыгар микән?!

– Гаяз әфәнде арабызда иң гыйлемле, иң туры сүзле милләтпәрвәр кеше, – дип, сүзгә тын гына тыңлап утырган Галимҗан хәзрәт Идриси кушылды. – Гитлер

хакимияткә килгәч, Гаяз әфәнде аның, дөньяда бары тик арийлар гына өстен булырга тиеш, дигән тәгълиматын кабул итмәде. Никадәр генә милләтпәрвәр булса да, милли мәсьәләдә Гитлерга таянмады. Ул мөһаҗирлектәге бөтен гомерен әдәбиятка багышлады. Милләтебезне нинди афәтләр көткәнен әдәби әсәрләр аша күрсәтергә теләде. Мин, Аллага шөкер, аның белән хәбәрләшеп торам. Арабызда хатлар йөри. Ватаннан киткәч, ул милләтебезнең аяныч язмышын сурәтләгән күпме генә сәхнә әсәре язмады! Аның эшчәнлегенә искитәрлек! Әле шулар өстенә гәзит-журналлар чыгарып ята. Ә Гитлер дөнья сугышын башлап җибәргәч, алманнар аның Берлинда чыгара торган «Милли юл» журналын яптылар; шуңа протест йөзеннән ул Германиядән Төркиягә китеп барды. Кадерсезгә калды Исхакый кордаш. «Прометей»да большевикларга каршы эш алып барды. Молотов белән Риббентроп килешүеннән соң полякларның «Прометей»ена да Исхакыйның кирәге шуның хәтле генә калды.

– Исхакыйны кадерсез, дисең син, Галимҗан хәзрәт. Без бөтенебез дә кадерсез кешеләр милләт өчен. Кемгә кирәк без? Кем белә безне? Әллә Шәфи кордашның комитет егетләренә кирәгебез бармы? Һәммәсе безне эмигрантлар дип белә. Сәвит хакимиятеннән котлары чыгып, ватаннарын ташлап качкан затлар итеп кенә карый. Бәлки, алар хаклыдыр да. Үзебез генә йөрибез бугай милләт, дип, милләтпәрвәрләр, ватанпәрвәрләр, дип. Ә Гитлер бездән файдалана. Әллә кайчаннан билгеле аның СССРны яулап алгач, бернинди милли дәүләт төзергә дә юл куймаячагы. Ә без нәрсәгәдер ышанып, үзебез уйлап тапкан хыялга алданып, монда аңа булышлык күрсәткән булып йөрибез. Безнең ярдәмебез кирәкмидер дә. Ярар, бетерик, туктатыйк бу сөйләшүне. Кая, берәр чынаяк чәй эчик тә таралыйк.

– Ашыкмагыз әле, Әхмәтвәли әфәнде. Гел сәясәт турында гына түгел, тормыш хәлләре турында да сөйләшик бераз, – диде Шәфи Алмас, Мәңгәр әфәнденең мәҗлесне түгәрәкләргә чакырган сүзләренә җавап итеп.

– Афзалетдин дустың кайда булды соң әле? Җырлашып утырсак, кәефләр күтәрелеп китәр иде. Югыйсә, бөтенләй мәгънәсезгә әйләнеп барган тормышыбыз турында гәп корып утырабыз.

– Афзал Демлинда шул хәзер. Анда комитетның музыкаль капелласын оештыргач, Афзалны хорда җырларга шунда җибәрдек. Иртәгә икенче батальонны Голландиягә озату була. Капелла шунда зур концерт бирергә тиеш. Барыгызны да шунда чакырам. Милләт егетләрен олылап, изге сәфәргә озатып калсак, күңелләре булыр иде.

– Ә нәрсә, татарларны да Голландиягә җибәрә башладылармыни? Туган илгә юл ябылдымыни? – диде Әхмәтвәли Мәңгәр, гаҗәпләнеп.

– Беренче батальоннан соң ышаныч бетте татарларга. Әле хәтта легионны куып таратабыз, дигән сүзләр дә йөри. Яңадан лагерь тормышы көтмәгәе мескен татар әсирләрен.

– Шулай укмыни? Хәлләрегез шәптән түгел икән болай булгач, Шәфи әфәнде.

– Әйтәм бит, Гитлер китергән казалар өчен миннән үч ала башлады «үзебезнең егетләр» дип йөргән татарлар. Күпме зыян китерделәр. Шулар өчен дип күпме тырышкан булам, – дип, яңадан үз зарына әйләнеп кайтты Искәндәр Яушев. – Шуңа күрә җәзасын да күрәләр, әнә. Туган илгә юлны яптылар үзләренә. Голландиядә, Франциядә калачак хәзер каберләре.

– Мескен татар... Кайларга гына китеп, ниләр генә күрми татар башы, туган ил, дип, ватан, дип йөреп...

## 10

1943 елның 23 февралендә Әхмәт Симаев «Винета» радиостанциясендәге эш бүлмәсендә үзе көйләгән радиоалгыч аша Совинформбюро хәбәрләрен тыңлаганда, татар халкының Бөек Ватан сугышы фронтларында сугышучы татар егетләренә юллаган сәлам хаты турында ишетте. Радиодан бу хатның кыскача эчтәлеген дә тапшырдылар. Хатның фронт гәзитләрендә басылып чыгуы турында да әйтелде. Фронт гәзитләре Берлинга хәтле үк килеп җитмәс, «Заря» редакциясе китапханәсенә килә торган «Правда», «Красная Звезда» гәзитләрендә аны, һичшиксез, басмыйча калмаслар, дип уйлады Симаев. Ул, хатның радиодан ишеткән кадәресен искә төшерә-төшерә, кыска гына хәбәр язып, аны «Винета»дан бирелә торган тапшыруында укып чыкты. Язмасын шунда ук ут төртеп юкка чыгарды. Тапшыруны күпләр тыңлаган иде. Эштән кайткан чакта ул алдан килешенгән урында Виктор Харчёв белән очрашты.

– Сине кызыксындырган нәрсәне белеп торам, – дип каршылады аны Виктор. – Татар сугышчыларына татар халкының хаты.

– Шул хатны табасы иде бит.

– «Правда» тагын ун көннән соң гына килергә тиеш. Анда басылмыйча калмас.

– Мин дә шуны сорарга килгән идем. Бүген эфирга кыска гына хәбәр чыгардым. Халык тыңлаган булырга тиеш.

– Тыңладык. Фрицлар аңламый калдылар. Без шыпырт кына тыңладык. Сокландык батырлыгыңа. Шәфи Алмас ишеткән булса, рәхмәт әйтмәс.

Өйдә Әхмәтне Алиш белән Рәхим Саттар да түземсезлек белән көтәләр иде. Алиш Шәфи Алмас өендә ярты айлар яшәп алганнан соң, шуннан ерак та түгел бер йортта бүлмә алып тора башлаган иде. Беркадәр вакыттан соң ул Әхмәт яшәгән йортка күченде.

– Иһ, «Идел-Урал»да да бастырып чыгарасы иде ул хатны! – диде Рәхим, Әхмәт аларны хатның кыскача эчтәлеге белән таныштыргач.

– Чыгарасы иде дә, чыгарып булмас шул. Берәребез шул уңайдан мәкалә язып бастырса гына инде.

– Үзем язам, егетләр. Тизрәк кулга төшерәсе иде ул хатны, – диде Саттар. – Менә бер мәкалә яздым әле, Казан турында. Алдагы санга кереп китсә, шәп булыр иде. – Ул кесәсеннән бөкләнгән кәгазь битләрен чыгарды һәм аларны Алишка бирде. – Бу язманы Кыямга тапшырырсың әле. Үземнең редакциядә күренеп йөрисе килми. Болай да Шәфи Алмасның күзенә ак булып төштем бугай инде.

Март башларында «Заря»га «Правда»ның 23 февраль саны килде. Татар сугышчыларына хат «Красная Звезда»да да басылып чыккан иде. Алиш Виктор Харчёвтан аларның икесен дә сорап алды. Әхмәт шул кичне үк хат буенча листовка әзерләде. Ул күптән түгел «Винета»дан ерак түгел генә урнашкан типографиядә эшләүче болгар студентлары белән танышты. Листовканы шул дуслары аша типографиядә бастырып, ишәйтеп алды. Хатны гәзиттә чыгару мөмкин түгел иде. Бердән, ул зур күләмле икән. Икенчедән, Шәфи, гәзитне басарга кул куйганда, һичшиксез, аны үткәрмәячәк иде. Шуңа күрә Рәхим хат нигезендә мәкалә язарга утырды.

«Татарские джигиты! Вам, кто не щадя сил и жизни грудью защищает каждую пядь родной земли на фронтах от моря Белого до моря Чёрного; вам, кто в первых рядах гвардейских полков и дивизий идёт в наступления, в дни

25-летней годовщины славной Красной Армии, в дни замечательных побед наших войск шлёт татарский народ свой пламенный салям!

Бесстрашные, честные, стойкие сыны и дочери татарского народа! Матери ваши, вскормившие вас грудью, и отцы, передающие вам своё благородство, шлют вам горящий, как лучи солнца привет и благославляют вас неустанно идти вперёд, мести без пощады!..»

Хат солдатларның күңеленә үтеп керерлек итеп, аларны фашистларга каршы каһарманнарча сугышка рухландырырлык чакыру сүзләре белән язылган иде.

– Моны безнең каләмдәшләр язган. Әллә каян сизелеп тора. Кави Нәҗми, Гомәр Бәшировлар кулы булырга тиеш, – диде Алиш. – Бу мәкаләне дә шундый ук югары прафос белән, әсирләрнең йөрәкләрен тетрәндерерлек итеп язарга кирәк. Фронтка киткәндә, һичшиксез, фашистлар өчен түгел, аларга каршы сугышка киткән шикелле хис кичерерлек булсын.

– Бик катлаулы мәсьәлә. Шәфиләр күзеннән үткәрерлек итеп тә язарга кирәк. Бәйләнеп торырлык итмәскә.

Рәхим соңгы көннәрдә шушы мәкаләне язу уе белән дәртләнеп йөргән иде. Ул аны үзенең бөтен осталыгын, талантын һәм белемен биреп язды. Хаттагы Габдулла Тукай шигыреннән китерелгән өзекне дә кертеп җибәрергә булды.

Рус җирендә без әсәрле, эзле без,
Тарихында бер дә тапсыз көзге без.
Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.
Бергә тормыш, бергәлек чиктән ашып,
Без шаярыштык, вакытлар алмашып.

Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? –
Без туганбыз бер җепкә бергә теркәлеп.
Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.

Муса, Рәхимнең мәкаләсен укыганда, аның Тукай шигырен шушы урында туктатуы белән килешеп бетмәвен белдерде.

Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? –
Хаккыбыз уртак ватанда шактый ук!

– дигән юлларын язмадыңмыни?

– Ничектер, урыны ул түгел шикелле.

– Нишләп урынлы булмасын? Нәкъ шунда урыны. Тукай бик белеп, нечкә тоемлап язган ул юлларны. Шәфиләр бит әнә шул хисләрендә уйнап, легионга өндиләр татарларны. Үз ватаннарын булдыру өчен, көрәшкә чакыралар. Бу юллар, Шәфи бәйләнә-нитә калса, мәкаләнең кирәклеген дәлилләү өчен дә бик мөһим мисал булачак сиңа.

– Килешәм, – диде Рәхим һәм Тукай шигыренең бу ике юлын да өстәп куйды.

Мәкалә бик шома гына кереп китте гәзиткә. Шәфи аны күрмичә дә калды диярлек. Номерны басмага тапшырганда, ул, гадәтләнгәнчә, редактор урынбасары Кыям Галиевтән нинди язмалар булуы турында кызыксынды да, «Басарга рөхсәт», дип язып, имзасын салды. Ләкин бу Кыям өчен зур хафага әйләнде. Гәзит чыкканнан соң, Рәхим Саттар мәкаләсе буенча Шәфи Алмаска Унгляубе алдында җавап тотарга туры килде.

– Минем өстә болытлар куера бугай, – диде Рәхим Алишка, Шәфине Унгляубе үзенә чакыртып алгач.

– Шәфи барыбыз өстеннән дә нәрсәдер сырлаган бугай анда. Судан коры чыгар өчен, Унгляубега шуны бирмичә калмастыр, мөгаен.

– Ул әйләнеп кайткалаганчы, исән чакта ычкынырга кирәк моннан. Алиш абый, мин шигырьләремне өч дәфтәргә язган идем. Икесен үзем белән алам. Төрле хәл булуы бар. Берсен сиңа биреп калдырыйм әле. Беребез исән калмасак, беребез калыр. Сакла әле, – диде дә, куеныннан дәфтәр чыгарып, Алишка тоттырды. – Егерме дүрт шигырь монда. Калганнары үземдәге ике дәфтәрдә.

Саттар качу турында күптән уйлап йөри иде инде. Гәзиттә татар сугышчыларына сәлам хаты уңаеннан язган мәкаләсеннән соң Шәфинең аны эзәрлекли башлаячагын ул сизенә иде. Бүген Шәфи Унгляубе алдында җавап тотарга киткәчтен, үзенең алга таба монда кала алмавына тәмам төшенде һәм качарга дигән ниятен тормышка ашырырга булды. Ул кача-нитә калса, ялгызы гына түгел, берничә легионер белән бергә китәрбез, дип сөйләшеп тә куйган иде. Шигырьләрен дә дәфтәрләргә күчереп әзерләп куйды. Кайбер шигырьләре өч дәфтәрендә дә кабатлана. Берсе исән калмаса, туган илгә икенчесе кайтыр дип өметләнде ул. Шуларның берсен Алишка тапшырды. Икенчесен беркөнне Крушинода булган концерттан соң музыкаль капеллада җырлаучы Әхмәт Шәриповка биргән иде.

– Ярый, хәерле юл сезгә. Юлда сак булыгыз инде. Польша аркылы китегез. Аннан ышанычлырак булыр, – диде Алиш.

Унгляубе Шәфи Алмасны янә эттән алып эткә салып сүкте. Немец лексиконында булган бер әшәке сүзне дә калдырмады.

Шәфи, чынлап та, бөтен гаепне Саттар өстенә аударды. Унгляубега аны күп гөнаһларда гаепләп, зур гына шикаять язган иде. Кыям Галиевкә дә эләкте. Аны кулга алдылар. Ә Саттарны таба алмадылар. Ул эзсез юкка чыкты.

Саттар Гайнан төркемендәге тагын дүрт егет белән башта Познань шәһәренә китте. Барысы да немец унтер-офицерлары киеменнән йөргән качакларны юлда тоткарлаучы булмады. Аларның максаты поляк партизаннарын эзләп табу һәм, аларга кушылып, дошманга каршы көрәшне дәвам иттерү иде. Ләкин киемнәренең немец офицерларыныкы булуы аларга каршы эшләде. Инде партизаннарга җитәбез дигәндә, урманда засадага очрадылар. Поляк партизаннары русларны гына түгел, немец киемендәге полякларны да яратмыйлар, сатлыкҗан дип кабул итәләр иде. Саттар егетләре, без – рус әсирләре, дип, коралларын ташлап, кулларын күтәрсәләр дә, алар белән сөйләшеп торырга теләмәделәр. Бишесен дә бер автомат чираты белән кырып салдылар.

Икенче көнне Муса яшерен оешма җитәкчеләрен җыеп, алда торган бурычлар турында сөйләшергә булды. Франциягә, Голландиягә җибәрелгән икенче, өченче батальоннар турында да Шәфинең кәефен кыра торган хәбәрләр генә килә иде. Шуңа күрә алга таба комитетта эшләр көннән-көн авырлаша, катлаулана барды. Яшерен оешма алдында да ниндидер җитдирәк операция үткәрү турында киңәшләшеп алырга кирәк иде. Муса егетләргә зоопарктан ерак түгел генә урнашкан «Ам Цоо» ресторанына җыелырга кушты. Әхмәт Симаевның листовкалар ишәйтә торган типографиясе дә шуннан ерак түгел бер йортта урнашкан иде.

Оешма утырышында Әхмәт Симаев, Абдулла Алиш, Фоат Булатов, Гариф

Шабаев, Фәрит Солтанбәков, Зиннәт Хәсәнов, Мичурин һәм Берлинга листовкалар алып китәргә дип Демблиннан килгән Ян Габдуллин белән Едлинодан килгән Абдулла Батталлар катнашты. Барысы да өстәлләренә Бавария сырасы китерттеләр. Күрше өстәлләрдә утыручыларның игътибарын җәлеп итмәс өчен, шаулашып, көлешеп утырдылар. Тыныч кына утыру җырлашып утырган немец солдатлары күңелендә ниндидер таныш булмаган чит телдә сөйләшүче татар егетләренә карата шик уятырга мөмкин иде. Муса сөйләгән чакта да үзара гәп корган кыяфәт чыгарырга тырыштылар. Муса соңгы вакытларда комитет тирәсендә барган ыгы-зыгы турында сөйләп алды.

– Оешманың эшләре начар бармый, – диде ул. – Легион башлыклары, беренче батальон Витебскида партизаннар ягына чыкканнан соң, башка батальоннарны көнбатыш фронтларга җибәрергә мәҗбүр. Безнең егетләр анда да тынгы бирми «дуслар»га. Ләкин комитетта яшерен оешма эшләве турында шикләнә башладылар бугай. Кулга алулар башланырга мөмкин. Уяулыкны арттырырга, саграк эш итәргә кирәк. Әхмәт, Совинформ нинди хәбәрләр сөйли анда? Шулар белән таныштырып китсәң иде, – дип, Җәлил Әхмәт Симаевка мөрәҗәгать итте.

– «Заря» гәзите егетләре Мәскәү белән элемтәгә керә башлаганнар. Совинформбюрога караганда, алардан алган хәбәрләр кызыграк. Шушы көннәрдә Италия армиясенең безгә каршы сугышучы дивизияләре тар-мар ителгән. Англия белән Америка гаскәрләре Италия территориясенә десант төшергән. Озакламый икенче фронт ачылырга мөмкин.

– Әйбәт. Безгә дә монда, фашистларның үз тылында, көрәшне көчәйтү мөһим. Мин август аенда, легионнарны берләштереп, баш күтәрү оештырырга, дип тәкъдим итәм. Фашистларның умыртка сөяген сындырырга вакыт җитте, егетләр. Казакъ, үзбәк, балкар, азәрбайҗан, әрмән легионнары арасында да яшерен оешмалар булырга тиеш. Шуларның җитәкчеләре белән элемтәгә керергә, гомуми баш күтәрү турында сөйләшүләр башларга кирәк. Власовның Азатлык армиясе подпольщиклары да шуңа әзерләнә.

## 11

Беренче татар батальонының Белоруссиядә партизаннар ягына чыгуыннан соң, фашистларның милли легионнарны Кызыл Армиягә каршы турыдан-туры сугышка кертү турындагы планнары җимерелде. Алар, бәласеннән башаяк дигән шикелле, төрки батальоннарны да, грузин, әрмән кебек халыкларның әсирләрен дә көнбатыш фронтка – Франция, Голландия, Югославия, Албания, Бельгия, Чехославакия кебек Европа илләренең партизаннарына каршы сугышырга җибәрергә тотындылар. Чөнки Европаның фашистлар басып алган бөтен илендә дә аларга каршы халык патриотлары партизан сугышлары алып бара иде. Ләкин легионерлар арасында яшерен оешмалар уздырган агитация үз эшен эшләде, аларның әледән-әле партизаннар ягына чыгулары хакында хәбәрләр килә башлады.

Совет гаскәрләренең зур җиңүләре белән рухланып, Европа илләрендә дә фашистларга каршы көрәш көчәйде.

Сугышны яшен тизлегендә үткәреп, җиңү яулау турындагы планнары барып чыкмаган нацистлар Сталинград фронтындагы җиңелүләреннән соң 1943 елның җәендә яңа операция оештырырга план кордылар. Германиядә армияне көчәйтү һәм яңа көчләр белән тулыландыру өчен, тоталь мобилизация үткәрелде. Ундүрт яшьлек үсмерләрдән алып кулына корал тота алган барлык

карт-корыга хәтле, барысы ике миллионга якын кеше рейх армиясенә солдатка алынды.

Фашистлар җәй айларында Совет гаскәрләренә каршы яңа операциягә әзерләнгәндә, аларның тылында, Германиянең үзендә һәм төп хәрби лагерьлары тупланган Польшада легионерлар баш күтәрергә әзерлек башлады. Муса, лидерлары Мостафа Шокай үлгәннән соң, Төркестан легионында әйдаманлыкны үз кулына алган үзбәк эмигранты Вәли Каюм-хан белән очрашырга кирәк дигән фикергә килде. Әмма Мусага Төркестан комитеты лидеры белән очрашу насыйп булмады.

Розенберг министрлыгының беренче татар батальонындагы уңышсызлыгыннан соң, легионнар Өченче рейхның баш яшерен полиция башлыгы Генрих Мюллер службасының нык күзәтүе астына алынды. Вустрау лагере ябылды. Әсирләрне легионнарга җибәрү туктатылды.

Әле март башларында ук Мюллер үзенең резиденциясендә Тышкы эшләр, Көнчыгыш биләмәләр министрлыклары вәкилләрен, Төркестан, Идел-Урал, Кавказ комитетлары җитәкчеләрен җыеп, зур киңәшмә үткәрде. Мюллер киңәшмәдә катнашучыларның тетмәләрен шәп тетте. Иң каты эләккәне Шәфи Алмаска булды. Башкаларның да башларыннан сыйпамады. Ләкин Шәфи Алмас киңәшмәдән, «бу мәхшәрдән котылсам, ике көн дә тормас идем, китәр идем бу «Идел-Урал»дан, дигән уйлар белән кайтты. Яушев заводларындагы янгыннардан да ныграк тәэсир итте Шәфигә Мюллерның бу киңәшмәсе.

– Шәфи әфәнде! Беләсезме, минем ярдәмчем Райнер Ольцша сезгә нинди характеристика бирә?

– Һич белмим, Мюллер әфәнде.

– Белергә иде. Ул сезне үз вазифагызга туры килми торган президент дип бәяли.

Мюллер, сүзләрен раслатыр өчен, киңәшмәдә катнашучы Ольцшаның үзенә мөрәҗәгать итте:

– Раслыйсызмы үз сүзегезне, Ольцша әфәнде?

– Раслыйм гына түгел, Шәфи әфәндене азат итәргә кирәк бу эшеннән дигән фикердә торам.

– Ишеттегезме, Шәфи әфәнде?!

– Ишеттем.

– Бик начар пропаганда алып барасыз легионерлар арасында. Пропаганда түгел, антипропаганда алып барасыз!

Мюллер өстәлендә яткан папкасыннан бер бит кәгазь чыгарып, һавада селкеде:

– Менә нинди пропаганда алып барасыз! Укып күрсәт әле, Биддер әфәнде, нәрсә язалар бу листовкада подпольщиклар?! – диде дә, кәгазьне тәрҗемәчесенә биреп, урыс телендә язылган листовканы укып чыгарга кушты.

Легионерларга мөрәҗәгать итеп язылган листовкада: «Фашист пропагандасына бирелмәгез, мылтыкларыгызны дошманнарга каршы юнәлтегез, тиздән булачак «икс» көненә әзер торыгыз!» дигән чакыру сүзләре бар иде.

– Иң кызыклысы һәм фаҗигалесе: листовка рейхсминистр Геббельс резиденциясендәге машинкада басылган! Никадәрле кыю һәм әдәпсез адым! Каһкаһә! Нинди «икс» көне ул?! Бунтмы?!

Мюллер беркавым сүзсез торды, листовканы яңадан папкасына яшерде һәм, кесәсеннән кулъяулык алып, маңгаена бәреп чыккан тир тамчыларын сөртте, галстугын бушатып, күлмәк изүләрен чиште.

– Эшне һич кичекмәстән төзәтергә кирәк, Шәфи әфәнде! Аңлыйсызмы?! Башкалар да – мыекларыгызга чорнап куегыз! Бүгеннән легионерлар арасына яшерен агентлар кертеләчәк. Һәр кеше аерым күзәтү астына алыначак! – Мюллер папкасыннан тагын бер кәгазь тартып чыгарды. – Ә менә бу листовканы поляклар язган дип бара тикшерүчеләр. 826 нчы батальонның дүртенче ротасы старшинасы Сөләйманов яткан матрас астыннан табылган листовканы ничек итеп поляклар язган дип әйтергә мөмкин?! Тикшерү эшләре дә канәгатьләнерлек алып барылмый.

Рейхсминистр үз кул астындагыларга да җитди кисәтүләр ясады. Кыска срокларда Сөләймановтан табылган листовканың очына чыгарга боерды.

Киңәшмәдән соң Сөләйманов матрасы астында табылган листовка буенча эш тагын да куркыныч төс алды. Аны кулга алдылар, карцерга ябып куйдылар һәм сорау алуларны көчәйттеләр. Сөләйманов беркемнең исемен атамаса да, сораша торгач, тикшерүче гауптман Геле листовка табылыр алдыннан ике атна элек кенә батальон легионерлары янына Демблиннан музыкаль капелла килеп концерт куеп киткәнлеген ачыклады. Капелланың җитәкчесе Гайнан Кормашевка шик төште. Геле кичекмәстән капелла составына шымчы кертергә, дигән карарга килде. Кешесе дә табылды. Едлинода Шәфи Алмас комитетта пропагандист булып эшләргә дип сайлап алган Мәхмүт Җамалетдинов атлы бер егет бар иде. Чыгышы белән Үзбәкстаннан. Егерме ике яшьләрдә. Мәхмүт үзенең комсомолда булганын да яшерми. Легионга язылырга үгетләп йөргәндә, әсирләр алдында немецларны эттән алып, эткә салып сүгәргә дә куркып тормый. Тегеләргә дә, боларга да ярарга тырыша. Легионерлар арасында үзе дә гади легионер булып йөргән батальонның контрразведка башлыгы Геле Мәхмүт белән әңгәмәләрендә аның шактый ук аумакай, үзенә файдалы вакытта, күп уйлап тормыйча, теләсә кемне сата ала торган кеше икәненә төшенде һәм музвзвод составына аны кертергә кирәк дигән нәтиҗәгә килде. Батальонда пропагандистларны легионерлар арасында Мичурин дигән фамилиясе белән генә атап йөртелә торган унтер-офицер сайлап ала иде. Гайнан пропагандистлар арасында Мичурин барлыкка килгәч, аны төрлечә сынап, яшерен заданиеләр биреп, ышанычлы егет икәнен ачыклады. Яшерен төркемнең шактый гына җаваплы эшләрен аңа тапшыра торган булды. Ләкин капеллада Җәлил изге ант бирдереп оешмага алган кешеләр Гайнан белән Баттал һәм Рушат кына иде. Мичуринга андый төркем барлыгын белгертмәделәр. Мәхмүт Җамалетдиновны батальонга пропагандист итеп, урнашкан тәртип буенча, Мичурин билгеләмәде, киресенчә, ул билгеләгәнне, гадәттә, раслау белән генә шөгыльләнә торган батальон командиры, капитан Гаумиц белән контрразведка начальнигы Геле тәкъдим иттеләр. Өстәгеләр кушкач, Мичурин алар кандидатурасын кабул итмичә булдыра алмады. Шулай итеп, батальон пропагандистлары арасына Мәхмүт Җамалетдинов дигән егет өстәлде.

Кичен Мичурин бу хакта Гайнанга сөйләде. Гайнан аңа сак булырга, яңа пропагандист белән бик ачылып китмәскә дип киңәш бирде.

Мичурин – татар егете иде. Чын исем-фамилиясе – Гали Корбанов. Ул белгечлеге буенча юрист, сугышка кадәр 97 нче җәяүле дивизиянең прокуроры булган. Сугышны беренче көненнән үк – фронтта каршылый. Чолганышта калып, үзен-үзе атып үтерергә талпынып карый, ләкин винтовкасының штыгы комачаулап, пуля аның ияген генә җимереп читкә оча. Нәтиҗәдә, әсирлеккә төшкәч, аңа озак кына лазаретта дәваланырга туры килә.

Капелла батальонда дүртенче ротаның эшче взводы дип саналды. Аны, гадәттә, музвзвод, дип йөрттеләр. Матрасы астыннан листовка чыккан Сөләйманов та шушы взвод легионеры булып хезмәт иткән иде. Капелла көн саен диярлек кичләрен репетицияләр үткәрә. Мәхмүт Җамалетдинов беренче көнендә үк репетиция барган блокка килеп, артистларның җырлаганын, коралларда уйнаганын карап утырды.

– Мин дә, мәктәптә укыганда, шигырьләр сөйли идем, – диде ул Гайнанга. – Берәр концертта мине дә катнаштырсагыз иде.

– Бездә бит барысы да профессионал артистлар. Бу үзешчәннәр бригадасы түгел. Ә хәзер, барыгыз, үз барагыгызга кайтып ял итегез. Иртәгә лагерьда концерт булачак. Шунда күрерсез егетләрнең нәрсәгә сәләтле икәнен, – дип, Гайнан Мәхмүтне репетиция барган җирдән чыгарып җибәрергә ашыкты. Аның егетләр белән кайбер мәсьәләләр буенча сөйләшеп аласы бар иде.

Мәхмүт карышып тормады. Барактан чыгып китте. Артистлар, репетиция ясаган кыяфәт чыгарып, кайсы җырлагандай итенде, кайсылары торбаларда баракны яңгыратты. Ә Гайнан берничә егет белән генә алда торган эшләр турында әңгәмә үткәрде.

Җамалетдиновның музвзвод тирәсендә йөри башлавына ике ай чамасы вакыт узды. Барысы да аңа ияләштеләр. Ул артык чәчрәп чыкмый, сораган, кушкан эшләрне карусыз гына, җиренә җиткереп үтәргә тырыша иде.

Август башларында Едлинога Муса Җәлил килде. Тагын биш көннән дүртенче батальон легионерлары өчен концерт планлаштырылган. Батальон ышанычны акламаган, һәм Бельгиягә җибәрелгән өченче батальон урынына беренче сентябрьдә Көнбатыш Украинага озатылырга тиеш иде. Җәлил аңа кадәр Әрмән легионы һәм поляк партизаннары белән берлектә Татар легионының восстаниесен үткәрү турында яшерен оешмалар үзәгенең карарын әйтергә дип килгән иде. Ул «Шүрәле» дигән комедия язган һәм, Шәфи Алмасның ризалыгын алып, шушы дүрт көндә комедиянең репетициясен үткәрергә җыенуын әйтте.

– Безгә дүрт-биш көн бирелә. Репетиция ширмасы астында баш күтәрүгә бик җентекләп әзерләнергә кирәк, – диде Муса Гайнанга, артистлар җыйналыр алдыннан. – Берәрсен иртәгә Берлинга җибәрергә. Симаев белән Алиш анда листовкалар әзерләп куярга тиеш. Шуларны алып кайтырга кирәк.

– Миңа батальон командиры иртәгә үк берәрсен фашистик агитация китаплары алып кайтырга Берлинга җибәрергә кушты.

– Кемне җибәрергә уйлыйсың соң?

– Батталны дип тора идем.

– Алайса, Баттал Алиш белән очрашсын, аннан листовкаларны алсын. «Идел-Урал» гәзитенең соңгы санын да алып кайтса, әйбәт булыр.

Икенче көнне Баттал юлга кузгалырга торганда, аны батальон командиры Гаумиц чакыртып алды.

– Үзеңә генә авырга туры килер. Китапларны да күтәрешеп кайтыр, иптәш тә булыр, унтер-офицер Мәхмүт Җамалетдинов белән бергә барып кайтыгыз, – диде ул.

Гел комитетчылар арасында, артистлар янында елышып йөргән кеше булгач, Баттал Мәхмүтне ияртергә каршы килмәде.

Поездда алар юл буе сөйләшеп бардылар. Мәхмүт үзенең сугышка кадәр кем булуын, кайларда эшләвен сөйләде. Үзбәкстаннан икән. Үзенең комсомолец икәнлеген дә әйткәч, Баттал беркатлылыгы, кешеләргә ышанучанлыгы белән,

аннан шикләнми башлады. Дөрес, яшерен оешма булуы, листовкалар чыгарып таратулары хакында сүз чыкмады.

Берлинда Мәхмүт, Батталдан бер адым да калмыйча, гел аның белән йөрде.

– Мин Берлинда әле беренче тапкыр. Адаша-нитә калсам, нишләрмен. Немец телен дә белмим, – диде ул.

Абдулла беренче көнне аны үзе белгән кадәр Берлин белән таныштырып йөрде. Зоопаркка да алып барды, Александрплац мәйданындагы һәйкәлләрне дә күрсәтте. Паркларга да алып керде. Икенче көнне алар «Идел-Урал» редакциясендә булдылар. Баттал, бер кеше белән сөйләшәсем бар, дип, Мәхмүтне Шәфи Алмасның кабул итү бүлмәсендә Сабит Кунафин янында калдырып, Алиш бүлмәсенә кереп китте.

– Кем белән йөрисең анда? – дип сорады Батталны таныш түгел кеше белән күргән Алиш.

– Комитет пропагандисты, – диде Абдулла. – Шикләнмә, ул берни дә белми. Миңа иптәш итеп кенә җибәрделәр.

– Кара аны, соңгы араларда бик нык тикшерәләр. Шымчыларның берсе булуы бар.

– Ул лагерьда март башыннан бирле инде. Андый-мондый шикле эшләре сизелгәне юк. Аралашучан егет. Комсомолец.

Ә Җамалетдинов Кунафин белән күптәнге танышлар, аның шымчы икәнен бик яхшы белә иде.

– Сезнең монда бик куркыныч кешеләр эшли икән. Сак булыгыз. Берсе белән менә ике көн инде Берлин буйлап аның дусларын күреп йөрибез, – диде ул Кунафинга.

Алар Берлиннан өченче көнне кич кенә кайттылар. Өч көн буе аралашып, сөйләшеп йөри торгач, Баттал Мәхмүткә үз кеше кебек карый башлады. Ул хәтта бер төргәк листовканы аңа күтәртеп йөртте. Мәхмүт төргәктә ни барын белми иде. Ул Абдулладан:

– Нәрсә бу? – дип сорады.

– Листовкалар, – диде Баттал.

– Листовка дигән сүзне ишетеп, Мәхмүтнең коты алынды. Куллары калтырана башлады.

– Курыкма, беркем дә белмәс.

– Тикшерсәләр? Гел шуны гына эзләнеп йөриләр бит.

– Тикшерә башласалар, җиргә ташларсың. Мин белмим, минеке түгел, диярсең. Без гел шулай итәбез, – диде Баттал.

Алар төргәкләрен музвзвод шөгыльләнгән баракка, Гайнанга кертеп бирделәр. Гайнан Абдулла белән бергә Берлинга Мәхмүтнең дә барганын белми иде. Аларны икесен бергә күргәч аптырап калды. Беркавым нәрсә әйтергә дә белмичә торгач, Мәхмүтнең төргәгеннән җитмеш листовка санап алды һәм аның кулына тоттырды.

– Син хәзер безнең белән. Боларны концерт буласы көнгә кадәр үзеңдә сакла, – диде.

– Кая куйыйм мин аларны?

– Мендәр йә матрас астына яшер. Кешегә сөйләмә. Беркем дә белмәс, – диде Гайнан. – Ә хәзер, барыгыз, баракларыгызга.

Мәхмүт үз барагына кереп калды. Абдулла үз барагына китте. Юлда аңа Мичурин очрады.

– Җамалетдинов сизмәдеме нишләп йөргәнеңне? – дип сорады ул аннан.

– Без аңа бер төргәк листовка бирдек сакларга.

– Син нәрсә?! Сатса?!

– Өч көн бергә йөреп, бер дә кырын сүз ычкындырмады. Ышанычлы кеше булырга тиеш, – диде Баттал. – Сатмас, листовкалар анда да булгач, безнең белән бер төркемдә саналачак бит.

– Ярар, сатса, ул да безнең белән бергә эш алып барды, дип торырбыз. Шулай да артыннан күзәтергә кирәк.

Гали Корбанов Мәхмүт белән бер барактан иде. Ул, Гайнан янына кереп, үзенең шиген әйтте. Гайнан, төргәкләрне чишеп, листовкаларны бүлгәләү белән мәшгуль иде.

– Боларны бер урында саклау куркыныч, үзебезнең егетләргә өләшеп чыгыйк әле, – диде Гайнан. – Син Мәхмүтне күзәтерсең. Боларын Рушатка, Зиннәткә, Әмировка бирергә кирәк. Матрас асларына яшерсеннәр.

Муса тугызы көнне яшерен оешма егетләрен җыеп киңәшмә үткәргән дә, баш күтәрү ундүртенче августка билгеләнүен әйтеп, шул ук көнне Берлинга кайтып киткән иде. Киңәшмәдә Гайнан, Сәйфелмөлеков һәм Хисаметдинов катнашкан. Гарәф каравылда торган. Муса егетләргә поляк партизаннары белән элемтә урнаштырылуын, коралларның Яушев заводыннан алыначагын әйткән; баш күтәргәндә, кем нинди эш башкарырга тиешлеген тәгаенләгәннәр.

**12**

Ул төнне Гали Корбановның күзенә йокы кермәде. Ә аннан ерак түгел генә койкада, йоклый алмыйча, Мәхмүт Җамалетдинов аунады. Төннең билгеле бер сәгатендә йокы дигән нәрсә, кеше никадәр генә уяу булырга тырышса да, үзенекен итә, күзләрен барыбер йомдыра һәм адәм баласы илле минутка бернинди тавышка да исе китми торган тирән йокыга тала. Гали дә шундый билгесезлек томанына чумып, күпмедер вакыттан соң өстенә ябырылып килгән ниндидер хәшәраттән коты алынып, сискәнеп уянып китте. Ул уянуга сикереп торып утырды һәм Мәхмүт койкасының буш икәнен күрде. Галинең йөрәге жу итеп китте. «Сатарга киткән», дип уйлады ул. Әле генә изелеп йоклап харап булган Галине инде бүтән йокы алмады. Ул төн буе әле бер, әле икенче якка боргаланып, әле авыр сулап, әле тын да ала алмыйча интегеп ятты. Берәр сәгатьтән ишектә Мәхмүт күренде. Күзе шундук Галинең ятагына төште. Аның уяу икәнен күреп, ул эче борчыган кеше кебек, корсагына ябышты. Аһ-уһ килгән булып, койкасына барып ятты. Аның күзенә дә таң атканчы йокы кермәде. Гали Мәхмүтнең, чынлап та, үзләрен сатканлыгын аңлады. Ләкин кемгә дә хәбәр итәргә инде соң иде. Иртән, торырга дигән команда булуга, аларны, сафка тезеп, ашханәгә алып киттеләр. Гали, башка көннәрдәгедән үзгә буларак, барак ишек төпләрендә һәм ашханә янында овчаркалар җитәкләгән немец солдатлары басып торуын күрде. Аларны ашханәдә легионның контрразведка начальнигы капитан Линкес белән батальон командиры Гаумиц каршы алды. Алар легионерларга утырырга рөхсәт бирмәделәр. Гаумиц, көндәгечә, аларны Guten morgen[5] дигән сүзләр белән каршы алмыйча, «Легионда татар һәм немецларның дошманнары барлыгы билгеле булды», – дип башлады.

– Үзегезгә күрсәтелгән зур ышанычны акламыйча, бөек фюрерга каршы җимерү эше алып барасыз! – дип кычкырды ул, төкерекләрен чәчә-чәчә.

Ул арада ишектән ниндидер кәгазь тоткан батальон контрразведчигы Геле

[5] Хәерле иртә *(нем.)*

килеп керде дә кәгазен, йөгереп барып, Гаумицка тоттырды. Анысы кәгазьдәге язуга күз йөртеп чыкты да:

– Гайнан Курмашёф! Рушад Хисамутдинof! – дип, исемлек укый башлады. – Vortreten[6]!

Гайнан белән Рушат алга чыгып бастылар.

– Wegführen![7] – дип команда бирде Гаумиц.

Ишек төбендә басып торган солдатларның икесе килеп, Гайнан белән Рушатны ашханәдән алып чыгып китте.

Батальон командиры исемлекне укуын дәвам итте:

– Зиннат Хасаноф! Аптулла Батталоф! Али Курбаноф! Шариф Амироф!..

Унбишләп кешенең исем фамилиясе укылганнан соң, аларны да бер адым алга чыгардылар, һәм дүрт-биш солдат килеп, ишеккә таба куалады.

Легионерлар: «Тагын кемнәрнең исемнәрен атарлар икән? – дигән курку катыш кызыксыну белән тын да алмыйча торганда, Гаумиц: «Махмут Ямалутдиноф!» – дип кычкырды. Солдатлар Җамалетдиновны алып чыгып киткәч, легионның контрразведка башлыгы Линкес, сүз алып, Гаумиц сүзләрен кабатлады. Шуннан соң легионерларга иртәнге ашка утырырга рөхсәт иттеләр.

Кулга алынучыларны, лагерь фургонына утыртып, Варшава төрмәсенә алып киттеләр. Лагерь территориясен чыгып, беркадәр баргач, автомашинаны туктатып, Мәхмүт Җамалетдиновны төшереп калдырдылар.

Алдагы көнне Батталлар комитеттан китүгә, Кунафин, Шәфи Алмас янына кереп, Мәхмүттән ишеткәннәрен түкми-чәчми аңа сөйләп бирде. Шәфинең бу яңалыктан тәне калтырый башлады. Кан басымы күтәрелде. Ул, калтырана-калтырана телефон трубкасын алып, Угляубега шалтыратты, аның белән һич кичекмәстән очрашырга кирәклеген әйтте.

Ә ике сәгатьтән «Винета» радиостанциясенең татар тапшырулары редакциясенә биш кеше килеп керде. Алар бүлмәдәге хезмәткәрләрнең бишесен дә бастырып бер рәткә тезделәр һәм өстәлләрне, тумбочкаларны, шкафларны актарырга, кәгазьләрне берәм-берәм тикшереп, китапларны ачкалап, нәрсәдер эзләргә тотындылар.

– Сез кулга алынасыз, – диде тикшерүчеләрнең берсе. Ахры, төркемнең җитәкчесе булгандыр. – Шәхси әйберләрегездән кала бернәрсә дә алмагыз.

Әхмәт Симаев, Афзал Фәтхуллин, Фәйзелхак Мингалин, Кәбир Газиев һәм Шәмсия Идрисине бүлмәдән алып чыгып киттеләр, Александрплац төрмәсенә илтеп, аерым камераларга ябып куйдылар.

Шул сәгатьтә үк «Идел-Урал» редакциясендә дә тентү үткәреп, Алиш белән типографиядә хәреф җыючы булып эшләүче Гариф Шабаевны кулга алдылар. Ә кечке якта Едлинодан репетиция үткәрергә дип киткән җиреннән кайтып кергән Мусаны фатирында гражданскы киемдәге таныш түгел ике ир көтеп тора иде.

*Икенче бүлек тәмам.*

---

[6] Бер адым алга! *(нем.)*

[7] Алып китәргә! *(нем.)*



Җәүдәт
Сөләйман

# АЯКТАГЫ ТЫШАУ ӘЛЕ КОЛЛЫК ТҮГЕЛ...

## Җуелмасын гына...

Аяктагы тышау әле коллык түгел,
Бәйләсә дә аякларны бергә.
Һәм казык та шулай, әле коллык түгел,
Бәйләсә дә баш-аяктан җиргә.

Давыл йолкып ала җирдән казыкларны,
Тышауларны үткер кылыч кисә,
Җуелмасын гына, канга-җанга сеңгән
кылычлардан үткер дала исе.
Давыллардан көчле ирек хисе...

## Чир

Чир белән җир бердәй яңгырашлы,
Ахры, чир ул махсус җирдән килә,
Безнең тәннәр бит ул җиргә азык,
Чир кимергән тәннәр җиргә иңә.
Авырулар килә-китә тора,
Куркынычы аның – исемсез чир,
Ул аждаһа – шулай азык җыя,
Җир куены көтә тәнне... тәкъдир.
Ахры, чир ул әҗәл токымыннан,
Чир-кармагын җайлап сала әҗәл,
Җан-бәгырьгә үрелгәннән бирле,
Шуннан котылырга эзли әмәл...

Җәүдәт СӨЛӘЙМАН (1955) – *галим, ТР Фәннәр академиясе академигы, шагыйрь; «Ямаулыклар», «Мин минсез дөньяда», «Күләгәләр» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт, М.Җәлил һәм Г.Исхакый исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

***

*Әнигә*

Тиз йөрешле поезд. Оча Нарбоннага[1].
Бордо[2] төбәгеннән юл үтә.
Бордо, дигәч, телдә кызыл шәраб тәме...
Хатирәләр – тирән. Ә ...истә!
Уңнан-сулдан очып үтә тоташ таулар,
Поезд тәрәзенә сыланып,
Мин авылда сыман, әни белән бергә,
Очып кайттым, хискә чолганып...
...Поезд тәрәзендә – зәйтүн агачлары,
Күңел тәрәзендә – наратлар,
Истә, әни, истә, чиләк тулы җиләк,
Үзең кара җиләк, ул чаклар...
Поезд оча гына! Чит-ят дөнья оча!
Бәдән фәкыйрь шунда, вагонда.
Ә мин үзем йөрим шәүрин буйларында,
Күңелем белән әни янында.
Мин поездда. Юлда. Әмма әни белән.
Шундый халәт – бер төш, бер өнем.
Юкка гына түгел, саташу да түгел –
Туган көне бүген әнинең...

## Кайдадыр көн туа...

Кичке шәфәкъ – әҗәл биләмәсе,
Болытларны манып шәмәхәгә,
Кәфен тегә сүнеп барган көнгә.
Кояш үзе әҗәл ятьмәсендә:
Сүреләә,
            күмелә,
                        төрелә бара шул кәфенгә.

Ятьмә күзләреннән йомры-йомры
чәчрәп чыгып кояш кыйпылчыгы
төнге күккә куна йолдыз булып.
Шул мизгелдә кайдадыр көн туа
Йорт-урамнар, күңелләргә тулып...

***

*Мирабель паласта концерт тыңлаганда...*

Зальцбург, Зальцах, Алып тавы[3],
Көйләрдән – үрмә-бишек.
Мин – бишектә. Оча күңел,
Җиде кат күккә күчеп.
Музыкантлар – фәрештәләр,
Тылсым тулы Мирабель[4].
Гайдн, Моцарт, Бах үзләре –
Скрипка, флейта, виолончель...

[1] Франциядәге шәһәр.
[2] Франциядәге төбәк исеме.
[3] Зальцбург – Германиядәге шәһәр исеме; Зальцах – Зальцбургтагы елга исеме; Алып тавы – Альп тавы.
[4] Мирабель – Зальцбургтагы бина-палас һәм шундагы концертлар залы.

## Читлек

Дәүләт. Дәүләт. Дәүләт...
Милләт. Хыял. Өмет.
Чикләр, чикләр, чикләр...
Телгәләнгән өммәт.
...Эчтән бикле читлек.
Читлектәге илләр...
Без соң җирдә кемнәр?
Читлектә дә – читләр...

***

Яши-яши күнегәсең табигатькә,
Диңгез-таулар урман-кырлар кебек якын,
Булсын Париж, Барселона йә Лиссабон,
Безнең белән бер калыптан, шул ук халкы.
Әйтмәс идем, монда ирек, ни теләсәң,
Шуны эшлә, күкләр, диеп, иксез-чиксез.
Монда да шул – дәүләт булгач, шул ук читлек,
...Әмма иркен читлекләре, эчтән биксез...

***

Барселона-Париж, ике шәһәр,
Ике мохит, әмма бер үк галәм.
Атылган ук булып поезд оча,
Тиздән – синдә, Париж,
бонжур, сәлам!

Котлар эзе тирән синдә Париж,
Кот иленнән[5] синең башланмышың,
Ул халыкның эзе тоныкланган,
Париж җуйган сүзләр яңгырашын...
...Ачуланма, Париж, сиңа түгел,
Атиллага күңел тарта бүген,
Тарта мине Каталуннар кыры[6],
Уклар сызгыруын откан күге...
Һун эзләрен тоя кан хәтере,
Бабалардан калган тамгаларны,
Кот оланнар, галлар, кельтлар иле –
Синдә рухы ерак бабаларның...
...Бу кырларда мәңгелеккә күчкән
Меңләп румнар, котлар, һуннар[7] каны,
Минем канда бүген
Кырны каплап кушылып аккан
канның тамчылары...

[5] Ил – Парижга нигез салучы кот халкы башта утрауда урнаша, шуннан Париж башлана. Утрауны алар ил дип атыйлар. Ягъни, Париж шул илдән-утраудан төзелә башлый (бу мәгълүмат «гид» сүзләреннән). Париждагы Сена (русча) елгасын да французлар Сен (Сөн) дип әйтә.

[6] Франциядәге Шампань өлкәсе Шалон шәһәре янындагы кырлар. Монда 451 елны Атилла җитәкчелегендәге һуннар белән Аэцией җитәкләгән румнар һәм визготлар арасында канлы сугыш бара. Ике яктан да йөз меңләгән яугир һәлак була. Бу сугыш-кырылышта җиңүче як булмаса да, тарихи мәгълүматларга караганда, шул сугыштан соң бер ел да үтми, Атилла үлә, шулай ук һуннар да, кыска вакытта, тиз арада таркалып юкка чыга.

[7] Каталун кырында сугышкан халыклар.

## Күңел тоя...

...Дөнья – тәмуг.
Әзме сызлау, бәргәләнү...
Тоя шуны тәнең, җаның, аңың булсын...
Кайтып-кайтып үзәгеңне телеп ала
чәнечкеле нәфес чыбыркысы.

...Дөнья – оҗмах.
Тән-өрфия өчен әзер
шифа сулы кизләүләре, саф һавасы,
нурлы кояш, татлы ризык-нигъмәтләре.
Хур иясе бишектәге һәр нарасый...
Күңел өчен меңләп төсләр, меңләп хуш ис,
Кошлар сайрый, моңлы-җырлы фани дөнья,
Аң чигендә зиһен үтмәс тибрәнешләр.
Акыл үтми моңа. Моны күңел тоя...

...Җәннәт-тәмуг – ике халәт бер дөньяда,
Гөлчәчәк күк. Чәчәге һәм энәләре...
Бер киселә, бер тырнала, бер сыйпала,
Шулдыр җанның күк катына үрләү мәле.
Сиңа, адәм, бердәнбер ул, ул бер дөнья,
Җәннәте дә, тәмугы да бергә шунда.
Башка җәннәт, башка тәмуг түгел, түгел,
Син адәмнән күккә ашкан бакый җанга...

## Дула, диңгез!

Учларыңда, диңгез, ташлар уйнатасың,
Син дулыйсың, гүя, ачулы,
Әйдә дула, диңгез, миңа шуннан рәхәт,
Дулкын баса йөрәк ярсуын.

Бер карасаң, дәһшәт, диңгез үрә баскан,
Күк йөзе дә кара, куркыныч.
Син улыйсың, диңгез, әйдә ула шулай –
Син улаган саен... мин тыныч.

Бар давылда үзенә бер сихри рәхәт,
Кайный дөнья, җанда – тантана!
Тәңре кодрәтендә ике халәт бергә:
Диңгез дулый – күңел шатлана...

Чыңгыз
Айтматов

# ЧЫҢГЫЗХАННЫҢ АК БОЛЫТЫ

«БЕР КӨН – БЕР ГОМЕР» РОМАНЫНА НИСБӘТЛЕ ПОВЕСТЬ

Төн пәрдәсе сыеклана башлаган ул сәгатьтә, кашка аты Акйолдызга атланып, аланнарда һәм олау табырларында йоклап яткан гаскәриләрне урап узганда, йөзбашы алда ни торганын уйлады һәм Ходайдан яңа туган сабый – гөнаһсызлардан гөнаһсыз җан иясе хакына булышлык итүен сорады, чөнки һәр яңа туган бала – ул Ходай хозурыннан вәхи-хәбәр; аның нияте буенча кемдер кайчан да булса кешеләр алдына, Ходайның үзе кебек, адәм кыяфәтендә килеп басачак, һәм шул чакта барысы да Алла бәндәсе нинди булырга тиешлеген күрәчәк. Ә Ходай ул – акыл ирешмәслек иксез-чиксез Күк. Кемгә нинди язмыш тиячәк – кемгә туарга да кемгә яшәргә – моны бер Күк кенә белә.

Йөзбашы Эрдене иярдә килеш, йолдызлы киңлеккә төбәлеп, күңеленнән Күкнең рәхим-шәфкатен сорарга тырышып карады, аннан язмыш җавабын көтте. Әмма Күк дәшмәде. Йокыга талган һәм төн сихрилегенә уралган Сарүзәк даласы өстендә ай гына миләүшә төсендәге яктылык агымы булып түгелә, бер ялгызы иң югары ноктада, бөтен күккә хуҗа булып тора иде...

Ә иртәнге якта яңадан добулбаслар, кешеләргә, торыгыз, коралларыгызны алыгыз, ияргә менегез, артык йөкләрегезне олауга ташлагыз, дип әмер биргәндәй, гөрселди, күкри башлады, һәм хаканның беркем дә тыя алмаслык чиксез хакимлеге илһам биргән, куалап йөрткән дала чирүе янә Кояш баешына таба юл алды.

Бу инде сәфәрнең унҗиденче көне иде. Сарүзәк даласының аеруча авыр үтелә торган, ифрат та киң өлеше инде артта калды, алдагы Җаек болыннарына бер-ике көннән барып җитәрләр, ә аннан соңгы юл изге сулары белән дөньяны ике өлешкә – Кояш чыгышы белән Кояш баешына бүлгән бөек Иделгә таба алып китәчәк.

Барысы да бер салынган сукмактан, күнегелгәнчә иде. Иң алда – биеп барган чем-кара атларда – байрак йөртүчеләр. Алар артыннан кизүвыллар һәм яраннар Чыңгызханны озатып килә. Хаканның ияре астында, һәрвакыттагыча тигез адымнар белән, яраткан юргасы, ак яллы, кара койрыклы Хуба атлый, ә баш очында, күз карашын иркәләп, хаканның йөрәгендә болай да көчкә тыеп торган яшертен масаю хисен кыздырып, әлеге дә баягы аерылмас юлдашы – ак болыт йөзә. Кая гына юнәлмәсен – ул да шул якка таба. Җирдән исә, офыкларны тутырып, Кояш баешына таба кешеләр ташкыны – Чыңгызхан чирүе, аның олаулары ургыла. Аларның ерактагы диңгез шавыдай гөрелтесе күккә хәтле

---

*Ахыры. Башы узган санда.*

күтәрелә. Исәбе-саны булмаган, иксез-чиксез, кешеләр, атлар, олаулар, корал, мөлкәт, хайваннардан хасил бу агым бөтенләе белән аның, Чыңгызханның, куәте һәм көченең гәүдәләнеше иде. Боларның һәммәсе дә аңардан килә, барысының да чыганагы – аның алдан ук билгеләп куйган ниятләре. Иярдә оеп барган шул мәлдә ул әле һаман, теләсә кем хыялланырга җөрьәт итмәгән, ә менә үзе зарыгып көткән нәрсә – бөтен дөньяны яулап алып, үлгәннән соң да хакимлек итә алачак, күк астындагы бер һәм бердәм, мәңгелек мәһабәт дәүләт кору уе белән яна. Ничек моңа ирешеп була? Кыя ташларына хәзердән үк төшерелергә тиешле Аның боерыклары аша. Ул фәрман-боерыкларны саклап торган кыялар исән булганда, дөнья белән аның ихтыяры идарә итүдән тукталмаячак. Шул сәгатьтә менә ниләр турында уйланды хакан, һәм, үлемсезлеккә ирешү ысулы буларак, ташлардагы язулар хакындагы кызыктыргыч фикер инде аның тынычлыгын алган иде. Ул моның белән кышын Идел ярында шөгыльләнергә карар кылды. Кичүне көткән арада галим-голамәне, акыл ияләрен һәм күрәзәчеләрне җыячак та мәңгелек дәүләт турында үзенең алтын фикерләрен җиткерәчәк, кыяларга уеп язылырга тиешле боерыкларын әйтәчәк. Бу сүзләр дөньяның астын өскә әйләндерер, һәм бөтен җиһан аның аяк астына егылыр. Ул шуның өчен яу сәфәренә чыкты да бит, җирдәге бөтен җан иясен әлеге максатка хезмәт иттерергә кирәк, ә моңа каршы килгән һәммәсен дә, уңышка ирешү юлында каршылык күрсәтүчеләрнең барысын-барысын – юлдан алып ташларга һәм юкка чыгарырга. Бугазына янә шигырь тыгыла башлады:

Дәүләтемнең алмаз түбәсенә  
кадап куярмын күктән айны алып... Әйе!..  
Чирүемнең чуен дагасыннан  
сукмактагы кырмыска да исән калып  
булмаслыгын белер... Әйе!..  
Көч-куәтнең чын бәһасен аңлый барып,  
атымның тирләгән савырыннан  
чал тарихның аумакай хурҗинын  
алыр әле  
яхшылыкның кадерен белгән яшь буыннар... Әйе!..

Шулай булып чыкты ки, нәкъ шул көнне, төш авышкач, Чыңгызханга, олаудагы бер хатын, мондый эшне ханның катгый тыюын бозып, бала тапкан, дип җиткерделәр. Кемнән тапкан – анысы әлегә билгесез. Бу турыда хептевыл (шымчы) Арасан әйтте – йөгерек кечкенә күзле, һәрвакыт бөтенесен белеп торучы кызыл яңаклы тынгысыз хептевыл бу юлы да беренче булып хәбәр китерде. «Минем бурычым барысын да ничек бар, шулай сиңа белгертү, бөекләрдән бөек хан, чөнки син бит бу уңайдан инде бер кисәттең». – Сүзләрен җил алып китмәсен өчен, хакан белән янәшә, өзәңгегә өзәңге тиеп барган хептевыл Арасан хырылдый төшеп кычкырды, муенын май баскан, шул аның тынын кыса иде.

Чыңгызхан әллә аңышып җитмәде инде, хептевылга шунда ук җавап кайтарырга ашыкмады. Ул мәлдә, күңел төпкелендәге ташъязмалар турында хыялга чумып барганлыктанмы, кинәт ыргылып кергән күңелсез хәбәргә тиз генә бирешәсе килмәдеме, әллә ул аңа шулай тәэсир итәр дип көтмәгәнен сиздермәскә тырышыпмы, Чыңгызхан шактый озак дәшмәде, бары тик атын куалап, аның адымын ешайта төште, инде кеш тиресеннән тегелгән җиңел тун итәкләре, куркынган кош канатлары сыман, як-якка очып бара башлады. Ә хептевыл Арасан, аңардан калышмаска тырышты, нишләргә дә белмичә,

уңайсыз бер халәт кичерде, үзенең янәшәдә булуы белән хаканның артык ачуын китермим, дип, атының тезгенен тартып туктатты, аннары, дәшә калса, аның сүзен ишетми калмас өчен, янә өзәңгегә өзәңге тиеп барды, тик хакимнең ни өчен шулай озак телсез калуының сәбәбен, мәгънәсен барыбер аңламады, югыйсә, аңа бит бары бер сүз генә әйтәсе иде, тик бер сүз: «җәзалагыз!» Һәм бөек хаканның яу сәфәрендә бала табуны тыюын санга сукмаска батырчылык иткән әнчекне дә, ул дөньяга китергән эт баласын да шул ук сәгатьтә анда, олауларда, буып үтерерләр иде. Башкаларга сабак булсын өчен, әдәпсез чәчбине киезгә урап тончыктыр, шуның белән бөтен эшкә чик куела лабаса.

Хакан кинәт җилкәсе аша гына шундый кистереп бәрде, хептевыл хәтта ияренда үрә катты:

– Соң нишләп, әле шул олау өстерәлчеге баласын тапканчы, берегез дә сизмәде-күрмәде аның көмәнле икәнлеген? Йә күреп тә эндәшмәдегезме?

Хептевыл Арасан моның ничек килеп чыгуын аңлатмакчы булып азапланды, тик әйтер сүзендә буталды, шуңа хакан аны тупас кына бүлдерде:

– Дәшмә ичмаса!

Бераз баргач, ул тагын зәһәр итеп сорады:

– Иясез икән, кем соң ул хатын: учак кабызучымы, пешекче яки мал караучымы?

Ә инде олауда бала тапкан хатынның байрак чигүче оста булып чыкканына чиктән тыш гаҗәпләнде, чөнки әлегә хәтле мондый эшләр белән кем шөгыльләнә, ничек кояш чыга һәм кайдан килеп яңгыр ява, – болар турында белмәгән кебек, кем тукымасын кисә дә аның алтын һоруңнарын чигә, кем аңа итек тегә яки гөмбәзләре астында бөтен тормышы аккан тирмәләрне кем кора, – бусын да беркайчан башына китергәне юк иде. Элек мондый вак-төяк турында ничектер уйланылмаган. Сәбәбе булмады: һәркайда – үз янында һәм чирүендә алан булып туктаган төшләрдә яки күңел ачу мәҗлесләрендә – ул килеп җиткәнче, ул күргәнче үк янып торган учаклар кебек, һоруңнар үзаллы җилфердәп каршы ала. Менә әле дә алда, юлын яктыртып, байрак йөртүчеләр ат биетеп атлый. Ул, Кояш баешына ятларныкын таптарга, аларны аяк астына салырга, дип, үз байраклары белән бара. Һәм шулай булачак та әле... Берни дә һәм беркем дә аны юлыннан бүләргә, аны туктатырга җөрьәт итмәс. Шул ук вакытта аның белән бергә дөньяны яуларга баручылардан кайсыныңдыр теләсә нинди, хәтта кечтеки генә буйсынмавы да үлем җәзасы белән киселәчәк. Буйсынмаган өчен җәза – берәүнең күпләр өстеннән хакимлеген алыштырмас корал. Ләкин бу очракта әлеге чигүче генә гаепле түгел, һичшиксез, баланы олауда яки гаскәрдә баручы кемдер ясаган бит... Тик кем соң ул?..

Шул сәгатьтән Чыңгызхан кара коелды, бу аның таш кебек каткан чыраеннан, керфек тә какмый торган селәүсен күзләренең авыр карашыннан һәм, җилгә каршы барган кебек, ияр дә утыруының киеренке рәвешеннән үк күренде. Әмма әлеге очракның, нинди дер чигүче һәм аның әлегә билгесез сөяркәсенең хакан сүзен ачу китергеч итеп тыңламавыннан бигрәк, күңелендә ачы, җуелмас, хурлыклы эз калдырган бөтенләй бүтән тарихны исенә төшерүе белән кәефен кырганын ашыгыч эшләр белән аңа якын килергә батырчылык иткәннәр арасыннан берәү дә белми иде.

Атасыз үскән бу ятимне һичкем дә, килер бер көн, ошбу үксез, тәрбиясез малай актыгы Дөньяның Дүрт Тарафы Әмире булыр, дип күз алдына китермәгән, ул үзе дә мондый хәлнең булырын уйлый алмаган вакытта, әле үзенең чын Темучин исемен йөрткәндә кичергәннәре, йөрәкне яндырып, яңадан кабатлангандай

булды. Ул чакта аңа гомерлек җәрәхәт салган бер вакыйга – авыр фаҗига һәм мәсхәрәләнү аша үтәргә туры килгән иде бит. Үсмер чагыннан ук «колагы киртеп куелган» яшь хатыны Бортэ ширбәт ае көннәрендә күрше меркитләр кабиләсенең һөҗүме вакытында урланып, әле аны каршы һөҗүм ясап кире кайтарганчы, әллә нихәтле, исәбе-хисабы булмаган, – ул чакта төгәл генә санарлык хәле дә юк иде, – көннәр һәм төннәр узды... Инде менә хәзер, күңел ярасы йомылган, берәүнең дә кулы мәңге ирешә алмаслык итеп үз исемен раслаган, бөтен дөньяны тетрәткән хаканның күпмеңле чирү башында Кояш баешын яуларга барган чагында шул аяныч хәлләр исенә төшәр дип кем уйлаган?!

Еракта калган ул төндә кара күкрәкле Этуген Җирендә яшь Темучинның үч алу анты яңгырады. Кабахәт меркитләр, өч көнлек канлы бәрелештән соң, коточкыч аяусыз кысрыклаудан, гадел җәзадан котылып, мескен гомерләрен саклап калыр өчен, торлакларын һәм ат көтүләрен ташлап, абына-сөртенә качтылар, ә үч алу антында шулай әйтелгән иде:

...Борынгы,ерактан күренгән байрагымны
яуга чыгар алдыннан мин корбанымның
канына манчыдым. Кан акты...
Үзем калын тавышы белән гөрселдәгән,
үгез тиресе тартылган добулбасны кактым.
Сырган кара көбәмне кидем дә
кара яллы йөгерек атыма утырдым.
Дәһшәтле кылычымны тотты кулым.
Ул әшәке меркитләргә бара юлым.
Алар белән сугышырмын мин үлгәнче...
Кырам бала-чагасына хәтле
меркитләрнең барысын.
Аларның җирләре, әйдә, бушап калсын...

Бу ант арат-киятлар ыругын үч алу орышына күтәргән Темучиннан куркып качучыларның акырышу һәм үкереп елаулары белән тулган төндә тормышка ашты. Качып баручылар уртасыннан өсте ябылган бер арба тәгәри иде. Як-якка бәргәләнеп тә аны таба алмыйча: «Бортэ! Бортэ! Син кайда? Бортэ!» – дип өзгәләнеп кычкырды һәм әлеге мәхшәрдә хатынын эзләп табарга тырышты Темучин, тик әлеге ябулы арбаны куып тоткач, аны куалап баручыларның һәммәсен кыргач кына: «Мин монда! Мин Бортэ!» – дип, хатын аңа каршы тавыш бирде һәм арбадан сикереп төште, ә ул атыннан җиргә тәгәрәде дә, алар бер-берсенә каршы ташландылар. Кочагына яшь хатыны исән-имин килеп сыенган мизгелдә ул йөрәгә кысып алганын тойды: таныш түгел ят ис, тәмәкедән сасыган мыек исе иде, ахрысы, кемнеңдер аның җылы, шома муенына капланып, тупас иреннәре белән кан чыкканчы суырып ләззәт алганын белгертеп тора иде. Ә бу вакытны тирә-юньдә канлы бәрелеш, орыш, үч алу дәвам итте...

Менә шул минуттан ул инде беркем белән дә якалашырга, сугышырга ташланмады. Әсирлектән коткарылган хатынын арбага утыртып, үзен көйдереп узган утны шунда ук тышка чыгармас өчен, берни дә әйтмичә, кайту юлына борылды һәм аннары бөтен гомере буе газапланды. Темучин аңлый: хатыны дошман кулына үзе теләп барып кермәде. Шулай булса да, ул ни исәбенә бу хәлдән котылып чыкты? Аның башыннан бер бөртек чәче дә төшмәгән ич. Төптән уйласаң, Бортэ әсирлектә җәфа чикмәгән, аның тышкы кыяфәте дә интеккән кешегә охшамаган иде. Юк, аннан соң да алар арасында бу хакта ачыктан-ачык сөйләшү-аңлашу булмады шул.

Шушы тар-мар итүдән соң исән калган меркитләрнең барысын да кырып бетерде диярлек, бүтән илләргә яки кеше аягы басмаган җирләргә күчеп китә алмаган аз санлы меркитләр инде, көтүче һәм хезмәтче булып, колга әверелделәр, алар хәзер һичнинди куркыныч тудыра алмыйлар иде. Берәүнең дә башына бу нәтиҗә – ул вакытта инде Чыңгызхан булып җитешкән Темучинның котылгысыз үчен гамәлгә ашыру икәнлеген аңламады. Меркитләрнең берсе дә, моның берзаман аларда әсирлектә булган Бортэгә нindидер мөнәсәбәте бар, дип әйтә алмый иде инде.

Соңрак Чыңгызханның тагын өч хатыны булды, тик язмышның теге вакыттагы беренче рәхимсез оруыннан калган авыртуны баса алмады. Хакан шул авырту хисе белән һаман яши иде. Беркемгә беленмәсә дә, каны саркып торган йөрәк ярасы белән. Бортэ беренче баласын – уллары Җучины тапкач, Чыңгызхан көннәр исәбен берәмтекләп санаган булды, әмма тегеләй дә, болай да килеп чыга, бала аныкы булырга да, булмаска да мөмкин иде. Билгесез булып калган кемдер, аның намусына тупас басып, бөтен гомеренә тынычлыгын алды, каһәр.

Инде бүтән билгесез зат, байрак тегүчегә бала ясап биргән ир, хаканга һичнинди мөнәсәбәте булмаса да, барыбер аның канын кайнатты.

Әле генә аңлаешлы, бөтенлекле дөньясы күз ачып йомган арада кыйшаеп, җимерелеп төшсен өчен, кайчак кешегә аз гына нәрсә дә җитә... Бөек ханның күңелен үзе кичергән хәлне искә төшерү актарып ташлады. Югыйсә тирә-юнендә барысы да шул хәбәрне ишеткәнчегә кадәрге кебек калды. Әйе, алдыннан, чем-кара атларын биетеп, аждаһалы һоруңнарын җилфердәтеп, әләм йөртүчеләр бара, ияре астында, – һәрвакыттагыча, яраткан юргасы Хуба; янәшәсендә һәм артыннан менә дигән чапкы атларында аңа йөгенгән яраннары калышмаска тырыша; як-ягында тугрылыклы сакчылары – ярты меңләп кизүвыллар көтүе; күз күреме араны иңләп, дала буйлап дошманны кырып барырлык көч-куәт – ничәмә-ничә төмәннән торган чиру һәм аларның таянычы – меңләгән олаулар ишелеп килә. Ә баш очында, бу кешеләр агымы өстендә, яуга чыккан беренче көннән бирле Күк-Тәңренең фатихасы булып, тугрылыклы ак болыт йөзеп бара.

Барысы да элеккечә кебек иде, шулай да, ханның әкренләп көчәя барган яшенен чакырып, кара болытлар куерды, дөньясында нәрсәдер урыныннан кузгалды, үзгәрде. Күрәмсең, кайсыдыр аның ихтыярын санга сукмаган, күрәмсең, кемдер үзенең тотнаксыз җенси дәртен аның бөек максатыннан өскәрәк куярга җөрьәт иткән, күрәмсең, ул адәмчек белгән көе аның боерыкларына каршы барган. Аның атлы гаскәреннән кемдер, хаканга тел-теш тидермәслек, тайпылышсыз хезмәт итәргә сусау урынына, бер җилбәзәк хатынның түшәген артыграк күргән! Һәм нindидер өч тиенлек ул хатын да – аңардан соң бүтән беркем байрак чигә алмас дип уйлады микән? – Ханның тыюын санга сукмыйча, олаудагы башка бөтен хатыннар, аерым рөхсәт булганчы, үз карыннарын саклаган вакытта, бала табарга тәвәккәллек иткән!..

Әлеге уйлар, явызлык болытлары белән күз яктысын каплап, чүп үләне, кыргый урман кебек акрынлап үсә барды, гәрчә бу очракның кисеп ташлаган тырнакка да тормаслыгын, аңа артык әһәмият бирмәскә кирәклеген аңлый да кебек ул, әмма эчендәге икенче тавыш, боеручан көч белән башына тукый-тукый, торган саен шәфкатьсезрәк була бара, сүзен аяк астына салып таптаганнарны бөтен чиру алдында кырыс җәзага тартуны таләп итә, бүтән фикерләрне баса һәм кысрыклап чыгара иде.

Хәтта тынгысыз Хуба, һәрвакыт ук кебек атылып тип-тигез оча торган юрга,

ул көнне хакан ияр өстендә генә үткәргәнлектән, юл дәвамында арта барган ниндидер өстәмә авырлыкны тойган кебек, күбекләнеп торган тиргә батты, элек мондый хәлнең булганы юк иде.

Чыңгызхан, чыраена дәһшәтле төс чыгарып, үзалдына йомылды, әмма алга баруыннан туктамады. Бөтен дөньяда хакимлеген урнаштырырга дигән бөек ниятен тормышка ашыру өчен, дала ташкынының Кояш баешына таба хәрәкәтенә бернинди көч тә комачаулык итә алмас кебек тоелса да, барыбер нидер булды: күзгә күренми торган, энә очы кадәрле генә бер чуерташ аның боерыкларыннан өелгән мәңге какшамас кебек тау башыннан аска таба тәгәрәп китте һәм бөтен күңел тынычлыгын юкка чыгарды. Ул юл буе шул хакта уйланды, тырнак астына кергән шырпы төсле, гел бер нәрсә аны борчыды, һәм, чуалган җепнең очын сүтеп-сүтеп тә таба алмаганга, үз тирәсендәге якыннарына торган саен ныграк ачуы килде. Ничек ул менә әле генә, теге ыштырбит инде баласын тапкач, аңа килеп әйтергә батырчылык итәләр, ә моңарчы алар кайда булган, кая караганнар, корсаклы хатынны күрмичә торып буламыни? Ул чакта сөйләшү дә икенче төрле булыр иде, азгын эт кебек артына тибә-тибә куып кына җибәрерләр иде аны. Ә хәзер ничек хәл итәргә? Килеп чыккан хәл турында аңа хәбәр ирешкәннән соң, олаулар өчен җаваплы нойонны аңлатып бирү өчен чакырып, ул аңардан зәһәр итеп сорап куйган иде: чигүче хатын баласын тапканчы, тугрылыклы шымчылар ишеткәнче, ничек шулай килеп чыга алды, бөтенесе дә беленмәс килеш торды? Ничек болай була ала ул? Нойон борын астыннан гына буталчык җавабын мыгырдады: имештер, Догулаң исемле байрак чигүче ул хатын аерым тирмәдә, һәрвакыт читтәрәк яшәгән, үз олавы булган, аңа бер хезмәтче беркетелгән, эшкә чумуына сылтап, һичкем белән аралашмаган, ә йомыш белән килүчеләр булса, төрле тукымалар, гадәттә байрак чигә торган ефәк өеменә төренеп-чумып каршы алган, һәм кешеләр аны, матур булып күренергә, бизәнеп-ясанып утырырга ярата, дип кенә уйлаганнар. Шуңа күрә, янәсе, йөкле икәнен дә белмәгәннәр. Яңа туган баланың атасы кем – билгеле түгел. Әле чигүчедән сорау алырга өлгермәгәннәр. Хезмәтче хатын, берни дә белмим, дип бара. Тот куянның койрыгын...

Чыңгызхан, ачуыннан гарьләнеп, бу тарих шул дәрәҗәдәге игътибарга лаек түгел, дип уйланды, әмма бала табуны тыю – ул үзе урнаштырган тәртип, ә һәр чирүнең җаваплы заты, әмернең бозылуы турындагы хәбәрне өстеннән төшерү өчен, югарыдарак утыручы хуҗасына җиткерә дә котыла, шул рәвешле, күзгә күренмәс чылбыр хаканның муенына килеп урала. Хәзер ул үз боерыгының тотыгы булып чыкты. Инде чигенү мөмкин түгел, җәза бирү котылгысыз иде...

Төн урталарына таба, йөзбашы Эрдене, ашыгыч йомышлар үтәп йөрүенә сылтап, меңбашына киттем, дип, аланнан чыкты, әмма бу аңа төнлә үзенең мәгъшукасы белән качу өчен бер хәйлә генә иде, әлбәттә. Бу вакытта инде хаканга барысы да билгеле булуын ул әле белми, Догулаң һәм бала белән качу юлы киселгәне дә аңа мәгълүм түгел иде.

Алмаш атын, бәйдәге ау эте сыман, йөгәненнән тотып барганда, йөзбашы Эрдене аланнарны хәвеф-хәтәрсез генә әйләнеп узды һәм, гадәттә Догулаң тирмәсе янында торган олауга якынлашканда, Ходайдан бары бер генә нәрсә – һәр төндә тирә-юньне әйләнеп чыга торган нойон күзәтчеләренә тап булмауны сорады. Болар – иң бәйләнчек һәм аяусыз адәм актыклары, әгәр берәр атлының ничектер сөт аракысы эчеп сәрхушланган икәнлеген сизеп алсалар да, аңа рәхим-шәфкать күрсәтмәсләр, шунда ук ат урынына тәртә арасына керергә һәм җигелергә мәҗбүр итәрләр, ә олауга менеп утырганы, камчы белән бәргәли-суккалый, дала буйлап куар...

Үз кул астындагы йөз сугышчыны калдырып-ташлап киткәндә, Эрдене белә иде: әгәр тота калсалар, аңа иң югары җәза – киез белән томалап яки асып үтерү яный. Хакан каһәреннән котылу юлы бер – ерак якларга, чит җирләргә башыңны алып кача алсаң гына исән калу мөмкин булачак.

Даланы бу юлы да айлы төн яктырта иде. Һәркайда аланнар, ат көтүләре сибелеп урнашкан, һәркайда пыскып торучы учаклар янында сугышчылар тезелешеп йоклап ята. Бу кадәр күп кеше һәм олаулар мәхшәрендә кемнең кая баруына һичберәүнең исе китми иде. Йөзбашы Эрдене менә шуңа исәп тотты да: аңа Догулаң һәм улы белән качып китәргә моннан да уңайлырак җай чыкмаячак, әгәр бу төндә тәкъдир аларга арты белән борылмаса...

Бәлагә тарыганнарын ул осталар табырына якынлашу белән аңлап алды. Өзәңгегә сикереп менеп, ике атның да иярләренә ныклап ябышты да, тынын да чыгармыйча, аларның күләгәсенә сыенды. Әйе, башларына бәла килгән! Иң кырыйдагы тирмә янында, тирә-юньне дөрләп янган уты белән яктыртып, бик зур учак яна. Дистәләп ясавыл, үзара кычкырып сөйләшә-сөйләшә, атлары белән учак тирәсендә таптанып торалар. Иярдән төшкәннәре – өчләп кеше булыр – бүген төндә Догулаңны утыртып качарга җыенган олауга ат җигеп маташа. Аннары Эрдене ясавылларның ничек итеп тирмәдән кулына баласын тоткан Догулаңны алып чыкканнарын күрде. Әнә ул, өстенә сусар тунын ябынган хәлдә, агарынып, хәлсезләнеп, куркынып, сабыен күкрәгенә кысып, учак яктысында басып тора. Ясавыллар нидер сорашалар бугай. Аларның: «Җавап бир! Җавап бир, диләр сиңа! Сөйрәлчек, уйнашчы!» – дип җикеренгәннәре монда хәтле килеп җитте. Аннары хезмәтче Алтунның үкереп елаганы ишетелде. Әйе, бу аның тавышы, һичшиксез, аныкы иде. Алтун өзгәләнеп кычкыра: «Мин кайдан белим?! Ни өчен мине кыйныйсыз? Кемнән тапканын кайдан белим, ди, мин! Далага чыккач, кичә генә узмаган бит! Әйе, баласын ул күптән түгел тапкан, үзегез күреп торасыз. Тик бу хәлнең, димәк, моннан тугыз ай элек булганлыгын аңламыйсызмыни соң?! Кайчан кем белән – мин аны ул чакта белә идеммени?! Нигә мине кыйныйсыз?! Ә аның ник котын аласыз, үлем хәленә җиткереп куркыткансыз, ул бит яңа туган сабый белән! Ул сезгә хезмәт итмәдемени, сезне яуга алып бара торган һоруңнарыгызны чикмәдемени? Хәзер аны ни өчен үтерәсез, ни өчен?»

Тояк астында калган зәгыйфь үлән кебек мескен Алтун – ул нишли ала инде, йөзбашы Эрдене үзе дә башын күтәрергә кыймыйча торганда, унлаган кораллы ясавылга каршы ул да бер ялгызы чарасыз иде бит?! Берсен яисә икесен дөмектереп үлсәң генә, әмма бу корбан нинди дә булса җиңеллек бирәме? Өер булып йөрүләре белән һәрвакыт оталар да шул ясавыллар. Бөтен көтүләре белән бугазга ябышып кан эчү өчен ябырылырга көтеп кенә торалар!

Йөзбашы Эрдене ясавылларның Догулаңны бала белән олауга утыртуларын, аның янына ук хезмәтче Алтунны да ташлауларын һәм аларны каядыр төн эченә алып кереп китүләрен күрде.

Шуның белән барысы да тынычланып калды, тирә-якта шомлы бушлык хакимлеге урнашты. Шул чакта гына бер читтәрәк этләр өрүе, атлар кешнәве, ял урыннарындагы кешеләрнең мыдыр-мыдыр нидер сөйләшкәне ишетелә башлады.

Чигүче Догулаң тирмәсе янындагы учакның уты инде шактый сүрелде. Җир өстендәге әле генә булып узган җил-давылны үзләренә сеңдереп, адәм балаларының тәкъдирендә язылган көрәш газапларын еракта күзәтеп торучы тавышсыз-өнсез йолдызлар, учак тирәсендәге бушап калган киңлеккә армас-талмас җете күзләрен текәп, тыныч, гамьсез балкуларын дәвам иттеләр...

Өнендә төш күргән кебек барган йөзбашы Эрдене бертын эчендә оеган, суынып киткән бармаклары белән алмаш атның башындагы йөгәнен капшап тартып төшерде һәм аның аяклары астына ташлады. Йөгән тонык тавыш белән җиргә ятты. Эрдене, тыны кысылып, үзенең йөрәк тибешен ишетте, сулыш алуы авырайганнан-авырая бара иде. Шулай да ул әле алмаш атның җилкә калкымына учы белән җиңелчә генә сугып алырлык хәл тапты. Бу ат инде хәзер аңа кирәк түгел, ул үз иркенә китә ала иде, һәм малкай, шуны гына көткәндәй, якындагы үз ишләре янына – төнге көтүгә таба юртты. Ә йөзбашы Эрдене, бер максатсыз, кая барганын, ник барганын үзе дә аңламыйча, мамык кебек йомшарган аякларын көч-хәл белән сөйрәп, дала буйлап китте. Аның артыннан, бушап калган йөгәнен әледән-әле чайкап, йомшак кына адымнар белән, тугры һәм аерылмас сугышчан юлдашы – йөзбашы Эрденене ничә орыш эченнән исән-имин алып чыккан кашка аты Акйолдыз атлады. Бу төндә аңа да яраткан хатыны һәм яңа туган баласы белән иясен явызлар тырнагыннан коткарырга язмаган икән шул.

Эрдене, ни дә булса булыр дип уйлап-нитеп тормыйча, сукыр кебек, аяк астын капшап кына бара; ике күзе дә юеш сакалы буйлап тамып төшә баручы яшь белән тулы, ә ай нурының тигез агынтысы, аны юатырга тырышкандай, бөкрәйгән, әледән-әле көзән җыерган кебек тартыша-тартыша дертләп ала торган иңнәрендә чайкалып, сыйпап озата иде... Ул, көтүдән куып җибәрелгән, бөтен дөньяда берүзенә генә тереклек итәргә калган ялгыз кыргый җанвар сыман, атлавын белде: булдыра алсаң – яшә, юк икән – үл. Бүтән һичнинди чара да юк... Ни эшләргә инде аңа хәзер, кая барып башын төртергә? Бу газаптан бары тик үлеп кенә – күкрәгенә, бертуктаусыз сызлаган йөрәгенә хәнҗәр кадап кына котылып буладыр, бары тик шул чакта әрнеп-яндырып торган яраны, авыртуны басарга мөмкиндер, яки инде үз-үзеңнән качып, кайдадыр эзсез югалырга, мәңгелек кочагында эреп бетәргә кала...

Йөзбашы җиргә егылды, тонык тавыш белән үкси-үкси, ташларга учларын, тырнакларын суйдырып, алга таба шуышты, ләкин җир аны кочагына алмады, шуннан соң торды, билендәге пычакны капшап тапты...

Дала тын, буш һәм айлы-йолдызлы, уч төбендәге кебек җәйрәп ята. Янәшәдә, ай яктысына коенып, бары тик бер җан иясе – тугрылыклы кашкасы Акйолдыз басып тора, сабыр гына үзенә әмер көтеп пошкыра иде...

Ул иртәдә дә, юлны дәвам итәр алдыннан, алдан ук калкулыкка җыелган барабанчылар, гаскәрнең җыелырга тиешлеген белгертеп, добулбасларын дәррәү дөмбәсли башладылар. Ярсыган добулбаслар, инде тиз генә тына алмыйча, арта баручы шомлы гөрселдәүләре белән тирә-юньне тетрәттеләр. Үгез тиресе тартылган барабаннар, яу вакытында бала тапкан азгын хатынны, байрак чигүчене, – аның исеме Догулаң икәнлеген кем генә белгәндер, – җәзалап үтерергә чакырып, капкын базына төшкән кыргый җанварлар кебек үкерештеләр, ярсыдылар.

Добулбасларның шашынган тавышы астында, бәйрәм тантанасына чыккан төсле, бөтен коралларын тагып, йөзәр-йөзәр булып тезелешкән атлы гаскәрләр калкулыкны ярым түгәрәк рәвешендә уратып алган, ә аларның як-ягында – йөкләрен тутырган олаулар, олау өсләренә исә яуга хезмәт итүче барчасы: тирмә коручы, корал ясаучы, каешчы, тегүче осталар – барысы да яшь, әле җимеш китерәчәк ирләр һәм хатыннар менеп төялгән. Бу нәкъ менә аларны куркыту, аларга сабак, гыйбрәт бирү өчен оештырылган мәхшәр-тамаша – бөтен халык алдында җәзалап үтерү иде. Хакан әмереннән чыгарга батырчылык иткән һәркем белеп торсын: ул да шулай, Ходай биргән гомереннән бер мизгелдә мәхрүм калачак!

Калкулыктагы добулбаслар, тамырлардан аккан канны суытып, күңелләрдә катып калган курку тойгысын ныгытып, ягъни Чыңгызхан хөкеме белән ризалашу, хәтта аны хуплауны көчәйтеп, гөрселдәвен дәвам итте.

Менә добулбасларның бертуктаусыз гүләве астында, өстенә чатыр корылган күчмә алтын тәхете-паланкины белән калкулыкка аның үзен – әмеренә буйсынмаган өчен, куркыныч җинаятьчене – яшь ананы җәзалап үтерү карарын кабул иткән хаканны утыртып алып менделәр. Ул тәхетне җирән төстәге калкулык өстенә – кояшның иртәнге беренче нурларында коенып җилдә җилфердәгән һоруңнар уртасына куйдылар. Алардагы ут бөркүче аждаһалар, җанлы булып, менә-менә сикерергә әзер тора иде кебек. Аждаһада хакан үзенең дәһшәтле көче гәүдәләнеш таба дип хыяллана, әмма чигүченең, аны уена да кертмичә, ә бөтенләй башка берәүгә – куенында иркәләгән дәртле һәм кыю ир-егеткә – үзенең аждаһасына җан өргән икәнлеген күз алдына китерә алмый. Тирә-юньдәге берәү дә тиздән башланасы кырыс җәза яшь хатынның тәвәккәллеге өчен булганын белми иде әле.

Менә ул мизгелләр килеп тә җитте. Барабаннар әкренләп тавышын баса башлады, җәзалап үтерү алдыннан алар тынып калырга һәм, шул рәвешле, авыр тынлыкны тагын да киеренкерәк итәргә, коточкыч хәл алдыннан вакыт агышын да туктатып торырга тиешләр, ә аннары, җан кыю вакыйгасын кыргый үкерү тавышлары белән озатып, яңадан ярсып дөберди башлаячаклар; бу вәхши туйның максаты да әлеге тамашаны күрергә җыелган бәндәләрнең кан исен тоеп исергән аңын томалап, кыргый тойгыларын – әле генә аралашып яшәгән, һичберәүгә зыян салмаган үз ишләреннән рәхимсез үч алуны, кеше кайгысына сөенеп тантана итүне, асып үтерүгә ул түгел, ә кемдер бүтән берәү дучар булачак, дигән яшерен шатлык белән юануларын ныгыту иде.

Барабаннар тынычлана башлады. Инде урнашып килүче бу тынлыкны җыелган халык кына түгел, хәтта җайдаклар астындагы атлар да бозарга кыймас кебек. Чыңгызханның үз йөзе дә таш сыман катып калган. Нык итеп кысылган кырыс иреннәре һәм керфек тә какмый торган тар уентылы күзләренең салкын карашы даладагы агулы елан торышын хәтерләтте.

Җәза үтәләсе урынга иң якын тирмәдән байрак чигүче Догуланны алып чыккач, барабаннар тәмам тынды. Алып гәүдәле ясавыллар аны кулларыннан эләктереп алдылар да пар ат җигелгән арбага йолкып менгезделәр. Догулаң арбада аркасыннан терәп торучы караңгы чырайлы яшь ясавыл белән янәшә басып калды.

Рәт-рәт булып торган кешеләр, бигрәк тә хатын-кызлар чыр-чу килде: «Менә ул, теге чигүче шул үзе инде! Уйнашчы! Иясез әнчек! Яшьлеге һәм шундый матурлыгы белән кайсыдыр нойонга икенче яисә өченче хатынлыкка бара алмас идеме! Ә ул ир дигәне өстәвенә картрак та булса, тагын да шәбрәк. Бер кайгы белмичә типтереп яшәр иде. Юк, үзенә сөяркә иярләштергән дә бала тапкан, җирбит! Карасана, хаканның илаһи йөзенә төкерү белән бер ләбаса бу! Ә хәзер әнә башы белән түләсен. Аның тәхете – дар агачында! Уеннан уймак чыктымы, ә, чибәркәй!» – Үз ишләрен чәйнәүгә, гайбәтләргә сусаган бу төркемнең рәхимсез хөкеме добулбасларның усалланып дөпелдәвенең дәвамы иде. Үгез тиресен тартып эшләнгән барабаннар хакан үзе күралмый башлаган кемсәгә нәфрәт уяту өчен шулай катгый һәм колакларны тондырып дыңгырдый да ич инде.

– Ә-ә, менә зина җимеше белән хезмәтче дә монда икән! Күрегезче! – дип, олау хатыннары зәһәр сөенеч белән кычкырып җибәрделәр. Бу чынлап та

хезмәтче Алтун иде. Ул чүпрәк-чапракка төрелгән күкрәк баласын күтәреп килгән. Алыптай ясавыл озатуы астында, куркынып як-ягына карана-карана, тәмам куырылып, Алтун, кулындагы җанлы нәни төргәге белән, үлемгә хөкем ителгән чигүченең җинаятен раслаган дәлил кебек, арба янында атлый. Җәзалап үтерү мәрәкәсен үтәр алдыннан, моны күзәтеп торучыларны куркытыр өчен, аларны юри шулай алып баралар. Догулаң аңлый иде, хәзер бүтән котылу юлы юк: бернинди кичерүне дә, һичнинди ярлыкауны да көтеп булмый.

Аларны мыскыл итәргә сөйрәп чыгарыр алдыннан, баласын тирмәдә соңгы тапкыр имезеп өлгерде ул. Берни дә аңламаган бәхетсез сабый, астыртын гына тына барган барабан тавышлары астында җиңел йокыда изрәп, тырышып-тырмашып, иреннәрен чәпелдәтте. Хезмәтче Алтун янәшәдә тора иде. Күз яшьләренә буылып, үкереп елаудан тыелырга тырышып, әледән-әле учы белән авызын каплый. Шул мәлдә алар үзара бер-ике сүз алышып өлгерделәр.

– Кайда ул? – дип пышылдады Догулаң, баланы бер имиеннән икенче ягына күчереп, гәрчә үзе белмәгәнне Алтун да белә алмаганын ул аңлый иде.

– Белмим, – дип җавап бирде тегесе, яшьләренә күмелеп. – Еракта дыр дип уйлыйм.

– Шулай гына була күрсен! Шулай булсынчы! – инәлеп әйтте Догулаң. Хезмәтче, җавап йөзеннән, ачынып, башын какты. Алар икесе дә бу мәлдә бер нәрсә турында уйлый: йөзбашы Эрдене качып котыла алсын да атына атланып ераккарак чапсын, күздән китеп югалсын иде, Ходаем.

Тирмә артында адымнар, тавышлар ишетелде:

– Йә, кайда алар? Өстерәп чыгар!

Чигүче, баласының төчкелтемрәк исен сулышы белән суырып алгандай, хәсрәткә чумып, аны соң тапкыр күкрәгенә кысты һәм калтыранган кулларыннан хезмәтчегә тапшырды:

– Күпмедер яши калса, ташлама инде, зинһар, күз-колак бул...

– Ул турыда уйлама! – Алтунның бүтән тыелыр хәле калмады, бугазындагы яшь төерен йоталмыйча, чарасызлыктан, ул үксеп елап җибәрде.

Һәм шунда ук ясавыллар аларны тышка таба сөйрәп алып китте.

Кояш инде офык өстенә күтәрелеп, даланы якты, җылы нурларына чумырган иде. Чигүчене җәзалаганнан соң юлын дәвам итәр мизгелне түземсезләнеп көткән кара болыттай гаскәрләр һәм олаулар төркемен төрле яктан урап, иксез-чиксез Сарүзәк далалары җәйрәп ята. Калкулыкларның берсендә ханның алтынсу тәхете-паланкины балкый. Тирмәсеннән чыккан арада, Догулаң, күз кыры белән, җеназа кабыгын хәтерләткән ул паланкинны – җирдәге Алла шикелле, беркем якын килә алмаслык хакан үзе биләгән тәхетне, ә шул мескен корылма тирәли дала җилендә җилфердәгән, авызларыннан ут-ялкын ургытып торучы аждаһалар белән бизәп, нәкъ менә аның оста куллары укалап чиккән һораң-байракларны күреп өлгерде.

Зиннәтле чатыр астында җәелеп утырган Чыңгызханга әлеге калкулыктан барысы да яхшы күренеп тора: дала да, гаскәр дә, олаулардагы кешеләр дә, ә өстә, һәрвакыттагыча, аның баш очында ак болыт йөзеп йөри иде. Чигүчене җәзалап үтерү ул иртәдә юлга чыгуны тоткарлады. Әмма, алга таба барыр өчен, монысын да эшләү фарыз бит. Җәзалау вакыйгасы аның катнашуында булган җан кыюларның беренчесе түгел, билгеле, һәм соңгысы да булмас, төрле-төрле очракларда аны тыңламаган бәндәләр нәкъ шул ысул белән юк ителделәр; хакан һичкайчан бөтен гавам алдында җәзалауның халыкны иң югары зат билгеләп куйган бердәм тәртипкә буйсындыру өчен хезмәт итүенә икеләнмәде, чөнки

болай үтергәнне куркып һәм, бер үк вакытта, әле үзләренә кагылмаганга күрә, мескеннәрчә куанышып тамаша кылулары кешеләрне хак юлга – бу рәхимсезлекне тиешле чара дип кабул итү һәм шуңа күрә хакимиятнең мондый адымга баруын аклау гына түгел, яклау һәм хуплау юлына да бастыра.

Менә әле дә, чигүчене тирмәдән сөйрәп чыкканда һәм аны мәсхәрәле, нәфрәт тулы карашлар астында уздыру өчен арбага менәргә мәҗбүр иткән вакытта, кешеләр төркеме, шөпшә күчедәй гүләп, хәрәкәткә талпынып алды. Чыңгызханның чыраенда исә бер генә тамыры да тартышып куймады. Ул чатыр астында, җилфердәгән һоруңнар һәм байрак саплары янында таш бүкәннәр кебек катып калган кизүвыллар уртасында, тыныч кына күзәтеп утыруын белде. Игълан ителгән җәзалап үтерү шуңа исәп тота да инде – һәркайсы белеп торачак: Кояш баешына таба бөек яу сәфәре барышында кечкенә генә комачаулык ясау да гафу ителми. Күңеленнән хакан аңлый: яшь хатыннан, анадан бу кадәр үк рәхимсез үч алуга бармаска, аны ярлыкарга да мөмкин иде, мәгәр анда мәгънә күрми, һәртөрле киң күңеллелек күрсәтү һичкайчан яхшылык белән бетми, хакимият көчсезләнә, кешеләр оятсызлана бара. Юк, ул бернигә дә үкенми, аңарда бердәнбер канәгатьсезлек тойгысы уяткан нәрсә: бу чигүченең сөяркәсе кем булганын шулай да ачыклап булмады бит.

Ә ул, асып үтерелергә хөкем ителгән хатын, күкрәк турысында күлмәге ертылган, чәчләре тузгыган хәлдә, инде арбада, саф-саф булып тезелгән гаскәр һәм олаулар каршыннан узып бара – иртәнге кояшта күмер кебек янып-ялтырап торган куе кара чәч учмалары аның каны качкан, нуры киткән йөзен яшерә. Шулай да Догулаң башын имәде, бушап калган күзләреннән тирә-ягына хәсрәтле карашын чәчеп бара, хәзер аның бернидә дә гаме юк сыман. Әйе, аның сере ачылды: менә ул – гомереннән артык күреп яраткан ирне сөйгән хатын, әнә аның тыелган бәгырь җимеше – шул мәхәббәттән туган бала!

Әмма кешеләрнең кызыксынуы көчле, алар аны кычкыра-кычкыра озаталар:

– Бия, ә синең айгырың кайда соң? Кем ул?

Үз-үзләрен ярсытып һәм явызлана барып, бу адәми затлар өере, әлеге гаеп-гөнаһ аларга да ягыла күрмәсен дигәндәй, төрле яктан ерткычларча кычкыра:

– Асарга кирәк зиначыны! Хәзер үк асарга! Сәфәр чыгасы бар. Нәрсә монда көтеп торырга?

Җәзаны оештыручылар шуңа исәп тотканнар да иде: чигүченең рухын нәкъ менә шашынган халык төркеме ныграк изә, сындыра ала. Гаскәриләр арасыннан күзләре баканыкы кебек кабарып торган сыбайлы бер нойон, – акырып-бакырып йөрергә оста булса кирәк, хакан каршында бу юлы да үзен күрсәтеп каласы килде бугай, – аерылып чыкты да, бер чарасыз калган чигүче арбасы һәм аның белән янәшә кулында бала тоткан килеш атлап баручы хезмәтче хатын янына юртып килеп җитте.

– Яле, җәмәгать! – Ул, барысын да туктатып, бигрәк тә рәт-рәт булып баскан атлыларга карап, каты итеп кычкырды: – Минем сүземә колак салыгыз! Бу ояты качкан фахишә кемнән бала тапканын күрсәтергә тиеш! Кем белән зина кылганын! Ә хәзер әйт, бу ир-атлар арасында синең баланның атасы бармы?

Догулаң, юк, дип җавап бирде. Рәтләр буйлап ышанмыйча-сагаеп гүелдәү тавышы узып китте.

Арба сафтан сафка таба тәгәрәде, ә йөзбашлары, бер-берсен үртәп, үзара кычкырыша башлады:

– Миндә юк булып чыкты! Бәлки, ул айгыр синең йөз арасындадыр?

Ул арада күк күкрәгәндәй тавышка ия нойон чигүчедән, кабат-кабат, яңа

туган баланың атасын төртеп күрсәтүен таләп итте. Менә арбаны чираттагы атлылар төркеме алдында туктаттылар, һәм яңадан шул ук сорау:

– Күрсәт, уйнашчы, кайсыннан таптың?

Нәкъ шул сафта, бу йөзнең башында, Эрдене үзенең кашкасы Акйолдызга атланып тора иде. Аның гаепле сыман карашы Догулаңныкы белән очрашты. Аларның күз карашларын нинди авырлык белән аеруына, шуны сиздермәс өчен, маңгаена төшеп чуалган чәчләрен артка ташлаганда, Догулаңның ничек тетрәнеп китүенә, бер мизгелгә йөзе кабынып һәм шунда ук сүнүенә гомуми ыгы-зыгыда берәү дә игътибар итмәде. Яшен тизлегендә күзләр белән бу күрешеп алу Догулаңга нинди куаныч һәм нинди әрнү алып килгәнен бары тик Эрдене генә белә иде. Күк күкрәгәндәй тавышлы нойонның соравына айнып киткән Догулаң, үз-үзен кулга алып, яңадан нык итеп җавап кайтарды:

– Юк монда минем баламның атасы, юк!

Йөзбашы Эрдененең шул чакта башын июенә дә янә беркем игътибар итмәде, тик ул үзен бик тиз кулга алды, йөзеннән генә ниндидер күләгә узды.

Ә җәлладлар инде әзер тора. Җиңе сызганулы киң озын кара халат кигән өчәве уртага ике өркәчле дөяне чыгарып маташа, ул шундый зур ки, иярдәге җайдакның аяк очы дөянең корсак уртасына гына җитә. Ачык далада урман-агач булмаганлыктан, күчмә кавемнәр борын-борыннан җәзаның шундый юлын сайлаганнар: үлемгә хөкем ителгәннәрне ике яктан пар итеп бер бауга бәйләгәннәр яки, ялгызын гына асарга туры килгәндә, буш ягын ком тутырылган капчык белән «тигезләгәннәр». Чигүче Догулаңга шундый капчык әзерләп куелган инде.

Акыра башлаган дөянең ярсуын өстенә кычкырып та, таяклар белән орып та көч-хәл белән басып, җәлладлар аны тезләнергә һәм, эре сөякле озын аякларын астына җыеп, җиргә ятарга мәҗбүр иттеләр. Дар агачы әзер иде.

Барабаннар да җиңелчәрәк гөрселдәшеп уяна башладылар, алар, кирәкле мизгелдә дөпелдәп, колакларны тондырырга һәм күңелләрне урыныннан кузгатырга тиеш иде. Шул чакта күк күкрәгән тавышка ия нойон яңадан чигүчегә мөрәҗәгать итте, инде бу юлы кызык табар өчен генә булса кирәк.

– Соңгы тапкыр сорыйм. Сиңа, тавык миле сөйрәлчеккә, барыбер дөмегәсе, һәм синең токымсыз эт баласына да яшәү юк! Шулай да сине ничек аңларга соң, чынлап та кемнән йөккә узганыңны белмисеңме? Бәлки, бераз көчәнеп карарсың да исеңә төшерерсең, ә?

– Кемнән икәнлеген хәтерләмим. Ул күптән һәм моннан бик еракта булган иде, – дип җавап кайтарды чигүче.

Дала өстен тупас ир-ат хахылдавы һәм зәһәр хатын-кыз чинашуы тетрәтте.

Нойон һаман бәйләнүен белде:

– Ничек аңларга, кайдадыр базарда ясатып кайттың булып чыгамы әллә?

– Әйе, базарда! – дип, үчекләп җаваплады Догулаң.

– Сәүдәгәр яки илгизәр идеме? Бәлки, базар карагыдыр?

– Хәтерләмим, сәүдәгәрме яки илгизәр булдымы, әллә базар карагымы, – дип кабатлады Догулаң.

Тамашага җыелган халык бу юлы да рәхәтләнеп хахылдашты һәм чинашты.

– Ә аңа нинди аермасы бар, сәүдәгәр булды ни дә, илгизәр яисә бур булды ни, иң мөһиме – бу эш белән базарда шөгыльләнү!

Һәм шулчак, көтмәгәндә, сугышчылар арасында кемнеңдер тавышы яңгырады. Бер ир-ат көчле һәм каты итеп кычкырды:

– Бу мин – баланың атасы! Әйе, беләсегез килсә, бу мин!

Һәм барысы да берьюлы тынып, катып калдылар. Кем булды соң бу? Ахыр минутта, чигүче чишмәгән серен үзе белән мәңгелеккә алып китә, дип торганда, үлем авызына кем кереп бара?

Һәм барысын да шаккатырып, үзенең кашка атын биетеп, рәтләр арасыннан йөзбашы Эрдене алга чыкты. Һәм Акйолдызны туктаган урынында тотып, өзәңгесенә баскан көе, халык төркеменә борылды да яңадан кычкырып кабатлады:

– Әйе, бу мин – баланың атасы! Бу – минем улым! Улымның исеме – Кунан! Улымның анасы – Догулаң! Ә мин – йөзбашы Эрдене!

Шул сүзләр белән ул бөтен халыкның күз алдында атыннан сикереп төште дә Акйолдызның муенына кизәнеп шапылдатты, тегесе куркудан сикереп китте, ә йөзбашы үзе барган шәпкә коралларын салып, аларны төрле якка ыргытты, үзе исә инде кулыннан җәлладлар эләктереп алган чигүчегә таба атлады. Әле генә хахылдашкан, чинашкан кавем дәшми-тынмый карап торды: барысы да үз иреге белән үлемгә каршы барган кешене күрде. Җәзага әзер торган сөйгәне янына килеп җиткәч, йөзбашы Эрдене аның алдында тезләнде һәм аякларыннан кочып алды, ә хатын, иркәләп, аның башыннан сыйпады, алар үлем каршында, шулай янә бергә кушылып, тын калдылар.

Шул минутта ук добулбаслар телгә килде, кинәт нәрсәгәдер тынычлыгын җуйган үгез көтүе кебек буыла-буыла үкереп, дәррәү дөбердәргә кереште. Бу – халык-чирүнең, үз-үзләрен белештермичә, хакан ихтыярын үтәп, шашынып канга сусауларын белдерү авазы иде. Һәм барысы берьюлы исләренә килде, һәрнәрсә кабат үз урынына кайтты, һәркайсына хәрәкәткә, юлга чыгарга әзер булып торырга, дигән боерык яңгырады. Барабан-хакимнең әмере бер: барчасына да башкалар кебек булырга, һәммәсе дә берсүзсез буйсынырга һәм үз бурычын үтәргә тиеш! Ә җәлладлар, тәҗрибәле мал чалучылар кебек, кичекмәстән эшкә кереште. Җәлладларга ярдәмгә тагын өч ясавыл ташланды. Алар йөзбашын җиргә егып, тиз генә аның кулларын аркасына каерып бәйләделәр, чигүчене дә шулай богаулап салгач, икесен бергә җирдә яткан дөягә тартып китерделәр, икесенә уртак бау ташладылар, аның бер элмәген йөзбашына, икенчесен, дөянең өркәчләре арасыннан уздырып, чигүченең нәфис муенына кигезделәр һәм, бик ашыгып, барабаннарның тынып тормаган шавы астында дөяне аягына бастырырга керештеләр. Малкай, инде бу юлы ипләп кенә яткан җиреннән торасы килмичә, өстенә нинди гөнаһ аласын аңлагандай, үҗәтләнеп каршылык күрсәтте, ул ямьсез итеп акыра, ачулы шакылдаткан тешләре белән берәрсен эләктереп алырга маташа иде. Әмма сыртына таяклар төшә башлагач, бөтен зур гәүдәсе белән торып басарга туры килде. Бер-берсен кабергәчә яраткан ике затның – үлем алдыннан да бер бауга бәйләп куелган пар корбанның – җансыз гәүдәләре өркәчләрнең ике тарафыннан асылынып калды.

Барабан ыгы-зыгысында хаканның чатырлы алтын тәхетен калкулыктан алып киткәннәрен күбесе сизмәде, ахрысы. Хәер, хакан үзе дә җәза мәрәкәсе үтәлгән җирдә юк иде инде, аңа күргән кадәресе бик җиткән; куелган бөек максатка ирешелде, хәтта көткәннән дә артык булды – чигүче белән йоклауны Дөньяның Дүрт Тарафы Әмиренә йөгенүдән өстен күргән теге билгесез ир-ат барыбер табылды, ул аның йөзбашларыннан берсе икән ләбаса, канун бозучының канга сусаган кешеләр көтүе күз алдында фаш булуы һәм шунда ук тиешле җәзасын алуы да шәп бит, бәлки, әнә күптәнге, заманында аның дошман коллыгына төшкән Бортэсен куенында иркәләп, аннары гомере буена хакан

күңеле белән үзенеке итә алмаган беренче баласының атасы булуы ихтимал, ул чакта да, соңыннан да кем икәнлеге беленмичә калган теге адәм актыгы өчен үч алу түгелме икән әле бу бәхетсез корбан...

Ә барабаннар, икесенә бер, өркәчләр генә аерып торган уртак бауны бүлешкән гашыйкларның дала белән бәхилләшеп узуын тантаналы гүләүләре белән озата барып, ярсып һәм буыла-буыла үкерделәр. Йөзбашы белән чигүче хатынның тынсыз-җансыз гәүдәләре шундый күтәргесез йөк күтәргән малкайның як-ягында чайкалып барды, бөтен дөньяны үкчәсе астына салырга дип ашкынучы хаканның, Кояш баешына барып җитеп, канлы тәхет баскычына басар өчен корбан чалуы иде бу.

Добулбаслар, күңелләргә боз коеп, шом салып, әле һаман да тына белмәделәр, һәм ул көнне һәркем, бернигә карамый үз максатына омтылган ханның ихтыярына каршы бара калса, ни буласын үз күзләре белән күрә алды...

Ясавыл-җәлладлар, мескен дөя – күчмә дар агачы белән, гаскәр һәм олаулар яныннан башларын югары тотып уздылар, алдан казып куелган чокырга мәетләрне төшергәнче, добулбаслар тынмады, барабанчылар, кара тиргә батып, үгез тиресен кагуларын белде.

Ул арада гаскәр яңадан юлга кузгалды, һәм Чыңгызхан чирүен сыендырган дала да Кояш баешына таба шуышты. Атлылар, олаулар, тамак туйдыру өчен куып барылган көтүләр, тәгәрмәч өстендәге корал ясаучы һәм башка шундый остаханәләр, – кыскасы, сәфәрдә катнашучыларның һәркайсы, ашык-пошык җыенып, Сарүзәк даласының бу каһәрле урыныннан тиз генә китәргә тиеш иде, алардан калган тирмә-учаклар эзендә үз-үзен кая куярга белмәгән һәм башкаларның да исенә төшерергә кыймаган бердәнбер җан – кулындагы бала белән хезмәтче Алтун гына калды. Аның турында дәррәү генә һәммәсе онытты, аның әле дөньяда икәнлегеннән оялган кебек, барысы да аны күрмәмешкә салышты, берәүдә дә бу ике хәсрәтле җан иясенең кайгысы юк иде.

Тиздән тирә-юньдә үле тынлык урнашты, бернинди добулбаслар, бернинди өндәү авазлары, байраклар калмады... Бары ат туплары тезелеп киткән юл, тояк чокырлары – Сарүзәк даласында тиздән эреп югаласы шушы эзләр генә сәфәрнең кайсы якка таба юнәлгәнен күрсәтеп тора иде...

Алтун, колакларны чыңлатырлык ялгызлыкка ияләшә алмый каңгырып йөргәндә, кичәге учаклар яныннан ташландык азык калдыкларын җыйгалап, ите яртылаш кимерелгән, күмерләнгән сөякләрне, алдагы көнгә, дип, букчасына салгалады, бүтән чүп-чар арасында кемдер онытып калдырган сарык тиресенә юлыкты, шул тирене, ирексездән үзенеке иткән бала белән икесенең төнгелеккә асларына җәяргә дип, култык астына кыстырды...

Чынлап та, Алтун алга таба нишләргә, кай тарафка юл тотарга, кайда сыену урыны табарга, яңа туган баланы ничек тукландырырга икәнен күз алдына китерә алмый иде. Әле кояш яктыртып торганда, ул нindидер могҗизага өметләнде, ә бәлки, көтмәгәндә бәхет елмаер да, нindидер торак – далада югалып калган көтүче тирмәсенә тап булырлар. Уйламаганда-көтмәгәндә берьюлы ирек тә, язмышның авыр йөген дә алган кол хатын, куркуын җиңеп, киләчәген хәерлегә юрарга тырышты. Тик нарасый тиздән ачыгачак, сөт таләп итә башлаячак һәм аның күз алдында ачлыктан үләчәк бит. Менә шул куркыта аны. Нәрсәдер эшләргә хәленнән дә килми иде.

Алтун исәп тота алган бердәнбер хыял – далада очраклы узгынчыларны булса да очрату, әгәр аларның арасында бала имезүче хатын да туры килсә, Кунанны аңа уллыкка бирү, ә үзен ирекле коллыкка тәкъдим итү. Хатын

бушлыкны иңләп-буйлап үзенә урын таба алмый йөри, кулында бала тоткан килеш, ару-талуны белми, бер юнәлешне дә аермыйча бара да бара: әле көнчыгышка, әле көнбатышка, аннары кабат көнчыгышка... Инде төш җитеп килгәндә, сабый торган саен күбрәк кыбырсый, шыңшый, үкси, ими сорый башлады. Хатын аның биләүсәсен кабат төрде, юл җаенда тирбәткәләп, тагын алга атлады. Тиздән бала чынлап торып елауга күчте һәм инде, тынычлана алмыйча, зәңгәрләнеп чыкты, Алтунга туктамый чара калмады, ул тирә-ягындагы өметсез бушлыкка карап ачыргаланып кычкырды:

– Ярдәм итегез! Ярдәм итегезче! Нишләргә инде миңа?

Күз иңләп бетерә алмаслык дала киңлегендә ни төтен, ни ут әсәре күренми. Бер кеше заты калмаган дөнья үзе дә өнсез-тынсыз ята... Иксез-чиксез дала шундый ук иге дә, чиге дә күренмәгән чалт аяз күккә тоташкан кебек, тик баш очында кечкенә ак болыт кына, кайда тукталырга белмәгәндәй, тып-тын әйләнеп йөри...

Бала елап өзгәләнде. Алтун аның өстенә иелә төшеп такмаклады:

– Йә гөнаһсызым, син миннән ни көтәсең соң?! Туганыңа әле җиденче көн генә бит! Үзеңнең бәхетсезлегеңә бу дөньяга килгәнсең... Ни белән tукландырыйм икән, ятимкәем? Күрмисеңмени, тирә-юньдә җан иясе дә юк! Бөтен дөньяда син дә мин, без икебез генә, хәсрәтле ике җан көеге, һәм тагын күктәге ялгыз ак болыт, хәтта кош та очып үтми, нибары шул ак болыт әйләнә дә тулгана... Кая барыйк инде без синең белән? Мин сиңа кайдан ризык табыйм, бәбкәчем? Безне ташлап калдырдылар, ә атаң белән анаңны астылар да кайдадыр күмделәр. Сугыш җәясе тартып, бу адәмнәр кайсы кыйблага табына, ни өчен байраклар тотып, барабаннар кагып, көч өстенә көч ташлана, һәм ул кешеләр сине, яңа туган балакайны ятим итеп, ач үлем авызына ташлап, кая бармакчылар?!

Алтун елаудан шешенгән сабыйны үзенә нык итеп кысып, яңадан дала буйлап йөгереп китте, йөгерүе – тик бер урында басып тормастан гына, хәсрәттән аягүрә үлмәс өчен... Ә нарасый аңламый, сыктаудан туктый алмый, елаудан буыла-буыла, үзенә тиешлене таптыра, анасының җылы сөтен таләп итә иде. Аптырагач, Алтун бер таш өстенә чүкте, күз яшьләре һәм ачу белән күлмәгенең якасын йолкып ертты һәм, тәмам өметсезлеккә бирелеп, аңа үзенең инде яшь булмаган, беркайчан да бала ирене тоймаган кечкенә имиен каптырды:

– Йә, мә инде, мә! Ышанмасаң – ышан! Мин сиңа сөт суырырга бирмәс идеммени, бәхетсез ятимкәй! Мә, ышан! Бәлки, ышанырсың да мине йолыккалаудан туктарсың! Әй, нәрсә сөйләп торган булам соң! Кемгә сөйлим! Минем буш имием ни дә, сүзләрем ни! И Күк-Тәңрем, шул көнемдә нинди җәза әзерләдең миңа?!

Бала, имигә ябышып, шунда ук тынып калды һәм, бөтен барлыгы белән, көтеп торган рәхәткә тиенәм дип өметләнеп, иреннәрен чупылдатты, шул вакытта шатлыктан яктырган күзкәйләрен бер ачып, бер йомып, теш казналарын эшләтә башлады...

– Йә, күрдеңме инде? – дип, бер ачусыз шелтәләп алган булды талчыккан хатын ими таптыручы бәләкәчне. – Ышандыңмы? Буш куыкны тарткалавыңнан ни файда? Син бит бу юлы тагын да ачырак итеп күз яше түгәчәксең, ул чакта шул каһәр суккыры далада нихәл итәргә? Алдыйсың, дип әйтер идең, мин сине алдыйммы соң инде? Бөтен гомеремне коллыкта үткәрдем, еллар буе кол булып йөрим, шулай да һичкайчан һичберәүне алдамадым, миңа әнием бала чакта ук әйтә иде, безнең нәселдә, минем Кытайда калган кардәшләрем

арасында берсе дә беркемне дә алдамаган. Йә, йә, бераз юанып ал инде, хәзер син ачы хакыйкатьне төшенерсең...

Хезмәтче Алтун, үзен котылгысыз фаҗигагә әзерләп, шулай сөйләнде, әмма бәләкәй колынның буш имидән аерылырга һич исәбе юк иде кебек, киресенчә, аның уч төбе хәтле генә йөзендә ләззәт яктысы балкуы бик сәер тоелды.

Алтун имиен сабыйның иреннәреннән сак кына тартып алды һәм кинәт, аның йөзенә шул кечкенә имидән ап-ак сөт агынтысы сирпелгәч, әкрен генә аһ итеп куйды. Бу хәлгә исе-акылы китеп, ул яңадан балага имиен каптырды, аны кабат алды һәм, чынлап та, тагын сөт тамчыларын күрде. Аңа сөт төште! Хәзер ул үзенең бөтен тәненә ниндидер яңа көч иңүен ачык итеп тойды.

– Йа Хода! – Хезмәтче Алтунның аптыравы ирексездән йөзенә чыкты. – Минем сөтем бар! Чын сөт! Ишетәсеңме, бәләкәчем, мин синең әниең була алачакмын! Син хәзер үлмәссең! Күк безне ишетте, син – минем михнәтләр чигеп алган балам! Синең исемең – Кунан, сине этиең белән әниең шулай дип атады, сине дөньяга китерү өчен алар бер-берсен яраткан иделәр һәм шуның аркасында һәлак булдылар! Балакаем, безгә бу могҗизаны тудыручыга – синең хакыңа сөтемне бүләк итүчегә рәхмәт укыйк...

Шушы хәлдән тетрәнеп, Алтун тынып калды, аңа эссе булып китте, маңгаена тир тамчылары бәреп чыкты. Чиксез киңлектә тирә-ягына каранып, ул, элеккечә үк, сыңар җан иясе дә – ни адәми зат, ни җанвар күрмәде, бары тик чалт аяз күктән кояш кына яктырта, һәм баш очында ялгыз ак болыт әйләнә иде.

Ап-ак сөт белән тукланып һәм шуннан оҗмах рәхәтлекләре алып, сабый йоклап китте, аның каз каурые кебек җиңел гәүдәсе йомшарды, ярым бөгелгән беләктә ышанып-тынычланып калды, сулыш алуы тигезләнде; ә хатын, бөтен кичергәннәрен, колагында кабат шаулый башлаган добулбасларның рәхимсез дөпелдәвен онытырга тырышып, моңарчы таныш булмаган бәхетне – баласын имезүче ананың җан-тән ләззәтен тойды, – чиксез күк, дала, сөт – аның бәләкәй имиенә кереп йомарланган кабатланмас бер бәхет йомгагы иде...

Ә ул арада бөек дала чирүе – атлы гаскәрләр, олаулар, көтүләр – сәфәрен дәвам итте... Дөньяны яулап алырга чыккан кансыз хаканның сугыш арбасы Кояш баешына таба тәгәрәде дә тәгәрәде. Кизүвыллар һәм яраннары озатуында, байрак йөртүчеләр артыннан җилдә җилфердәгән ачык кызыл каймалы, уттай ефәк һәм алтын-ефәк җепләр белән чигелгән, авызыннан ялкын ургылдыручы ярсу аждаһалы кара һоруңнар уртасыннан ару-талуны белмәс, язмышның үзе кебек гаҗәпсендереп торган төстәге – ак яллы һәм кара койрыклы алыштыргысыз юргасында Чыңгызхан «утравы» йөзеп бара иде... Юрганың кургаштан койган кебек авыр тояклары астында гүләп, Җир шары артка таба тәгәрәде, хаканның чиксез мәмләкәте офыкка кадәр җәелеп, яңадан-яңа киңлекләр исәбенә һаман артты, үскәннән-үсә барды. Шушы чиксезлек һәм бөеклек белән чагыштырганда, ком бөртеге генә булган хакан, һаман комарланып, күз күргән һәм күреп бетерә алмаган җирләрнең һәммәсенә ия булырга, Дөньяның Дүрт Тарафы аны үз хуҗасы итеп тануына ирешергә ашкына иде. Шуңа ул яу белән чыкты һәм чирүен һәлакәткә алып барды...

Ул көнне хакан үзен кырыс һәм сүзсез-өнсез тотты, аңа шулай булу килешеп тә тора шикелле. Әмма күңелендә нинди ташкын-давыллар уйнаганын берәү дә күз алдына китерә алмый иде. Кинәт һичкем көтмәгән хәл килеп чыкты: хакан кисәк кенә атын кайтыр юлга борды, артыннан ашыга-ашыга килүчеләр, аның белән чак кына йөзгә-йөз бәрелешмичә, як-якка читләшеп өлгерде. Хакан, борчылулы йөз белән, калтыранган учын каш өстенә куеп, юкка гына аяз күк

йөзен айкады, юк, ак болыт кайдадыр тоткарланмаган, артта да калмаган, алда да күренми иде. Шулай көтмәгәндә югалды ул, аны бер дә ташламый озатып барган ак болыт. Ул көнне дә, икенчесендә, бер атнадан соң да бүтән күзгә чалынмады. Болыт хаканны ташлап китте.

Идел якасына барып җиткәч, Чыңгызхан Күкнең аннан йөз чөерүен аңлады. Ул алга таба барудан туктады. Аурупаны яуларга улларын һәм оныкларын җибәрде, үзе, калган гомерен уздырып бетерергә һәм кайдадыр билгесез урында җир куенына иңәр өчен, урдасына кире борылып кайтты.

***

Бу якларда поездлар кояш чыгышыннан кояш батышына һәм кояш батышыннан кояш чыгышына таба йөри иде...

1953 елның февраль урталарында Сарүзәк далалары аша кояш чыгышыннан кояш батышына таба баручы пассажир поездлары арасында махсус вагон өстәлгәне дә кузгалып китте. Тәртип саны куелмаган, иң алдагы багаж вагоны артына ук тагылган, чуен тәгәрмәч өстендәге бу «арба» башкаларыннан берни белән дә аерылмый, тик тышкы яктан бер өлеше почта бүлеге булып, аңардан тома аерылган икенче яртысы дәүләт куркынычсызлыгы органнарына аеруча кирәкле мәхбүсләргә вакытлыча яшәү урыны иде. Бу очракта шундый «бәхет»кә Казакъстан МГБсының бер оператив бүлегендә армый-талмый хезмәт куючы өлкән тикшерүче Тансыкбаев уйлап тапкан эшнең корбаны Әбүталип Котлыбаев ирешкән булып чыкты. Нәкъ менә аны, Тансыкбаевның уяу күзәтүендә һәм көчәйтелгән сак астында, башка калаларга «гастроль»гә алып баралар иде.

Тансыкбаев, чыннан да, үз максатына ирешүдә ару-талуны белмәс бик тынгысыз бәндә икән, сорау алулар юлда да дәвам итте. Майорның бурычы, аның уенча, немец әсирлегеннән серле шартларда качып, Югославиягә барып чыккан һәм анда, булачак югослав ревизионистлары белән генә түгел, Англия разведкасы белән дә турыдан-туры элемтәгә кергән затлардан корылган ятьмәне соңгы төененәчә сүтүдән гыйбарәт иде. Совет хакимиятенең шул заманда ук әзерләп куелган һәм сәгате сукканчы посып торучы дошманнарын, берәм-берәм, армый-талмый сорау алу, аларның күрсәткәннәрен башка чыганаклардан алынган мәгълүмат белән чагыштыру юлы аша ачыкларга, аннары тикшерү эшенең иң төп нәтиҗәсе-йомгагына – бусын «гаделлек ханбикәсенең тантанасы» дип йөртәләр бугай – гаепләнүченең үз гөнаһын тулысынча тануына һәм кылган эшләре өчен үкенүенә ирешергә һәм, шуңа таянып, ул адәм актыкларын ахыргача фаш итәргә, гадел хөкем кулына тапшырырга кирәк.

Моңа инде тиешле оеткы салынган – Әбүталип Котлыбаевтан фашистларга каршы Югославия җирендә сугышкан элеккеге хәрби әсирләрнең дистәгә якынын исемләп хәтеренә төшертү мөмкин булды; тикшереп карагач, аларның күпчелеге, әле дә исән-имин көе, илнең төрле почмакларында яшәп ятуы ачыкланды. Тегеләре шулай ук инде кулга алындылар һәм үз чиратларында көрәштәшләреннән тагын байтак кына исемнәрне атадылар. Бер сүз белән әйткәндә, әлеге эш күзгә күренеп үсә, ныгый, аңа инде ит куна башлады. Тансыкбаевны, өстә утыручы башлыклары фатихасы белән, чын-чынлап җитди фасылга күчереп бара иде. Уңышлы булып чыккан очракта, Югославия компартиясе белән кызганнан-кыза барган халыкара ызгыш-талаш җирлегендә, Сталин үзе Титоны идеологик каһәренә дучар иткән чакта, ул шактый отышлы

булып чыгарга мөмкин. Өстәвенә әлеге гадәттән тыш «эш», аны кузгатып-кыздырып җибәргән Тансыкбаевка гына түгел, башка калалардагы күпсанлы коллегаларына да «мул уңыш җыеп алу» вәгъдә итә, форсаттан файдаланып, барысының да өскәрәк үрмәлисе, үсәсе килә иде. Шуңа алар бергәләшеп хәрәкәт итү юлына бастылар да инде. Һәрхәлдә, Чкалов (элеккеге Ырынбур), Куйбыш, Сарытау кебек өлкә башкалаларында, күзгә-күз очраштыру һәм төрле яклап сорау алу өчен, Әбүталип Котлыбаев дигән «күчтәнәче» белән, Тансыкбаевны түземсезләнеп көтәләр.

Тансыкбаев та вакытны бушка уздырмады, ул һәр эштә тизлек белән алдырырга һәм үз дигәнендә нык торырга ярата иде. Тикшерү астындагы тоткынның, ярымподвалдан чыгып, юлга кузгалуны ничек кичерүен, тәрәзә артыннан йөгереп узган станция яны авылларына нинди сыкрану һәм сагыш белән текәлүен дә күрде ул, әлбәттә, күрмичә калмады. Котлыбаев күңелендә нинди давыллар уйнаганын аңлый иде Тансыкбаев һәм, шуңа күрә, мөмкин булганча, аның ышанычына керергә тырыша, янәсе, ул, намуслы тикшерүче, аңа бер тамчы да яманлык теләми, чөнки Котлыбаевны әллә ни гаепле дип санамый, имештер, аның резидент, чит ил махсус хезмәтләренең агентура челтәре җитәкчесе түгеллеге билгеле, әгәр Әбүталип Котлыбаев өер башында торган резидентны ачыкларга һәм, иң мөһиме, аны фаш итәргә, күзгә-күз очрашу вакытында һич шикләнмәслек итеп исбатларга булышса, шуның белән үз хәлен җиңеләйтә алачак. Бик тә, бик тә. Биш-алты ел дигәндә, күрерсең дә торырсың, гаиләсенә, балаларына әйләнеп кайтыр. Теләсә нинди очракта, тикшерүнең гадел төгәлләнүенә ярдәм итсә, иң югары җәзадан – атып үтерелүдән котылып калачак, ә киресенә катып, «эш»не никадәр бутаса, органнардан дөреслекне яшерсә, аның үзенә шулкадәр начаррак булачак, гаиләсенә шулхәтле күбрәк бәхетсезлек китерәчәк... Тансыкбаев тоткынны шуңа ышандырырга тырышты.

Аның тагын бер уен тузы – корбанының Сарүзәк риваятьләрен язып алган кәгазьләре, бигрәк тә маңкорт турындагысы һәм «Сарүзәктә җәзалап үтерү» дигәне: әгәр хезмәттәшлек итүгә барса, алар «эш»кә теркәлмәячәк, ә инде Әбүталип моңа колак салмый икән, Тансыкбаев хөкем итүчеләргә боларның барысын да ачып салырга мәҗбүр булачак, борынгылык тузаны астына яшерелгән милләтчелек коткысы дип карарга тәкъдим итәчәк. «Маңкорт турындагы риваять» – надан бабайларның онытылган һәм хәзер чүплеккә ташланырга тиешле телен торгызуга юнәлгән, милләтләрнең кушылуына каршы булган зарарлы өндәү. Ә «Сарүзәктә җәзалап үтерү» – бөек юлбашчыбызны гаепләү (әстәгъфирулла! ) һәм дәүләт интересларының аерым шәхес мәнфәгатьләреннән өстен куелуы идеясен тәнкыйтьләү, череп таркалган буржуаз «шәхес иреге»нә теләктәшлек күрсәтү – күмәкләштерүнең, ягъни хезмәт коллективын бер максатка буйсындыруның гомумалгарышына кизәнү, ә бит моннан инде социализмны инкяр итүгә дә ерак калмый. Билгеле булганча, социалистик тормыш кануннарын бозуның теләсә нинди очрагы кырыс җәзага тартыла... Җәмәгать малына рөхсәтсез кул сузган, – әйтик, күмхуҗ басуыннан бер башак алып кайткан кешене юкка гына ун елгача лагерьга хөкем итәләрмени?! Ә инде идеологик «башак»ларны җыючы турында әйтеп тә торасы түгел! Әгәр шулай төреп бирсәң, хөкем мондый гаепләүләрне өстәмә статья буенча карарга мөмкин. Ныграк ышандыру-куркыту өчен, Тансыкбаев Сарүзәк әкиятләренең ачык кинаяләрен кычкырып укып күрсәтте, болар, ул һәрвакыт басым ясап әйткәнчә, Котлыбаевны кулга алу һәм аның белән хәтәр «уен»ны башлап җибәрү өчен, Буранлы станциясеннән килгән беренче әләк-нигез булган иде...

Поезд инде икенче тәүлек юлда. Билгесезлеккә бару булса ни, рәшәткәле тәрәзә аша булса ни, Сарүзәккә якынлашкан саен, күз алдыннан йөзеп үтүче киңлекләр Әбүталипның рухи халәтен барыбер ныгыта иде. Сорау алулардан бушаган сәгатьләрендә, йөрәкне тырнап торган янаулардан һәм «яхшылык теләү»ләрдән арыса да, ул табаклы калай белән тышланган купе-камерасына кереп бикләнә дә үз-үзе белән ялгызы гына кала ала. Дөрес, Алматы ярымподвалындагы кебек үк, монда да бөтен төштән төрмә исе килә, назирның ишек тишегеннән зәһәр карап торган бәбәге астында яшәү биредә дә андагыдан рәхәтрәк түгел, шулай да бу – барыбер хәрәкәт әле, юл халәте, урын алыштыру һәм, ни генә димә, монда ул теге, тилерү хәленә җиткергән, тәүлек буе түшәмнән күзне сукырайтып ишелүче яктылыктан котылды, иң мөһиме: күңелендә, бер кабынып китеп, янә сүнеп янган, һич тә тынмый торган өмет яктысы – Буранлы станциясе аша узганда, балаларын, хатынын бер мизгел эчендә генә булса да күреп калу мөмкинлеге кабынды. Шултикле вакыт эчендә аларга ни бер хәбәр сала алмады, алардан да сыңар юллык хат ала алмады бит ул.

Ябык төрмә машинасында аны Алматы янындагы станциягә алып барганда һәм каравыл астында махсус вагонга – мәхбүсләр купесына этеп-төртеп керткәндә, менә шушы өмет һәм борчулар белән мөлдерәмә тулы иде Әбүталипның күңеле. Юлга кузгалгач та, поездның Сарүзәк ягына таба барганын сизүгә, күңеле яңа көч белән сыкрана башлады: күзенең бер кыры белән генә, бер керфек каккан арада гына балаларын, Зарифасын күрергә иде, аннары ни булса, шул булыр...

Бик сагынган иде ул, хәзер бүтән нәрсә турында уйлый да алмый, Алладан бары, Буранлы аша үтү көндезге вакытка туры килсен, тик төнгә, караңгыга калмасын да, поезд шушы станция аша, нәкъ менә Зарифа белән балалар урамда, күз алдында булган вакытта узсын, ягъни алар барак эчендә чакта уза күрмәсен, дип ялвара.

Язмыштан сораган нәрсәсе менә шул гына иде. Аз да түгел, күп тә түгел. Ә бит, уйлап карасаң, чынлап та, язмыш дигәненә ул көткән мәлдә балалар белән Зарифаны ишегалдына алып чыгу ни тора, малайлар үзалларына уйнап йөргән булсын, ә Зарифасы, бауга керләрен элә-элә, узып баручы поездга борылып карасын, балалар да кинәт, баскан урыннарында уеннарыннан бүленеп, вагоннарның кояш нуры сикереп уйнаган тәрәзәләрен санап калыр иде. Ә бәлки әле поезд, тотар да станциядә берничә минутка туктарга уйлар, сирәк булса да, андый хәлне дә күргән бар иде бит! Әбүталипның күңеле айкала башлый: бер яктан, кинәт шундый бәхет ишелеп төшмәс микән, дип өметләнә, икенче яктан, юк, кирәкмәс, мондый авыр сынауны, кичерешләрне йөрәге күтәрә алмас, шартлар, өстәвенә балалар да кызганыч, аталарын рәшәткәле тәрәзә артында күрсәләр, аларга ни булыр, үкереп еларлар тагын... Юк, юк, күрешмәвең хәерлерәк...

Язмышның күңелен йомшарту һәм теләкләре тормышка ашсын өчен, ул, әледән-әле тимер юл тамгаларына карап, тукталышлар буенча поездның хәрәкәт итү вакытын исәпләргә һәм чамаларга тырышты, аңа Сарүзәктәге Буранлы станциясен тәүлекнең кайсы вакытында узачакларын билгеләү мөһим иде. Шулай да шикләнү һәм борчылулардан бу исәпләүләрнең туры килгән чагында да котылып булмый, бигрәк тә кышын бу еш очрый. Күп итеп кар яуганда, поезд соткарланырга, графиктан чыгарга, соңарырга мөмкин бит. Иң үкенечлесе, аталары поезд белән төнлә, өйдән берничә дистә адым ераклыкта

гына узып киткәнен сизмичә, балалар белән Зарифа йоклап калырга мөмкин. Ә болай килеп чыгуы – бик ихтимал, Әбүталип, үзенең тулысынча көчсезлеген, язмышның кая таба борылуыннан һәм мәгънәсез бер очракка туры килүеннән тулысынча бәйлелеген танып, тагын да ныграк газап чигә иде.

Әбүталипның тагын курыкканы һәм Ходайдан аны бу бәладән йолуны бик сораганы: лачын күзле тикшерүчедән шул мәлдә генә булса да коткарып торуы, Тансыкбаевның чираттагы сорау алуны алар Буранлы станциясен узып барган сәгатьтә оештырмавы иде.

Кешенең бары тик мизгел эчендә генә якыннарын күрергә дигән самими теләгенә күпме каршылык һәм хәтәр киртәләр явызларча каршы тора, иректән мәхрүм ителүнең бәясе шулкадәр иде; тик бернәрсә сөендерә һәм өметләндерә, аның камерасындагы тәрәзә барган шәпкә уң тарафта – нәкъ шул Буранлы станциясендәге барак урнашкан якта булып чыкты.

Барча бу фикерләр, шик-шөбһәләр, куркулар Әбүталипны кичерешләр чоңгылына тартып кертеп, аның хәзерге булмышын онытгырган кебек иде, ул инде, киеренке көтү халәтенә тулысынча күчеп, үзе турында кайгыртмый, бу дөнья гамьнәре белән яшәргә теләми, тикшерүче Тансыкбаевның авыру хыялында уйлап чыгарылган, имештер, әле сугыш вакытыннан ук әзерләп куелган дошман агентурасы челтәрен ачыкларга, шулай итеп, янәсе, дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итү максатына ирешергә маташкан оятсыз бәндәнең аңа таккан һәм тануын берөзлексез таләп итеп торган коточкыч гаепләүләрен дә башыннан чыгарып ташлаган кебек иде.

Кулыннан ни Ходай, ни иблис тота алмаган Тансыкбаев үзе, Ходай белән иблис шикелле, бөтенесен алдан исәпләп һәм билгеләп куйган, бары тик ул кушканча хәрәкәт итәсе генә калган. Шул ният белән ул юлга чыкты, шунлыктан менә мәхбүсләр купесында Әбүталип Котлыбаевны да, «і» өстенә соңгы ноктаны куярга дип, үзе уйлап чыгарган «дошманнар» белән күзгә-күз очрашуга алып бара.

Әбүталипның исә Ходайдан үтенеп сораганы шул гына: вагон тәрәзәсеннән, бер мизгел эчендә булса да, мәңгегә саубуллашып, уллары Эрмек белән Даулны күзләре белән иркәләп узарга, Зарифасын күрергә һичкем комачаулый алмасын иде. Ул инде бүтәнгә өметләнми, язмыштан узмыш юк икәнлеген күңеле сизеп һәм аңы белән ачынып кабул итә, тәкъдире шулай, күрәсең! Бу – аңа бәхетнең соңгы елмаюы булачак, бүтән беркайчан да гаиләсенә әйләнеп кайту турында хыяллана алмаячак, чөнки Тансыкбаев каршында ул, чиксез хакимияткә ия хан алдындагы кебек үк, тулысынча яклаучысыз һәм хокуксыз, димәк ки, иртәрәк булырмы, соңракмы, барыбер, атып үтерелү яисә лагерьларда черүдән кала, һичнинди өмет юк, башка бер юл да күренми. Әбүталип күптән шундый нәтиҗәгә килде: ул – Тансыкбаев кулындагы котылгысыз һәлакәткә дучар ителгән корбан. Үз нәүбәтендә, Тансыкбаев мескенкәй – мәгънәсез тормышында икмәк черетүче, бер көнлек данга мохтаҗ, әмма даими рәвештә үзен-үзе чарлап торган, имештер, социализмның дөньяны яулап алуын туктатмакчы һәм җирдә коммунизм тантанасына комачаулык итмәкче дошманнарны армый-талмый эзләүгә һәм аларның тамырын корытуга юнәлтелгән җәза машинасының бер вак кыргыч кисәге.

Кайчандыр кемгә булса да гаепләү итеп ябыштырылган «халык дошманы» мөһере, әсир аркасына уелган йолдыз кебек, куптарып ала торган түгел. Аңардан бары тик теге яки бу төрле җәзаны алып – атып үтерелү, егерме биш, унбиш яисә ун елга ирекгән мәхрүм ителү белән генә котылып булачак. Мондый очраклардан башкача чыгуны көтәргә мөмкин түгел. Җәза бирүче генә түгел,

халык та «дошман» дип ябыштырыла торган бу мөһерне бертөсле укыйлар: әлеге тылсымлы төшенчә, ничектер этәрелеп, көч алып китсә, дошманнарны «ахыргача фаш итү» өчен җәлладның кулына теләсә нинди корал биреп, даими рәвештә аны җинаятькә этәрәчәк, ә канлы иблиснең корбаннары һәм аңа кул чабучы гавам илнең бу фаҗигасен изге максатка туры килүче ихтыяҗ дип кабул итәргә тиеш була. Чынлап та шулай түгелмени! Зиндан стенасына, сугыштагы кебек, «Сталин өчен!» дип каннары белән язып китүчеләр, кайсы окоптан чыгып, нинди пулемёт авызына капланалар?

Поезд тәгәрмәчләре Сарүзәк далалары буйлап алга тәгәрәде. Тансыкбаев белән аның тоткыны бер вагонда баралар иде. Майор фикеренчә, аларның һәркайсы, үзенчә булса да, хезмәт іяләренең бәхете хакына әлегәчә посып яткан идеологик дошманнарны фаш итү турында кайгырта, чөнки социализм моннан башка асыл мәгънәсен югалтыр, үзеннән-үзе таркалып-таралып төшәр, кояш астындагы күлдәвек кебек кибеп парга әйләнергә мөмкин иде. Шуңа күрә һәрдаим кем беләндер көрәшү, кемнедер фаш итү, нәрсәнеңдер тамырын корыту таләп ителә. Моның өчен бер яктагыларны – вакытыннан алда яңа дәрәҗә, икенче яктагыларны, бераз көттеребрәк булса да, үзләре «сигнал» җибәреп фаш иткән танышларыннан бушагач, рәшәткәле тәрәзә көтә...

Ә поезд тәгәри. Әбүталип, поездны туктатудан гаҗиз булган кебек, берничек тә ачы язмышын үзгәртә алмый, котылгысыз золым белән килешергә мәҗбүр иде. Хәзер ул боларның барысына да шулхәтле буйсынып һәм өметен өзеп карый, баштагы авырту тойгысы тупасланган һәм тәвәккәл каршы килү дәрте булмаган да кебек сүнгән. Инде, яңадан дөньяга туарга туры килсә дә, Тансыкбаев артында торган төссез, кешелексез көчкә буйсынудан котылып булмасын аңлый ул. Бу көч сугышта һәлак ителүдән куркынычрак һәм әсирлектә түбәнсетелүдән мыскыллырак, чөнки аның ахыры-азагы күренми, ул дөнья яратылганнан бирле килә иде, ахрысы. Ихтимал, Әбүталип Котлыбаев, тыйнак кына мәктәп мөгаллиме, кешеләр арасында, дәҗҗал белән йөзгә-йөз килеп, аның Галәм киңлекләрендә шактый озак эшсезлектән интегүе өчен җавап тотучы затларның берседер. Әйе, бары тик адәмнән азган ерткыч кына гасырлардан гасырларга үз ишләренең тамырын корытып баручы золым иясе була ала... Икенче яктан караганда, Әбүталип, «Сарүзәктә җәзалап үтерү» риваятен искә төшереп, Тансыкбаевны дөя аркасындагы дар агачының икенче башына «тигезләү» өчен асылган ком капчыгы итеп күз алдына китерә. Ул да, мескен, үзләре корган үрмәкүч тозагының корбаны түгелме икән? Иртәгә бүләк алып, берсекөнгә адәм рисвае булып йөрер көннәре килер бит әле аның да, дип, вакыт-вакыт рәхимсез җәлладын чын күңелдән кызгана иде Әбүталип. Бер поездда, бер махсус вагонда, гадәттән тыш мөһим бер эш буенча бергә барулары да аны шундый уйларга этәрә иде.

Тансыкбаевны төрле станцияләрдә җирле дәрәҗәдәге хезмәттәшләре каршылап, мөһим эшеннән бүлеп тордылар, кем – дуслык хакына, кем ялагайланып кына аңа төрле юл ризыклары һәм затлы эчемлек китергәндә, Әбүталипны бу хәтта шатландырды, тегенең сорау алу белән интектерергә вакыты азрак кала иде. Юл рәхәтен күреп барсын, әйдә. Кызыл Урда вокзалында бигрәк тә җылы очрашу булды, дуслары Тансыкбаев вагонына ак сөлге белән капланган, буы күтәрелеп торган табак күтәреп килгәннәр. Ишек төбендә сый-хөрмәтне кабул итүче сакчыларның берсе: «Казы, кабырга! – дип ярым пышылдап, авызына килгән суларны көчкә йотып куйды. – Исе генә дә ни тора! Шәһәрдә мондыйны таба алмыйсың. Дала ите шул!»

Тансыкбаевның, шинелен җилкәсенә генә салып, перронга рәхмәт әйтергә, саубуллашырга чыкканын күрде рәшәткәле тәрәзә читеннән Әбүталип. Түгәрәкләнеп басканнар, минсиңайтим, барысы да сайлап алган кебек нык, таза гәүдәлеләр, бүрткән кызыл яңак-йөзлеләр, елмаюлы тук чырайлылар, бик дәртләнеп кулларын болгыйлар, дәррәү көлеп җибәрәләр, – күрәсең, яңа анекдоттандыр, – салкын һавада авызларыннан кайнар пар бөркелә, башларында каракүл бүрек, юка гына кар өстендә, мөгаен, үкчәләре шыгырдыйдыр. Ә һәрвакыт уяу милиция бу тирәгә берәүне дә якын җибәрми, махсус вагон янында майорны саклаучылар баскан, үз-үзләренә ышанган, бәхетле халык, мәхбүсләр купесында алар богаулап керткән – карак түгел, кемнедер көчләгән яки үтергән кеше түгел, ә, киресенчә, намуслы, әдәпле, сугыш һәм әсирлек газапларын кичергән, балаларына һәм хатынына мәхәббәттән кала бүтән табынуы булмаган, шул мәхәббәттә тормышының төп мәгънәсен күргән зат интегеп утыруында берсенең дә эше юк. Нәкъ менә шундый, дөньядагы бер фиркадә дә тормаган һәм шуңа күрә кайсыдыр почмакка башын орып ант та эчмәгән, тәүбә дә итмәгән кеше аларга, хезмәт халкы бәхетле яшәсен өчен, төрмә сәкесендә ятарга кирәк булып чыкты...

Кызыл Урдадан соң таныш, күңелгә якын җирләр башланды. Кич җитеп килә иде. Кар баскан түбәнлекләрдә, бөгелеп-сырылып, Сырдәрья ялтырап китте, һәм, инде кояш чыгып барганда, дала уртасында Арал диңгезе күренде. Баштарак әле камышлы текә борылмасы ачылды, аннары, ерактагырак чиста суы йә утраучыгы белән, диңгез үзенең барлыгын сиздерергә тотынды, ә тиздән Әбүталип тимер юлның янында ук диярлек юеш комда диңгез ярына бәрүче дулкыннарны күрде. Боларның һәммәсен: карын, комын да, яр буендагы ташларны да, җил иркендәге диңгезне, шулай ук ташлы ярымутраудагы коба дөя көтүен дә – әле бит боларның барысы да анда-санда таралган болытларның ак таплары белән чуарланган биек күк астында, аларны берьюлы мизгел эчендә күздән кичерү гаҗәп иде.

Әбүталипның исенә төште: Буранлы Идегәй – Арал диңгезе тумасы, ә Казангап таныш балыкчыларыннан товар поездын озатып йөрүчеләр аша үзе яраткан киптерелгән арал балыгын әрҗәләп ала иде, аның йөрәге кабат борчылып кысылды – Буранлы станциясенә инде ерак та калмады – төн кичәсе генә, ә иртән, сәгать уннарда яки чак кына соңрак, махсус вагон таккан пассажир поезды гүләп килеп чыгар да Буранлының җилләрдә таушалган кечкенә йортлары, чәнечкеле кибәннәре, киртәләнгән кура һәм дөя каралтылары яныннан ыжгырып үтәр, бер-берсенә ялганып күзне камаштыра торган тимер юлларны артта калдырып, шунда ук, булмаган да кебек, күздән югалыр. Кояш чыгышыннан кояш батышына һәм кояш батышыннан кояш чыгышына таба үткән хисапсыз поездларны кем санаган, әмма Зарифага ул таңда кояш батышына таба махсус вагонның мәхбүсләр купесында Әбүталип узып китәчәген йөрәге әйтерме, ә бәлки, нәкъ шул сәгатьтә улларының күңеле ниндидер аңлатып булмый торган киеренке бер тойгы кичерер дә, алар поезд каршыларга йөгереп чыгарлар? Йа Раббым, кешеләргә шулкадәр авыр һәм ачы язмышны ник бирдең икән?

Февраль кояшы инде офык артына тәгәри, еракта, җир белән күк арасындагы, салкын булса да, мич авызыннан чыккан кебек алсу балкышка уралып сүнеп килә, озак та үтми, дала киңлегенә кышкы төн пәрдәсе төшәр. Эңгер-меңгер эченә әле генә күзгә чалыныр-чалынмас торган күренешләр кереп югала, станция утлары кабына. Ә поезд, суга баручы кыз кебек борыла-сырыла, дала төненә сукмак сала...

Йокы алмый интектерде Әбүталипны. Калай белән тышланган купе-камерада бикле килеш, ул үзенә урын таба алмый, почмактан почмакка бәргәләнә, уфыра, әледән-әле, назирның ачуын китереп, бер йомышсыз әбрәкәйгә чыгарга сорый. Тегесе инде, купе ишеген бераз ачып, берничә тапкыр кисәтү дә ясап алды:

– Тоткын, син нәрсә, һаман кыжмырдыйсың? Болай ярамый! Тыныч кына утыруыңны бел!

Әмма Әбүталип үз-үзен тынычландыра алмый иде, шуңа күрә кизү торучыга ялынмый булдыра алмады:

– Тыңла әле, ялварып сорыйм, туган, йоклап китәргә ни дә булса бирче, югыйсә үләм бит. Ипидер әгәр! Ә мин үле килеш сезгә кирәкме? Башлыгыңа әйт, үлсәм, минем белән нишлисез? Чынлап әйтәм, бер тамчы йокы алмый!

Ничек кенә сәер булмасын (бу кадәр тиз хәленә керүнең сәбәбен Әбүталип икенче көнне иртән аңлады), назир Тансыкбаев купесыннан ике төймә йокы даруы алып килде, һәм шуннан соң гына, дару эчкәч, инде төн уртасында Әбүталип йокымсырап китте, әмма барыбер чынлап торып йоклый алмады. Йокымсыраган хәлдә, тәгәрмәчләр тукылдавы һәм тыштагы җил улавына колак салып, төшләнеп ятты: имеш, ул, тәгәрмәч астына эләгүдән куркып, тыны кабып, хырылдап, паровоз алдыннан йөгерә, ә поезд аның артыннан бөтен көченә чаба икән. Паровоз алдыннан шпаллар буйлап ул җенле төндә йөгерде дә йөгерде, бу бастырылу, чынлап та, өндә булган кебек, шулхәтле ачык һәм куркыныч иде. Тамагы кипте, сусады. Ә паровоз аның артыннан, ут бөркүче фаралары белән өтеп, һаман куа килде. Ул, буран уйнаган юл читенә карый-карый, рельслар арасыннан җан-фәрманга йөгерде, гаҗизләнеп ярдәмгә чакырды: «Зарифа, Даул, Эрмек, кайда сез? Минем янга йөгерегез! Бу мин, сезнең атагыз! Кайда соң сез? Аваз бирегез!» Беркем дә дәшми, алда кара бушлык, ә артта – менә таптыйм, менә изәм, дип, дөбердәп килүче паровоз. Бу өскә баса-баса куган албастыдан качарлык хәл калмады... Шунлыктан тагын да авыррак була барды – курку, өметсезлек аякларны богаулый, гәүдә тыңламый, сулыш өзелә иде...

Иртә таңнан, җилкәсенә сырмасын салып, агарынган, битләре җилсенгән Әбүталип инде рәшәткәле тәрәзә буенда утыра һәм далага карап бара иде. Тышта әле караңгы, салкын да булырга тиеш, әмма, таң атуын белгертеп, әкренләп көн ачыла барды. Һава болытлы, күктә аяз уйдыклар күренсә дә, кар явуы бик ихтимал...

Әйе, инде Сарүзәкнең төп җирләре башланды, аларны кыш дәвамында кар баскан, кайбер төшләренә көрт өелгән, шулай да, игътибар беләнрәк карасаң, кашлык урыннарны, чокыр-чакырларны чалымлап була, ара-тирә тораклар кала, аларның морҗаларыннан иртәнге мич-учак төтеннәре күтәрелә. Бу чит-ят түбәләр дә өсләрендә эңгер булып тирбәлгән кышкы төтеннәре белән күңелгә якын иде. Тиздән Кумбель станциясе, ә аннан, өч сәгать тирәсе баргач – Буранлы. Күршедә генә дип әйтергә була, монда Идегәй белән Казангап йомыш төшкәндә дөяләрдә дә килгәлиләр иде: мәет ашларына, туйларга... Менә әле дә бу иртәнге сәгатьләрдә, башына төлке тиресеннән тегелгән зур колакчын бүрек кигән кемдер, коба дөягә атланып, дала буйлап бара. Әбүталип рәшәткәгә үк сыланды, ә, бәлки, безнекеләрдән берәрсе булып куяр... Әйтик, Идегәй, үзенең Каранарын иярләп, ниндидер эш белән бу якларга килеп чыкмас, дип, кем әйтә ала? Куәтле ата дөясендә эһ дигәнче йөз чакрымны узу аңа ни тора? Чапса, кайдадыр Африкадагы жирафтан кимен куймый иде бит Каранар.

Һәм ничектер, үзе дә аңышмастан, Әбүталип поездан төшәргә тиешле кеше кебек җыена башлады. Ике мәртәбә аягына киеп салды, чолгауларын яңадан әйбәтләп урады. Юл капчыгын тутырды. Һәм көтә башлады. Шулай да утырып тора алмады, сакчылардан иртәрәк юынырга рөхсәт сорады, тик купега әйләнеп кайткач, тагын үзенә шөгыль таба алмый кыбырсыды.

Ә поезд Сарүзәк далаларыннан бара иде... Үзенең чын хәленнән аерылмас өчен, Әбүталип кушырылган кулларын ике тезе арасына кыстырып утырды, инде тәрәзәгә дә сирәк кенә күз сала башлады.

Кумбель станциясендә поезд берничә минут торды. Монда инде барысы да үз иде. Хәтта каршыга очраган поездлар да, – товарныкы яки пассажир ташучылар булсын, – Әбүталипка якын һәм таныш булып тоелды, чөнки алар күптән түгел генә Буранлы аша үткәннәр, ә анда аны балалары һәм хатыны көтә. Бу инде җансыз җисемнәрне дә яратырга җитә иде.

Менә поезд яңадан юлга кузгалды, әле ул перрон буйлап барган арада, станциядән чыгып җиткәнче, Әбүталип аңа таныш булып тоелган йөзләрне күздән кичереп өлгерде. Әйе, әйе, һичшиксез, ул аларны, үзе күргәләгән Кумбельнекеләрне, белә иде, алар да, мөгаен, Буранлыда элек-электән яшәгән Казангап, Идегәй, аларның гаилә кешеләре белән аралашканнардыр. Казангапның улы Сабитҗан мондагы мәктәпне тәмамлады, шуннан институтка укырга китте...

Станция юлларын артта калдырып, поезд тизлек җыйды, торган саен кызурак бара башлады. Кумбельгә балалар белән карбыз алырга, аннары үзе генә Яңа ел чыршысы артыннан, башка йомышлар белән килгәне исенә төште Әбүталипның...

Иртән бирелгән ризыкка Әбүталип хәтта кагылмады да. Буранлы станциясенә бик аз ара – ике сәгать ярымлык юл калган иде, шул турыда уйлап, инде хәзер ул, кар ява күрмәсен дә буран чыкмасын, дип курыкты, ул чакта Зарифа белән балалар өйдә утырачаклар, һәм аларны бит ерактан да күрмәячәк...

«Йа Хода, – дип эченнән ялварды Әбүталип, – бу юлы гына карыңны туктатып торсана. Бераз түз инде, аннары туйганчы яудырырсың. Язга кадәр вакыт күп бит әле. Ишетәсеңме? Бик үтенеп сорыйм!» Үзалдына йомылып, кушырган кулларын янә тезләре арасына кыстырып, Әбүталип фикерләрен бер төенгә җыярга, сабырлыгын тупларга тырышты, аның сораганын Күкләр ишетсен, вагон тәрәзәсе аша гына булса да хатынымны һәм балаларымны күрергә язсын иде дип ихластан тели, шул мизгелне түземлек белән көтәргә разый иде ул. Ә менә алар да аны күрсәләр... Иртән, ишек артында кизү торган назир күзәтчелегендә битен-кулын юганда, ул күгәргән юынгыч өстендәге яшел төс иңгән иске көзгегә күз салды һәм үзен танымады: күзләрендәге очкын сүнгән, чәчләре чаларган, чырае идән астында үргән бәрәңге сабагы кебек аксыл, үлекнеке шикелле сары, маңгаендагы, йөзендәге җыерчык буразналары шулкадәр тирән уелып кергән, хәтта немец әсирлегендә дә мондый бетәшкән түгел иде ул... Ә бит картлык турында уйларга әле иртәрәк... Уллары Даул белән Эрмек, хатыны Зарифа күрсәләр, мөгаен, танымаслар, куркып калырлар. Шулай да өенә әйләнеп кайта алса шатланырлар иде, үзе дә, балалары һәм хатыны янында тынычлык табып, яңадан элеккеге хәлен торгыза алыр иде кебек...

Шулар хакында уйланып, Әбүталип тәрәзәгә күз салгалап барды. Менә яңадан таныш ике кашлык, арасында дөя өркәчедәй батынкы урын бар. Буранлы бала-чагасы белән шунда барырга, алар, дулкыннан дулкынга

сикергән кебек, чыр-чу килеп, сөенә-сөенә, кашлыктан кашлыкка йөгереп уйнасыннар, дип хыялланган чаклары искә төште.

Шулвакыт тоткын купесындагы ишек йозагына кискен генә шылтыратып ачкыч тыктылар, бусагада ике назир пәйда булды.

– Сорау алуга чык! – диде аларның берсе, өлкәнрәк дәрәҗәдәгесе булса кирәк.

– Нинди сорау алу? Ничек? Нишләп?

Әбүталипның мондый кыланышын болар көтмәгән иде, әлбәттә.

Өлкән назир хәтта аңа якынрак килде, күзләрен акайтып, беренче күргәндәге кебек текәлеп карады, ычкынмаганмы бу, янәсе:

– «Нишләп» – нәрсә дигән сүз? Аңламыйсыңмы әллә, сорау алырга дәшәләр сине!

Әбүталип, өметсезләнеп, башын түбән иде. Бер булмагач булмый икән. Тәрәзәгә сыланып, шулхәтле көткәнне күрермен дип өметләнде бит. Инде, һични уйлап тормыйча, тәрәзәгә ташланыр иде, әмма анда – тимер рәшәткә... Буйсынмый чара юк. Әбүталип, җилкәсенә авыр йөк салган кешедәй, әкрен генә урыныннан кузгалды һәм, назирлар озатуында, дар агачына барган кебек, Тансыкбаев купесына китте. Шулай да соңгы өмет чаткысы сүнмәгән иде: алда әле сәгать ярымлык чамасы юл бар, бәлки, аңа хәтле сорау алу да төгәлләнер. Бөтен ышаныч шунда гына... Тансыкбаев купесына кадәр нибары дүрт адым. Шул дүрт адымны Әбүталип бик озак барды. Ә тегесе аны көтеп тора иде.

– Кер, Котлыбаев, гәпләшеп, эшләп алыйк әле. – Йөзе һәм тавышы кырку булып күренсә дә, яңа гына кырынып, әче исле хушбуйга манчыган яңагын канәгать төстә сыйпаштыргалап, үткер күзләре белән Әбүталипны чишендергән төсле, сөйләнеп каршылады Тансыкбаев. – Утыр. Утырырга рөхсәт итәм. Сиңа да, миңа да шулай уңайрак булыр.

Сакчылар, бер сүз дәшү белән керергә әзер булып, ишекнең теге ягында калды. Ә лачын күзлене барыбер болай гына үтерергә мөмкин түгел. Кул астында берни дә юк. Ни шешә, ни стакан күренми, гәрчә, җае чыкканда, майор, ялгызы гына булса да, кәгеп алырга ярата. Купедагы аракы һәм кабымлык исе шул турыда сөйли иде.

Поезд, элеккечә үк, Сарүзәк даласын ярып, алга баруын белде, Буранлы станциясенә кадәр юл-ара кыскарганнан-кыскара. Тансыкбаев исә ашыкмый, нindидер язуларын укый, кәгазь арасында казына. Әбүталип, түземсезләнеп, урындыгында борсаланды, бу тынлык берничә минут эчендә дә аны җәфалап, зарыктырып өлгерде. Әлеге «эшләп алырга» чакыру шулкадәр авыр иде аңа, шуңа, сабырсызланып, Тансыкбаевка сүз катмый булдыра алмады:

– Мин көтәм, гражданин начальник.

Тансыкбаев, гаҗәпсенеп, күзләрен күтәрде:

– Көтәсең? – дип, аптырап, Әбүталипны тагын бер кат күздән кичерде. – Нәрсә көтәсең?

– Сорау алганны. Җавап тотарга...

– Ах вон оно что! – дип русчалап сузып куйды Тансыкбаев, бу минутта тоткыннан өстенлеген тою рәхәте кичерә һәм ачыктан-ачык тантана итә иде ул. – Что ж, бу начар түгел, Котлыбаев, әйтер идем, гаепләнүче, кылган гамәлләренә үкенеп, үз ихтыяры белән сорау алганны көтсә һәм, билгеле, тиешле җавабын тотса, бу – бер дә начар түгел... Димәк, аның әйтер сүзе бар, тикшерү органнарына ачар сере бар. Без икебез дә бер фикердә бит? – Тансыкбаев сорау алуны бүген нәкъ шулайрак, янаудан, сүгенүдән тыелып,

баллы-майлы тел белән, янәсе, дустанә алып бару кулай булыр, дип уйлады. – Димәк, син гаебең нәрсәдә икәнен аңлагансың, – дип дәвам итте ул, – һәм, хәтта үзең дошман булсаң да, тикшерү органнарына ярдәм итәсең килә, совет властеның дошманнары белән көрәшкә үз өлешеңне кертергә ашкынасың, шуның белән кырыс җәзаны йомшартырга телисең. Синең белән миңа совет властеның эти-әнидән дә кадерлерәк булуын аңлау кирәк. – Органнарда армый-талмый хезмәт итүче Тансыкбаев, үз-үзенә сокланыпмы, әллә, бик акыллы сүзләр сөйлим бит, дипме, канәгать бер төстә тынып торды. Аннары өстәп әйтте: – Мин һәрвакыт сине төпле кеше дип уйладым, Котлыбаев, һәм синең белән уртак тел табасыбызга һәрвакыт өметләндем. Ник дәшмисең?

– Белмим, – дип, икеле-микеле җавап бирде Әбүталип, – аңламыйм, минем гаебем нәрсәдә, – дигән булды, үзе яшертен генә вагон тәрәзәсенең тышына карап алды. Поезд күктән җиргә кадәр салынган авыр болытлар юрганы астында бик көчәнеп бара, шулай да Сарүзәк даласы, баш әйләндергеч тизлек белән, тавышсыз кинодагы кебек, артка йөгерә иде.

– Минем менә нәрсә әйтәсем килә, Котлыбаев. Ачыктан-ачык сөйләшик әле, – дип дәвам итте майор. – Сине бит, король шикелле, махсус вагонда болай гына алып бармыйлар инде. Аерым купеда теләсә кемне бушка йөртмәгәнне дә беләсең. Димәк ки, син – тикшерү эшендә бик кәттә шаһит. Синнән күп нәрсә тора. Шуңа күрә сиңа аерым таләп куела. Уйла. Ныклап уйла. Ә хәзер мин әйткәннәрне тыңла. Бүген кич, соң гына без Ырынбурга, ягъни мәсәлән, Чкаловка барып төшәбез. Анда безне көтеп торалар. Бу – безнең беренче тукталыш. Беләсең, анда ике братаның яши. Попов Александр Иванович һәм татар Сәйфуллин Хәмит. Икесе дә инде ышанычлы сак астында. Сүз уңаенда исеңә төшерим, алар синең күрсәтүең буенча утыралар. Икесе дә синең белән Бавариядә әсирлектә булуларын таный. Аннары бергәләп качкансыз, бик сәер шартларда, чөнки таш чыгара торган җирдән, ни өчендер, сезнең бригада гына кача алган, бусын әле без ачыкларбыз. Аннары Югославиядә сыену урыны тапкансыз. Аларның икесе дә шунда Англия миссиясе белән очрашуда булганнарын күрсәтә. Ни-нәрсә турында сүз барганын син яхшы беләсең. Болар хакында истәлекләреңдә үк тәфсилләп теркәгән идең. Кызыклы гына язмалар, минсиңайтим. Безгә Попов – резидент, ә Сәйфуллин – аның уң кулы һәм, кирәк була калса, аны алыштырырга әзер торучы кеше икәнлеге мәгълүм. Син, Котлыбаев, билгеле, агентурада йомышчы малай гына, шуңа күрә, тикшерү эшендә ярдәм күрсәтсәң, шактый җиңел котыла алырсың дип уйлыйм.

– Ниткән агентура? Әйттем бит инде, минем кырык бишенче елдан, сугыш беткәннән бирле аларны күргәнем юк, – дип бүлдерде Әбүталип.

– Анысы әһәмиятсез нәрсәкәй. Бөтенләй мөһим түгел. Шәхси очрашу, икәүдән-икәү калып сөйләшү турында сүз бармый. Арада кемдер элемтәче булган. Әйтик, шул ук гаделлек яратучы Идегәй Җангилдин, ди. Ул Ырынбурга яки башка җиргә бармадымы? Сезнең кем ашадыр элемтә тоткан булуыгыз да бар бит. Син башта уйлап бетер.

– Әгәр Идегәй Ырынбурга үзенең дөясе Каранар белән барды, дисәм, шул җитәме? – Әбүталипның түземлеге төкәнгән иде.

– Син һаман үз киреңә ябышасың, Котлыбаев. Юкка гына. Мин бит яхшылык белән сөйләшмәкче булам, тик син артың белән борыласың. Каршы торуың үзеңә зыянга гына. Ә Идегәй мәсьәләсендә борчылма, бездә урын җитәрлек, кирәк булса, аны да алырбыз, хәтта дөясе белән дә сыяр. Аңа тимәсеннәр, дисәң, күзгә-күз очрашу вакытында җүләр сатма.

Алдагы паровоз каршыга килүчесенә озын, көчле итеп сызгыртты. Аның гайрәтле гудогы Әбүталипның йөрәген кузгатты. Буранлы станциясенә кадәр барып җитү өчен вакыт беткәннән-бетә бара иде. Лачын күзленең фараз йөртү, гөманлау рәвеше Әбүталипны шөбһәгә салды. Мондый мәкерле көчкә бу илдә каршы торырлык берни дә юктыр. Ләкин шушы мәлдә Әбүталипны хәлдән тайдырган нәрсә – Тансыкбаевның гомер булмаганча теленә салынуы, күп сөйләшергә теләве һәм сорау алуны тиз генә төгәлләргә җыенмавы иде.

– Менә шул. – Тансыкбаев, үз алдындагы кәгазьләрне читкәрәк этеп, Әбүталипка күзләрен күтәрде. – Ышанам, без бер-беребезне аңларбыз, синең бу бәладән котылу юлың шунда гына. Ышанам, Ырынбурдагы күзгә-күз очрашу икенең берсен хәл итәчәк: йә син миңа эшне төгәлләргә булышасың, яисә мин, үкенечкә калмасын өчен, барысын да эшләячәкмен; ә аннан соңгысы – хөкемнән тора: дүртенче тапкыр утырырсыңмы, әллә «вышка» ук алырсыңмы. Бала-чага түгелсең, бөтен ягын да аңлыйсың. Күр дә тор, сез хезмәт иткән Титога кадәр үк барып җитәчәкбез. Бу хәлләрне Иосиф Виссарионович үзе күзәтеп тора. Беркем дә җәзасыз калмаячак, тамырларыгызны рәхимсез куптарып атачакбыз. Шуңа күрә, дустым, язмышыңа рәхмәт укы, мин сиңа зыян салырга теләмим. Тик син дә, әйткәнемчә, бурычлы булып калмаска тиеш. Ни турында сүз барганына төшендеңме?

Әбүталип җавап кайтармады, бары тик, эсселе-суыклы булып, Буранлы станциясенә барып җитәсе минутларны санады. Үзенекеләрне тәрәзәдән генә булса да күрергә язмаган, ахрысы. Аның миен шул фикер бораулады.

– Ник дәшмисең? Синнән сорыйм, нәрсә турында сүз барганын аңладыңмы? – дип төпченде Тансыкбаев.

Әбүталип баш какты. Әлбәттә, аннан ни таләп ителгәнен белә ул.

– Йә, күптән шулай дип әйтергә кирәк иде! – Тансыкбаев баш кагуны ризалык бирү билгесе дип кабул итте, урыныннан торды, Әбүталип янына килде, хәтта аның җилкәсенә кулын салды. – Мин акыллы гына егет икәнлегеңне, дөрес юлга чыгасыңны белә идем. Димәк, шулай килештек. Бернидән дә шикләнмә. Мин ничек әйтсәм, барысын да шулай эшлә. Иң мөһиме – күзгә-күз очраштырганда каушап калма, барысын да ничек булганынча сөйлә. Попов – резидент, кырык дүртенче елдан башлап, Англия разведкасына ялланган, илгә кайтарылыр алдыннан Титоның үзендәге киңәшмәдә катнашкан, баш күтәрү, фетнә кебек хәлләр була калса, дип, озак вакытка исәпләнгән йөкләмәләр алган. Менә шул җитә. Инде теге татар Сәйфуллин турында. Болай булып чыга. Сәйфуллин – Поповның уң кулы. Артык сүз кирәк түгел. Калганын үзебез карарбыз. Кистереп әйт һәм икеләнмә. Сиңа берни дә янамый. Берни дә! Мин сине ташламам, уңайсыз хәлдә калдырмам. Димәк, шулай килештек. Исеңдә тот. Дошман белән озак сөйләшеп тормыйбыз, аны юк итәбез. Ә дусларга безнең күңелләр хуш. Аннары, онытма, минем белән шаяру яхшыга илтми... Тукта, син нишләп агарындың әле, тирләп тә киттең кебек, хәлең начарландымы әллә? Һава җитмиме?

– Әйе, үземне начар хис итәм, – диде Әбүталип, баш әйләнүен һәм күңеле болгануын җиңәргә тырышып, чыннан да, ул бозылган ризык ашап агуланган кеше сыман иде.

– Ярар, алай икән, тоткарламыйм. Бар, Ырынбурга җиткәнче ял итеп ал. Әмма Ырынбурда койрыгың алтатар кебек торсын. Аңладыңмы? Күзгә-күз очраштырган чакта һичнинди уңга-сулга тайпылу юк. Бернинди «хәтерләмим, белмим, оныттым»нар булырга тиеш түгел! Барысын да ничек сөйләштек

шулай эшлисең. Ә калганына борчылма. Анысын үзебез ерып чыгарбыз... Менә шулай. Хәзер язып-сызып маташмыйбыз, бар, ял ит, ә Ырынбурда очрашу нәтиҗәләре буенча кәгазь тутырып, куллар куярбыз, тәртибе шундый. Бар. Синең белән аңлаштык дип саныйм. – Шул сүзләр белән Тансыкбаев Әбүталипны тоткын купесына озатып җибәрде.

Бу мизгелдән, әйтерсең лә яңабаштан, Әбүталип өчен ниндидер аерым тормыш башланды. Поезд да тизлеген арттырган кебек тоелды. Тәрәзә артында яхшы таныш урыннар йөгереп уза. Буранлыга кадәр санаулы минутлар гына калган булырга тиеш. Тынычланырга, үз-үзеңне кулга алырга, теләсә нинди хәлгә әзер булырга, әмма барысыннан да бигрәк ярсып чапкан ат шикелле поездны тыярга кирәк иде. «Поезд әкренрәк барсын», – дип уйлады Әбүталип, ниндидер сихри көчләрне үзенә теләктәшлеккә чакырып, һәм тиздән поезд, чыннан да, тизлеген киметкән кебек булды, әллә аңа гына шулай тоелдымы, барыбер тәрәзәдәге күзне суырып китә торган күренешләр сабырлана төште. Шунда ул үз-үзенә әйтеп куйды: «Барысы да мин сораганча булыр!» Һәм бераз тынычланды, сулышы иркенәйде; рәшәткәле тәрәзәгә сыланып, көтә башлады.

Поезд, чынлап та, Буранлы станциясенә – кайчандыр Әбүталипны дөнья нужасы читкә кагып, куалап китергән, шунда, балалар үскәнче, тарих түнтәрелешләре авышканчы дип кенә корган оясына җитеп килә иде. Тик боларын ук күрергә насыйп булмады шул. Гаиләсен язмыш кочагына ташларга туры килде, ә үзе менә хәзер бу җирләрне тоткыннар вагонында узып бара.

Әбүталип тәрәзәгә шулкадәр киеренкелек белән ябышты, әйтерсең лә күргәннәрен бөтен гомеренә, ахыргы сулышына кадәр, күзендә соңгы чаткы сүнгәнче хәтерләп калырга тиеш иде. Февраль кышының төш уртасында күргән бар нәрсәсе: кар көртләре, тимер юл буендагы кары эреп, бераз сары балчык беленә башлаган төшләр, байтак өлеше әле ак юрганы астында яткан, урыны-урыны белән генә ачылган дала. Ул аларны изге манзара буларак, табынып дип әйтерлек, дулкынланып, яратып күзәтте. Менә таныш кашлык, менә уйсулык, ә бу – Зарифа белән икәү, җилкәләренә эш кораллары салып, юл төзәтергә йөргән сукмак, менә – җәй көне Буранлы балалары, алар янында аның малайлары Эрмек белән Даул да йөгереп уйный торган кечкенә алан... Ә менә дөяләр төркеме, тегендәрәк тагын бер пар, аларның берсе – Идегәйнең Каранары, аны еraktan ук аерып була, шундый егәрле мал, каядыр үзалдына ашыкмый гына йөрер; тукта, бу ни булды – тәрәзә артында кар бөртекләре талпынды, кинәт кар яварга кереште, шулай шул, иртәдән үк күктә болытлар куера башлаган иде, һава бозылырга булган икән, тик кар дигәнең аз гына көтеп торса да ярый иде ләбаса, бик аз гына, инде бит киртәләп алынган дөя абзарлары һәм морҗасыннан төтен күтәрелгән беренче түбәләр күренде, ә менә, гадәттә, вокзалда гына була торган юл чатын – стрелканы да узып барабыз, поезд бер юлдан икенчесенә күчә, рельслар ялганган төш белән тәгәрмәчләр шакып хәбәрләшә, һәм паровоз йөртүчеләргә иң элек «юл-чатчы» – стрелкачы оясы-будкасы янында кечкенә флагы белән, һаман да шул, беләгендә, корыган агач шикелле, сеңерләре кабарып торган Казангап күренә; ай Алла, Казангапның «оя»сы да чакматашын чаккан арада гына күзгә чалынып калды, поезд инде алга таба, торак-посёлок яныннан узып бара; уңда – кечкенә өйләр, аларның түбәләре, тәрәзәләре, менә кемдер өенә кереп китте, Әбүталип аның аркасын гына күреп калды, ә менә кемдер киртә-такталар тирәсендә кайнаша, бала-чагалар өчен нәрсәдер кора. Идегәй, әйе, бу ул, Идегәй, аның өстендә – җиңнәре сызганулы сырма, янында кызлары, алар белән Эрмек тә шунда, әйе, газиз, кадерле улы Эрмек, ул Идегәйгә җирдән

нәрсәдер алып-биреп тора, йа Ходa, аның йөзе күзгә чалынып кына китте, ә Даул кайда соң, Зарифа кайда? Әнә, зур корсагын күтәреп, бер хатын атлый, станция башлыгы Сауленың җәмәгате ул, ә менә Зарифа да килә икән, яулыгы иңнәренә шуып төшкән, Зарифа белән Даул икәү бергә, Зарифа кече малаен кулыннан җитәкләгән, башы аңа таба иелгән, улына нидер сөйли-аңлата иде булса кирәк, алар Идегәй белән бала-чагалар нәрсәдер ясап яткан төшкә баралар, Әбүталипның: «Зарифа! Бәгырем! Даул! Даул, улым! Бу – мин! Сезне соң мәртәбә күрәм! Бәхил булыгыз! Даул! Эрмек! Бәхил булыгыз! Онытмагыз! Мин сездән башка тора алмыйм! Сездән башка, газиз балаларымнан, яраткан хатынымнан башка миңа тормыш юк! Бәхил булыгыз!» – дип ачыргаланып кычкырганын, өметсез тавышы белән станцияне яңгыратканы ишетелмәсен өчен, кулы белән авызын каплап өлгерүен алар белми.

Ватылган күңел көзгесенең ялтыравык кыйпылчыклары кебек ул мизгелләр, озак көтелгән Буранлы станциясен поезд күптән узып киткәч тә,ербөтен булып җыелды һәм, кабат-кабат, Әбүталипның күз алдына килеп басты. Инде тәрәзә артында ишеп-ишеп кар ява иде, инде күптән барысы да артта, еракта, әмма Әбүталип өчен вакыт әле генә кичергән күренешләр эчендә туктап калды: юлның үзенә бөтен авырту тойгысын һәм бу дөньяда яшәү мәгънәсен сыйдырган кисәгендә...

Гәрчә, тоташ кар яву аркасында, тышка карап баруның инде мәгънәсе булмаса да, ул үзен барыбер тәрәзәдән аерып ала алмады. Менә әле дә тәрәзәгә кадаклап-богаулап куелган кебек хәлдә бара. Аны шунысы тетрәтте: ул, бу дөньяның гаделсезлеге белән килешмәсә дә, барыбер кемнеңдер ихтыярына буйсынырга, шым гына, телсез җан иясе кебек, хатыны һәм балалары яныннан качып-посып узарга мәҗбүр булды, чөнки башына моңарчы ирегеннән мәхрүм иткән әлеге кара көч басты һәм, поездан сикереп каласы, хатынының, балаларының күзенә күренәсе, сагынып-саргайган гаиләсенә таба башын югалтып чабасы урында, кимсетелгән вә мескен кыяфәттә, кечкенә тәрәзәгә карап катты, бер почмакта утырырга һәм селкенмәскә боерылган эт хәлендә калдырган Тансыкбаевка үзе белән теләсә ничек кыланырга мөмкинлек бирде. Ниһаять, бераз тынычланыр өчен, бу минутларда Әбүталип, ачыргаланып, үз-үзенә сүз беркетте, аны телдән кычкырып әйтмәсә дә, барыбер аң төбенә салып, күңеленә бикләп куйды...

Күз ачып йомганчы булган күрү-күрешүнең ачы ширбәтен ул хәзер төбенә кадәр эчә иде. Инде тик шул гына аның хәленнән килә, тик шул гына аның ихтыярында калды – кабат-кабат барысын да җентекләп, бөтен ваклыклары белән күз алдында яңарту: иң элек һаман да шундый, сеңерләре кабарып торган кулындагы кечкенә флагын тотып, каккан казык кебек, урынын ташламаучы Казангапның таныш чалымнары, – станциянең әле бер, әле икенче башында баскан килеш, ул үз гомерендә ничәмә-ничә поездны уздырып җибәрде икән; аннары Буранлының кечкенә өйләре, терлек-туар өчен каралты-куралары китте, моржалардан сыек күксел төтен күтәрелгәне күзне иркәләп узды, һәм аннан соң, бала-чага арасында мәш килгән, шул вакытта аларга нидер корып маташкан Буранлы Идегәйне күрде, – өстенә җиңнәре сызганулы сырма, аягына кирза итекләр кигән зур, нык-таза гәүдәле, кара-туткыл йөзле Идегәй... Мондый туры, дөрес кеше, кыя кебек, үз-үзе булып кала алган адәм дөньяда бүтән бар микән, менә ул балалар белән бик яратып, җанын ярып бирердәй булып, нәрсәдер турында сөйләшә, аңа такта кисәгеме, әллә бүтән нәрсәме сузып торган улы Эрмек, анысы иске кечкенә кышкы бүректән һәм киез итекләрдән; шунда ук, Ходайның рәхмәте, алар янына килеп баручы Даул белән Зарифа... мескен

Зарифасы – иңнәренә шуып төшкән яулыгы ачкан кара бөдрә чәчләре, агарынган, шундый үз, кадерле йөзе; төймәләре чишелгән бишмәте, аякларындагы кайчандыр ул сатып алган тупас итекләре... – шулхәтле ачык булып күренде... Һәммәсе дә чиксез якын, онытылмас бу күренешләр Әбүталипны әле бик озак озата барды, ул үзенә газиз затлар белән күңеленнән генә кат-кат бәхилләште... Мондый югалтуны һичкайчан һәм һични белән дә алыштырып булмый иде...

Юл буе тышта кар яуды, җәяүле буран себерде. Ырынбурга барып җитәрәк булырга тиеш, ниндидер станциядә поезд бер сәгать чамасы туктап торды, юлларны көрттән арындырдылар... Монысын ул тыштан килгән тавышлардан аңлады, кешеләр, һава торышын һәм дөньядагы бөтен нәрсәне каһәрләп, сукрана-сукрана эшлиләр иде. Аннары поезд яңадан кузгалып китте дә, кар-буран өермәсенә уралып, алга таба тәгәрәде. Ырынбурга озак керделәр, юл буендагы куаклар, кара кәкре ботаклары белән, ташландык зираттагы корыган агачлар сыман, томан эчендә генә күзгә чалынып бардылар. Кала үзе яхшылап күренми дә иде. Вагоннарны аеру станциясендә төн ката басып тордылар – махсус вагонны озак кына төп составтан аердылар. Әбүталип моны вагоннарның этешү-төртешүеннән, берсен икенчесенә китереп ялгаучыларның тавышыннан, манёвр локомотивларының кычкыртуларыннан чамалады. Аннары вагонны тагын каядыр тартып киттеләр, күрәсең, запас юлгадыр.

Инде төн урталары иде булса кирәк, махсус вагонны үзенә билгеләнгән урынга кертеп куйдылар. Соңгы этелеп алу, астан ишетелгән соңгы команда: «Шәп! Тугар атыңны!» Вагон, җиргә ябышып калган кебек, шып туктады.

– Йә, булды! Җыен! Чык, тоткын! – дип, купе ишеген ачып әмер бирде өлкән назир Әбүталипка. – Тоткарлама! Чык! Йокы бастымы? Әнә саф һава сула!

Әбүталип аңа каршы әкрен генә урыныннан кузгалды һәм, назирга якын ук килеп, салкын тавыш белән:

– Мин әзер. Кая барырга? – диде.

– Әзер икәнсең, ул чакта атлавыңны бел! Ә кая барырга икәнен конвой күрсәтер. – Назир Әбүталипны коридорга уздырды, әмма шунда ук аны туктатты, гаҗәпләнеп һәм җене чыгып җикерде:

– Кая киттең? Ә синең юл капчыгың каламыни? Нишләп алмадың? Әллә аны мин күтәрешер дип көтәсеңме? Бар, хәзер үк сәләмәләреңне җыеп чыккан бул!

Әбүталип купега борылып керде, зиһене таралганлыктан онытып калдырган юл капчыгын теләмичә генә кулына алды һәм, янә коридорга чыккач та, вагон буйлап ашыгып, борчулы кыяфәттә килүче җирле ике погонлы белән бәрелешә язды.

– Тукта! – Әбүталипны назир стенага кысрыклады. – Уздырып җибәр! Күзең чыкканмы әллә, иптәшләр каршы алырга килгән.

Вагоннан тышка атлаганда, Әбүталип теге ике адәмнең Тансыкбаев купесына шакыганнарын ишетте.

– Иптәш Тансыкбаев! – Дулкынлану аларның тавышларына да чыккан иде. – Килеп җитүегез белән! Без инде сезне көтеп арыдык! Зар-интизар булдык! Ә бездә бүген кар ява! Гафу итегез! Танышырга мөмкинме, иптәш майор!

Кораллы конвой, – өчесе дә колакчын бүрек кигән, өсләрендә солдат формасы, – тоткынны, юллар аша алып чыгып, ябык машинага хәтле озатырга дип, аста көтеп торалар иде.

– Йә, төш! Нәрсә терәлеп каттың? – дип, конвойчыларның берсе ашыктыра башлады. Назир озатуында, Әбүталип дәшмичә генә баскыч буйлап аска атлады. Җил белән котырып буран уйный иде, йөзгә кисәк кенә салкын һава килеп бәрелде. Баскычның тимер тоткалары кулны куырып алды. Таныш түгел

станциядәге юл утлары белән генә яктыртылган караңгылыктан һәм кар белән капланып килүче рельсларның чәбәләнүеннән башлар әйләнеп китте. Моңа манёвр локомотивларының төрле яктан хәтәр-куркытып сызгыртуы да килеп кушылды.

– Туксан җиденче санлы тоткынны тапшырам! – дип, өлкән назир конвойга хәбәр салды.

– Туксан җиденче санлы тоткынны кабул итеп алам! – Өлкән конвойчының җавабы кайтаваз булып яңгырады.

Әбүталип белән саубуллашканда, өлкән назир:

– Булды! Кая кушалар, шунда атла! – диде. Аннары ни өчендер өстәп куйды:
– Ә анда машинага утыртырлар да алып китәрләр...

Бәреп яуган кар-бураннан йөзләрен каплап баралар иде. Әбүталип, җилкәсендәге юл капчыгына ышыкланды да, чамалап кына рельслар һәм шпаллар аша атлап чыга-чыга, конвой астында алдагы паровозларга таба юл тотты... Әле тегендә, әле монда төнге сменадагы локомотивлар сигнал биреп кычкыртуын дәвам итте.

Тансыкбаевны миһманханәгә алып китәргә килгән Ырынбур коллегалары, көтелгән кунакны каршылауны билгеләргә дип, аның җылы купесында бераз тоткарланырга карар кылдылар. Танышу хөрмәтенә, шайтан суын шунда, купеда ук, кабымлык белән йотып куярга, дигән тәкъдим дә керде: кич җитте бит инде, эш сәгате бетте. Кем риза булмасын. Сүз барышында Тансыкбаев йомгакның уңайга таба тәгәрәвен әйтергә булды: күзгә-күз очраштыруның уңышлы барып чыгасына ышаныч зур, диде, шуның өчен алар Алматыдан хәтле килделәр дә бит инде.

Коллегалар бик тиз аңлаштылар, тик, җанлы сөйләшү кызып киткәндә генә, кинәт тыштан ярсып кычкырган авазлар һәм вагон коридоры буйлап чабышкан итекләр тавышы ишетелде. Купега конвойчы белән өлкән назирыргылып керде. Конвойчы канга баткан. Авызы-бите кыргый төскә кереп чалшайган. Тансыкбаевка честь биреп кычкырды:

– Туксан җиденче санлы тоткын һәлак булды!

– Ничек инде һәлак булды? – Тансыкбаев, үз-үзен белештермичә, сикереп торды. – «Һәлак булды» – бу нәрсә дигән сүз?

– Паровоз астына ташланды! – дип ачыклык кертте өлкән назир.

– «Ташланды» – ул ни дигән сүз? Ничек инде ташланды?! – Тансыкбаев, шашынып, якасыннан эләктереп, назирны селкеде.

– Без юлларга килеп җиткәч, уңнан да, сулдан да манёвр поездлары кузгалды, – дип бутала-бутала аңлатырга кереште конвойчы. – Шунда ук составны кузгатып йөртә башладылар. Тегендә-монда... Ну, без көтеп торырга тукталдык... Шул чакта тоткын кинәт, юл капчыгы белән кизәнеп, башыма китереп орды, ә үзе туп-туры узып баручы паровоз юлына, тәгәрмәчләр астына ташланды...


Барысы да хәлнең көтелмәгәнлегеннән югалып, тынып калган иде. Тансыкбаев, бәрелә-сугыла, чыгарга җыена башлады.

– Нәгъләт, кулдан ычкынды бит, кабахәт! – дип, калтыранган тавыш белән сүгенде ул. – Бөтен эшне бозды! Барып чыкмады, ә! Котылды бит, китте! – Барысыннан өметен өзеп, кулын селтәде дә үзенә, тутырып, бер стакан аракы салды.

Аның Ырынбурдагы коллегалары шулай да конвойчыны, килеп чыккан хәл өчен бөтен җаваплылык синең өстә, дип кисәтергә онытмадылар...

*1991*

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ** *тәрҗемәсе.*



Рашат
Низами

# КАЙДА ЯЛГАН, КАЙДА ДӨРЕСЛЕК?..

## Абынам...

Күзләремне текәп бер карасам,
Ямьсезлеккә килеп абынам...
Илдә берәр ялгыш җибәрелсә,
Дары кебек дөрләп кабынам!

## Хәтәр

Әй, түрәләр һәм дә газиз халкым!
Әйтер сүзем сезгә шул хакта:
Туган телне теркәп куймаслармы
Халыкара «Кызыл китап»ка?..

## Иҗат

Ялгыз утрау кебек яшәп ятам,
Мин азатмын дөнья чүбеннән.
Эзлим, табам энҗе-мәрҗәннәрне
Тормыш дигән диңгез төбеннән.

## Шулпа

Куян шулпасының шулпасына
Түзәсең шул – акчаң тарайса.
Сәясәтнең тозсыз ашларына
Күнегүе кыен лабаса!

---

Рашат НИЗАМИ (1950) – *шагыйрь, прозаик, публицист. «Кызыл Җәй», «Яшәүгә гимн», «Сәйдәшнең соңгы елы» дигән роман-эссе авторы. Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## Манифест

Колак салды «безнекеләр»
Маркснның теләгенә:
Коммунизм дигәннәре
Булды тик шәүлә генә!..

## СССР

«Черек империя!» – дидек,
Таза җире күп иде.
Генсек «бабай»ларның гына
Сөйләгәне чүп иде...

## Бәддога

Халыкара рингта –
сугыш... кара сөрем...
Ник ашкынмый илләр яктыга?
Канлы сугыш генералларына,
Бомбаларга – бездән бәддога!

## Йокымсырый...

Кече парламентлар хокук сорый,
Башларына суксаң – йокымсырый.
Берни аңламыйча яшәп ята
Йә Машенька шунда, йә Шәмсурый.

## Ике тормыш

Сарай, яхта, хәтта самолётлар –
Олигарх өчен чүп кенә.
Пенсионер сөт һәм икмәк ала,
Вак акчасы җитми чүт кенә.

## Томана

Китапларга кереп чумды ишәк,
Өстәленә өйде һәммәсен.
Күпме эзләсә дә... табалмады
Яшәү белән үлем мәгънәсен.

## «Формула-1»

Илдә «КамАЗ»ны күтәрдек,
«КамАЗ» безне күтәрде.
Кайтарыгыз азатлыкны –
Сорамыйбыз бүтәнне!

## Аллергия

Үлән яки чәчәк тузанымы?
Болар миңа пүчтәк бер нәрсә.
Иң кыены – сәясәтче «брат»
Күзгә әгәр төтен җибәрсә!

## Муса. 1944 ел

Күрәсезме, яңа киллер булып
Күтәрелә яңа фашистлар.
Кешелеккә пистолетын төби
Яңа Гитлер, яңа Дантеслар.

## Доллар

Рубльне яратучы сирәк,
Бик күпләрне доллар кол итә.
Ач күзеңне! Шушы яшел кәгазь
Күп илләрне тузан, көл итә.

## Теләк

Сугыш чукмарларына мин
Зур сугыш башлар идем, –
Крокодиллар мыжгып торган
Елгага ташлар идем!

## Дөнья

Мин дөньяны тыңлыйм...
Кошлар сайрый.
Зәңгәр күлдә сазын уйный җикән.
Диктаторлар шушы матурлыкны
Тыңлый яки аңлый белә микән?

## Кырда

Сап-сары кыр – көнбагышлар иле...
Көнләшәмен, ахры, мин юләр:
Көнбагышлар... кызга борылып карый –
Кояш диеп әллә белделәр?

## Яңгыр

Яңгыр ява. Үләннәрне бөгә.
Күкнең төбе гүя тишелгән.
Шәбәренгән татар Шүрәлесе
Дулап чыга... әкият эченнән!

## Сәясәт

Дөньяларны бутый сәясәт,
Дөреслеккә кушып ялганны.
Ахмак бәндә генә сизми кала
Янәшәдән
Ять-яшь тарих узып барганны.

## Конституция

Безнең хокукларны яклаучы көч
Конституция, дигәндә...
Тот капчыгың!
Көмеш капкалары ялган аның,
Чынлык аунап ята идәндә.

## Бөрештек

ЖКХлар җылы бирүләрне
Туктатсалар – туңдык, бөрештек.
Утка, суга бәя күтәрелә, –
Кайда ялган, кайда дөреслек?

## Бер саплам


Кеше гомерләре – бер саплам җеп,
Ашыгып ага вакыт кич-иртән...
Вәт инәсен... Әҗәлетдин картның
Чалгы кайраганын ишетәм.

## Ятим

Язмыш шулай нигә кыерсыта? –
Ике күздән кайчак яшь ага.
Алименты пүчтәк нәрсә аның,
Әти кирәк ятим балага.

## Хөрәсән

Көн узсынга гына яшәп ята –
Акыл йоклый, кайнамый фикер.
Ике явыз черкине үтерде...
Көн үтте бит – Аллага шөкер!



Илдус
Диндаров

# КАРШЫЛЫКЛАР КЫРЫ

ПОВЕСТЬ

## 1. Сугышчан бурыч

Татвоенкоматның туплану пунктында ничәдер тәүлек куна-төнә интегеп, чиләнеп беткәннән соң, Әлфисне һәм аның белән тагын ике кешене ниндидер майорга чакырттылар. Алар керүгә, бүлмә хуҗасы – күзләре шешенке кабаклары астына яшеренгән, пеләш башлы карт – ыурыныннан авырсынып кына кузгалды да диварга эленгән СССР картасы янына барып басты. Бүлтәйгән корсагы мөмкинлек биргән кадәр иелә төшеп, шуннан нидер эзләде. Аннары бусага төбендә таптанган ир-атка, борылмыйча гына:

– Ну, орлы, бире килегез! – дип әмер бирде.

Тегеләр, бу нинди әкәмәт күрсәтер икән, дигәндәй, бер-берсенә карашып, җиңелчә генә аракы исе аңкытып торган офицер тирәсенә өерелештеләр. Ул кулындагы күрсәткеч таягы белән картаның аскы өлешендә, каядыр Урта Азия чүлләрендә «адашып» йөри иде. Әллә географиядән бик үк хәбәрдар түгел, әллә башы чатнабрак тора идеме, кыскасы, өметсез рәвештә Арал диңгезенә кереп «баткач», «йәле, малый, шул чёртова Узун-Агач станциясен табып бир!» дип, таягын карсак буйлы егеткә сонды. Һәммәсе дә сәхнә пәрдәсе зурлыгындагы сызымлы әсбапның «чабуына» карап кадалдылар. Әлфис «Узун-Агач» дигәннең бетереп татарча яңгыравын ишеткәч, ихтыярсыздан горурланып куйды һәм «безнеңчә, иң дөресе Озын Агач буладыр инде ул» дип, эченнән генә хатаны төзәткәндәй итте...

Шуның артыннан ук, бик хәтәр борын-каш җыерып, ифрат эшлекле кыяфәткә кергән иптәшләре белән, барабан корсаклы майорны, хәрби картада хәлиткеч һөҗүм юнәлешен билгеләүче штаб әһеле сурәтендә күз алдына китерде дә, чүт кенә көлеп җибәрмәде Әлфис. «Бөркет»ләрнең киеренкелектән чамасыз агарып каткан йөзләре, борын тарткалап, мышный-мышный, мәгънәсез төстә диварга текәлүе, һавалы офицерның исә кулларын күкрәгенә кушырып, мәгълүм Наполеон рәвешен алуы, чыннан да, шундый «илаһи» күренешне хәтерләтә иде.

Ниһаять, указка, тимер юл җепселләре буйлап чаба торгач, төртелеп калды.

---

Илдус ДИНДАРОВ (1949) – *язучы, журналист; «Гомер фасыллары», «Күңел яктысы», «Җәй кайда кышлый?» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Нурлатта яши.*

Тәбәнәк буйлы егет: «Менә Узун-Агач!» – дип, кош тоткандай сөенеп, хәбәр итүгә, бүлмә хуҗасының көр команда тавышы гөрелдәде:

– Так вот, призывник иптәшләр, сезнең алга самостоятельно!.. Менә шушы Узун-Агач станциясенә, андагы «N» хәрби частена барып җитү бурычы куела. Сезгә шундый зур ышаныч күрсәтелә. Аңлашылдымы? Документлар, командировочныйлар – бухгалтериядә. Всё!

Азаккы сүзен әйткәндә, ул, без никрутлар турында бөтенләй онытып, ындыр табагы кадәр өстәлендә казына иде инде.

Бухгалтериядә эшне тиз тоттылар. Һәркемгә ике тәүлеккә, өчәр сум исәбеннән, ашау-эчү әҗере бирелде. Озатканда үрә катырып, ранжир буенча бер рәткә тезеп бастырдылар. Документларны: «Син старший буласың!» – дип, бүтәннәрдән калку, чөгә балыгыдай озын буйлы, тар җилкәле Рәмзигә тапшырдылар. Икенде күләгәсе төсле буй-сынын карап кына арада иң юашын, үшәнен, арык гәүдәлесен өлкән итеп билгеләү галәмәте юлдашларының мин-минлегенә тиеп, берникадәр гаҗәпкә калдырды калдыруын. Армиядә шулайрак икән ул: уй белән түгел, буй белән үлчәп, дигәндәй, беренче чиратта озын кешене өстен күрәләр, эшлеклерәккә, юньлерәккә саныйлар икән, дигән сыек фикер икесенең дә башыннан йөгереп үтте. Әлфис кисәк үзендә бер мизгелгә генә, әллә кайдан гына калкып чыккан хакимлек сөю, түрә булу дигән татлы, әшәке хиснең кымырҗып куюын тойды һәм аңа бик уңайсыз булып китте. Вертикаль хакимлек, астан өскә таба, түрә-карага һичсүзсез буйсыну системасына корылган җәмгыятьтә гел шулай инде... Ул шундый итеп көйләнгән ки, нибары ике кеше генә дә үзара мөнәсәбәткә керә икән, шундук каршыга, котылгысыз рәвештә, кем баш була да, кем буйсына, дигән катлаулы, авыр сорау килеп баса. Үз-үзен ярату, мин-минлек, өстенлеккә ирешү сыйфаты һәрбер адәм баласының канында бар; аңардан бер селтәнүдә генә арыну мөмкин дә түгелдер. Бөтен хикмәт аны билгеле бер күләмдә, бер чиктә, ихтыяр көче белән тезгенләп торудадыр, мөгаен. Әмма Әлфиснең бәласе анда түгел иде: аңарда кемнедер буйсындырып, өстенлек алу теләге һичкайчан булмады, ул моңарчы андый мәртәбәле йөкне үз өстенә алмаска тырышты; ә менә шул сыйфатның киресе – буйсыну хасиятенә дә бик авырлык белән килешә, бирешә иде. Заманында хәрби флотта хезмәт итеп кайткан Салих агасы, сиңа мондый холкың-фигылең белән службада бик кыенга туры киләчәк, энем, дип, тикмәгә генә кисәтмәгәндер. Тагын шунысын да күзәткәне бар Әлфиснең: бүксәсен киереп, акыра-бакыра командалык итү өчен үлеп китә торган бәгъзе бәндә, үзенә туры килгәндә, һичнинди вөҗдан газабы кичермичә, югары торучыларга, рәхәтләнеп бил бөгә, баш ора, җанын бирердәй булып, буйсына да белә.

Әлфис әле генә өскә ишелеп төшкән яңалыктан бермәл исәңгерәп китте, ни сөенергә, ни көенергә белмәгән ике иптәше кебек үк, туплану пунктыннан йөгереп диярлек урамга чыкты. Көзге бакчага кереп, тормышларында әле генә хасил булган үзгәрешләр, вәкарь чырайлы майор, тагын әллә ниләр турында, шәрран ярып, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, кызып-кызып гәп кордылар.

– Мәтәм, берәрегезнең Урта Азия ягына барганы булдымы соң хатябы? Касы поездга утырасы икән? Ницек уйлыйсыз? – диде, беркемгә дә аерым тукталмыйча, терекөмештәй йөгереп торган чем-кара күзләрен уйнатып, кисмәк кебек базык, кыска буйлы, әле генә кодрәтле указка тотып карау бәхетенә ирешкән. Чүпрәле мишәренең шулай «ц»лаштырып «сүләшүенә» игътибар итми мөмкин түгел. Әмма аны үртәргә ничектер тел әйләнми. Эчкерсезлеге, шаянлыгы белән үзенә җәлеп итә торган, тынгысыз, кыбырсык,

кайгыртучан егет иде ул. Тора-бара үзенчәлекле сөйләменә дә күнегелде, ул кадәр үк колакны ертмый башлады... Хәсрәтле-борчулы чагында каратут йөзендәге калын иреннәре гел хәрәкәттә, сәер генә кыймыл-кыймыл килеп тора икән әле тагын. Үзе, хәзер үк, каядыр чатыр чабарга хәстәрләнгән кеше кебек, аркасындагы бөрмә капчыгының бавын да бушатмыйча, эскәмиянең бер башына чүккән. Калган икесе биштәрен, кулсандыгын читкәрәк, кайсын кая ташлап, бөтенләй туарылып, бәдәннәрен таратып, рәхәтләнеп утыра. Бу өч-дүрт төндә казармада рәтләп йокы кермәде шул. Хәл китеп, йончылган, алҗынган, эт булынган. Бәләкәй командның башлыгы буласы йомыкый Рәмзи, тәмам мәлҗерәп төшкән әнә. Җитәкче буларак, һәрчак уяу торырга, абруйлы, йомгаклау сүзен ул җиткерергә тиешле, югыйсә.

Әүвәл кеше-кара сүзен тыңлап, эченнән генә исәп-хисап итеп, соңра үз фикерен әйтергә күнеккән Әлфис:

– Иң элек, малайлар, капчыкларны ризык белән тутыру турында кайгыртыйк без. Сәфәребез озын булырга охшаган, ике-өч көнлек кенә түгелдер. Булган акча уртак казнада торсын, – диде. Аннары юаш Рәмзине үпкәләтмәс өчен янтыгына төртеп: «Син ничек уйлыйсың, старшой?» – дигән булды.

– Мин нәрсә, ...мин дә сезнең кебек, ...мин каршы түгел, – дип, гаепле бала сыман каушап, мөгрәде тегесе. Каушавын каушый, әмма эш рәтен белә, уңган, хәстәрле кеше икән үзе. Кибеттән мул итеп ризык, әйбер-төрбир сатып алганда, пырдымсыз Фаик кына: «Аракысы кайда соң, әзи[1], рәзе дүрт-биш шиша[2] алмак келәмисең?» – дип, Рәмзигә чекерәеп карады. Тегесе төксе кыяфәт белән, мыгырдана-мыгырдана, ризасызлык күрсәтеп, хуҗалык «кирәк-ярагына» ничәдер шиша «Мәскәүски»не дә тыгарга мәҗбүр булды. Аның бу кысмырлыгын дустанә күз кысышып, көлемсерәп үткәреп җибәрделәр. Күр, карун, саран, яңа байгураны, нишләгән була: шәхсән үз кесәсеннән чыгарамыни, янәсе. Дөресен әйткәндә, Рәмзинең хәмер ише зыянлы малга күңеле тартмый, җитмәсә әле, шул чүп-чар өчен акча әрәм-шәрәм итүне бөтенләй дә хупламый иде. Мондый үтә саранлыгының асыл сәбәбе кояшлы тарафка кузгалган поездга утыргач кына ачыкланды...

Әлфиснең бу мыштымбай белән тәүге танышуы әлеге дә баягы туплану пунктының тынчу казармасында ук булды. Утарга ябылган сарыклар сыман, анда бәрелеп, монда сугылып йөрүдән тәмам туйган, арыган, билгесезлектән ачуы кабарган, көч-дәрманын кая куярга белмәгән, шәраб пары белән иләсләнгән никрутлар, караңгы иңеп, командирлар кайтып киткәч, тотыналар, минсиңайтим, бер-берсенең тузанын «кагып» сугышырга, дөмбәсләшергә. Чаллылар Әлмәтләргә каршы чыга, Сарманнар, Минзәлә егетләрен ошатмыйча, буза куптара. Катлы-катлы сәке-сәндерәләр өстенә сузылып, биштәренә баш төрткәннәргә төне буе йокы эләкми инде. Карусыз, ялгызак, боек авыл малайларын сагалап кына йөри бергә укмашкан башкисәр хулиганнар өере. Юктан гына килеп, чәердәй ябышып каныгалар, акчасын, затлы әйберләрен акыртып талыйлар...

Үзенә арка куеп, черем итүче озын буйлы, чандыр малайны ике бәндә дорфа гына эткәли-төрткәли башлагач, түзмәде, сикереп торды Әлфис. Гәүдәгә уртачадан аз гына биегрәк күренсә дә, тыгыз, нык бәдәнле, кабарып торган мускуллы, таза куллары, кем әйтмешли, үз урынында. Озынча ак йөзле, калку борынлы, куе кара кашлы, коңгырт күзле, гадәти ир-егет ул үзе. Уң як каш өстендә нәзек кенә иске җәрәхәт эзе бар, аскы ирене бераз алга чыгыбрак тора.

[1] Әзи *(диал.)* – абзый, абый.
[2] Шиша *(диал.)* – шешә.

Әмма бу үзенчәлеге Әлфиснең йөзен-битен бозмый, аны мөлаем һәм шул ук вакытта үзсүзле, үҗәт, нык ихтыярлы кеше итеп күрсәтә иде... Әлфиснең буй-сынына сынаулы, бәяләүчән караш ташлап, иң мөһиме – тамчы да шүрләү шәүләсе сизелмәгән, тып-тыныч кына карап торган күзләренә баккач, дәшми генә чигенде, тиз генә шыкайды билгесез ике мәлгунь.

Шул адәм актыкларына «ясак» түләү нияте белән, букчасында казынырга тотынган күрше егет, көтмәгәндә үзенә яклаучы табылгач, бу хурлыклы ниятеннән ваз кичте.

...Инде хәзер, бар йокы качкач, таңга кадәр сөйләшеп яттылар. Яңа танышы Югары Ослан районыннан икән. Рәмзи исемле. Фамилиясе Кутузов дидеме? Ялгыш ишетмәдемме дип, кабатлап сорады Әлфис. Шундый атаклы фамилия йөрткәнгә, ничектер уңайсызланып елмайды да Рәмзи, кыенсына төшеп аңлатты:

– Әти бит... Безнең фамилия ...элек Котдусов булган үзе... Бабам Котдус исемле... Әти тоткан да ...авыл советында эшләүче әшнәсеннән... Кутузов дип яздырткан. Шуннан бирле...

Әлфис шуның өчен генә дә, белер-белмәс килеш, урынсызга хафалануына сәерсенеп, кызганып карап куйды егеткә. Эх, томаналык! Тарихыбызны белмибез, санламыйбыз. Фельдмаршал үзе дә бит татар нәсел-ыруыннан чыккан. Аның да ич ерак бабасы Котдус атлы. Кутузов фамилиясе шуннан, куян шулпасының шулпасы кебегрәк, ясалган да инде. Аны исә тач урысныкы дип йөрибез һаман да... Гомумән, үз милләтенә, татарга кагылышлы мәсьәләләрдә бик нәзбереккә, талымчанга, вакчылга әверелә Әлфис, дәреслекләрдә тарихи дөреслекне, хакыйкатьне гаделсез рәвештә тупас уйдырмалар белән дыңгычлап тутырып, бозып күрсәтүне ифрат авыр, әрнеп кабул итә. Һәрхәлдә үз алдында милләтен кимсетүгә һич кенә дә юл куймый. Андый чакларда, кемнең кем булуына карамастан, әтәчләнеп, кызып-кызып бәхәскә, алышка ташлана торган гадәте бар. Үзе татарчасын җиренә җиткереп, әдәби нормаларны саклап, сыңар урыс сүзен дә кыстырмыйча сөйләшергә тырыша. Бу – кыланып-нитеп, күзгә төтен җибәрүе түгел; татарлыгы белән ихластан горурланып, ана телен, аңлы рәвештә ярату галәмәте. Авызыннан бер кәлимә оятсыз сүз дә ычкынмый аның. Ул Чеховның: «Тәрбияле кеше эте янында да сүгенми», – дигән тәгъбирен үзенә тормыш кагыйдәсе иткән...

Туган авылы белән таныштырганда, Рәмзинең:

– Кызыл Байрактан мин, – дип ирәя төшебрәк әйтүен бик ошатты ул. Егет аның алдында бер карышка үсеп киткәндәй булды хәтта! Туган җир кадере, кодрәте аның җанында бар әле, димәк. Әлфис үзе исә бу атаклы, күркәм авылны күптәннән ишетеп белә. Салих Сәйдәшев исеменә бәйле ич. Кызганыч, анда барып, мәшһүр композиторның аяк эзләрен саклаган изге төбәкне күрергә туры килмәде әле аңа. Армиядән кайткач та әлеге истәлекле урынга сәфәр кылырга ниятләп куйды ул...

## 2. Бәлки, сиңа «Наполеон» кирәктер?

Плацкарт вагонга кереп, үзләре генә бер почмакка сеңгәч, ниндидер кара көч тырнагыннан, сулышны кысучы кысанлыктан, рухи тарлыктан, ниһаять, арынгандай, җиңел сулап куйдылар. Туган йорт җылысы, иминлеге, татулыгы урнашты сыман биредә. Купе өстәлен кыяр-суган, тавык ите, пәрәмәч-коймак, чәкчәк, ипи-тоз, балык консервасы белән тутырдылар. Аяк астында, коргаксыган җаннарны ымсындырып, ара-тирә шешәләр дә күңелле чылтырап алгач, ашкын хис-тойгылар бөтенләй ташып чыкты, шау-гөр башланды. Экзотика эзләп, каядыр мавыктыргыч, кызыклы туристлык сәяхәтенә кузгалдылармыни!

Тамак төпләрен әче «арыш мае» белән шәп кенә чылаткач, тартынып торулар бетеп, иркенлектән, рәхәтлектән тәмам туарылдылар.

Араларында иң шугы Фаик, кулы белән өстәлдә «барабан» кага-кага, балачактан ук таныш бер мәгълүм такмакны көйли:

Әтәц менгән киртәгә, кикерикүк итәргә.
Әтәцкә повестка килгән әрмиягә китәргә!
Әтәц әтә: мин бармыйм, таук әтә: мин калмыйм;
Әтәц әрмиягә китсә, бер йомырка да салмыйм.

Тостлар әйтешү, мәзәк сөйләшү китте. Һәркем нотыгын хәл кадәри үткенрәк, кызыклырак, тапкыррак итәргә тырыша. Нәүбәт Рәмзигә җиткәч кенә, түгәрәк мәҗлес учагы, куәсе җитмәгән шампан шәрабе сыман сүрелә язды.

– Егетләр, – диде ул, табын ямен җибәреп. – Зинһар, кыстамагыз, миңа эчәргә ярамый...

– Бүген әсирлектән котылу хөрмәтенә ярый! Йә, йә, назланып, кыланып утырма инде, – диде Әлфис, тегене дәртләндерергә тырышып.

– Бәлки, син коньяк кына йиппәрәсеңдер берцәк, ә? Әйтик, «Наполеон» дигән затлысын... Әллә «Камю»га да даволенмы?! Йә, йә, мәзелесне бозма! –дип шамакайланды, официант кебек, бөлгенә сөлге салган Фаик.

– Аңлагыз инде, ...миңа аракыны бөтенләй эчәргә ярамый бит... Ышаныгыз, зинһар! – дип инәлде «штрафка калган» Рәмзи. Хәтта гаҗизлектән күз яшьләре атылып чыкты.

Юк, ми шәрифләренә исерткеч сөреме ягылгач, егетләр рәхимсез: «давай булгач, давай!» Шул рәвешле тинтерәткәч-йөдәткәч, соңгы дәлилен чыгарып салды «командир»:

– Аңлагыз! Миндә ...аллергия! – дип пышылдады ул, бик каты серен бүлешкәндәй, күрше купе ягына карангалап, колагын шомрайтып.

Шул чит-ят сүзне ычкындыруы булды, табын тәртибен санламавы өчен, кашлары җыерылып, чырайлары чытыла башлаган мәҗлестәшләр, дәррәү ихахайлап, көлешә башлады. Ну инде! Теләсә нинди сәбәпне кабул итәргә әзерләр, әмма шушы сәер, хикмәтле «аллергия» дигәне генә чеп-чи мәзәк, сафсата тоела иде аларга. Үлән-чәчәк исеннән нидер була дип каядыр ишеткәннәре бар барлыгын. Һи, ул бит авылда үсмәгән, чытлык кызлар белән генә булгалый, диләр ич! Аллергия, имеш! Мигрень түгелме тагын! Әлфис, Рәмзидән бөтенләй йөз чөерүләреннән шикләнеп, сыйлау-кыстауны чикләргә вакыт җиткәнен аңлады:

– Печтик кенә эчеп куй да инде...

Иплән кенә, шулай араны җайларга тырышуына карамастан, Әлфиснең асылда үз сүзендә нык торуына инангач, Рәмзигә боргаланырга хут калмады. Ул, тәүге тапкыр күргәндәй, иптәшләренә күз йөртеп чыкты, үз кулы белән агу эчеп, үлем җәзасына хөкем ителгән бөек философ Сократ кебек, караңгы чырай белән: «Ярый, ...эчәм! Карагыз аны... азагы... ничек...» диде дә стакан төбендәге сыекчаны бер тында йотып куйды. Шуннан соңмы... шуннан соң коточыргыч хәл килеп туды: акай күзләрен кан баскан, бите бурлаттай кып-кызыл булган Рәмзи, маңгае белән шап итеп өстәлгә капланды һәм башын салган килеш, бер мәлгә тынсыз-өнсез калды. Бетте, үлде, харап булды!.. Ул да түгел, авызларын карга очып керерлек итеп ачкан хәлдә, тораташтай катып калган иптәшләрен сискәндереп, укшып-укшып коса башлады. Рәмзинең бөтен фаҗигасен хәзер генә тойдылар бугай. Мәҗлеснең кызыгы бетте... Әлфис

җәһәт кенә сырхауның баш астына курткасын рәтләп салды, кулъяулыгын, юешләтеп, маңгаена куйды:

– Кеше үтерә яздык ич, дураклар! Менә сиңа уеннан уймак!

Бу аянычлы, иләмсез, авыр күренеш Әлфисне бигрәк тә нык тетрәндерде. Аңа район газетасы битләрендә «яшел елан»ның адәм баласына зыяны-зәвере турында еш язарга туры килгән булса да, шушы агулы эчемлекнең үтергеч көчен-кәсафәтен якыннан торып, болай итеп, барча күңел кайтаргыч, ямьсез нечкәлекләре белән, беренче тапкыр күрүе иде. Шәхсән үзенә килгәндә исә, бәйрәмнәрдә, «кызыл» көннәрдә эчми түгел, эчкәли иде, әмма ул юха елан белән «дуслыгы» һичкайчан булмады. Киләчәк армия хезмәтендә аннан саграк булырга дигән анты менә шушында, шушы үкенечле вакыйгадан соң тагын да ныгый төште бугай. Мут, наян Фаик та мыек очына ни булса да бөтерми калмагандыр.

Рәмзи үпкә-кинә сакламый торган, «мировой» егет булып чыкты үзе. Чыраена бераз адәм төсе кереп, рәткә килгәч, зәгыйфь, инәлүле тавыш белән:

– Зинһар, анда баргач, минем аллергия турында сөйләмәгез ... – дип үтенде.

Икесе дә, кан агызып ант итмәсәләр дә, бу көтелмәгән куркыныч хәлнең шулай якынча зыянсыз, имин генә үтүенә сөенә-сөенә, ул хакта авыз да ачмаска сүз бирделәр.

Бер-бер артлы, төрле поездларга утырып, бишенчеме-алтынчымы көн барулары. Барасы юлның иге-чиге офыкларга томырылган рельслар очында. Ә аларның кайчан беткәне бар?! Җир шары түгәрәк ич... Поезд тәгәрмәчләренең рельс ялгаулары турысында сикереп-сикереп алуы, «тык-так» иткән ритмы, никрутларга «зык-зак, зык-зак, озак-озак» дип ишетелеп, үрти, үчекли төсле. Озын юлның кайчан бетәсен белмәгән, чамаламаган кеше өчен юл газабы икеләтә ялыктыргыч бит ул. Вагонда моңсу тынлык урнаша. Авыз күтәреп ни турында сөйләшергә соң? Барча яңалык тәүге көннәрдә үк сөйләнеп бетте. Күз карашы, ирексездән, вагон тәрәзәсеннән ялт та йолт күренеп калган ялыктыргыч, гел бертөрле күренешләрне йота. Йота да оныта, күңелдә һич ни сарылып, берегеп калмый. Каты кылганнар котырып үскән буш дала да дала гына...

– Бакчы, әзи, күпме җир сөрелмичә, әрәм ята. Бездә булсамы! Ё-моё! – диде кинәт туп кебек гәүдәсе белән тәрәзәгә капланып барган Фаик. – Менә ничә көн киләбез, ийеме, ник бер трактор оцрасын. Духы да юк... Әллә монда бер дә эшләмиләрме икән? Ни ашап яшәмәк келиләр икән?.. Әтәм аны, авыллары да әллә нинди генә...

...Табигать көне белән үзгәрә, яңара башлады... Берничә сәгать үтте микән, очы-кырые күренмәгән шул ук бөек дала кинәт танымаслык үзгәреш кичерде. Анда-санда чатырга да, алачыкка да тартым тәбәнәк корылмалар, каралты-кура, саман йортлар, дуваллар очрый башлады... Әлбәттә, тирә-юньдәге яшәеш, көнкүреш турында тәрәзә аша күзгә чалынып өлгергән манзара буенча гына фикер йөртергә кала. Борынгы казакъ акыны: «Ни күрәм, шуны җырлыйм», – дигән төсле, поезд кайдан үтә, шул тирәдәгесе күзгә керә дә бетә – вәссәлам! Әле генә «Волга», «Москвич» автомобильләре, заманча автобуслар туктап торган тимер юл кичүен уздылар. Ул да булмый, ишәккә атланган фәкыйрь генә киемле кеше сыны, кинотасмадагы шикелле йөгереп, артка шуышты. Әнә тимер юл буенда тәкәббер кыяфәтле дөя, «төкерәм дөньясына» дигән күк, поезд, үзенә ышкылып дигәндәй, гүелдәп узганда да, авыр керфекләрен күтәрергә дә иренеп, һич кымшанмый, күшәп тора... Ерак офыкта, күгелҗем дала читендә үк ак тирмәләр тезмәсе шәйләнә... Менә шундый чуалчык күренешләр, иске белән яңа буталып беткән, болгавыр манзара – бүгенге

пассажирның күңеленнән вакыт төшенчәсен юып ала сыман. Һәр станция, вокзал бинасының маңгаена кадакланган «Бөек Ватан сугышында Җиңүгә – 30 ел!» дип язылган плакатлар гына хәзер кайсы чор, ни замана хөкем сөрүен искәртә һәм, вагонда ара-тирә кыштырдаган тыңкыш радио гына, КПССның XXV съездын лаеклы каршылау турында такылдап, искә төшереп тора иде.

Бер тукталышта яннарына буй-буй чапан кигән, тигез итеп кырылган башына төсе уңган дупы[3] чәпәгән, иңенә ике яктан асылынып торышлы чыпта капчыклар салган, сирәк төкле, арык йөзле бер карт кереп утырды. Бергәбергә күңеллерәк булыр, дип, аңа урын биреп, кысылыштылар. Сәламнәр алышкач, йөзьяшәр картның пәйда булуын гына көткәндәй, сәфәрчеләр ифрат кызыксынып, сораша башладылар: Казакъстанның яманатлы «Ач дала» исемле бушлыгы моннан бөтенләй читтә кала икән... География дәресләреннән таныш, зур гына станциягә килеп тукталгач, «димәк, тиздән Кыргызстанга җитәбез», дип, эчтән генә иркен сулыш алды Әлфис.

Черем итеп азапланган карт, күзләрен ачты да, таулар ягына ымлап, эчке бер дулкынлану, чиксез олылау һәм ихлас табыну белән:

– Ала Тоо! – диде.

– Нәрсә, бабай, Алатаумы? – дип, Әлфис шундук аның сүзен эләктереп алды.

Бабай миләш кагы төсле җыерчыклы йөзен тутырып елмайды һәм, башын ия-ия: «Ала Тоо! Ала Тоо»! – дип тәкрарлады.

– Хи, әллә ни биек тә түгел икән! – диде Фаик, артык гаҗәпсенү сиздерми генә. – Бакчы, Керкәле таулары кебек, дисәм...

Әлфис, җир тирәли сәяхәт-маҗаралар, янар таулар, океаннар турында күп укыган егет, бозлы очлым кигән, каракучкыл-яшел итәкле, галибанә, бөек тауларны болай түбәнсеткән өчен үпкәләгән, ризасызлык белдергән кебек, урынында кымшанып куйды һәм, кайчандыр укыганнарын исенә төшереп:

– Ерактан гына шулай тәбәнәк күренәдер ул. Якыннан килеп карасаң! Казакълар, кыргызлар өчен иң изге таулар инде барыбер. Өстендә яшеллек белән ак карлы үзәннәр аралашып, ала-кола булганга, шулай Алатау дип атаганнар аны.

Астагы ятакта бөгәрләнгән Рәмзинең кинәт ыңгырашып куюы уйларны бүлдерде. Теге пирәшләүдән соң, тернәкләнеп кенә килә әле егет... Менә ул акрын гына торып утырды һәм ерактагы таулардан күзен дә алмый карап бара башлады. Талчыккан, йончыган чырае яктыра төште. Әһә, рәссамның да күңеле уянды, аңарда да иҗат уты кабынып килә иде бугай. Рухи савыгып, юнәеп баруына куанып, аны тагын да үсендереп, юатасы килеп китте Әлфиснең:

– Без барасы җир әнә теге таулар артында гына! Башыңны югары тот, командир! – диде ул, шаяртып.

## 3. «Сез Казаннан түгелме?»

Ниһаять, поездлан поездга күчә-күчә, куе сакал-мыек үстереп, рәтле кием күрмәгән йолкыш дәрвишләргә охшап калган никрутлар, данлыклы Озын Агач дигән стансага килеп җиттеләр. Поездлан төшүгә, иң әүвәле совет законнарын ихтирам итүче чын патриот булып тәрбияләнгән, зыялы кешеләргә хас риясыз, күндәм, карусыз, ыктымат[4] затлар җирле хәрби комиссариатны эзләп киттеләр. Янәсе, кайда соң ул безнең газиз, кадерле часть, күзләрен талдырып, тилмереп безне көтеп торучы гаскәриләр? Анда ничек эләгәсе?

[3] Дупы *(үзб.)* – үзбәк түбәтәе.
[4] Ыктымат *(диал.)* – һәр эшне җиренә җиткереп башкаручы.

Ни турында сүз баруын ишеткәч, ошбу хәрби учреждениенең бөтен халкы урамга чыкты. Ерак юллар гизеп килгән биштәрле-чемоданлы мосафирларны тәмам шаклар катып, сокланып чолгап алдылар.

– Неслыханно! Казанның үзеннән! Безнең мондагы халык кулына повестка тоттыруга, шундук тауларга кача әнә, – дип тел шартлатты карт кына бер прапорщик. Икенчесе, ялкау гына сагыз чәйнәп торганы, мыскыллы көлемсерәде:

– Болар да инде... Ник армиягә шулхәтле атлыгып торалардыр...

– Курорт дип беләләр микәнни аны? – дип, иңнәрен сикерткәләде кызыл иренле ханым.

– Тау һавасы иснәп, бәлзәм эчеп сихәтләнергә килгән алар, – дип шаркылдады өченче офицер.

Күренеп тора, әллә кайдагы, таныш түгел татар иленнән ашкынып килгән, сәер холыклы кешеләрнең мондый намуслы, вөжданлы, кыю гамәле турында көнләшү белән, ятсынып сөйләнәләр.

Бу мәхшәргә, «аю биетү» тамашасына, болдырдан төшеп килүче төз буйлы, аеры кара сакаллы полковник нокта куйды:

– Йә, җитәр, эш урыннарыгызга таралышыгыз! Нинди чабата кәмите оештырдыгыз монда?!.

Аннары ул, шаян карашлы зур, якты күзләре белән кунакларга карап алды да үз бүлмәсенә чакырды. Юл документлары буенча, хәрби кафедрасыз вуз бетергәннән соң, армия сафларына бер елга гражданлык бурычын үтәргә баручылар, ягъни «одногодниклар» икәнлекләре мәгълүм булгач, аның хөрмәте тагын да арта төште бугай. Ни дисәң дә, малай-шалай түгел болар, тормышны азмы-күпме күргән, азу теше ярган, салмакланган ирләр. Армиянең «алтын фонды»н тәшкил итүче халык. Шуңа да, үз дәрәҗәсенә тиң күреп, гәп корды, кайнар чәй тәкъдим итеп, тегене-моны белешкәч, «N» частена ничек барырга кирәклеген иренмичә аңлатып бирде. Бераз ялгышканнар икән Казанның туплану пунктындагы хәрби стратеглар: бу төбәк әле Казакъстанга керә, егетләргә кирәкле Серая Вода станциясе янә бер-ике тукталыш аша, кыргыз җирендә, ди.

...«N» часте сәер атамалы станциядән берничә чакрымда, таулар итәгенә сыенган Кызылсу дигән бистә янында булып чыкты. Биек кызыл таш койма белән уратып алынган, шактый зур биләмәгә охшый. Уртасына биш почмаклы йолдыз сурәте төшерелгән яшел капкалы КПП[5] аркылы машиналар тыз-быз килә, гаскәриләр керә-чыга тора. Менә ул тулы бер ел буена хәрби хезмәт үтәсе икенче туган йорт!

Егетләр, әллә ни искитәрлек күренмәгән частьны читтән генә күзәтеп тордылар, тордылар да, иң элек базарга сугылырга булдылар. Кесә төбендә ятып, тузанга баткан акча калдыгына тегесен-монысын алып, «гражданка»да соңгы тапкыр иркенләп сыйланырга иде исәпләре. Эш көне булгангамы, биредә сатучылардан гайре, кеше сирәк, үтәли җил генә уйнап тора иде. Каранып йөргәндә, боларга нindидер солдат иярде. Ничектер шикләнеп, кырын-кырын гына күз салгалый бу. Погонында сержант тасмалары, киң күкрәген кырыкмаса кырык төрле значок басып алган. Кулында җитмешенче еллар башында гына кулланышка кергән затлы «дипломат» портфеле. Фуражкасыннан бөселеп чыккан коңгырт чәчләре тузгыган. Пычрак идәнле вокзалларда, аяк астында рәвешен югалтып, кыршылып, таушалып беткән биштәрләрдән, ятакларда аунап изгәләнгән киемнәребездән чамалап алды ахрысы ертлач, әрсез, очлы күз тәкәллефсез-нисез генә якынлашты да:

[5] КПП – тикшерү-үткәрү пункты.

– Сез Казаннан түгелме? – дип төбәп сорады. Уңай җавап ишеткәч, шатлыгыннан алдарак басып торган Рәмзине кочып алып, «Мин бит сезнең покупатель!» дип, аркасын дөп тә дөп төяргә кереште. Күз яшьләре сыгып еламый гына! «Сатып алучы» исеме аның телендә шулхәтле якын, назлы, дәрәҗәле яңгырый, әйтерсең лә туган агагыз дигәнне белдерә иде.

Бистә читенә, аулак төшкә чыгып утырдык. Никрутларның барлы-юклы сый-нигъмәтенә чәчәп-чәчәп куя сержант. Бигрәк ачка «киселгән» икән, бахыр, бүре сыман умыра гына алдына куйганны. Дөяне төге белән йотар иде, валлаһи! Соң, шулай булмый ни, частька кайтканда бар акчасын аракыга бетергән дә, суган суы суырып, авызын чөйгә эләргә дучар булган.

...«Дембель заданиесе» итеп моңа өч никрутны, ягъни мәсәлән, хәзергесе вакытта каршында, чирәмдә кырын яткан өч кешене, Казанның туплану пуктыннан алып кайту бурычын йөкләгәннәр икән. Татарстаннан булуын да исәпкә алганнар, күрәсең. Никруты-чурты качмас әле, дип, башта Балык Бистәсе районындагы туган авылына сыпырткан бу. Киткән шуннан агай-эне, дус-иш, күрше-күлән белән табын кору. Шултиклем сәрхушләнүдән соң, ниһаять, бераз айнып, аңкы-тиңке хәлендә Казанга барса, аның «тауарын» «сатып алучыдан» башка гына «шудырганнар», имеш. Поездга утырып, куа чыгудан бүтән чарасы калмаган. Иң кыска, туры юл үзенә яхшы таныш, никрутлардан алданрак килеп җиткән, билгеле. Кайткан уңайга частька кермичә, кача-поса, ни тапса, шуны капкалап җан асраган. Ә тегеләр, ягъни – без, аймылышка яңгылыш, дигәндәй, адаша-адаша, әллә ниткән поездларга эләгеп, тиле кеше әйтмешли, Урал тауларын урап, Алтайларны айкап, көч-хәл белән килеп аудылар ласа азаккы пунктка. Күпме сагалап йөреп тә, үз өлешенә тиешле тере «тауар»ны очратмагач, болар армиядән кыяклады, ахрысы, дигән уйдан эченә шом кергән, чәчләре агара язган, имеш... Бирим дисә колына, чыгарып куяр юлына, диләр бит, барыбер йомры башлар – үзебез тап булдык менә. Туры килеп торуын күр син аның: теләсәң дә уйлап чыгара алмассың моңа охшаш әкәмәт очракны!

Шул куанычыннан һәм дә карыны туклыктан, күңеле тәмам һушланган «дембель», кикерә-кикерә, әллә нинди антлар эчә, «картлачлар» сезне канат астына алсыннар дип, колакларына каты киртләп калдырам», ди, минем хәлне командованиегә генә чишмәгез, дип, чын дөресен сөйләмәскә куша, гозерли. Әлфис, андый коры вәгъдәне колак читеннән генә уздырып җибәрде.

Тантаналы минутлар җитте. Итек-читек ямаучы будкасы янында тукталып, ботинкаларын кояштай ялтыраткан сержант, мизгел эчендә бөтенләй чит-ят кешегә әверелде, таш чырай белән, яңа танышларын сафка тезде дә: «айт-два»га бастырып, хәрби частька алып керде. Үкчәләрен бер-берсенә шак та шок каккалап, өч кеше составындагы призывниклар төркемен алып кайтуы турында полк буенча кизү офицерга күзен дә йоммыйча, чатырдатып рапорт бирде.

## 4. Белмәгәннең беләге авыртамы?

Частьның үзендә мунча булмау сәбәпле, яңа килгән «одногодниклар»ны котельный душында гына коендырып чыгардылар. Солдат формасын болын кадәр зур тимер ангарның бер читенә, өстәлгә аударганнар иде. Үзеңә кирәкне үзең сайлап аласы. Кызыл йолдызлы бүрекләре, фуражкалары, панамалары ярый инде, ә менә бүтән төр киемнең үлчәме, чамасы чамага туры килми генә бит! Биредә борынгы грек фәйләсуфларына хас, боздай салкын тынычлык,

сабырлык белән карарга күнеккәннәр икән аның ише вак-төяк мәсьәләгә. Армия сафлары агымына яңа эләккән «салажон»[6]ның, икенче төрле әйткәндә, беренче елын вакларга керешкән «әрвах»ның киеме кешечә, рәтле-башлы булуы һич мәҗбүри түгел; бакча карачкысыннан аз гына ятышлырак булса, шул җиткән. Үз үлчәменнән зуррак яисә кечкенәрәк, шактый туза төшкән, сүсәргән форма тоттыру исә яшь солдатны кимсетү, җәберләү, үз урынын, үзенең кем икәнлеген белеп торсын, борынына киртләп куйсын, дигән сүз икән. Мыскыллаган кебек, манара хәтле кешегә таман шинельне тәпән буйлыга бирәләр, кыска буйлыныкын торнадай озын аяклыга сузалар. Шундук киемнең эчке ягына известь сыекчасы белән яндырып, исем-фамилияңне язып куясы. Болай булгач, үзеңә ярардай кием сайлап, бер-берең белән алыш-биреш ясарга хакың юк. Әлфиснең үзенә ул «байлыктан» сорыдан-соры, зурдан-зур, шундый шинель эләкте ки, итәге кинофильмнардагы Дзержинскийныкы кебек җирдә сөйрәлә.

Атныкы сыман сузан чырайлы, кара хәтфә мыеклы каптёрщик яңа килгәннәргә игътибарсыз, үтәли генә караш ташлап:

– Каеш белән тыгызлап каптыргач, утыра ул. Барыбер төннәрен каравылда торганда гына киясе. Кызыл мәйданга Җиңү парадына барасың юк, – диде һәм, бәйләнчек чебенне кугандай, кулын гына селтәде.

Җәй өчен уңып, агарып каткан панама сыман шыксыз кәпәч бирделәр. Өстә – шундый ук, кешедән калган, кыскача «хэбэ» дип атала торган, ягъни безнеңчә, киже-мамыклы тукымадан тегелгән гимнастёрка да чалбар. Дөрес, парадка, нарядка яисә бәйрәмгә, рәешкә киелә торган китель өр-яңа, гәүдәгә текмә-тек ятып тора иде. Бу чордагы армиягә, ботинкалары белән бергә, яңа гына кертелгән форма иде ул.

Погоннар, петлицалар өләшкәндә, беркатлы Фаик танк сурәте төшерелгән кара погоннарга нәфесен сузган иде дә... Андыйлар халыкта нигәдер иң мәртәбәлесе санала, ал төстәгесеннән, төрмә саклаучыныкы ул, дип җирәнеп, борын җыералар. Өтек мыек, аның сабыйларча мөлдерәп торуын күреп:

– Самолёт төшкәне, лётчикларныкы төсле зәңгәре кирәкмиме тагы? Тот капчыгың, төбе төшмәсен! – дип, кешни-кешни көлде. Очучы булырга да өлгерерсез! Явыз «картлачлар»га эләксәгез, көлегезне күккә очырырлар, – дип, борын астыннан гына мыгырданды. Аягыннан җир тарткан, кәтүк кенә булса да, полк элитасына керә иде ул. Гади солдатта аның эше юк, даны-шаны бар чөнки. Каптёрщик белән өлкән командирлар да исәпләшә. Түшәмгә кадәр сузылган киштәләрдә кием-салым тутырылган каптёрка бүлмәсенең караңгы почмагында сыйлап та җибәрә ул зур йолдызлы кемсәләрне. Келәт саклаучы бу халык, күркәдәй өрелеп, шөһрәтле генералиссимус сүзе белән охшашлык күргәнгәме, үзен борынгы каптенармус белән чагыштырырга ярата. Гәрчә патша армиясенең унтер-офицер чинындагы ул тырыш хәрби хезмәткәрнең тырнагына тормаса да. Каптёрщик ул гап-гади амбар саклаучы гына инде, югыйсә. Гел старшина тирәсендә сырпалана. Тегесе исә аның күпчелек кыңгыр эшләренә күз йома. Әрсез каптёырщик иртәнге разводка, прогулкага чыгуны, хәтта кичке тикшерүгә басуны да үзе өчен гарьлек гамәл дип саный. Һәрхәлдә, үз «өне»ннән бүтән җирдә өтек мыегын да, борынын да күрсәтми торган иде ул.

...Бу часть Совет Армиясенең «Гражданнар оборонасы» гаскәрләре дип аталган төренә керә икән. Бер сүз белән генә әйткәндә, пехота! Җәяүле гаскәр... Мондагы полк дигәне кәгазьдә генә, хәрби хезмәткәрләренең саны бөтен бер батальонга да җыелмыйдыр. Ә менә хәрби өйрәнүләр вакытында гражданкада

[6] «Салажон» *(жарг.)* – яшь солдат.

запаста торучыларын, ягъни гади телдә «партизаннар» дип аталучыларын да чакыргач, меңнән ашып китә ди. Зур, биек гаражларда, ангарларда илдә тынычлык хөкем сөргәндә кагылмаслык запас, хәрби арсенал: төрле маркадагы автомашиналар, махсус техника консервациядә саклана, диләр.

Полк командирының политчасть буенча урынбасары, подполковник Семёнов, документлардан Әлфис Галимдаровның журналист булуын белгәч, төп кебек калын, кыска аякларында әле алга, әле артка чайкала биреп:

– Менә сезгә тәүге сугышчан задание: безнең ...э-э-э ...данлыклы полкның шанлы үткән юлы..., традицияләрне дәвам итү..., анда хезмәт итүнең яшьләргә нинди зур горурлык ...фәлән-төгән өстәвен ...эһем ...тагын шуныңише патриотик сүзләр кыстырып чыгыш ясарсыз. Текстын алдан миңа күрсәтерсез! Понятно! – дип, йомшак кына тавыш белән, әмма ике уйламаслык, катгый төстә үтә җаваплы йомыш кушты. Армиядә солдатның фикере белән кызыксынып-нитеп тору юк икән. Тантаналы ант кабул итү соңында исә солдатның яшәеше, көндәлек тәртибе, үзен тотышы тулысынча командирларның, хәрби түрәләрнең приказына, ихтыярына буйсына һәм бу көннән башлап яңа сугышчының уй-фикере, кәефе, теләк-омтылышы сукыр тиен дә тормый.

Татар журналисты булса да, кергәндә урысчасын да үтемле, төгәл ермачлый ала торган егет сынатмады. Бакыр самавыр кебек кызгылт йөзле Семёнов, тантанадан соң үзе килеп, Әлфиснең кулын кысты. Хәрби округ газетасына язышып торырга дигән «аталарча» киңәшен дә өстәде. Егетнең абруе, болай булса, күзгә күренеп үсәргә тиеш иде. Монда бер ел хезмәт итеп каешланып беткән гаскәриләр дә читләп-читләп кенә, кызыксынып карап үткәлиләр, сирәк-мирәк сүз дә каткалыйлар иде. Берсе: «Тагир Ташмухаметов!» дип, үзе килеп күреште. Киң җилкәле, таза гәүдәле. Ә ап-ак бармаклары йомшак, нәзек, сузынкы... Битен вак кына миңнәр, кара төрткеләр чуарлаган. Дусларча елмая-елмая, милләттәшләренең кулын сак кына кысып чыкты да Таһир:

– К сожалению, татарся аз билям, – дип, үкенечле көрсенеп куйгандай итте. Ташкент татары икән... Тиз генә танышты да, тагын нидер сораштыра күрмәсеннәр дигәндәй, ашыгып китеп тә барды. Гомумән, кеше күзенә сирәгрәк чалынырга тырыша төсле иде ул...

...Ай ярым вакыт үттеме икән, «Казан татарлары»н роталарга, взводларга бүлделәр. Иң тәүдә, кылларын тарткалап, кемнең ни-нәрсәгә кулы ятуын, маһир булуын, сәләтен ачыкладылар. Рәмзинең рәсем ясауга һәвәслеген Семёнов аеруча хуп күреп, җанланып китте. Ирен чите белән генә елмаеп:

– Как раз рәссам демобилизациягә җыена, бүгеннән мастерскойны кабул ит! – дип боерды. Бүтәннәр, Рәмзигә күктән бәхет йолдызы чүпләгән адәмгә караган кебек, көнләшеп караштыргалыйлар. Муенын сузып, остаханәгә куана-куана чабып килсә, тукмак борынлы азәрбайҗан бер дә сөендерергә ашыкмады.

– Ну, парин, килеп каптың, көне-төне пахать будешь! – дип котын алды.

Бусы да тактик әмәл: дембельгә китүчеләр «җайлы» эш урынын шул рәвешле күрәләтә торып, каты яманлыйлар, эттән алып эткә салалар. Янәсе, яңа алмаш, килә-килүгә үк, оҗмах бакчасына чумдым дип куанмасын әле. Астына шыр җибәрсен башта! Бер михнәтнең бер рәхәте дә бар икән үзе: бистәдән хат ташу эше дә йөкләнә ди художникка. Иркенләп һава сулап кайтасың, кибеткә-фәләнгә сугылырга да җай чыга. Чибәр-чибәр кыз-мыз да очрап куюы бар.

Әлфис, солдаттан таштай шомарып кайткан бертуган агаларының киңәшендә торды, мин фәләнне булдырам, дип, сикереп төшмәде; төзү-кору, шомарту-сылау, тимер-томыр эшенә һичнинди катнашы юклыгын алдан ук

сиздерергә тырышты. Тегермән тик торса, ташы ярыла; ә менә солдатның теле тик торса, үзенә рәхәт: башы ярылмый, дип тиккә генә әйтмиләр ич. Югыйсә, иң әүвәле ташчылар, балта осталары, штукатур-малярлар белән үлепләр китеп кызыксына, төпченә командирлар. Чөнки һәрберсенең газиз гаилә почмагы, дачасы бар, анда төзисе, төзәтәсе, ремонтлыйсы бина, каралты-кураларның мәңге бетәсе юк. Торбалар салу өчен озын чокырларны, кар базларын кәттә командирлар үзләре казымас ич инде.

Фаикның медицинадан азмы-күпме хәбәрдарлыгы сизелде. Үзе спортсмен да әле: рәхим ит, санчастьтагы санинструктор вазифасы нәкъ синең өчен.

Татарча укый-яза белүдән, ана телендә шигырь-мигырь чыгарудан гайре һичнигә сәләте, «үнәре» ачыкланмагач, Әлфисне разведка взводына куйдылар. Хәйран дәһшәтле, хикмәтле итеп, «химик-разведчик» дип атала ул, ягъни мәсәлән, дошманның атом, химик һәм бактериологик коралына каршы көрәшнең алгы сызыгында торучы, каршы яклар һөҗүменнән яисә табигый афәт-һәлакәттән соң тирә-юньне агулы һавадан арындыру, халыкны коткару, яклау подразделениесе хезмәткәре. Булдыра алмасаң, өйрәтербез, теләмисең икән – мәҗбүр итәрбез, дип янадылар командирлар. Бу катгый гыйбарә армиядә еш кулланыла һәм теләсә нинди каршылык күрсәтү билгесен, канәгатьсезләнү-ризасызлык әсәрен шуның белән генә каплыйлар да куялар.

Әлфис, ниндидер мәкалә өчен материал туплаганда, полкта комсомол эшен алып баручы капитан Серёгин белән аралашты. Ул, түшен, йон-каурыйларын бертуктаусыз чистартып, күпертеп торган чыпчык кебек, әледән-әле керпе чәчен сыйпаштыргалап, авыз-бит тирәләрен сөрткәләп мәш килә торган кеше икән. Әйтәсе дә юк, чибәр, зифа буйлы, сөйкемле егет. Әмма итәк чабуларын җыештырып, алдын-артын караштыргалап йөрүчән, шик-шөбһәле, фикерсез, иярчен, туңбаш.

– Сез моны замполит белән килештердегезме соң? – дип сорады ул, кулъязманы укыгач, нечкә кашларын җимереп. Җавап та көтмәстән, иреннәрен кыймылдата-кыймылдата, тагын бер кат күз йөртеп чыкты. Кәгазь битләрен сак кына читкә алып куйды да, чиста, алсу тырнаклы бармакларын өстәлдә биетеп:

– Батальонның, Фрунзе музей-йортын карап, концертта булып кайтуы турында матур гына язгансыз... И шуның белән бетерергә иде! Частьта «солдат клубы», әдәби салон, үзешчәннәр түгәрәге оештыру һәм башка шуның ише чүп-чар турында сырлау нәрсәгә кирәк булды? – диде.

Әлфис, бу сораудан беравык аптырап, өнсез калды. «Ник синә иртән теш чистартып торырга?» кебегрәк урынсыз сорау куйган томана адәмгә тиз генә ни әйтергә белми, тотлыгып калган кебек инде бу. Ниһаять, тавышына мөмкин кадәр ныклык өстәп:

– Ничек инде... Буш вакытларында солдатлар кешечә ял итсә, бәйрәмнәрдә кичәләр, концерт оештырсалар... – дип авызын ачуга, кырт кисте ыспай капитан:

– Армиягә хәрби хезмәт үтәргә килүегезне онытмагыз, иптәш рядовой. Монда ял йорты түгел. Сез, кеше булудан бигрәк, иң әүвәле – солдат!

Аннары ул, сүз беткәнгә санап:

– Мәкаләгезнең ул җирләрен кыскартып, подполковник белән килештергәч, округ газетасына үзем кертеп чыгармын, – диде.

Башына таяк белән органдай, миңгерәп чыкты Әлфис шул солдафон яныннан.

Әлфиснең бөтен теләген-омтылышын, якты уй-хыялларын сүндереп, сүрелдереп чыгарды капитан. Менә сиңа яшьләрчә, комсомолларча янып яшәү

һәм эшләү, хезмәт итү! Моннан соң ул газетага язышам дип ник атлыгып торсын әле. Концерт-мазар оештырабыз, кичке клубта әдәбият турында җыелып фикер алышабыз дигән татлы хыяллар да җилгә очты... Сазлыкта яшәгәндәй, саф һавадан мәхрүм булып, череп ятарга гына кала монда...

## 5. Академиядә уку ансат түгел

...Армиядә сирәк була торган хәл: өч татар солдатын, кинәт кенә, «срочно» полк командиры полковник Стандовның шәхсән үзенә ияртеп алып киттеләр. Бытбылдык йомыркасы төсле сипкелле, саламдай сап-сары чәчле, мөлаем бу кешене, дөрес булса, Болгариянең үзеннән, диләр. Монда хаклык бар бугай, фамилиясе дә шуңа ишарәле бит. Милләте болгар булса, Идел буе булгарларына кардәш тиешле сымаграк инде ул, ягъни мәсәлән. Безгә дә якын кеше була инде... Әлфис, канатлана төшеп, шулайрак фикер йөртте.

Бүлмәгә килеп кергәч, кулларын панама читенә тидереп, сәламләгән иттеләр. Эре сөякле, авыр сынлы, олпат гәүдәле полковник, һич көтелмәгән җитез хәрәкәт белән, түрдәге урыныннан купты да кулы белән озын өстәл янына күчәргә ымлады. Бу ни бу! Гражданкадагы кебек, итагатьле генә кызыксынып, һәркайсының исем-фамилиясен, кайсы югары уку йортын тәмамлавын сораша ласа! Ә бит ул чын күңелдән, дигән матур уй ток кебек дертләп үтте Әлфиснең арка миеннән. Ант биргән көнне саф алдында яңа солдатлар белән таныштыргач:

– Күрәсезме, хәзер армиягә нинди көч килә... Югары белемле, зур квалификацияле, укымышлы, хәстәрле, әзер кадрлар! Кадерләрен белеп, тулы куәтенә файдаланырга кирәк аларны... Әгәр дә ки, элеккеге хәрби хезмәткәрләрдән кемнәрнеңдер аларны рәнҗетергә кулы кычыта икән, рәхим-шәфкать көтмәгез. Со мной будете иметь дело! – дип каты кисәткән абруйлы, дәһшәтле җитәкче бит ул. Әлфис шуларны исенә төшереп алды да, урта яшьләрдәге бу хәрбине, кайсы ягы беләндер шундый ук аксыл йөзле, сары чәчле һәйбәт укытучысы Зариф Шәриповичка охшатты... Чү, ялгыш ишетәме, Әлфискә мөрәҗәгать итә түгелме соң?

– Ә Сез, Галимдаров, шигырьләр язасыз, диләр... Боевой листоклар өчен менә дигән материал... Бәлки, берәрсен укып та күрсәтерсез, – диме?

Үзенә атап мондый аерым игътибар көтмәгән шагыйрь-солдат алай да югалып калмады. Ике кулы белән киң каешын рәтли-рәтли торды да, бераз каударлана төшеп:

– Гафу итегез, мин татарча язам... Сезгә кызык булыр микән? – дип җавап та биргән, берочтан сорау да куйган төсле итеп, полковникның асыл ниятен ачыкларга тырышты. Мәгәр, чын кызыксыну сизгән очракта, берәр шигырен сөйләргә дә теләге юк түгел иде. Әмма андый-мондый омтылыш белдермәде полковник. Аның күзендәге җылы чаткылар ничектер бер-бер артлы сүнә, сүрелә барды, азакта күмердәй чем-кара күз алмалары гына торып калды:

– Алай икән, – диде ул, бераз көттереп, битараф кына. Бу сүз аның авызыннан, начар икән, дигән шикеллерәк яңгырады. Бу сөйләшү үзе дә һични аңлатмый торган дежурный сөйләшү генә, нindидер бер мөһим эшне билгеләү алдыннан разведка ясау кебек кенә иде бугай. Ә бит Әлфискә ошый башлаган иде бу кеше. Ул инде безнең уртак тамырларыбыз турында, ерак бабабыз – мәшһүр Кубрат хан, 680нче елларда Дунай буйларында Беренче Болгар патшалыгын төзегән улы Аспарух, Кубрат ханның шул ук дәверләрдә Идел буе дәүләтенә нигез салган кан-кардәшләре турында да сүз кузгатырга уйлап кергән иде, җүләр. Теле бик кычытса да, үзенең кайда утыруын исенә төшереп, бик вакытлы иренен тешләп калды. Канатланган күңеле шундук сүрелде, кәефе шиңде. Бу совет полковнигы

мундиры кабыгына төренгән хәрбинең болгарлыгы да шул хәтле генәдер әле. Татарлар турындагы мәгълүматы да Татвоенкомат белән генә чикләнә, мөгаен. Гомумән, полктагы офицерларның күпчелеге сыман, тавышын бөереннән чыгарып, кәҗүнни кырыслык белән, эре сөйләшә торган кавемнән иде.

Күпме генә утырдылар инде, шунда да күңелсезләнде Стандов. Кул сәгатенә күз салып алды да:

– Сезгә шәхси үтенечем бар. Ансын минем ярдәмчем аңлатыр, – дип, әңгәмәне төгәлләп, урыныннан торды.

Егетләр, ярдәмчегә ияреп, күрше бүлмәгә уздылар. Тегесе сүзне, үгезне мөгезеннән эләктергән шикелле, хәрбиләрчә кыска тотты. Хикмәт шунда икән: полк командиры Мәскәүдә читтән торып хәрби академиядә белем эсти. Димәк, генераллыкка укый, дип эчтән генә бәя бирде Әлфис ...Югары математикадан контроль эш буенча ниндидер кыенлык килеп чыкканмы шунда. Иптәш полковник шуны чишеп бирүегезне үтенә, ди. Яңа гына үтүкләнеп, шыгырдап торган киемле, көяз офицер: «Менә сезгә фикерләү предметы. Җәмгысе ике сәгать вакыт җитәдер?» дип сөален бушлыкка ыргытты да, үз бурычын үтәгәнгә санап, ишекне шартлатып бикләп тә китте.

Өч «яшь сугышчы» бөтенләй гаҗиз булып, балтасы суга төшкән кеше хәленә калып, күпмедер вакыт аптырап утырды. Берничек тә мондый катлаулы «хәрби задание» көтмәгән иде алар. Ниһаять, билгесез шартлаткыч матдә белән эш иткәндәй, сак кына шул «фикерләү предметын» – контроль эш биремен кулдан-кулга йөртеп чыктылар.

– Йә, математиклар, физиклар, күрсәтегез һөнәрегезне! – дип шаярткандай итте Әлфис, киеренкелекне йомшарту өчен генә. – Югыйсә, башыгыз губадан чыкмас!

– Тешләшмә, шагыйрь иптәш! Югары белемле кешеләргә санап, барцабызга да кушылган әмер ләбаса бу. Ул-бу булса, син дә язадан[7] котыла алмассың, – дип кырт кисте чырае көл кебек агарынган Фаик. Күбесенчә аның өстенә кала ич бу хәсрәт капчыгы. Шул «капчыкның» чияләнеп беткән бавын ничек чишәргә?

Эшкә ябыштылар. Тирләп-пешеп чыктылар. Әлфис белән Рәмзи дә, белгәннәрен әйткәләп, өстәлгә капланды. Кабинетта вакыт искиткеч тиз үтә, моңарчы аның болай тиз узуын тойганнары юк иде әле монда. Совет мәктәбендә дә, югары уку йортларында да төпле, җүнле белем бирәләр иде шул элек. Бөтен белгәннәрен җигеп, очлап чыктылар тәки. Зиһенле, фәһемле Фаик – йомры баш җитәкчелегендә каты чикләвекне чәлпәрәмә китерделәр. Баш өстендә куркыныч та янап торгач...

Нәкъ ике сәгатьтән соң ярдәмче ишекне ачты һәм:

– Барысы да тәртиптәме?! – дип, салкын күзләре белән бер генә чәнчеп алды.

Казармага кайтып барганда, һаман да шик-шөбһәле Әлфиснең сүзсез, инәлүле карашын әллә ни озак күтәрә алмады Фаик:

– Оцлап чыктык бит, әзи, йавабы да точно булырга тиеш, курыкма! – дип, аны тынычландырырга ашыкты. Янә дәшми-нитми генә атлый торгач, түзмәде:

– Ә ницек булганын киләсе экзаменнарда академиягә цакыртып әтерләр! – дип, усал гына төрттереп алды.

### 6. «Армиягә иң элек чын солдат кирәк!»

Полк командиры, читтән торып, хәрби академиядә каты мәрмәр ташын кимереп, хезмәт карьерасының текә кыяларына үрмәләвен дәвам итсен. Ә безнең татар егетләре өчен, Совет Армиясенең гражданнар оборонасына караган

[7] Яза *(диал.)* – җәза.

частенең үз тормышы, үз университеты, үз академиясе. Армиянең язылмаган кануннарын, гаскәри көнкүреш әлифбасын, рәхимсез, шәфкатьсез кагыйдәләрен үзләштерү җиңел бирелмәде. Монда барысы да яңача, үзгә, һичнинди фәнгә сыймый торган программа буенча бара. Томана солдафонлык һәм хакимлек белән изү сабаклары... Чеп-чи ялган, алдашу, күз буяу, хәйлә-мәкер укулары.

...Шәфкатьсезлек һәм миһербансызлык дәресләре... Тупас көчнең, золымның, наданлыкның интеллекттан, аң-белемнән өстен чыгып, чәчәк атып, тантана итүе – фәкать менә шушы даирәдә, мохиттә генә мөмкиндер...Егетләр боларның һәммәсен дә үз башларыннан кичерделәр, татыдылар. Дөрес, төрлесе төрле дәрәҗәдә.

Басынкы Рәмзи ярты төнгә хәтле штаб мастерскоеннан, кәнсәләрдән кайтып кермәде, өсте-бите аллы-гөлле буяулар белән чуарланган буладыр иде. Армиядә бит плакат-шигарьләрне, икенче төрле әйткәндә, күргәзмә агитация материалларын партия игълан иткән һәрбер кампания саен алыштырып торырга күнеккәннәр. Барысы да түләүсез чөнки. Политчасть кушкан берәр плакатны кысага куеп, ясап, тиешле рәсемне кәгазьгә йә киндергә төшереп өлгермисең, берәр атнадан тагы «көн кадагына суга торганы» таләп ителә. Качырып кына, үзе өчен генә нидер сызгаларга да вакыты калмый мескен Рәмзинең. Ярый әле, бистәгә почтага барганда, җаны-тәне белән ял итеп кайта. Аның хат ташучы дигән «блатной» эшен күпсенеп, көнләшеп йөрүчеләр дә бихисап шул. Янәсе, солдат боткасын капкаларга да өлгермәгән килеш, нинди җайлы урынны каптырды салажон. Непорядок! Чарасын күрергә кирәк! Химик разведка взводына гел шулай мач килеп тора! Аңа хәтле булган художник та шул ук взводтан иде бит.

Буйга әллә ни булмаса да, мускуллары туп кебек өрелгән, тимердәй каты иде Фаик Заһитовның. Тәүге көннәрдә үк турникта уйнап, һичнигә исе китмәскә өйрәнгән «картлачларны» да таң калдырды ул. Аркылы тимер борыска куллары белән ябыша да зыр-зыр әйләнә малай! «Кояш», диләр бугай бу алымны. Штанга белән мавыгучы спортсмен да әле. Аны санчасть башлыгы – май баскан кысык күзләренең нинди төстә икәнен дә аерып булмаслык, кәкре аяклы капитан Торсыновның үз службасына эләктереп алуы гаҗәпмени?! Алтын еланлы погоннар таккан чиста, ару гимнастёркасы өстеннән ак халат киеп кенә йөри хәзер егетең. Авыруларны кабул итеп, теркәп, табиблар кулына тапшыра. Кирәге чыкса, чирле солдатны бистә хастаханәсенә ияртеп бара. Әмма аңа да йокы аз эләгә: гел төнге кизүдә торырга тиеш икән бердәнбер санинструктор. Бүтән медицина хезмәткәрләренә тиешле йөкне дә үз җилкәсенә ала, димәк ки.

Әлфис химик-разведчик дигән хикмәтле, серле исем күтәреп йөргәч тә, гел ниндидер «эзләнүләрдә», сугыштагы сыман «дошман» тылында «тел» эләктерергә яскана, дип фараз кылулар көлке булыр иде, әлбәттә. Ул вазифа бөтенләй башка юнәлеш ала монда. Бер-ике тапкыр махсус лаборатория машинасында кырга чыгып, ниндидер пыяла капсулаларны ватып, андагы сыекчаларны бер-берсе белән катнаштырып, буташтырып, реакциягә кертеп маташудан башка, илне атом-төш афәтеннән саклау буенча әллә ни майтарганы юк. Күбесенчә каравылга бастыралар аны. КППда дневальный булды, казарма буенча да кизү торды. Каравылның 1 нче постында – полк байрагы сагында тору дәрәҗәсенә дә иреште.

Монысы бик мактаулы, мәртәбәле, дисәләр дә, штаб бинасының икенче катында, нәкъ менә көньякка караган ачык тәрәзә каршында, төннәрен сәгатьләр буена карабин тоткан килеш, селкенмичә дә үрә катып тору, ай-һай, кемгә генә ошар икән. Штаб башлыгы, тынгысыз осетин кешесе, Чапайныкыдай купшы,

куе мыеклы майор Таривердиев көтмәгәндә, сиздерми генә килеп, уяулыкны сынарга ярата. Кытайлар белән чик сызыгындагы бер кисәк җир өчен дәгъва кылып, салкын сугыш оештырып, матавыкланган чор. Ике арадагы «ызан» якын монда, күз күреме ераклыгында гына. Командирлар, уяулыкны, саклыкны көчәйтү максатыннан, диверсант-фәлән белән куркытып, котны алып, эчкә шом йөгертәләр. Штаб тәрәзәсеннән кул сузымындагы таш койма аша граната ыргытсалар, дип, Әлфис тә дөм-караңгы төннәрдә шүрләп куйгалый.

Ә беркөнне, иртәнге развод вакытында, саф алдына Әлфиснең посттагы алмашын бөкрәйгән, мескен кыяфәтле сержант Чагинны китереп бастырдылар. Полковник Стандов аңа беравык җирәнеп карап торды да: «Син моңа лаек түгел!» дип, үз кулы белән погоннарын йолкып атты... Үткән төндә штаб башлыгы, песи адымнары белән, баскычка сак кына басып, икенче катка күтәрелгән чакта, каравылчы, карабинын бер читкә куеп, изрәп йоклап утыра икән. Мылтыгын алгач та сизмәгән мокыт.

...Әлфиснең яхшы журналист булуын танып, аеруча, ант бирү көнендә һәйбәт чыгышын да ошаткан политчасть башлыгы, әле ел башында гына училище бетереп килгән яшь лейтенантлар турында, хәрби округ газетасына аерым мәкалә язарга тәкъдим иткән иде. Булачак язманың «Лейтенантский корпус» дигән килешле исемен дә уйлап тапкан хәтта. Алар арасында Галушка да бар. Төнге эчү маҗараларыннан башы чыкмаган, взвод командиры буларак та әллә ни эш кырмаган хәчтерүшне дә алдынгылар рәтенә кертеп язаргамы инде, дип сәерсенде Әлфис. Ширантай кебек ябык, какча гәүдәле, сызык мыеклы бу кешене полкта яратмыйлар. Куштан, түрә-карага тәлинкә тота белә, астан ут йөртә, сиздерми генә чага торган бәндә, диләр. Йә, шуны ни йөзең, вөҗданың белән мактап, күккә чөеп язасың ди. Әлфис күңеле тартмаса, яисә лаек булмаса, туган агасын да мактаудан тайчына торган принципиаль, гадел журналист иде. Киребеткән, үзсүзле, тискәре адәм түгел, ә бәлки, үзе нәзек, үзәге нык дигәндәй, чакматаш төсле ул... Тегенең исемен төшереп калдырды да сырлап җибәрде мәкаләсен хәрби газетага. Озакламый басылып та чыкты. Ленин бүлмәсендә өелешеп укыдылар. Ни өчен Галушканы кертмәвен подполковник сорамады. Шуның белән эш бетте дип санап йөрде Әлфис. Әмма хәрби хәбәрченең шул «гөнаһы» ниндидер юллар белән сөрхәнтәйнең үзенә барып ирешкән бит.

Әлфис Рәмзи алачыгында взводның чираттагы «Сугышчан листогы»н эшләп утыра иде. Бермәлне, көтелмәгән кунак – лейтенант Галушка кереп утырды. Хром итек кигән, тал чыбыгыдай нечкә сыйракларын берсе өстенә берсен бау кебек урап куйды да, нечкә бармаклары арасына сигарет кыстырып, сүзсез генә егетләрнең шөгылен күзәтә бу. Аннары күгәргән иреннәрен чалшайтып, зәңгәр төтен өрә-өрә:

– Менә сиңа карыйм да, Галимдаров, армиягә син ни өчен килдең икән, дип, баш ватам. Кеше нинди дә булса һөнәргә ия булырга тиеш бит инде бездә. Чәч алучымы, телефонистмы, әнә якташың кебек (ул Рәмзигә ымлады) художникмы шунда. Ансыз солдат хезмәте, яшәеше бик авырга туры килә бит... Һәрвакыт кыен ашап тору рәхәт булырмы соң?! – дип, сүз башлады да, нәрсәгәдер ишарәләп, сак кына кинаяләп бетерде.

– Әйе шул, солдатның чын һөнәри, дипломлы төзүче-ташчы булуы да шарт. Командирларга дача салу өчен! Шулаймы, сезнеңчә, иптәш лейтенант? – дип төрттерде Әлфис һәм тегеңәргә, эшен бүлмичә, тыныч кына карап куйды. Коңгырт күзләре гел чиста аның, шүрләү-нитү күләгәсе күренми.

Эчке киеренкелек һәм дулкынланудан аскы ирене алгарак чыга төште дә, кашы өстендәге нәзек кенә иске яра җөе кызарып чыкты. Куркыныч янаганда, яисә бинахакка гаепләгәндә, шулхәтле кыю тота ул үзен, гаделлек хакына башкитмәле гамәл кылырга әзер инде менә.

– Төзүче булу начармыни? Калымлы эш... Теге ял көнне дә, кемнәр тели, дигәч, «андый эшне башкарганым юк», дип, военврачның җәйге флигелен төзешергә барудан баш тарттың. Үзеңә дошман җыясыңмы?

– Мин армиягә ташчы булырга дип килмәдем, – диде Әлфис, аңа каршы үҗәтләнеп. Һәм бераз уйлана торгач, шундук әңгәмәдәшенең үз коралын куллануны кирәк тапты, купшы пафоска, белә торып, берникадәр демагогиягә бирелеп, дәвам иттерде:

– Илемне, Ватанымны дошманнан сакларга, дип, шуның өчен яклаучы профессиясен ныклып үзләштерергә килдем... Барыннан да элек, армиябезгә яхшы әзерлекле чын солдатлар таләп ителә дип беләм... Итекче дә читекче, амбарчы түгел... Һәм мин солдат хезмәтен җиренә җиткереп үтим бугай. Сугышчан һәм политик әзерлек отличнигы булуымны раслаган значокларымны менә үзегез күреп торасыз, полк командиры тарафыннан белдерелгән рәхмәтләр дә җитәрлек ...Хезмәт итүем, вазифаларымны башкару чутыннан миңа дәгъвагыз юктыр бит?

Шул сүзләрне әйтүгә, Әлфис сынын турайтып басты да, тыгыз мускуллы тәненә сыланып торган гимнастёркасының итәкләрен тарткалап һәм җавап көткәндәй, башын күтәреп, туп-туры офицерның бәбәгенә текәлде.

– Ну, ну... – дип, үзен дә туйдыра башлаган, файдасыз, кирәксез әңгәмәдән тайчынырга мәҗбүр булды бәйләнчек. Солдатның ныклы тәвәккәллеге дә әллә ничек кенә «айнытып» җибәргән төсле тәэсир итте аңа... Ул үзенең хаклы түгеллеген тойдымы-юкмы, әмма «алга таба күрербез кемлегеңне» дигән уйлары чырайсыз йөзендә аермачык ярылып ята иде. Әлфис инде солдат тормышындагы төп кагыйдәләрнең асылын, эчтәлеген төшенеп өлгергән һәм һичкая тайпылмыйча, фәкать шуның белән эш итәргә күңелендә ныгыткан иде. Иң мөһиме – таза мускуллар түгел, үзен аклый торган аек усаллык һәм тәвәккәллек. Үзеңнең рухи көчеңне, кешелегеңне сындырырга мөмкин булмавын күрсәт, икенче юлы инде ул, көчлерәк булуга да карамастан, яңадан кагылып та карамас. Шуннан соң гына, азактан, элек кылган гамәлләреңөчен үкенү хисләре кичермәячәксең...

## 7. «Алар белән разведкага барырга була»

Кечкенә буйлы, граждански кәчтүм-чалбар кигән нәфис гәүдәле егетне очратсаң, аның «N» частендагы дәһшәтле, кырыс, усал комвзводларның берсе булуына ышанмассың да. Ә ул, Байгасаров Улмас, кызлар төсле чибәр йөзле, юка борынлы, кара мыеклы казакъ, полктагы яшьтәшләреннән аермалы буларак, өлкән лейтенант чинында. Җитмәсә әле, читтән торып хәрби уку йортында белем ала. диләр. Әти-әнисе тауларда гомер кичерә, туган нигезенә гел кайтып йөри икән. Кай арада өлгерәдер, хәрби өйрәнүләрдә, спорт ярышларында ул җитәкләгән икенче взвод һәрчак алдынгы урыннарны яулый. Аларда дисциплина да көчле. Гаепле солдатка чем-кара, матур күзләре белән бер генә томырылып карап ала ул. Сугышчыларын «карт»ка, «яшь»кә бүлми, һәркайсы белән тигез мөгамәләдә. Әмма һич кенә дә төче әшнәләрчә түгел. Әлфискә аның, полк командиры алдында да дәрәҗәсен белеп, үзен иелми-бөгелми тотуы ошый.

Байгасаров өйрәнүләр кырында, РХБЗ[8] дәресләре белән Әлфисләр төркеменең бигрәк тә җанын алды, җелегенә үтте. Һәркемнең, теманы йокыдан торгызып сорасаң да, чатнатып җавап бирерлек итеп үзләштерүенә ирешмичә, тынычланмады өлкән лейтенант. Химик саклану формасын салганда-кигәндә билгеле бер вакытка сыешмый торып, үлсәң дә күнегүләрне туктатмый иде ул. Противогаз киеп чапканда, бичара Рәмзи беркөнне сулышы кабып егылды. Түбеннән киселгән агачтай капылт кына ауса да, ай-ваена карамыйча, торгызып, ахыр чиктә сөйрәлеп булса да финишка кадәр тырмашырга боерды Байгасаров. Болай бәлҗерәп, бүтәннәргә дә зыян салуын Рәмзи үзе дә аңлады булса кирәк. Бөтен көчен-ихтыярын җыеп, финиш сызыгына барыбер үз аягында барып егылды. Ял итәргә тукталгач, җебеп төшүе өчен, иптәшләрчә көлемсерәп кенә шелтәләде аны Байгасаров, ихтыяр көченең кодрәте турында тәҗрибәсеннән кызыклы мисаллар китерде.

Инде менә аның белән тагын очрашырга язган икән... Яңа килгән газета-журналларда актарыну нияте белән, Ленин бүлмәсенә керергә торганда, ишек аркылы ишетелгән шактый кызу бәхәс туктатты Әлфисне. Тавыш-өнгә караганда, взвод командирлары Галушка белән Байгасаров болар. Үз исеме дә колакка чалынгач, ирексездән сагаеп калды инде...

– ...Иго дәвереннән калган гадәт ул аларда. Кызган тимер белән көйдереп алырга, яндырырга кирәк аны! Әнә, эшлексез Галимдаровын гына алыйк... (Бусын, әлбәттә, аңа каршы күптән ятрәкләнеп[9] йөрүче Галушка әйтте.) Байгасаров аны кискен төстә бүлдерде:

– Безнең мәңге айнымас Сергеевларны, Босягиннарны яклыйсыңмы? Әллә губаны туган йортына әверелдергән Кошманнымы?! Әйе, килешәм, бистәгә, аракы кибетенә йөгерүдә аларга тиңнәр юк... Автопарктагы техник спиртны урларга да остардылар... Ә менә полк байрагы янында фотога төшерергә, көндез фонарь яндырып эзләсәң дә, араларыннан юньлесен табып булмый. Галимдаров исә шуңа иң алдан лаек булды! Йөгерү буенча батальон ярышында да гел беренче килә. Бүтән якташлары да шулай ук. Татарларның йә, әйт турысын, кайсы булса да самоволкада тотылганы, Уставка сыймый торган башка гамәл кылганы бармы? Юк шул.

– Ә теге Ташкенттан килгән Ташмөхәммәтов татар түгелмени? – дип, янә чабата кайтарып маташты саламторхан, шактый гына дәшми торганның соңында.

– Син бармак белән... эхем... нине бутама! Ташмөхәммәтов тибындагы ул Урта Азия наркоманнарын телгә дә аласым килми. Гарык! Болар бит Татарстаннан! Элек Самарада хезмәт итәргә туры килде миңа. Казанга да баргаладым. Шуннан бирле яхшы беләм, бик хөрмәт итәм ул кешеләрне! Эшчән, вөҗданлы, намуслы, ышанычлы халык. Алар белән бер дә курыкмыйча разведкага барырга була!

Икесе дә, дәлилләре беткәндәй, бермәл тынып калдылар. Сүзне сабыр гына Улмас дәвам иттерде:

– Син, Сергей, шуны аңла: Галимдаров начар солдат түгел ул. Әллә аңа үзеннән дүрт-биш яшькә кечерәк пацаннар белән хезмәт итүе җиңелдер, дисеңме? Икеләтә кыенга туры килә ич! Ә бит тырыша, кемнән дә калышмый. Бәлки, аңа кайбер нәрсәләргә, кагыйдәләргә күнүе авыррак та биреләдер әле... Карт солдат каткан тал кебек, бөгеп-сыгылдырып кара син аны! Әллә кайчан чыныккан, ныгыган холыкны сындыруы... Ай-һай, вряд ли!..

[8] РХБЗ – радиацион, химик һәм биологик саклану чаралары.
[9] Ятрәкләнү *(диал.)* – кыдрачлану, әтәчләнү, гайрәт чәчү.

Яхшы сүздән кинәт күңеле тулышкан Әлфис калганын тыңлап тормады, сак кына кире борылды. Берәр сәгать буш вакыты бар икән әле... Китапханәгә кереп утырудан да яхшысы булмас. Бирелә Валентина Павловна исемле бик тә ягымлы, чибәр хатын эшли. Кайсыдыр дорфа офицерның хатыныдыр дип тә белмәссең үзен. Иренең тупаслыгы, туңбашлыгы өчен җаны әрнидер төсле аның, шуның өчен кешечә, эчкерсез, ягымлы... Әмма – юк, үзенең холкыфигыле шундый аның! Солдат – балакайларны аналарыдай якын итә. Бу якты бүлмәгә кергән һәрберсенең туган җире, өйдәге хәлләре турында сорашырга һич иренми. Китапханәдә аяк эзен калдырган һәрбер солдатның тормышы бик яхшы таныш аңа, чөнки алар ишле түгел. Командирлар арасыннан да китаплар белән мәшәкатьләнүчесе сирәк. Әлфиснең, менә, нинди тема белән кызыксынуына чаклы хәбәрдар. Аның өчен яңа кайткан «ЖЗЛ» сериясе әсәрләрен, тарихи романнарны җыештырып куя.

– Валентина Павловна, гафу итегез инде, Чеховның китабы табылмады бит. Матрац арасына яшереп куйган идем, югыйсә, – диде Әлфис, исәнләшкәч тә кулларын җәеп.

Китапханәченең елмаюлы, матур йөзенә күләгә йөгерде. Гүя, әле генә кояш нурларында көләч булып торган түгәрәк күлгә узгынчы кара болыт шәүләсе төште... Ул әдәпле, тәрбияле, намуслы егетнең кайгысын бик аңлый иде. Соңгы ярты елда вакыт тигән саен укырга яраткан солдатка һич тынгы бирмиләр, икенчеме, өченчеме тапкыр инде этләнеп, яшереп куйган җиреннән юк итәләр китапларын. Кемнәрдер астыртын гына үчләшә, эзәрлекли. Ханым, соңгы мода белән өеп куйган сары чәчле башын китапханә кафедрасы артыннан калкыта төшеп:

– Син, Галимдаров, аның өчен уңайсызланма, бирегә генә кереп укы соң вакытың булганда. Ә тегеләре һичкая китмәс, соңыннан да табыла ул. Беренче генә тапкыр түгел, борчылма юкка, – дип тынычландырырга тырышты.

Әлфис «Огонёк» журналын, «Комсомольская правда» газетасы саннарын йотылып караштырырга кереште. Көнозын кар базыдай тып-тын торган бүлмәдә, ниһаять, һәйбәт кеше пәйда булуга сөенгән ачык күңелле, гәп корырга яратучан хатын ара-тирә кайбер яңалыкларны җиткерә, үзе дә сораша. Ул арада ишектән Улмас Байгасаров килеп керде. Бүлмәдәгеләр белән тыенкы гына, баш иеп исәнләште һәм аның соравы буенча туплап куелган бер кочак махсус әдәбиятны күтәреп, чыгып та китте.

– Хәрби китапларны су урынына эчә! Мәхәббәт романнары түгел, дошман һөҗүменнән саклану, тактика һәм стратегия хезмәтләре, хәрби карталар бит! – дип тел шартлатып сөйләнде Валентина Павловна.

...Һәм шул истәлекле очрашудан соң әллә ни күп тә узмады, полкта абруй казанган өлкән лейтенант Байгасаров атылып үлгән дигән яман хәбәр аяз көнне яшен суккандай итте. Сунарчылыкка күңеле яткан булган икән мәрхүмнең. Тау арасындагы туган авылына-кышлакка кайткан саен, атасының борынгы мылтыгын алып, ауга йөрергә яраткан. Бу юлы кыяташта абынып киткән дә, көянтә хәтле озын мылтыгының ничектер ялгыш тәтесенә басып, туп-туры уң чигәсенә эләккән. Шул җирендә егылып җан да биргән. Һәрхәлдә аның белән бергә сәйран чыккан лейтенант шулай дип сөйләгән.

Байгасаровның матәменә биш солдатны да ияртteләр. Сержант Табидзе, рядовойлар Овчинников, Бекасов... Әлфис тә эләкте бу кайгылы-почётлы отрядка. Тау-кыя арасындагы агачсыз, шыр ялангач зиратка күмгәч, мәрхүм хөрмәтенә хәрби коралдан хушлашу залпы бирергә тиеш иде алар. Мәетне башта ислам йоласы буенча зурлап, аннан соң хәрби хөрмәт күрсәтеп җиргә

иңдерделәр. Көнозын язгы тау суыгында парад кителе белән генә тегесен-монысын эшләп йөри торгач, тәмам өшегән, туңган, аяк-куллары каткан солдатларны үзләрен генә аерым бүлмәгә урнаштырдылар. Идәндәге ашъяулык өстенә төрле ризык өеп куелган, инде менә зур табакта буы бөркелеп торган тәмле ит тә керде. Авыз суларын тыярлык түгел. Эчәкләре чөкри кычкыра башлады, җитмәсә. Әмма бу яктагы тау халкының симертеп эт ите ашавы гадәти хәл булуын ишеткәннәре бар. Шунсы кулдан тота ...Бозау хәтле зур-зур, таза маэмайларның үзләрен дә күрделәр ич бүген.

Каты чәчле, әрсез Бекасовның да тәмле булар чыгарып торган симез ит калҗаларына күзе кызды. Тәкате тәмам китте, ахрысы: яхшы аш калганчы, яман корсак ярылсын, дигән төсле, иңнәрен сикерткәләп куйды да алдындагы кисәккә үрелде... Бүтәннәр аның мондый тәвәккәллеген эчтән генә кызыгып, көнләшеп күзәтсәләр дә, кичерешләрен үртәү, үчекләү, ирештерү сүзләре белән басарга тырыштылар:

– Кара аны, Бекас, эткә әйләнмә тагы!

– Курыкма! Ишләре янына бәйләп кенә калдырырбыз!

– Чистый эт икәнсең, Бекасов! Һау-һау-һау!

Шул рәвешле усал шаяртып, кылтаеп утырганда, Улмасның атасы килеп керде. Солдатларның, назлы кияүдәй, тыйнак кына, шупырдатып чәй эчеп, йөзем-өрек, көлчә ише ризык капкалауларын гына күргәч, моның хикмәте башына барып җитте бугай. Әлеге тәшвишнең урынсыз булуын, моның куй ите икәнлеген аңлатырга теләп, яңа гына чалынган сарык тиресен кертеп күрсәтте хәтта. Шуннан соң гына көнозын ачка беткән солдатлар җылы, сусыл иткә ябырылдылар да ых булганчы сыйландылар. Бераздан сөяк-санак кына аунап калды табында.

Әлфис, җаен туры китереп, картны юатып, татарча берничә сүз әйтте. И, күңеле булды шуңа мөхтәрәм аганың: җыерчыклар пәрәвезе кунган хәсрәтле йөзенә елмаю әсәре саркыды. Үзләренчә нидер сорашты, озатканда татарчалап: «Сау бул!» – дип кул болгады.

Кайтканда урыс малайлары: ни турында сөйләштегез аның белән, әллә кызын сиңа килештегезме, дип шаярттылар, мәрхүм казакъның зифа буйлы, искиткеч чибәр, унсигез яшьлек сеңлесен күздә тотып. Солдатның шул инде аның: бераз гәпләшергә җай чыктымы, теленнән хатын-кыз төшми. Иреннәрен ялый-ялый, авыз суларын корытып, алар белән мөнәсәбәт, сөю фронтындагы батырлык турында сүз куерталар. Әлфис исә бу турыда бөтен интим нечкәлекләре белән ачыктан-ачык сөйләшүне һич өнәми иде. Бигрәк тә хәзер, кайгылы көндә. Күз алдыннан өлкән лейтенантның сөйкемле йөзе китми, татарлар турында яратып әйткән сүзләре хәтердә яңара.

## 8. «Сынаттың, якташ!», яисә Алма-Атаның алсу йорты

КПП полк биләмәсенең бер читендә урнашса да, барыбер частьның үзәге кебек. Бередән берөзлексез кеше үтеп тора, эч пошканнан бер-ике сүз алышып өлгерергә була. Моннан офыкка хәтле киң кырлар җәйрәп ята, икенче якта мәһабәт таулар күккә үрли. Шуларга карап хыял диңгезенә чумасың. Гомумән, постта торганда рәхәтләнеп хыялланырга, фантазия корырга мөмкин, шуңа ярата да Әлфис каравылны. Беразга гына булса да ялгыз калырга, үз уйларың белән генә яшәргә ирек бирә торган бердәнбер урын ул каравыл посты. Һич булмаса, бармак бөгә-бөгә, һәр атна саен керәсе мунча исәбеннән чыгып, дембельгә чаклы тагы ничә мунча калганын санасаң да, кәеф күтәрелеп китә...

Билгеле, КППдагы дневальный постында торганда, алай бик таралып, изрәп төшәргә ирек бирмиләр. Әледән-әле капканы ачып, машиналарны, бүтән техниканы тикшереп кертергә йә чыгарырга кирәк. Иртә таңнан тишегеннән штаб башлыгы майор Таривердиев килеп җитә. Тынгысыз, җитез, эшлекле кеше дә инде. Гади, мөлаем кешегә охшаган үзе. Туктап хәл-әхвәл алышырга да иренми. Менә хәзер дә тәмәке кабызу өчен капка янында тукталды да, нигәдер тоташ пыялалы КПП бүлмәсе ягына күз атты. Анда кизү офицер күренмәгәч, Әлфис янынарак килеп:

– Син, Галимдаров, акыллы кешегә охшагансың...Тәртип һәркемгә дә бер тигез булырга тиеш. Шулай бит? Менә нәрсә, солдатлардан гайре биредә эшләүчеләрнең, офицерларның барысын да кертеп, кайчан килеп, кич кайчан китеп баруларын төгәл генә теркәп кал әле. Яшереп кенә, минем өчен! Сәгатен-минутын күрсәтеп, ярыймы? Югыйсә, эшкә теләсә кайчан йөрергә яратучылар, дисциплинаны санга сукмаучылар үрчеде соңгы арада... Килештекме?

– Так точно! – дип, үрә катып честь бирергә генә калды Әлфискә. Әлбәттә, нинди генә яхшы кеше булмасын, Таривердиев хакына гына шымчы хезмәтен үтәргә уена да килмәде аның. Холкы андый түгел, иман белә торган, зыялы, намуслы, затлы нәселдән. Эшкә соңарып яисә иртәрәк ычкынучыларны саный китсәң, монда-а-а... Кичкә таба Таривердиевның сораулы карашына, юк, дип кенә башын чайкады. Билгеле, Әлфискә ышанып бетмәде теге, аны-моны әйтмичә, күзенә текәлеп карады да, иреннәрен бүлтәйтеп, башын чайкап куйды.

Берничә көннән штабка дәштеләр. Моңа һич кенә дә куанмыйсың, әлбәттә. Берәр төрле юк сәбәп табып, солдатның аркасын «камчыларга» инде. Таривердиев, теге чакта берни дә булмагандай, әдәпле генә исәнләште дә солдатка урындык тәкъдим итте, үзе арлы-бирле йөреп:

– Рядовой Галимдаров! Сезгә особый сугышчан задание кушмакчы булабыз. Сезнең кардәшегез рядовой Ташмөхәммәтов бөтенләй бәйдән ычкынды. Безнадёжный наркоман, понимаете ли... Шуны Алма-Атага, госпитальгә озата барырга кирәк. Аның милләттәше буларак, сез уртак тел табарсыз дип уйлыйм. Поездга утырып, әлбәттә инде, коралсыз-нисез. Гадәттән тыш хәл килеп чыга калса гына, берәр чарасын күрерсез... Мине дөрес аңлый торгансыздыр бит?.. Хәер, комиссоваться итәргә торганда, аның үзенә дә качып китүнең мәгънәсе юк... Аннары аның физик хәлен үзегез күреп торасыз. Мин сезгә ышанам. Моны дембель заданиесе итеп кабул кылыгыз! – диде дә, саран гына көлемсерәп, аптырашка калган солдатның кулын кысты.

Менә сиңа дембель заданиесе! Таһир Ташмөхәммәтов барып чыккан наркоман инде. Бистә мунчасына барган саен, бина артындагы сазлыкка гына чыгып керә, үзе генә белгән ниндидер үлән таба да шуны суырып кәефләнә, рәхәт чигә, тәмам исерә. Аны, «үзебезнең халык вәкилен» күтәреп кайту Әлфисләр өстенә төшә.

Үзе дә якташлар итеп ихластан үз күрә, санлый Таһир. Айнык чакта сөйләшеп туймаслык шәхес ул. Укыган. Музыкант. Баянда сиптерә генә. Өендә пианино бар ди... Булыр да, сөйли башласа, авызына каратып тота. Бах, Бетховен, Моцарт, Чайковский, Шостаковичлар турында әллә ниләр белә. Тик менә татар композиторларыннан бер Рөстәм Яхин гына таныш икән үзенә. Татарчасы да аның ипи-тозлык кына. Хәлле гаиләдән булганга, посылканы да еш ала. Авыз иттерми калмый. Үзенчә юмарт, кешелекле егет.

Әлфис авыруның шәхси картасын алырга кергәндә, санчастьта шәфкать туташы Ольга берьялгызы гына иде. Тулы иреннәренең чигеннән чыгып, кызыл помада белән моның кадәр дә чамасыз, мул итеп буямаса, сөйкемле генә туташ үзе. Болай исә, читтән торып караганда, борыны да кызылга манчылган төсле

күренә. Шул хатасын берәрсе үзенә әйтми микәнни? Сөйләшергә дә бик җайлы Ольга. Менә хәзер дә, Таһир турында сүз чыккач, Әлфискә «сер итеп кенә» әллә ниләр җиткерде. Хезмәт итәргә килгәндә, «алма кебек» матур егет булган икән ич безнең Ташмөхәммәтов! Эшчән, тәрбияле, шаян егет. Наркотик турында сүз дә булырга мөмкин түгел ул чакта. Музыка остасы. Шәп җырлый, теләсә кайсы музыка коралында уйный. Монда барысы да күз алдында бит... Элек хәтта аракы да эчмәгән. Кая ул! Былтыр гына монда эшләп киткән Макасов үзенең сигез яшьлек кызын пианино уйнарга өйрәтергә дип өенә чакырта башлаганчы. Менә шуның фатирында аракысын да, спиртын да, башкасын да эчәргә өйрәнгән күндәм, карусыз музыкант егет. Макасов белән бергә. Тегене эштән кудылар. Ә бусы әнә кешелектән чыкты. Кызганыч, дөнья биргесез алтын егет иде.

Ярый, агылый да тагылый булып, Әлфис Галимдаров белән Таһир Ташмөхәммәтов икәүләшеп чыгып киттеләр хәтәр юлга. Казакъстан башкаласына, гадәти пассажир поездына утырып. Кәнсәләрдән озатканда, кайберәүләр, булачак фаҗигане, бүтән төрле гадәттән тыш хәлне фаразлап, астыртын гына көлеп калды. Ул-бу чыга калса, берәр нәрсә белән башына гына орырга, дигән ихлас кайгырту сүзләрен колагына пышылдаучылар да табылды. Әлфис исә тәкъдиренә ышанып, тәвәккәлләде – утырды да китте. Әмма болай да тәмам бетерешкән хаста кешегә бармагы белән дә кагылмаячагына иманы камил иде. Таһир инде нindидер үгет-нәсихәт бирүдән узган. Аның максаты, хасияте башкада, бүтән темага гәпләшергә теләге дә сизелми.

Вагонга кереп утыруга, Әлфиснең күзенә карап, болай диде ул:


– Курыкма, якташ, мин сиңа зыян китермәм, исән-сау барып җитәрбез. Әмма ачыктан-ачык әйтәм, үлән капмыйча түзә алмыйм мин. Син миңа комачаулама гына, үз дозамны беләм...

Бераздан, бәдрәфкә генә чыгып керим әле, дип киткән Таһир, поезд буйлап аның ише зәхмәтне сатып йөрүчеләр белән иснәшеп, танышып та өлгергән. Бөтенләй миңгерәп килеп ауды да Әлфис катына, озак кына мышнап, ыңгырашып, бәргәләнеп ятты. Ул исәңгерәп, аңына килеп, торып утырырга маташканда, поезд Казакъстан башкаласына җитеп килә иде инде. Әлфис моңа үлемнән котылган кешедән ким шатланмагандыр. Бүре дә тук, сарык та исән, дигәндәй, чәчләр үрә торырлык нәрсә булмады! Ташмөхәммәтов вәгъдәсендә торды.

Госпитальне табып, баш табиб кулына тапшыргач кына, күңеленә бөтенләй рәхәт булып китте солдатның. Ташмөхәммәтов үзенә бер кәефле иде. Биредән инде турылап туган ягына кайтып китәсенә һич шикләнми иде ул. Армиядәге хәрби медицина әһелләре белән елъярымлык көрәше аның файдасына тәмамланырга тора. Әмма моны җиңүгә санап буламы соң?! Һәм ни бәрабәренә яуланган шикле җиңү бу? Солдатның шәхсән үзен ничек кенә гаепләсәләр дә, армиянең бозык мохите тәрбияләгән бала ич ул! Асылына, төбенә төшеп карасаң, Таһир бит үзе корбан, битарафлык, бюрократлык, солдафонлык, кансызлык корбаны. Андый нечкә хисле, зәгыйфь рухлы, талантлы затларны мәҗбүри хәрби хезмәткә алып, азагында кем отты инде? Гражданкада файдасы күбрәк тигән булыр иде ләбаса яраткан эше белән шөгыльләнсә?!

Госпиталь капкасыннан чыкканда, хәрби задание үтәлүгә сөенүдән бигрәк, Таһирга бәйле күңелсез кичерешләр биләп алган иде аны. Киләчәге нинди булыр, тәкъдире ничек очланыр икән читкә тибәрелгән, адашкан ул татар баласының?!

*(Ахыры киләсе санда)*



*Ринат Абзалов 1954 елда Татарстанның Сарман районы Сарман авылында туа. Сарман урта мәктәбеннән соң Казан дәүләт төзүче-инженерлар институтының архитектура факультетында белем ала. «Чаян» журналында баш мөхәррир урынбасары булып эшли.*

*ТРның атказанган матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр хезмәткәре. Казанда яши.*

Ринат
Абзалов

# ҺӘР КӨН – АЧЫШ...

## Әткәй күзләре

Сугыш кырларыннан алҗып кайткан
Әткәйләргә авыр булгандыр;
Җаннарына сеңгән юл тузанын
Хәмер белән алар югандыр...

Канлы юллар, үлем чагылышын
Уйчан карашларда күрдек без.
Бакыр медальләрен, мактанышып,
Күлмәкләргә тагып йөрдек без.

Үткәннәрдә калгач туп атуы,
Һәм мәхшәрле утлы далалар,
Күкрәп килде җиргә ут эчендә
Үз мизгелен көткән балалар...

Тын тормышка сусап, көеп беткән
Басуларда аваз салдык без.
Кара икмәк, кысыр ашлар ашап,
Яшәү көче, җегәр алдык без.

Әткәй-әнкәй салган агач йортта
Кайгы-михнәт күрми үстек без.
Алар корган төпле, нык тормышта
Колач җәеп, кыю йөздек без.

...Һәр буынга килә зур сынаулар,
Яманлыкның кара дулкыны.
Безнең җаннарны да өтә һаман
Туксанынчы еллар шаукымы...

Менә без дә зур агайлар булдык –
Инде безгә яшьләр баш ия.
Балаларның нәни балалары
Бабайлардан ала тәрбия.

Үсеп килгән шаян оныгымның
Җитдиләнә кайчак йөзләре.
Сорау белән карый кебек кайчак
Уйчан күзләр –
эткәй күзләре...

## Очам

Очам... Очам…
Кая очам, белмим,
Артка, алга, уңга, сулгамы?..
Әллә күккә – биеклеккә ашам,
Әллә аска – төпкә убаммы?..
Кайсы якка  – мин битараф моңа,
Иң мөһиме – шушы халәтем.
Ләззәт бирә миңа онытылып,
Иркен сулап очу сәләтем.
Чын ирекне тою мөмкинлеге
Бүләк иткән Ходай адәмгә.
Шуңа күрә «ас-өс» төшенчәсен
Кертмәгән ул чиксез Галәмгә...

## Ачыш...

Гаҗәеп хәл: яшем арткан саен,
Һәр көн ясыйм яңа ачышлар:
Күк йөзе, күр, нинди зәңгәр икән,
Алтын төстә  кырда арышлар.
Минем хатын – иң чибәре икән –
Читтә торсын япь-яшь кызларың;
Җәен көндез эссе була икән,
Һәм чатнама суык – кышларың.
Язгы җилләр гел саф була икән,
Исертерлек – шомырт исләре,
Шәрабтан да каты ега икән
Онтылмаган сөю хисләре...
Ә көзләрнең төсләр галәмәте
Ярып керә талган күңелне.
Күңелләрдә шашкан шул бәйгедән
Яшәргән күк тоям үземне...

Һәр көн – ачыш.
Агышында бәйрәм,
Төпсезлеккә койган дәрьяның.
Китеп барабыз без, соң булса да,
Гүзәллеген аңлап дөньяның...

## Кем ул анда?

Язгы җилләр чәчем сыйпаганда,
Сизеп бөек гомер бәйгесен –
Тоймыйча да җылы ул сулышны,
Көттем һаман аның җәйгесен.

Җәй җилләре битем үпкән чакта,
Күрми сихри таңнар балкуын,
Офыкларга карап дога кылдым,
Бирче, диеп, көзнең алтынын.

Үкергәндә көзге ачы җилләр,
Җәйне озайтырга тырыштым –
Җылы эзләп, шыксыз агачларның
Кәүсәсенә барып елыштым.

...Салкын карлар баскан бар дөньяны,
Күз ачкысыз давыл урамда.
Кем ул анда, ялгыз мосафирдай,
Нидер көтә кышкы буранда?..

## Туган авыл, диеп...

Туган авыл...
Мең кат таныш җырлар:
Куе урман, яшел тугайлар,
Иркен басу-кырлар, саф чишмәләр,
Күкләрендә сайрый тургайлар...
Хуш иследер аның болыннары,
Бормалыдыр аның сулары,
Шаулап үсә анда мул игеннәр,
Матур аның кыз һәм уллары...

Табармын дип яңа бер җылы сүз,
Тыңлап карыйм тагын, тагын да.
Уйлап куям: әллә бөтенебез
Тудык микән бер үк авылда?

Ишетәсе иде җанны ярып
Керердәй сүз, күңел сусагач.
...Авыл, диеп җырлар язмыйк, дуслар,
Башка әйтер сүзләр булмагач...



*Чулпан Хаҗиева 2001 елда Казан шәһәрендә туа. Хәзерге вакытта 2нче татар гимназиясендә XI сыйныфта укый.*

*Үзен проза өлкәсендә сыный: повестьлар, хикәяләр яза. 2018 елда аның хикәяләре Россиякүләм «Глаголица» иҗат конкурсында Гран-прига лаек була.*

Чулпан
Хаҗиева

# ӘСӘЛЕМ...

ХИКӘЯ

Җирнең кайсы гына ноктасында булсам да, гел бер үк кешеләрне күрәм. Бүген минем Казанда беренче генә көнем, ләкин мондагы кешеләрне үзем туган Испаниядә дә көн саен очратам кебек. Минемчә, сез дә аларны танырсыз, алар бит һәрвакыт безнең арабызда, ә бәлки, без дә күптән шундый ук кешеләргә әверелгәнбездер. Аларны күрәсегез килсә, мин утырган паркка гына килегез. «Саф һава сулап, бүгенге көн өчен энергия җыям», дип акланып, үзләренең Инстаграмнарына яңа фотолар әзерләргә килгән кешеләр монда бихисап. Әнә берсе иртәнге сәгать җидедә «подписчикларына» видео аша хәерле позитив иртәләр, уңышлар теләп, башы күккә тигәндәй елмаеп мөрәҗәгать итә дә соңыннан, борынын салындырып, инде биш ел буе интегеп эшләгән эшенә китә. Ә берсе үзен иртәнге кояш нурлары һәм ямь-яшел хәтфәдәй чирәмдә фотога төшерергә дус кызын ияртеп килгән. Парктагы каеннарның һәр ботагына тотынып төшкәннән соң, алар, һичшиксез, колакларына наушник тыгып, шул фотоларны редакцияләячәк һәм лайклар санының артканын тикшереп торачак.

Әле кичә генә минем дә проблемаларым шул Инстаграм белән чикләнсә, бүген башны башка уйлар бораулый. Хәзер үземне дөньядагы иң бәхетсез кешедәй хис итәм. Бер көндә мин 17 ел буена төзегән якты тормышымны, якын дусларымны, диңгез буенда урнашкан яраткан өемне, мәктәбемне, беренче мәхәббәтемне калдырырга мәҗбүр булдым. Югары уку йортына керү, Испаниядә шәхсән үземнең ресторанымны ачу кебек планнарым, әлеге парктагы балаларның комнан ясалган сарайлары кебек чәлпәрәмә килде. Әти-әни минем өчен кадерле булган бар нәрсәне тартып алды сыман. «Кызым, Назлы, Казан бит ул – синең ата-бабаң туып үскән җир, син монда да бар максатларыңа ирешә алачаксың, яңа тормыш башлавы да авыр булмаячак. Әз генә вакыт үтсең, син бу шәһәргә гашыйк булачаксың», – дисәләр дә, мин аларга ышанмыйм. Бердәнбер кызларының

язмышы белән уенчык кебек уйнагач, әзрәк тынычландырырга гына телиләр алар. Минем әти – Испаниянең иң атаклы хирургларының берсе. Казанга яшәргә килүнең сәбәбе дә шунда. Имеш, монда әти кебек табиблар җитешми, ә чит илгә очарга мөмкинлекләре булмаган, авыр операцияләргә мохтаҗ кешеләр бик тә күп. Шуңа да әти минем дөньяма күз йомып, бу шәһәрдә яңа тормыш башларга карар кылды. Хастаханәгә якынрак фатирны да озак эзләмәдек. Хуҗаларына аны бик тиз арада сатарга кирәк булган, шуңа безгә зур ташлама ясадылар. Әлбәттә, мин дә алар урынында тизрәк качар идем моннан, артык бер генә көн дә тормас идем. Әлеге паркны биләп алган кешеләр арасында гына үземне бик үк ялгыз хис итмәсәм дә, өйгә кайтырга кирәк, әнидән тагын лекция тыңлау гына җитмәгән иде миңа.

Җәй быел Испаниядә дә салкын килде, ләкин бүгенге көн аеруча моңсу тоела. Парктагы, йөзләреннән елмаю төшми торган балалар да, кешеләрне әз генә бәхетле итәргә тырышып, үзенең ахыргы җылысын, якты нурларын бирергә теләгән кояш та, хәтта Инстаграмдагы 2336 подписчик та күңелне җылытмый. Шуңа күрә мине көтәчәк яңа бүлмә генә түгел, ә яңа тормыш та күңелемә тынычлык өстәми иде.

Ишекне ачып, фатирга керү белән, мине ниндидер салкынлык биләп алды, әлбәттә, ул күптәннән үзенең эшен оныткан батареялардан, кыршылып беткән ак стеналардан, рамнары искергән тәрәзәләрдән түгел иде. Әти-әни тегендә-монда йөгереп, аңа игътибар итмәсә дә, сизәм: бу фатирда инде күптәннән бернинди өмет һәм күңел тынычлыгы калмаган... Әлеге урынның тәрәзәләре, кояш бар бүлмәләрне дә үзенең нурында коендырырлык итеп урнашса да, ишекне ачуга сине бәхетле кешеләрдән калган яктылык биләп алмаса, Африканың иң эссе кояшы да күңелне җылытмаячак. Күрәсең, элеккеге хуҗаларның моңа вакытлары, бәлки мөмкинлекләре, яисә, гомумән, теләкләре дә булмагандыр.

Шулай бу фатирның серенә төшенәсем килә торган мәлдә, эшсезлектән интегәдер, дип уйлапмы, фикерләремне әни бүлдерде. Минем моңсу һәм ниндидер җавап көткән күзләремдә, әни әле дә Казанга алып килгәнгә нәфрәт һәм үпкә күрсә, аларда инде бары тик бушлык һәм ул бушлыкны җиңеп чыгарга тырышкан якты киләчәккә өмет тә бар иде. Әни инде шул чиксез аңлатулардан туеп, миңа сораулар бирмичә генә, үз бүлмәмә кием-салымнарны урнаштырырга кушты. Шул эш кенә булса да миңа уйларымны онытып торырга ярдәм итәр дип теләгәндер инде ул.

Машинадан әти алып кергән кап-әрҗәләр, ниһаять, бүлмәне тутырды. Иң беренче булып үземнең иң бәхетле мизгелләрем сурәтләнгән фотоларымны киштәләргә тездем. Менә бу фотоларда мин дусларым белән. Юлда рамнарның пыяласы чатнаса да, минем аларга карата мәхәббәтем беркайчан да чатнамаячак. Шул рәвешле, йөрәгем күңелле хатирәләр белән тулган арада, игътибарымны тузанлы киштәләрнең берсендә хуҗасыз калган китап җәлеп итте. Элеккеге сәер хуҗаларның нәрсә укыганнарын гына булса да беләсе килү теләге белән, мин китапка таба кулны суздым. Юк, бу китап түгел, ә күз яшьләре белән кайбер битләре катып калган, кайбер җөмләләрен укып та булмаслык дәрәҗәдәге көндәлек иде. Безгә кадәр торган хуҗаның көндәлеге. Ыгы-зыгы аркасында мине генә борчый торган сорауларга җавап табу нияте белән, кыяр-кыймас кына бу көндәлекнең беренче битен ачтым. Аның тышында «Хәдичәм, дөрес юлны сиңа йөрәгең күрсәтер. Сине мәңге яратучы әниең Клара. 2003 ел» дигән нәсыйхәт язылган иде. Димәк, минем кулда Хәдичә дигән кызның беренче мәхәббәте, ничә еллар буена бу тормыштан алган

сабаклары, дуслары тарафыннан хыянәт кичерү, мәктәптәге укытучылары белән булган мөнәсәбәтләр турындагы язмалардыр инде, дип уйладым мин. Алай булса, һичшиксез, Хәдичә минем хәлне аңлар иде. Үзем өчен ниндидер киңәшләр табармын, дип, мин беренче көн вакыйгаларын укырга керештем.

«1 июнь. Кадерле әнием, бу дөньяда синсез ялгыз калганнан соң, инде ундүрт тапкыр 1 июнь үтте. Әмма ундүртенчесендә генә син миңа аеруча җитми башладың. Син миңа бу көндәлекне беренче тапкыр кулга тоттырган көнне хәтерлисеңме? Әлбәттә, әнием, синең өчен дә бу көн хәтереңдә мәңгегә уелып калгандыр. Син мине унбиш яшемдә «Халыкара балаларны яклау көне» уңаеннан бәйрәмгә алып бардың. Көндәлек сатып алып, сөендергәннән соң, йөзеңдә балкыган елмаюың әле дә күз алдымда тора. Синең шулкадәр ягымлы елмаюыңны мин хәзер кызым – Әсәлнең бәхетле күзләрен күргәч кенә аңлый башладым. Син якты дөньядан киткәч, ул гына миңа яшәргә көч һәм дәрт өстәп торды. Берничә көннән аңа җиде яшь тулачак, бигрәк зур үсте инде. Үскән саен, ул сиңа охшый бара, әнием... Ә холкы минеке... Дүрт яшендә үк укырга-язарга өйрәнде, дуслары курчак киендереп уйнаганда да, тәрбияче артыннан китап күтәреп йөри иде минем Әсәлем. Менә хәзер дә ул кулына китабын тотып йокыга китте. Нигәдер көндез күп йоклый, нәрсә генә эшли башласа да, хәле тиз бетә. Бер дә тик торганы юк үзенең, шуңадыр инде. Хәзер ул уянганны көтәм, син мине ундүрт ел элек алып барган бәйрәм мәйданын күрсәтәчәкмен. Аның өчен генә түгел, үземә дә шул урынга кире  кайту зур вакыйга булачак...»

Шуның белән көндәлекнең беренче язмасы тәмамланды. Ләкин шул язмадан соң да, күңелдә авырлык сиздем. Уйларымда Хәдичә минем хәлемә керер кебек тоелса, хәзер үзем аны аңларга тырыштым. Бу дөньяда һәркем өчен дә иң кадерле кешене югалтып, яшәүнең тәмам тәмен тоймый башлагач, Ходай аңа өмет бүләк иткән. Мәгънәсез караңгы тормыштан чыгу юлын күрсәтүче маяк булып, аның кызы туган. Балалы өйдә мондый бушлык берничек тә хөкем итә алмый, димәк, ялгышканмын. Эш, чыннан да, иске ремонтта булгандыр. Мин әнием янына фатирны үзгәртү тәкъдимнәре белән чыгып кердем дә, көндәлекнең икенче битен ачтым.

«4 июнь. Кадерле әнием, йөрәгем дөрес сизгән: бәйрәм мәйданына бару минем өчен бик зур вакыйга булды. Аның зурлыгы куркынычлыгы белән тәңгәл килә. Әсәлем үзе кебек баллы мамык ашаганнан соң, аның яшендәге башка балалар җыелган, шарлар тараткан урынга барырга сорады, ләкин... барып җитә алмады. Үзенең кечкенә тәпиләре белән зур кызыл шар артыннан йөгергән арада, аңын югалтып егылды. Әнием, хәтерлисеңме, син минем бер йөткерүемне ишетеп тә, кичектермичә хастаханәгә алып бара идең? Шуңа күрә, мин начар уйларны читкә куеп, башына эссе генә тигәндер дип уйласам да, табибка күренмичә булдыра алмадым. Әсәлнең хәле турында сөйләгәч, ул да миңа: «Хәдичә ханым, 7 яшьлек шук кыз өчен бу гадәти хәл. Урамда эссе, кояш кыздыра, бәлки, бик сусаган булгандыр. Барысы да яхшы булачак, борчылмагыз шулхәтле», – дип, Әсәлне бәйрәм уңаеннан кәнфит белән сыйлап, өйгә кайтарып җибәрде. Табибның сүзләре миндә ышаныч уятмаганга күрә, мин барыбер томография узарга булдым. Нәтиҗәләр билгеле булгач, табиб миңа нәрсәдер аңлатырга тырышып карады, ләкин: «Сезнең кызыгызда баш мие шеше табылды. Өченче дәрәҗә», – дигән сүзләрдән соң, мин инде аны тыңлый алмадым. Син үлгәннән соң, минем әле шулай йөрәк тетрәнгәне юк иде, әнием.. Кызымны могҗиза, бары тик могҗиза гына коткара алачак».

Бер белмәгән кешенең кайгысы минем күңелне шулкадәр әрнетә алыр дип

башыма да килмәс иде. Күздән яшь тама. Күпме генә киләсе язманың куанычлы булуын теләсәм дә, әтием шул өлкәдә эшләгәнгә күрә, могҗизаларның аз, бик аз булуын аңлый идем мин. Ләкин алар юк түгел. Әсәлне Хәдичәдән тартып алмаячаклар, бу мөмкин түгел, шуңа күрә дә мин укуымны дәвам иттем.

«9 июнь. Кадерле әнием, мин табиблардан көткән кебек, син дә миннән яхшы хәбәрләр көтәсеңдер. Алар юк дип язсам, үземне бирешәмдер кебек хис итәм. Әлегә булмаса да, алар, һичшиксез, булачак. Табиб кичә Әсәлне мактады. «Кызыгыз зурларга караганда да көчлерәк, аның күзендәге бәхет ялкынын саклап кала алсагыз, ул авыруны да җиңеп чыгарга мөмкин, Алла теләсә», – диде. Анализлары киресен сөйләсә дә, бу сүзләр миндә ниндидер өмет уятты. Шуңа күрә, авыруга игътибар итмәсәк, ул Әсәлне калдырыр дигән максат белән, без бүген беренче тапкыр кибеткә киттек. Әле җәй башы гына булса да, кайбер җирләрдә мәктәп формалары эленеп тора иде. Кызым аларны әллә кайдан күреп алып, мине шунда алып барды. «Әнием! Кара нинди матур!!! Мәктәпкә шуны кисә-ә-әм, бик кызык булыр иде, ул яңа сандалиларыма да килешәчәк. Ну кара инде, нинди матур!» – диде ул, салават күперенең бар төсләре кергән сызыклы колготкиларга төртеп. Үзенең дуслары белән көз көне мәктәпкә барачагына бар йөрәге белән ышана иде. Бүген мин кызым теләгән бар нәрсәне алдым. Өйгә кайтуга, ул бөтен мәктәп әсбапларын үзенчә барлап, алсу төстәге рюкзагына матурлап тыгып, аны инде ишек төбенә илтеп куйган иде. Йолдызым минем...»

Нәни Әсәлнең сызыклы колготкилары ахырга кадәр пакетка төрелгән халәттә кала алырга мөмкин дигән уйлар минем күз яшьләренә туктарга ирек бирмәде. Мин яңа битне ачтым.

«12 июнь. Кадерле әнием, кичә төнлә Әсәлне хастаханәгә алып киттеләр. «Аңа анда яхшырак булачак», – диделәр. Бүген мин, ул палатада йоклаганда, беренче тапкыр аның янында еладым, йөрәгем түзмәде. Ул шуны сизеп уянгач, шар кебек зур, әле һаман да янып тора торган күзләре белән миңа карады да: «Әнием, мин сине шу-у-ундый каты яратам, елама инде, хәзер ак халатлы абый миңа баш авыртмасынга тагын тылсымлы дару эчерә дә, без өйгә кайтачакбыз. Ә анда безне туңдырма көтә, шулай бит, әнием?» – диде. Хәзер аның организмында нинди көрәш барып та, ул мине шулай тынычландырырга көч тапкач, минем кызыма карап еларга хакым юк иде. Төн тыныч үтте».

«14 июнь. Кадерле әнием, ике көн эчендә барысы да үзгәрде. Әсәлнең хәле көннән-көн начарая. Табиб әле генә кулыма «Дүртенче дәрәҗә» дигән бәяләмә тоттырды. Тиз арада операция турында карар кылырга кирәк. Әнием, мин имзамны куярга булдыра алмыйм. Операциясез аның тагын ун ай яшәргә көче җитәчәк, ә аны ясатып, йөрәгенә авыр килсә, аны сине югалткан кебек, мәңгегә югалтачакмын. Ләкин аның ахыргы мөмкинлеген тартып ала алмадым, бар нәрсәне хәл итүче операциягә ризалашырга туры килде. Аңа кадәр синнән калган фатирымны сатарга кирәк булачак. Әсәлемне янымда калдырырга атом бөртеге кебек кенә дә мөмкинлек булса, мин аның өчен барысына да әзер, кызганыч, мин моны бик соң аңладым бугай...»

Әйе, мин, чыннан да, Хәдичәне аңларга тырыштым. Аның көндәлеген укыганда, үземне бәйрәм мәйданында, мәктәп формасында, хәтта хастаханәдә дә Әсәл артыннан күзәтүче шаһиттай хис иттем. Минем өчен шул күзәтүнең һәр минуты, һәр мизгеле зур сынау кебек иде. Ләкин ничек кенә авыр булса да, Хәдичәгә моннан мең кат авыррак. Чөнки ул Әсәлсез яши алмыйча, үзен югалтырга мөмкин. Әниләр безгә нинди генә салкын сүзләр әйтсә дә, аларның йөрәкләре бары тик балалары өчен тибә. Минемчә, моны һәр кеше беләдер, бу

сүзләр күп кенә җырларда, әсәрләрдә, киноларда очрый, ләкин сезнең шуны аңлап, әниегезне бернинди сәбәпсез кочаклаганыгыз, аңа рәхмәт әйткәнегез бармы? Кызганыч, минем дә юк бугай. Икенче биткә күчәр алдыннан, әнием янына барып, гафу үтенергә теләдем.

«19 июнь. Кадерле әнием, биш көн буе мин Әсәл яныннан китмичә, аның янында булдым. Әле генә телефоннан шалтыратып, фатирны алырга теләүчеләр турында хәбәр иттеләр. Беләм: синең ахыргы теләгең минем шул фатирда матур, бәхетле тормыш алып баруым иде. Ә хәзер ул, бәлки, бу дөнья белән кызымны тоташтыручы ахыргы нечкә җептер. Фәнгә генә ышанган табиблар да могҗиза турында әйтә башлаганнан соң, мин Әсәлне бер минутка да үзен генә калдырмадым. Башта Әсәл теләгән әйберләрне алып тегендә-монда йөргәндә, бу бүлектәге балалар бүтәннәрдән бер дә аерылмый, шундый ук шат күңелле кебек тоела иде. Ләкин аларның сөйләшүләренә игътибар итә башлагач, үземнең кайда икәнлегемә, чын мәгънәсендә төшендем. Аларның әңгәмәләрендә «үлем» дигән сүз нәкъ «иртәнге аш» кебек еш кулланыла иде. Бер бала гына иртән төшенкелек һәм салкын караш белән уянса, аны кичкә таба өмет һәм якты хисләр биләп ала алганына хәйран калдым. Әле күптән түгел генә үлемне химиотерапия белән чагыштырганда җиңелрәк күреп тә, хәзер ул үзенең пеләш башын тотып, шампунь экономиясе турында башка яшүсмер балалар белән көлешә иде. Әсәлнең дә шул балаларның арасында булуы миңа инде ничә көн йокы бирмәде...»

«25 июнь. Кадерле әнием, минем кызым бүген беренче тапкыр: «Бәлки, син туңдырма яисә яраткан китабыңны укырга телисеңдер? Сиңа берәр нәрсә кирәкмиме?» – дигән сорауларга пышылдап кына «тынычлык» дип җавап бирде. Аның күзләрендә хәзер ут түгел, хәтта курку да күренмәде. Кечкенә генә булса да, табибларның аңа кызгану белән караганнарын аңлый иде ул. Мин вакытлыча дус кызымда яшәп торам. Дүрт көннән операция».

Киләсе язманы күпме генә укырга тырышып карасам да, Хәдичәнең күз яшьләреннән соң калган таплар миңа ирек бирмәде. Көндәлектә тагын берәр язу табармын, дип, бөтен битләрне карап чыкканда, алар арасыннан, инде күп тапкыр кулга алынганга күрә, төсләре уңып беткән визитка килеп чыкты. Табибның исемен укырлык түгел иде, ләкин аңа да карамастан, хастаханәнең адресы яхшы күренде. Әсәл белән әле егерме минутлап кына таныш булсам да, ул миңа шундый якын кебек тоелды. Шул кечкенә вакыт эчендә дә Хәдичә кичергән авырлыкларны үз йөрәгем аша үткәрдем. Операция турындагы кирәкле мәгълүмат ничектер кулыма эләккәч, шул көнне йөрәкләре бердәм булып тибүче әни һәм кыз янында булырга тиешлегемне сизә идем. Чыннан да, мин бу фатирның бушлыгы иске ремонтка бәйле түгел дип ялгышмаганмын, ләкин ялгышсам, минем күңелемә мең кат җиңелрәк булыр иде шул.

Иртәгә ике кешенең язмышы билгеле булачак. Нәкъ иртәгә кечкенә, ләкин зур йөрәкле, гөнаһсыз баланың гомере хөкем ителәчәк. Иртәгә сабый бала әнисе белән калырга яисә, әбисе янына китеп, күзләрен мәңгегә йомарга мөмкин. Иртәгә операция көне.

Көндәлекне яңадан һәм яңадан укып, уйларымны Әсәлдән аера алмыйча, йокысыз төнем үтеп китте. Операциянең вакытын төгәл белмәгәнгә күрә, мин хастаханәгә иртәрәк барырга булдым. Кичәге көн белән чагыштырганда, бүген кояш тагын да тырышыбрак инсаннарны үзенең нурларында коендыра иде, хәтта каршыма очраган кешеләрдә дә бүген ихлас елмаюлар күренде. Аларның һәрберсенең яшәүгә мәгънә өстәп торучы якыннары, үзләре генә аңлый торган

кайгырулары, бәхет чыганаклары бардыр, мөгаен. Димәк, мин ялгышканмын. Бу дөньяда тормыш юллары бер үк булган кешеләр юк. Алар барысы да төрле. Шундый уйлар белән, кулга көндәлек тотып, ярты сәгать эчендә хастаханәнең бусагасы янына килеп җиткән идем. Белмим, бәлки, бу зур теләгем генәдер, әмма йөрәк кенә түгел, хәтта кояш та, урамнан узучылар да, биектәге ирекле кошлар да «барысы да яхшы булачак», дип пышылдаган сыман тоелды миңа.

Ләкин, каршымда инде ничә көн йокламаган, елаудан күзләре шешенеп беткән, куллары калтыраган хатынны күргәч, өмет канатларым сынган кебек булды. Каршымдагы хатын Хәдичә иде. Ул бер ноктага карап утыра-утыра да, сискәнеп китеп, озын коридор буенча, үзенең нишләгәнен аңламыйча да, тегендә-монда йөри. Соңыннан, аяклары тотмый башлаганын сизеп, авыр сулап кире урынга утыра. Димәк, хәзерге минутта нәни Әсәл үлем белән көрәшә. Хәдичә янына килергә бераз курыксам да, мин аны үзен генә калдырып китә алмый идем, чөнки көтү зонасында аннан башка беркем дә күренмәде.

Әкрен генә атлап, янына килеп утырдым. Озак вакыт ул, гомумән, минем якка карамады, мин дә сүз башларга кыймадым. Шулай ул тагын бер тапкыр урындыгыннан торгач кына, кулымдагы көндәлеккә игътибар итте. Ундүрт ел элек әнисе бүләк иткән көндәлеген ул меңнәр арасыннан да таныр иде. Аның төссез, хәтта бер тамчы да күз яше калмаган, курку тулы күзләренә берничә секундка төбәлгәннән соң, кичекмәстән аңа көндәлекне суздым. Аннан соң да ул миңа бернәрсә әйтмәде. Шуңа күрә мин үзем сүз башларга булдым.

– Минем исемем – Назлы. Бу көндәлекне фатирыгызда таптым. Сезнең өчен ул бик мөһимдер, шуңа күрә... – дип дәвам итәсем килсә дә, әлеге сүзләрем урынсыз икәнлеген аңлап алдым. Ул бер сүз дә дәшмәде. Берничә минут тынлыктан соң, янә дәвам иттем. – Хәдичә ханым, барысы да яхшы булачак, Әсәл кебек ихлас йөрәкле кешеләргә мохтаҗ безнең дөнья. Шуның хәтле аны яратучы әнисен ташлап, ул китмәячәк, менә күрерсез! Аны әтисе һәм туганнары да сездән ким яратмыйдыр. Дөрес, алар турында мин көндәлектә бернәрсә дә очратмадым. Ләкин алар бар бит. Ә шундый терәк булганда...

Әмма мин югалып калган анага өмет өстәрдәй сүзләрне әйтеп бетерә алмадым, ул мине бүлдерде.

– Юк, Әсәлнең әтисе дә, туганнары да юк...

Бу сүзләрне ишеткәч, ашыгып әйткәннәрем өчен бик үкендем, сүз таба алмыйча: «Сезнең югалтуыгыз белән уртаклашам. Ләкин барыбер, аның әтисе дә Әсәлнең тормышы өчен көрәшәдер», – дидем.

– Юк, син мине дөрес аңламадың, аның әтисе исән, ләкин ул хәзер аның тормышы өчен түгел, ә үзенең бизнесы өчен көрәшә, – дип, минем якка карамыйча гына җавап кайтарды Хәдичә.

– Димәк, ул Әсәл белән сезнең яныгызда булырга лаеклы кеше түгел. Көндәлегегезне берничә тапкыр укып чыктым, барлык әниләрнең дә балаларына мөнәсәбәте шундый булса, бу дөньяда бәхетсез балалар калмас иде. Сез хәлдән килгән бар нәрсәне дә эшләдегез, хәзер кызыгызның язмышы Ходай кулында. Барысы да, һичшиксез, яхшы булырга тиеш, – дип тынычландырырга тырыштым аны.

Сүзләремне әйтеп бетергәч, карашымны Хәдичәгә юнәлттем. Ул һаман да бер ноктага төбәлеп тора иде, эре-эре күз яшьләре тамганын күрдем. Кинәт, хатын йөзен ике кулы белән каплап, җыелган бар кичерешләрен чыгаргандай, үкси-үкси елап җибәрде. Эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлап җиткермәсәм дә, миңа кыенлык килгәндә әнием кочаклагандай, аны кочып алдым. Ә ул, беренче

тапкыр минем якка борылып, күз яшьләрен сөртә-сөртә, карлыккан тавыш белән: «Барысына да мин гаепле...» – дип кабатлады.

– Хәдичә ханым, сезнең монда бернинди гаебегез дә юк! Шулай килеп чыкканга, беркемне дә гаепләп булмый. Кызганыч, бу тормыш гадел түгел шул кайчакта...

Әсәлнең әнисе соңгы күз яшен сөрткәннән соң, инде гәүдәсе белән минем якка борылып, сүз башлады.

– Назлы, син дөрес әйтмисең, бу тормыш гадел. Хәтта кайвакыт аның гаделлеге куркыта да. Бәлки, аңлап та бетермисеңдер, ләкин нәрсә генә булса да, ахырда барыбер гаделлек җиңәчәк. Аны айлар, еллар буе көтә аласың, ләкин сине иң кыен минутта, иң авыр җәза белән хөкем итәчәкләр. Менә мин дә, үземнең җәзамны алдым бугай... – диде дә карашын киредән идәнгә юнәлтте.

– Гафу итегез, ләкин мин сезне аңлап бетермәдем, – дидем, Хәдичәнең сүзне дәвам итүенә өметләнеп.

– Мин үзем дә әле генә аңлый башладым, Назлы. Кызыма диагноз куйганнан бирле, дөреслекнең күзенә карарга куркып, үземә акланулар эзләдем. Ә аның хәзер операция өстәлендә ятуына бары мин генә гаепле. Әйе, бары мин генә. Җиде ел элек операция өстәлендә үзем ятарга тиеш идем. Гомеремдәге иң зур ялгышлыктан нәрсә туктатып калганы хәтеремдә түгел, ләкин мин аны югалтудан баш тарттым. Анысы да Әсәл өчен түгел, ә үземнең файдам турында уйлап кылынган карар иде. Танышканнан бирле берничә айдан соң балага узганымны белгәч, Әсәлнең әтисе кичекмәстән аборт ясатырга кушты. Нигә икәнлеген белмим дә, бәлки, яраткангадыр, миңа бу сүзләрне ишетүе авыр булса да, аңа каршы килергә уйламадым. Әле әфлисун орлыгы кебек кенә бала өчен, иң зур мәхәббәтемне югалтырга теләгем юк иде. Ләкин бу гамәл минем киләчәктә бала алып кайтырга барлык юлларымны ябасын аңлый идем. Табибларның сүзен тыңлап, баланы калдырырга булдым. Әсәлнең әтисе алдында тезләнә-тезләнә еласам да, ул барыбер киемнәрен җыеп, мине ташлап китте. Бүтән аны күрмәдем. Шул көннән башлап, үземнең бәхетсезлегемдә карынымдагы баламны гаепли башладым. Һәрбер көнем авыр сынау кебек тоелды. Инде түгәрәкләнгәнем күренә башлагач, мине эштән кудылар. Журналлар бары тик матур гәүдәле модельләрне генә ярата икән. Гомерем буе хыялланган эшемне югалтканнан соң, Әсәлгә нәфрәтем тагы да үсә төште. Беләсеңме, Назлы, мин көн саен йоклар алдыннан шул баладан котылу чаралары турында уйладым. Ә иртән торуга, нindидер хис туктатты. Сизенүем дөрес булган икән. Дус кызым киңәше буенча, интернеттан балама әти-әни таптым. Бу йөктән котылып, үземнең элеккеге тормышыма кайту гына түгел, ә шуның өстенә тагын зур сумма акча алу мөмкинлеге мине ул мәлдә иң бәхетле кеше итә иде. Шулай итеп, мин баламны кочагыма да алмыйча, чит кешеләргә биреп җибәрү көнен көтә башладым. Бай кешеләр, балалары дөрес үсеш алсын өчен, мине ай саен акча белән тәэмин итеп тордылар. Ләкин адвокатлары шалтыратканнан соң, күзләремдәге сөенеч уты аларның, мәңгегә сүнеп, бүтән беркайчан да кабынмас кебек тоелды. Тугызынчы айга чыкканда, бу баласыз гаилә аерылышырга уйлаган. Зур күләмдәге компенсация түләгәннән соң, мин алар белән генә түгел, ә, гомумән, үзем теләгән киләчәк белән дә хушлашкандай идем. Ә Әсәлдән котыла алмаганымны аңлагач, аны үземдә калдырырга уйладым. Юк, Назлы, әни инстинктлары уянганга түгел, ә үземнең барыбыр бәхетле була алуыма ышанмаганга гына ул әле дә минем белән. Беләсеңме, ул тууга, кызым өчен Ходайга рәхмәт әйтү түгел, аны хәтта

кулыма да алмадым. Аңа тиктормас, төннәрен йокы бирми торган, егетемнән аерган йөккә карагандай карадым. Бу хәл озак дәвам итте. Кышкы төннәрдә үземнең бу дөньяда бернинди дә терәксез, әзме-күпме акча кертә торган эшсез дә калганымны уйлап, аборт ясатмаган көнемне искә төшерә идем. Ә бала бит ул барысын да сизә икән, Назлы. Син аны кечкенә, бернәрсә дә аңламый дип уйлысың, ялгышасың. Әйе, еллар үткән саен, ул минем тормышымның алыштыргысыз өлешенә әверелә барды. Аның «әни» дигән беренче сүзе, гөнаһсыз чем-кара күзләре, кулын миңа сузып, нәни тәпиләре белән тып-тып атлап килүләре нindидер рәхәт хисләр уята иде. Ул янымда чакта үземне ялгыз дип уйлаудан туктадым. Әсәл мине төшенкелектән чыгарды, дип әйтү дә ялгыш булмас кебек. Ул миңа «әнием» дип эндәшкән саен, туганчы әйткән сүзләрем өчен хәзер инде үземә карата нәфрәт уяна... Шулай итеп, мин үземә эш тә таптым, яшәргә әниемнән калган фатир да бар иде. Кулымдагы бәхет өчен сөенүләр, язмыш үткәндәге хаталарны сызып, тормышны яңа биттән башларга мөмкинлек биргән сыман тоелды. Ләкин бу тормыш гадел шул, Назлы. Кызым карынымда чакта әйткән сүзләрем, аннан котылу теләге, эзсез генә онытылыр, минем арттан кире кайтмас, дип ялгышканмын. Әсәлем, менә үзенең кирәксез бала булганын тоеп, хәзер ике дөнья арасында көрәшә. Үткәннәргә кайтып булса, мин балама ул әле әфлисун кадәр генә булганда да, үземнең мәхәббәтемне биреп, ни дәрәҗәдә кирәк икәнлеген көннән-көн аңлатып килгән булыр идем. Ләкин хәзер соң инде. Һәм бар гаеп миндә генә.

Хәдичәне интектергән, әмма авызын ачып бирәүгә дә әйтергә кыймаган, йөрәгенең иң караңгы урыныннан чыккан сүзләрне мин бүлдермичә генә, сүзсез генә тыңладым. Соңыннан, аның сулышында нindидер җиңеллек сизелгән кебек булды. Әле тормышның бернинди авырлыгын да татымаган унҗиде яшьлек кыз булсам да, Әсәлнең шундый халәтен, Хәдичәнең өстендә нинди җаваплылык торганын аңлый идем.

Бу тормыш, чыннан да, гадел икән шул. Синең әйткән һәр сүзең, һәр теләгең, хәтта уйларың да хөкемсез калмаячак. Еллар үтеп, кылган начарлыкларың өчен әле һаман җавап бирмәгән булсаң, димәк, киләчәктә сине тагы да авыррак җәза көтә. Ә әни кеше өчен баласының бер гөнаһсызга авырлыклар кичергәнен күрүдән дә яман сынау була аламы? Мөгаен, юктыр. Җәзада нindидер дөреслек сизеп, кеше үзен тынычландыра да аладыр, ләкин синең өчен балаң интеккәндә, дөреслек турында сүз алып барып та булмый шикелле. Баланың язмышы әти-әни кулында. Һәм аның белән уенчык кебек уйнарга беркемнең дә хакы юк. Киләчәктә балаңның күзләрендә бәхет күрергә теләсәң, син башта аңа үзең лаек булырга тиешсең. Бу тормыш гаделлек өчен беркемне дә кызганмый. Шуны белеп тә, кешеләр дөрес юлга соң, бик соң басалар. Нәкъ шуның өчен, хәзер, операция өстәлендә ятучы Әсәлне түгел, ә минем янымда хатадан әрнүче Хәдичәне хөкем итәләр. Кызының дуслары белән беренче сыйныфка бара алмавы, әнисе күрмәгәндә генә качып туңдырма ашап, салават күперенең бар төсләре кергән колготкиларны кия алмавына да Хәдичә, бары Хәдичә генә гаепле булачак...

Ләкин бу сүзләрне Әсәлнең әнисенә әйтергә минем көчем җитмәде. Ул аларны үзе күптән аңлый иде... Шуңа да карамастан, аның ягына борылып: «Бу тормышта гаделлек белән бергә гафу сорау да бар», – дидем. Шул сүзләрне әйтүгә, коридорның аргы башында ишек ачылды. Кояш нурларыннан сузылган юл буйлап килүче ак халатлы кеше Әсәлнең табибы иде.

# ЧУЛПАН ХАҖИЕВА. «ӘСӘЛЕМ...»

Хикәя беренче җөмләләреннән үк үз эченә алып кереп китә. Бер яктан, *«Җирнең кайсы гына ноктасында булсам да, гел бер үк кешеләрне күрәм»,* дигән башлам укучыга интрига бирә: аның логик яктан дөрес булмавы акылны-фикерне вариантлар эзләргә этәрә. Шуның артыннан ук татарча «сөйләүче» «мин»нең Испаниядән булуын хәбәр итү кызыксыну уята: фәндә моны көткән белән туры килмәү эффекты (көтү горизонтының акланмавы), дип атыйлар. Аны өйрәнүче махсус фән тармагы да бар – ул рецептив эстетика дип атала.

«Әсәлем...» – романтик хикәя. Уйлап табылган автор-хикәяләүченең биографик автор белән тәңгәл килмәве һәм «текст эчендә текст» – Хәдичәнең көндәлек дәфтәре пәйда булу иҗат методы ягыннан башка юлга кереп китү мөмкинлеге булганлыкны: җиңел генә күпкатламлы постмодернистик хикәягә әйләнә алуын  да искәртә. Әмма монысы мөмкинлек булып кала.

Хикәянең сюжеты катлаулы түгел. Әти-әниләре белән Испаниядән Казанга күчеп килгән Назлы үзенә охшап җитмәгән фатирда көндәлек дәфтәренә тап була. Аны укып, Хәдичә һәм аның нәни кызы Әсәл, кызның авыруы турында белә. Бу тарих аны тетрәндерә. Назлы аларны эзләп хастаханәгә бара. Соңгы: *«Кояш нурларыннан сузылган юл буйлап килүче ак халатлы кеше Әсәлнең табибы иде»,* җөмләсе бу ике кеше язмышын өметкә юнәлтә. Гомумән, йомгакның шулай ачык, билгесезлек ноктасындарак калуы отышлы: ул әсәрне тормышчанрак итә, уйландыра.

Шушы сюжет эчендә Ч.Хаҗиеваның гаять матур табышлары бар. Беренчедән, Хәдичә тарихының «гөнаһ-җәза» структурасында бирелүе текстның фәлсәфи һәм эмоциональ тирәнлеген тәэмин итүче алымга әйләнә. Хәдичә кызына килгән авыруны үзенең башта баланы авыр йөк кебек кабул итүе белән бәйли. Башта – аборт ясатырга, аннары баласыз гаиләгә биреп җибәрергә ниятләвен, кызын акрынлап кына ярата башлавын сөйләгәндә, Хәдичәнең: *«Кызым карынымда чакта әйткән сүзләрем, аннан котылу теләге эзсез генә онытылыр, минем арттан кире кайтмас, дип ялгышканмын. Әсәлем менә үзенең кирәксез бала булганын тоеп, хәзер ике дөнья арасында көрәшә. Үткәннәргә кайтып булса, мин балама ул әле әфлисун кадәр генә булганда да, үземнең мәхәббәтемне биреп, ни дәрәҗәдә кирәк икәнлеген көннән-көн аңлатып килгән булыр идем. Ләкин хәзер соң инде. Һәм бар гаеп миндә генә»,* дигән сүзләре бала авыруы фаҗигасен икеләтә тәэсирле итә.

Шушы сөйләшүне йомгаклап, Назлы-хикәяләүче нәтиҗә чыгара: *«Бу тормыш, чыннан да, гадел икән шул. Синең әйткән һәр сүзең, һәр теләгең, хәтта уйларың да хөкемсез калмаячак. Еллар үтеп, кылган начарлыкларың өчен әле һаман җавап бирмәгән булсаң, димәк, киләчәктә сине тагы да авыррак җәза көтә. Ә әни кеше өчен баласының бер гөнаһсызга авырлыклар кичергәнен күрүдән дә яман сынау була аламы? Мөгаен, юктыр. Җәзада ниндидер дөреслек сизеп, кеше үзен тынычландыра да аладыр, ләкин синең өчен балаң интеккәндә, дөреслек турында сүз алып барып та булмый шикелле. Баланың язмышы әти-әни кулында. Һәм аның белән уенчык кебек уйнарга беркемнең дә хакы юк. Киләчәктә балаңның күзләрендә бәхет күрергә теләсәң, син башта аңа үзең лаек булырга тиешсең. Бу тормыш гаделлек өчен беркемне дә кызганмый...»* Әлеге нәтиҗә берничә фәлсәфи фикерне үзенә туплаган: 1) Бу тормыш гадел: һәр гөнаһ яки начарлыкка җәза бар. 2) Бала язмышы олылар кулында – аңа лаек булып яшәргә кирәк. Хикәянең ахыры тагын бер фәлсәфи канунны калкуландыра: гөнаһ өчен җәза үтәү генә түгел, гафу сорау да гаделлекне торгызырга сәләтле.

Самими һәм гади тоелсалар да, бу кануннар әхлак-нәсыйхәтне үз күргән татар әдәбияты традицияләрендә, шул ук вакытта Ч.Хаҗиеваның тормышка фәлсәфи карау сәләте турында сөйләп торалар. Аларны Назлы сүзләре буларак аерып чыгармау отышлырак булачагын да әйтергә кирәк. Беренче канун үзе дә тексттан аңлашыла: аны тагын бер тапкыр кабатлау юлы белән дә укучыга җиткерергә мөмкин булыр иде. Икенчесен исә көндәлек ярдәмендә яки шулай ук Хәдичә сүзләрендә белдерү мөмкинлеге бар. Чөнки әсәрнең иң башында, Назлының үз ситуациясенә бәйле, *«Бердәнбер кызларының язмышы белән уенчык кебек уйнагач»* сүзләрендә мотив күренеп китте инде.

Текстта уйнатылып бетмәгән тагын бер табыш – көндәлекнең Хәдичәнең әнисенә атап язылуы. Ана-бала мөнәсәбәтләрен Хәдичә-Клара, Әсәл-Хәдичә, Назлы-әнисе кебек янәшәлекләр ярдәмендә күрсәтү яңа фикер-нәтиҗәләргә алып чыгарга сәләтле.

Тагын бер үстерергә мөмкинлек булып та өзелеп калган табыш – Ч.Айтматов геройлары белән аваздашлык. Сирәк очрый торган Әсәл исеме генә түгел, бәлки Хәдичә дә – Ч.Айтматовның «Тополёк мой в красной косынке» повестена ишарә ясый. Повестьтагы мәхәббәтне югалту тарихы да, аның поездда журналистка сөйләнгән хикәя кебек язылуы да, баланың атасын белмәве дә, тагын кайбер детальләр без карый торган хикәя белән аваздаш тоела. Әмма, исемнәрдән тыш, хикәядә бу аваздашлык файдаланылмаган (бәлки, исемнәр дә очраклы сайлангандыр...) Гәрчә әсәрне тирәнәйтү өчен мондый янәшәлекне уйнатырга булыр иде.

Шуның белән бергә, укылышны тәэмин итсәләр дә, хикәядәге күп кенә күренеш-детальләр сюжет белән ярашып бетми. Беренчесе – Назлының Испаниядән кайткан кыз булуы. Хикәя башында интрига ясаган әлеге факт, кызның әти-әниләре турындагы мәгълүмат кебек үк, алга таба әсәрдә катнашмый. Гаилә Испаниядән түгел, Казанда яшәп, зуррак фатир сатып алган булса да, әсәрнең төп эчтәлеге үзгәрмәс иде. (Бу очракта, эленеп торган мылтыкның атарга тиешлеге хакындагы һәркемгә мәгълүм хакыйкатьнең әле дә кире кагылмаганлыгын искәртик.)

Хикәя паркта инстаграмга кую өчен фотога төшеп йөрүче яшьләр күренешеннән башлана. Аларның да чит кеше кайгысына битараф түгеллеген ассызыкларга бер дигән мотив! Текст башындагы кешеләрнең бер төрле булуы турындагы фикерне хастаханәгә барганда очраганнарга карап кире кагу кебек!

Хикәядә хикәяләүче-мингә карата психологизм алымы – үзанализ куллану әсәрнең тәэсирлелеген арттыра. Хәдичә образына карата да автоматик язу алымын куллану отышлы булыр иде. Бу персонаж күбрәк тышкы факторлар аша тергезелә. Кайчакта мондый тормыш сынаулары артып киткән кебек тә тоела. Мәсәлән, авырга узган яшь хатынның эштән куылуы *(«Инде түгәрәкләнгәнем күренә башлагач, мине эштән кудылар. Журналлар бары тик матур гәүдәле модельларны гына ярата икән») –* сериалларга тартым ясалма булып китә.

Гомумән алганда, хикәя укыла. Әсәр укучыны үз эченә алып керә, ахырга кадәр билгесезлектә тота. Шул ук вакытта әдәби алымнар, аларны урынлы файдалану, кабатлауларга, символларга, табигать күренешләренә мөрәҗәгать итү ягыннан осталык җитмәү үзен сиздерә. Тел-сөйләм мәсьәләсендә, каләмнең өйрәнчек булуы һәр җөмләдә диярлек күзгә ташлана. Әйтик, *«үзен иртәнге кояш нурлары һәм ямь-яшел хәтфәдәй чирәмдә фотога төшерергә»* фразасы *«үзен иртәнге кояш нурларына коенган ямь-яшел хәтфәдәй чирәмдә фотога төшерергә»* кебегрәк булганда дөрес. *«Әлеге паркны биләп алган кешеләр»* дигәндә *«биләп алган»*ны кешегә карата кулланырга кирәкмәгәнлекне әйтергә мөмкин. Матур кыз баланың күзләрен *«шар кебек зур»* дип бәялисе дә килми. Һ.б., һ.б.

Әмма сюжет кора, интрига ясый белүе Чулпан Хаҗиеваның язучылык сәләтенә ия булуы турында да сөйли. Уңышлар аңа.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*

*«Шифалы куллар» әдәби конкурсы*



Фирүзә
Җамалетдинова

# «...КИСМӘ БЕЗНЕҢ КАНАТЛАРНЫ!»

хикәя

Әни янына без ай яктысында барабыз. Терлек-туарны карап, йорт эшләрен тәртипкә китереп, бушагач, дөресрәге. Әниебез ничә айлар инде хастаханәдә ята. Күңелебез тулы борчу. Кешеләр хәсрәтле йөзебезне күрмәсен, дип тә бугай, әти сәфәрне кичке якка калдыра. Безнең хәлне ай гына белә шул... Ай күкләргә сыймаслык дәү. Шомландыргыч яп-якты үзе.

Барганыбыз саен әни безне итәгенә утырта да:

– Балакайларым, айга карап сорагыз, айга карап теләгән теләкләр кабул була, дип әйтә торган иде борынгылар, – ди. Моны бер дә исебездән чыгармыйбыз. Тукранбашлы, күкчәчәкле хуш исле арбага менеп утыргач та күккә, чиксез билгесезлеккә төбәлеп:

– Аллакаем, терелт безнең әниебезне! Аллакаем, безгә әнидән башка бик кыен, ишет безне! – дип ялварабыз. Бу мәлдә минем күзләремнән мөлдер-мөлдер яшь тама. Тамган саен кул сыртымны пешереп алгандай тоела. Моңарчы игътибар итмәгәнмен: күз яше ачы гына түгел, кайнар да икән әле. Авыргач, әни үзе дә Аллаһы Тәгаләне бик еш искә төшерә башлады. Бер баруда әйтеп тә куйды:

– Бәхетсез чорга туры килдек шул, балакайларым. Комсомол уставы ятлатканчы, дога ятлатсалар, моңарчы Илаһым әллә нинди яхшылыклар биреп бетергән булыр иде, – диде.

Юл озын. Юл озак. Арба дыңгыр-дыңгыр дыңгырдый, тәгәрмәчләре көзгедәй ялтыраган иске шома юлда алпан-тилпән чайкала. Тәгәрмәчләр, арба тавышы, атның вакыт-вакыт иелгән башын күтәрә төшеп, пошкырып-пошкырып куюлары безнең бу салкынча караңгы кичтәге борчу-хәсрәтләребезне тагын да тирәнәйтеп җибәргәндәй тоела. Башка әллә нинди авыр уйлар керә. Аңласа, моны, авырып, әнисе хастаханәгә эләккәннәр генә аңлыйдыр, мөгаен. Ай сагышлы тыгыз сарылыкка чумырып, арбабызга тагылып, бер тотам да калмыйча артыбыздан атлый. Ул үзе дә безне кызганадыр шикелле. Район хастаханәсе авылдан ун чакрым тирәсе арырак. Кайчакта, мәңгелек юлга чыкканбыздыр кебек тоела. Ә юл һаман озыная гына бара...

– Яңа өй төзеп кергәч кенә, тормыш бетәр микәнни, балалар? – дип куя әти, үзалдына сөйләнгәндәй.

Инде безгә әти үзе дә үзгәчәрәк күренә. Шул арада аның йөрешләре

авырайды, адымнары салмакланды, маңгаена җыерчыклар уелды. Көлемсәр иреннәре дә югарыбрак китте шикелле. Әни сәламәт чакта аның елмаюы да, сөйләшүе дә башкача, серле җылылык белән өртелгән булган икән. Шушындый көләч халәте кырыслыгын да җиңә иде төсле.

Ә өебез чиксез матур безнең. Шәһәрдән тәрәзәләргә дәү-дәү чәчәкле пәрдәләр кайтартты әни. Шуңа да кергән бер кеше: «Сездән чыгасы да килми», – дип, йортыбыздагы гүзәллеккә мөнәсәбәтен белдерә. Ә үзебезгә хәзер өйнең бер яме дә калмагандыр сыман. Чөнки әнисез яңа өй дә шомлы, хәтта өстәлдәге самавыр да моңсыз-ямансу булып, тынсыз-өнсез тора бирә.

Яңа өйгә күчтек кенә әле югыйсә. Күрше Мәфтуха апа кергәндә, әни бертапкыр болай дип тә әйтеп куйды:

– И җаныем, шушы йортны төзеп-корып чыгар өчен тавыкка изгәнне күбрәк ашарга туры килде шул... Балаларымның да тамакларын кыстым... Әллә шуның золымы төште инде... Азау тешне алдырып кайтканнан бирле хәлсезләнеп торам әле...

Плитә өстендә һаман тавыкларга вак бәрәңге пешеп утыра. Моны теләгәнчә ашарга була. Бәрәңге бер дә туйдырмый, ди әни.

– Тамакны да туйдырмый, – дип кет-кет көлә күршебез.

Дөрес, мәктәптә миңа ак күмәч тә эләгештергәли. Тик әни монысын белми шул... Без Рафил белән бер партада утырабыз. Аның әнисе ипи пешерүче булып эшли. Аларда он иркен. Ул көн дә ак ипи алып килә дә һәр дәрестә парта астына төшеп китеп, берәр телемне урнаштырып менә. Укытучы апа:

– Син нишлисең анда, Сабиров? – дип дәшкәндә, ул телем инде тамак төбен төерләтеп, ашказанына юл алган була. Шулай да, башта, һәр көнне беренче тәнәфестә үк ипи янчыгын парта өстенә чыгарып салып, иң тәмле кытыен миңа кубарып бирә. Мин дә артыгын чыдый алмыйча, апа борылган арада, әз генә сындырып аны авызга кабып куям. Шунда, үзәгемне өзеп, әнием искә төшә. Әнием пешергән икмәк, кара оннан булса да, тагын да хуш ислерәк иде ләбаса...

– Күрче, нәләт төшкерене! – дип куйды әти, татлы уйларымнан бүлеп. Юлыбызны көлтә койрык – төлке кисеп чыгып бара икән. Бездә, җырдагыча әйтсәк, төлке уйный торган орлар бар. Шуңа авылыбызда каз көтүен көтәләр. Төлкеләрнең яман холкын халык сөйләп бетерә алмый. Их, белсәләр иде күпме нәфрәт җыйганнарын көлтә койрыклар! Төшмәсләр иде алар безнең авылга. Тимәсләр иде казларыбызга. Әйләнеп тә карамаслар иде, билләһи. Ә бит алар турында башка сыймаслык гыйбрәтләр дә ишетелгәли. Имеш, бер баланы җиләккә барган җиреннән төлке алып киткән. Караңгы урман авызында комач кызыл нәни сандалилары гына торып калган ди бахырның...

Югыйсә, безнең авылда тирә-якка даны таралган аучы да яши. Ни карыйдыр ул Сафа абзый. «Оча торган кошка атмыйлар», – дип өйрәтә һаман малайларны. Ә төлке оча да белми ләбаса. Ник атмыйдыр ул аңа? «Синең күзең – үрдәктә, минем казлар – йөрәктә», – дип үртәргә ярата аны көтүче Хәмит абый.

Күршебез – каз көтүчесе Хәмит абый һаман да өйләнмәгән егет әле. Бераз аксаклап атласа да, аны казлар да, кешеләр дә ярата. Кайбер авазларны, сүзләрне дә дөрес әйтә алмый. Монысы да килешеп кенә тора үзенә. Кайчак бармаклары да ярдәмгә килә. Аның бу гариплегенең үз тарихы бар, диләр. Хәмит абыйның сабый чагына бәйле ул. Алты ай дигәндә аңа нидер булган: көн елаган, төн елаган. Шунда күрше карчыгы әнисенә: «Мөгаен, моны җен алыштыргандыр, белми калгансыздыр», – дигән. Имеш, баланы кыйнарга кирәк икән. Шуннан җен үз баласын кызганып кире алып китә ди...

– Елап өйне туздырды, бәгырькәем, – ди Мәфтуха апа әле дә. Барыбер дә аның тәненә бер тамчы ит кунмаган, зәгыйфьлеге белән һаман борчыган да торган. Кемдер шулчакта Мәфтуха апага: «Казанда балалар йорты бар икән, шунда биргән нарасыйларны бик тиз дәвалыйлар да икән», дигән хәбәр алып кайткан. Иртән баланы калага илтеп куйганнар, кичкә Мәфтуха апа авыша башлаган... Ана кеше баласыннан башка яши аламыни инде?

Шул ук машина белән төнлә барып та алганнар Хәмит абыйны. Барыбер дә табиблар биреп җибәргән бер янчык дару аны тиз рәткә керткән...

...Ул, ел да иртә язда каз көтүен алып чыкканда, бер дә егетләргә охшамаган була: сакал-мыегы кырылмаган, чалбарына ышкып пәке кайрарлык. Ап-ак тәнендә күмгүк кан тамырлары күренеп тора, ач яңаклы, буйчан, үзе бик ябык. Симез төлкеләрдән курыкмыйча, ничек каз көтүен ышандырып алып чыгып китәдер? Хәер, иптәшкә никель быргысы бар инде барын. Шуннан куркалардыр көлтә койрыклар. Сәер тавышны казлар да таный. Иртән бер кычкыртып җибәрдисә, йортта шау-шу башлана: кайсы канат җилпи, кайсылары каңгылдаша, ата каз исә бии-бии капка ягына юнәлә. Аңа башкалар иярә. Аннан капкалар ачылып китә, һәм урам өстенә әкрен генә аклык күтәрелә. Салкынча җиләс һавада гүя тын гына ап-ак болытлар йөзеп бара. Әйтерсең, әллә кайда, ерак-еракта булып күренгән ап-ак болытлар кисәк-кисәк вакланып коелган да, җиргә үк төшеп җитә алмыйча, һава белән ике арада эленеп калган. Әйтерсең, болытлар канат кагына...

Олы көтү, ягъни сыер-сарыклар болынга киткәч, әнә шулай безнең урамда каз туе башлана. Бераз арырак, кибет янында аларны Хәмит абый көтеп тора.

Ул күбрәк казлар белән сөйләшә:

– Әйдә, җәй канатыңны! – ди, быргысын болгап. Һәм, кулларын алга сузып, аларга табан һаваны өткәндәй итә:

– Очтык әйдә, очтык, дим...

Әйтерсең, үзе дә казлар затыннан.

Юк, юк, һич тә казлар затыннан түгел, чөнки Хәмит абый бернидән дә курыкмый, әни әйтмешли, җәйге түгел хәтта көзге күкрәүләр дә сискәндермидер аны. Моны минем күргәнем бар. Яңгыр коеп яуганда, яшен яшьнәп, күкләр тетрәп-тетрәп киткәндә дә, кешеләр «бисмилла» әйтеп чәч-башларын сыпырганда да тып-тыныч карашлары белән казларга сынап карап тора ул. Тегеләре исә шөлли, күкрәүләр тынганчы шым гына, өнсез торалар да аннан гыйгылдаша башлыйлар. Озын муеннарын алга ук сузып, Хәмит абый янына җыелалар. Яклаучы, саклаучы бер Аллаһы Тәгалә икәнне аңлый көтүче абый. Ә казлар моны кайлардан чамаласын соң?

Хәмит абый быргы кычкыртудан ары берни белмәсә дә, аның каз көтүчесе булып йөрисе килми, тик хәерчелек бу кабаладан бер генә адымга да ары чыгармый. Чабудан ычкындырмый.

– Әти дә үлеп китте бит, ичмасам, – дип куя ул кешеләр белән сөйләшкәндә.

Әтисе сугыштан алып кайткан яраларыннан мантый алмаган, диләр. Ә әнисе Мәфтуха апа авыл кешеләренең эремчек-сөт ише әйберләрен күрше авылдагы базарда сатып йөри. Шуннан әҗерен үзенә дә калдыра. «Чәйнәгән синеке түгел шул әле, йоткан синеке», – дип куештыра сәүдәсе бармаган көннәрдә. Ул вакытсыз картайган, бөкрәйгән, карчыкларга охшап тора. Чал чәчләре агып чыккан. Тешләре дә коелып беткән. Үзе бер дә аптырамый: «Тешсез килгән, тешсез китәргә кирәк инде бу дөньялардан», дип кенә куя. Һәм гел бер җырны җырлый:

Каптыр, каптыр туныңны,
Катырыплар киярсең.
Өлешеңә туры килсә,
Карт булса да сүәрсең.

Ире үзеннән күпкә олырак булса да, аны бик сөйсә дә, сугыштан көтеп алса да, өлешенә туры килгәне белән озак яшәргә насыйп булмаган шул. Башка юл таба алмыйча, чарасызлыктан бәргәләнгән кешеләр тагын башка бар микән безнең авылда? Юктыр да. Алар авыл өчен дә үз кешеләр түгел, кайлардандыр читтән килеп урнашканнар. Читтән килгәннәрне безнең авыл читкәрәк тибәрә шул. Үзләре дә җылылык эзләп артыгын кешегә елышмыйлар кебек, ике яклап салкын, үтәли җилгә чыгып баскан затларга охшап тик торалар, нигәдер.

Хәмит абыйның сеңлесе Сәринә белән без бер сыйныфта укыйбыз. Аны апа «гөмбә» дип орыша. Сәринә курка. Еш кына парта асты юпь-юеш була. Аннан шуны аягын әкрен генә шуытып, төп салынган киез итегенә сеңдереп бетерә...

«Хәерче балаларын укытучылар да аямый шул. Дәрес белми, имеш... Авылда каласы бала белән алай ук кыланмасалар да ярар иде... Нигә канатларын кисәргә инде, җә?» – дип үртәлә Мәфтуха түти.

Апа урысча берәр сүз әйтә дә безгә кабатларга куша. Сәринәне такта янына ук чыгарып бастыра.

– Мел, – ди ул, аңа усал төбәлеп. Сәринә «мял», дип кабатлый. Апа чыдый әле. Чигәсендәге күренеп торган зәңгәр кан тамыры гына тартышып куя.

– Мел...

– Мял.

Апаның йөзе үзгәрә. Кулы дерелди башлый.

– Мел, – дип кабатлый ул, янә тавышын күтәрә төшеп.

– Мал...

Апаның сабырлыгы сына, кулындагы акбурны идәнгә атып бәрә.

Икенче дәрестә тагын аны такта янына чакыра.

– Колхоз, – дип кабатлый бу юлысы.

– Калкуз.

– Колхоз.

– Калхуз.

Тагын дәреснең рәте китә. Дәреслек язучыларын да әйтер идем инде... Беткәнме сүз урыста? «Папа», «мама» җитмәгәнме, җә, авыл баласына?

Сәринә генә түгел, без беребез дә тере урыс күргәнебез юк. Ә аларның ничек сөйләшкәнен күз алдыбызга да китерә алмыйбыз. Хәтта, такта янына табан атлаганда, ни шаян Рафил да чарасыз кала:

– Уф, йөрәгем, такта чәй,
Сорамыйдыр башка чәй,

– дип уфтана-уфтана, авырлык белән кыймылдый. Әмма безгә аның җан әрнүе бик яхшы аңлашыла. Шулай да ул Сәринә кебек курыкмый. Апа куйган икелене сөйрәп ашханәгә чапканда, бөтенесен оныта. Анда безгә сөт бирәләр. Стаканнарны кулга тотуга: «Мин кичә фермада күрдем, бу битунның авызында алты мәче утыра иде сөт ялап, – дип, хәтта үзе дә ышанырлык итеп сөйләвен белә. Шуннан сөт салучы апа: «Лыгырдыкның лыгырдыгы, арт капканың шыгырдыгы»,– дип көлеп калса да, без сөтне этеп кенә куябыз да китеп барабыз. Их, күрмәгән булсачы ул бу мәчеләрне!

Апа да аның шуклыгын, шаянлыгын ярата кебек.

Орыша-орыша да үзе дә көлә башлый.

Хәер, безне өйдә дә орышып кына торалар. Беркөнне мин әниемне уйлыйуйлый, чишмәгә төшеп, керләр чайкап мендем. Кайтсам, әтиемнең сеңлесе Хәния апа әнинең хәлен белешергә килгән. Ул минем тастагы керләремне бармак очына гына элеп карады да:

– Сабыны калган бит, үскәнем, бар, кабаттан арулап мен, ату кияүгә дә алмаслар үзеңне, – диде кыргый кырыслык аша. Мин аның кыргыйлыгына күнгән, чөнки ул җае чыккан саен: «Кәнфитләнеп торырга... без сезнең кебек шикәр-кәнфит ашап үсмәдек», – дип кенә җибәрә.Әйтерсең, балачагы сугыш чорына туры килгәнгә мин гаепле. Хәер, Гитлер үзе исән булмагач, бу сүзләрне тагын кемгә әйтсен инде ул? Каһәр-рәнҗеш шулай чылбыр булып чордан-чорга сузыладыр шул...

– Кияүгә чыкмыйм да әле мин, – дип авызымны турсайтсам да, киттем тасымны күтәреп су буена. Чөнки олылар сүзенә колак салмау начар гадәт. Бигрәк тә Хәния апаныкына. Ул артымнан: «Су һәрнәрсәне ак итәр, бары йөз карасын гына ак итә алмас», дип сөйләнеп калды.

Гасырлар буена дөнья пычрагын юып яшәгән ару чишмә ул безнең. Суы мул: әтиемнең тун җиңе калынлыгында дисәм, дөрес булыр микән? Кышынҗәен аның тирәсеннән кеше өзелми. Чебен-черки шул тирәдә бөтерелә. Өрфия өередәй әле өскә күтәреләләр, әле җиргә якынаеп очалар. Күңелләренә шунда юаныч табалар, күрәсең.

Керемне салуга, чишмә кулларымны чемердәтеп алды, аннан бөтен тәнемә суык таралды. Янәдән әнием искә төште. Их, әни, син сау-сәламәт булсаң, безне бу юлларда йөртмәс идең бит. Ару чайкамагансың, имеш... Апаны да әйтер идем инде...

Менә шулай өйрәтергә ярата ул Хәния апа. «Көянтә аша сикермә, ботыңа кыярак чыгар». «Ашаганда аягыңны селкетмә, шайтанны тирбәтәсең», тагын әллә ниләр... Берәр әйткәнен тыңламый кара! «Тибә торган атны аны кеше арасында йөртмиләр, аерым ябалар. Тибүдән кала тешли дә торган була бит әле ул, каһәр...» – ди. Димәк, киресен әйтергә ярамый. Кеше рәтеннән кемнең төшеп каласы килсен соң!

Хәния апаның мине су буена җибәрүе әйбәт тә булды әле. Мин агымсуга төбәлеп, Аллаһыдан әниемә һәм аны дәвалаучы табибларның барысына да сәламәтлек, мәрхәмәт сорадым.

Ә Хәния апага бер тамчы үпкәм дә калмады.

Әнә, Сәринә әнисенә иптәшкә кыш буена чана тартып урманга менә, чыбык-чабык җыеп кайта. Тик аннан җылы төшә микән ул иске өйләренә? Укытучыны монысы кызыксындырмый шикелле. Дәрес белмәгәне өчен теле белән җәзалый. Әллә сипкелле булганы өченме? Безнең сыйныфта бер генә сипкелле кыз да юк башкача. Минем әни Сәринәнең сипкелләрен кояш үпкән эзләр ул, ди. Димәк, аны укытучы апа яратмаса да, кояш ярата! Кояш бит әле югарырак, кояш бит әле бездән өстәрәк тә!

– Әтине дә фашистлар җәзалаган, – дип куйды ул миңа бер тапкыр тирән дулкынлану аша. Бабасы да репрессия корбаны булган икән. Монысын Мәфтуха апа сөйләде. «Бер гаепсезгә адәм баласының маңгаена терәп атсыннар әле, белерсең аннары кемгә ышанырга», – дип куйды, тирән йөрәк әрнүен сиздереп. Кешеләргә ышанмый ул хәзер. Ә бит әтисенең атылганын үзе дә бик соң белгән. Әниләре һаман аларны: «Әнә теге очка барыгыз,

әтиегезне каршы алыгыз, – дип, үзе дә хыялына ышана язып, һаман өйдән куган. «Тамак ач. Кузгалак ашыйбыз. Ул исертә. Әтиләрне каршыларга йөгерәбез аннары:

Ачы кузгалаклар җыйдык
Зәңгәр тәлинкәләргә.
Алла боерса, әткәй кайтыр
Күзге ярминкәләргә...

– дип җырлыйбыз. Көтә-көтә күз алмаларыбыз агып чыгардай була», – дип сөйли безгә.

Тик әтиләре кайтмый...

Мәфтуха апа әллә бар дөньяга ачуы килүдән, әллә тормыш авырлыгыннан, әллә түбәнсенүдән: «Без бәкедәге б...к кебек, батмыйбыз да, катмыйбыз да», – дияргә ярата. Миңа ошап бетми, әлбәттә, болай әйткәне. Телдә әллә башка гыйбарәләр беткәнме?

Димәк, безнең язмыш шуннан диюедер Сәринәнең дә. Без аның белән җәй буе казларга көрпәгә кушып болгатып бирергә әрекмән яфрагы, кузгалак, кычыткан җыябыз. Шул чакта Сәринә миңа әнисенең гомер буе җырлый торган җырларын җырлый.

...И Ходаем, бирмә хәсрәт,
Биргәнең җитәр инде...

– Әйдә, без ничек тә сабыр итәрбез, казларыбыз гына исән булсын, – дип куя ул, артыгын арып киткәч.

Казлар яз буена безнең караңгы карават астында утыра торгач, тәмам ябыгып-талчыгып, бетләп бетәләр. Алар оя тирәсенә якын килгәнне дә өнәмиләр, якыная башласак, чәлтерне хәзер эләктерергә генә торалар. Язын балтырына кара төшмәгән кеше калмыйдыр да, мөгаен, авылда.

Безнең нинди җаваплы эш башкарганны күрмисез мәллә, янәсе... Кояшлы өйдә, якты тәрәзәләрдән кергән яктылыкка коенып йөрүегез җитмәгән, безнең тынычлыкны бозасыз. Их, сезне!..

Йомры йомшак бәбкәләр хакына күгәргән аяклар белән йөрсәк тә, әнкә казга сүз әйтмибез, түзәбез. Чыдарга кирәк чөнки.

Көтү чыкканчы әле бәбкәләрнең канатлары да җүнләп калыкмаган була. Хәер, йомры йомырка шулай җан иясенә әверелсен инде! Аларның тишелеп чыккан мәлләре үзе бер тамашага әйләнә. Менә йомырканың бер очы ватылып китә. Шуннан нәни бәбкәнең борын төрткәне күренә. Ул әле чыгарга ашыкмый, бу дөнья дигәннәрендә һава торышы ничегрәк икән дигәндәй, тишектән борын очын гына кыймылдатып тик тора бирә. Бераздан кабыктан арынырга кирәклегенә төшенгәндәй була, куышын вата-вата, күзләрен ачар-ачмас кына әйләнә-тирә белән таныша. Тәне юпь-юеш, үзе дер-дер калтырый, йомыркадан тыш та тормыш барлыгын белүенә бер дә сөенми төсле... Бераздан тәпиләренә баса, йоннарына сап-сары төс иңә. Үзе һаман алпан-тилпән килеп, артка чүгә-чүгә тәпили.

Ә көзге якта алар танып булгысызга әверелә. Көтү кайтканда урам әкият дөньясына әйләнә. Капкалар ачыла: алар аклыкны кабул итәргә әзер. Җирдән күтәрелә-күтәрелә аклык ташый. Һәр капкадан өерелеп болыт өере керә бара, күк белән җир урыннарын алыштыргандай тоела. Гүя болытлар канат

кагына. Бу сокландыргыч күренешкә таң калып торган чаклар да бар иде бит. Әни сәламәт чакта, хәтта бәбкә чыгаруның бер авырлыгын да сизмәгәнбез. Ана каз ата казга сер түгеп кергән арада, мин, оядагы йомырканы колагыма куеп, әле дөнья күрергә өлгермәгән бәбкәнең йөрәк тибешен тыңлап торырга ярата идем. Дөньяга яңа җан яралганын тою, аның йөрәк тибешен ишетү яшәешкә, тормышка нисбәтле тискәре уйларымны таратып җибәргәндәй тоела иде. Тишелеп чыкканнарының томшыгын сузып ничек сулаганына да күп тапкырлар шаһит булдым. Бөтенесе дә гади генә, гадәти генә иде кебек. Хәмит абый кулына тапшырганчы, бер кыенлык белән очрашканны да хәтерләмим. Ә көтүчегә тапшыргач, өстән йөк бөтенләйгә төшеп китә. Аннары һәммәсенә Хәмит абый җаваплы. Әйе, әйе, көтүче буласы килмәсә дә, ул җаваплы!

Ә Хәмит абыйның каз көтүчесе буласы килмәве тагын бер гадәтеннән күренеп тора: ул өзми-куймый тәмәке тарта. Бакчаларында үскән үләнне газета кәгазенә төрә дә һаман төтәтеп йөри. Көтүче булып киткәнче, тәмәкене бар дип тә белми иде, диләр. Әтиләре үлү хәсрәтен дә тәмәкесез күтәргән бит инде югыйсә... Ә миңа Хәмит абый көтүче булып тугандыр сыман тоела, чөнки ул безнең урамдагы һәр бәбкәне таный. Кич кайтканда, капка төбендәгеләргә әйтә уза:

– Бүген сезнекеләр басуга кыякларга гына тордылар, җелегемә төштеләр, мур кыргыйлары, – ди. – Көрәйделәр. Малның көрлеге – көтүчедән инде, хәер...

Яки:

– Сезнекеләр судан чыкмады, бетләре шунда коелып калгандыр, ахрысы...

Яки:

– Казлар күбрәк сыңар аякта тордылар, иртәгә әбизәтельне суытачак, – дип күзәтүләре белән уртаклаша.

Менә шундый ул Хәмит абый! Һәм аны алда бәхет көтәдер төсле. Чөнки көтүче абыйның йөрәге саф. Мондый кешеләр бәхетсез була алмый. Артыгын гади дә. Тик безнең авылда чамасыз гади затларны бик исәпләмиләр, җүләрсетебрәк карыйлар. Җүләр дип беләләр дә бугай. Монысы кызганыч, әлбәттә.

Мин үз-үземә «Ни өчен?» дигән сорауны бирми калмыйм. Ни өчен аларның әтиләре үлгән? Һәм күңелемнән җавап ишетәм: «Сугыш гаепле!» Ни өчен аларның әниләре шулай бөгелеп төшкән? «Сугыш!..» Ни өчен минем сыйныфташым Сәринә ятим? «Сугыш!» Кемнәр уйлап тапкан бу сугышны җир өстенә? Ник? Ә бит балаларга әти кирәк. Мәфтуха апаның да ялгызына тормыш тарту ничек кыен әнә.

Мин беләм, Хәмит абыйның карт әнисе дә сугыш корбаны. Аның яхшы кеше икәнен бөтен авыл белә. Андый кешеләрне Аллаһ үзе дә таный ди, имеш. «Бәндәләрем яхшы дигән кешене мин ничек начарга чыгарыйм?» дип әйтә ди... Әнием шулай сөйли.

Безнең казларны да Хәмит абый көтә. Көтүчене үз итсә дә, әтием кинәт казларны бер дә яратмый башлады, «теге чуваш хатыннары» дип кенә җибәрә, чөнки ул аларны әле әнием чирләгәнче, чуваш авылына барып үзе алып кайтты. Чувашлар эшчән халык, алар гомергә безнең авылны каз, сарык, бозау белән тәэмин итеп торалар. Әнием белән бер оя каз утыртып, күп итеп бәбкә үстерергә хыялланганнар иде бу юмарт җәйдә. Тик якты хыяллары мизгел эчендә чәлпәрәмә килде. Казны безнең карават астындагы үргән оясына урнаштыргач та әнине больницага алып киттеләр. Әни юклыкны каз да сизде. Төнге өчтә үк уяна да кыбырсый башлый. Кайчак оясыннан сикереп

төшә. Җайлап яңадан кертеп утыртырга, аны һаман саклап торырга кирәк була башлады. Тик минем өзелеп йоклыйсым килә. Әни киткәннән бирле, нигәдер, кыйнап ташланган кешедәй йөрим. Әтинең дә тормышта бер гаме дә калмады. Еш кына көчле-кодрәтле әти, мескен кыяфәттә, бөгәрләнеп, учактагы утка карап утыра. «Әниегез үлә», – ди дә киң җилкәләрен сикертә-сикертә яшь сыга. Аннары: «Йа Раббым, кисмә безнең канатларыбызны! Терелт безнең әниебезне, табибларыңның җаннарына, кулларына көч иңдер!» – дип битен учлары белән каплап күккә төбәлә. Чөнки әтиемнең соңгы баруында әнине каты авырулар янына, өченче каткка күчергәннәр, ул астагы катка әти белән күрешергә дә төшә алмаган. Югыйсә, әни беренче катта ятканда, кич төнгә авышканда барсаң да, тәрәзә аша сөйләшеп кайта торган идек.

Кисмә канатларыбызны... Бу җөмләнең төбенә-тамырына ук төшеп җитә алмасам да, әтинең әрнүен, аның мине дә кызгануын чамалап, тоеп торам. Үзем дә эчтән генә: «...кисмә канатларыбызны!» дип кабатлыйм.

Бу хәсрәт дәрьядай тирәнәйгән саен, безнең әтиебезгә булган мәхәббәт тә тирәнәя генә бара. Чөнки ул әнине ярата. Һәм яратуын яшерми. Ир башы белән безнең алда елап утыра. Әни чыгып киткәннән бирле, караңгылыкка яшеренгән олы юлдан безгә кайгы гына килеп торадыр кебек.

Ә ата казыбыз бәбкә чыгар көннәрне көтә. Әзгә генә болдырдан янына очып төшкән әнкә казны күргәч, башын югары чөеп, тыпыр-тыпыр бии. Ике канатын берьюлы җәеп, сөенеченнән кагынып-кагынып ала.

– Теге «чуваш хатыны»н йортка чыгарыйк мәллә, кызым, – диде әти иртән үк. Мин караватның чигүле япмасын ача төшеп, тал чыбыгыннан үрелгән көрән ояны бүлмә ягынарак тарттым. Каз да ушлы икән, муенын кыегайтып күземә карап-карап алды да оядан сак кына төшеп, каңгылдый-каңгылдый йортка юнәлде. Бусага төбенә җиткәч тә ул кире борылып оясы янына килде: йомыркаларны барлагандай итте. Һәммәсе дә исән-аман икәнлеккә ышангач кынадырмы, тышта үзен түземсезлек белән көтеп торган сөеклесенә аваз салды:

– Гый-гый-гый...

Ата каз тавышны шунда ук ишетте. Ярты юлгача болдырдан өскә үк менеп, аңа каршы килде. Бөтен ишегалды сагыну моңсулыгы һәм күрешү куанычы белән тулды. Алар бер-берсеннән тотам да калмыйча, гыйгылдаша-гыйгылдаша әле атлап, әле йөгереп йорт буйлап йөрделәр.

Тик әнкә каз озак юанмады. «Бераз гына сабыр ит, кадерлем», дигәндәй, ата казга моңсу караш ташлап, баскычка менеп басты да янә:

– Гый-гый-гый, – дип, минем якка төбәлде. Шунда ук ишекләрне тутырып ачып куйдым. Оясына патшабикәдәй, эчке бер горурлык белән менеп кунаклауга, мин аны янәдән карават астына этеп керттем. Өйдә тынлык урнашты.

Бәбкәләр чыгар көн дә килеп җитте. Дөресрәге, мин аларның ничек чыкканын күрми дә калдым. Әни яныбызда чакта гына кызык булган икән лә кош-корт дөньясын күзәтү. Ул йомыркаларны җылымса суга салып, бәбкәләрнең тибү-типмәвен тикшерә торган иде. Хәрәкәтсез, тып-тыныч ятканнарын кулына алып, монысы буш булды, ахрысы, дип пошынып та куя. Барыбер ватмый, киредән каз астына урнаштыра иде. Ахырдан, җан әсәре беленгәч, ярый әле ватмадым, бер бәбкәдән колак кагасы булганбыз, дип сөенә дә иде. Инде менә күзәтү бер нәрсә, ә аларны карау, тәрбия кылу бөтенләй башкача икән бит. Без, әти белән беренче тапкыр, бәбкәләрне түгәрәк тазга

тутырып, әткә каз янына чыгардык. Әнкә каз тазыбыздан һич күзен алмыйча, бездән тотам да калмыйча, артыбыздан йөгерде. Һич күрелмәгәнчә, быел ишегалдын яшел чирәм басты. Чөнки йортта тавык белән каздан башка кош-корт, мал калмады. Әниегез терелгәч, яшьрәк тана карарбыз, балалар, дип, сыерыбызны да сатып җибәрде эти. Сарыкларны исә иткә суйдык.

Мин берәм-берәм таздан бәбкәләрне бушатканда, ана каз белән ата казның куанычы безнең йортка гына сыярлык түгел иде. Хәер, дөньяга ничек сыйгандыр ул шатлык? Ана каз ата казның алдына ук чыгып, озын муенын күккә сузып тыпыр-тыпыр килде. Аңа ата каз кушылып китте. Аннары алар парлашып күз алдыбызда тәпиләрен еш-еш алдырып биеделәр дә биеделәр. Парлы биюнең үз ритмы барлыгын казлар да белә икән. Шул бергәлекне тою аларны да бәхетле итәдер, күрәсең.

– Шатлык казларны да биетә, эти, – дидем мин, сокланып.

– Күрәм, кызым, – диде эти, елмаеп. Бу аның әни киткәннән бирле беренче елмаюы иде. Минем күңелне дә рәхәтлек биләде. Көн яп-якты. Күктән кояш йортка җете нурлар чәчә. Яшел чирәмдә бәбкәләр тәгәрәшеп йөри.

– Сез бәхетле, – дидем, йомры йомгакларны кулга алып, – сезнең әтиегез дә, әниегез дә яныгызда... Шулчак күзләремә яшь тулды.

Ургылып-ургылып кояш нурлары төшә, бәбкәле кулым һәр нурның җылысын тоя, күңелем исә нәни йомшаккайларны шулай яратып, олылаган табигатькә чиксез рәхмәтле иде. Алар шул җылылыкта да дер-дер калтырыйлар, үзләре әнкәләре янәшәсендә дә нидәндер канәгатьсез тавышлар чыгарып чырык-чырык киләләр.

Без читтән генә күзәтеп, боларга ни ашатасы икән соң, дип, әни өйдә чакларны искә төшереп утырдык.

– Әниең йомырканың сарысын изеп бирә иде кебек, кызым, – диде эти. – Каты гына пешер дә пычак белән вакларбыз аннары.

– Әнинең тары боткасы биргәне истә калган. Әллә карабодай, бодай да пешерә иде микән?

Мин боларын хәтеремне актарып алып әйттем.

Менә бит ничек, әни барында мондый эшләрнең уйга да кереп чыкканы булмаган. Хәзер икәүләшеп баш ватабыз.

Чирәм арасына төшергәч тә бәбкәләр тәмам чарасыз калдылар. Тагын да ныграк калтырана башладылар. Әллә кояш яктысыннан күзләре чагылганга микән соң, дип уйлап куйдым аптыраганнан. Аннан әкрен генә үлән тәмләп карадылар. Үлән сабагына ябышалар да тарта-тарта артка чүлегеп китәләр. «Егылып киткән саен үсә ул бәбкә», ди иде әни. Әйдә, тарта бирсеннәр! Үссеннәр генә!

Ә ата каз белән ана каз, томшыкларын томшыкка терәп, сер сөйләшеп алды, алар да бәбкәләре тирәсендә әвәрә килде. Кыскасы, бу вакыйга эчендә мин тәмам чарасыз идем. Аларны нишләтәсен әни генә белгән лә... Барыбер дә төн кунарга өйгә керттек. Ана каз бик сакланып кына бәбкәләрнең һәммәсен киң канатлары астына яшерде. Иртән торуыбызга бу куанычны җимереп өебездә бер яманлык пәйда булган: йомры йомшаккаебыз күзләрен ачмаска дип йомган иде.

– Менә алтау гына калдылар, ничек саклыйсы икән инде боларын? Әниең янына барганчы булса да үтермәскә иде бит...

Мин җавап бирмәдем, җилкә башларымны гына сикертеп куйдым. Тик бәхетсезгә – вакытсыз дигәндәй, икенче көнгә тагын бер бәбкәбез җан

тәслим кылган иде. Өченче көнне өченчесе, аннан дүртенчесе... Кыскасы, бу хәлгә безнең чик куя алмсыбыз көн кебек ачык иде инде. Әти ана казны тәмам күралмый башлады. Чөнки гаиләсе кими барганны ул үзе дә сизә: әллә нинди ачы тавыш белән кычкырып-кычкырып куя иде. Ана башы белән ник үзе сакламый ул бәбкәләрен? Югыйсә, саклый да шикелле, «гый-гый» килеп тирәләрендә бөтерелеп йөрүдән туктамый.

Бәбкәләрне дә тиргәп алдым. Җил-яңгыр тими, ояда буран ыжгырмый, ник яшәргә тырышмый ул бәбкәләр? Бар табигать, җир өстендәге барча тереклек заты минем әнигә бәйле микән әллә соң?

Барыбер дә соңгы бәбкәнең салкын гәүдәсен учларыма кысып, мин бик озак еладым.

– Ярар инде, борчылма, кызым, шушындый кыска гомер язылган булгандыр, әниең савыгып кайткач, яренгә, ояга йомыркаларны күбрәк тезәрбез, – диде әти, үзен-үзе тынычландырырга теләп. Мине юатуы да шушыдыр сыман тоелды. Ләкин күрәселәребез алда булган әле...

Иртә таңнан мин ана каз гыйгылдавына уянып киттем. Битемне дә юып тормастан, йортка ашыктым. Бер-бер хәл бар мәллә соң? Әллә урманнан төлке төшкәнме? Шулай да ни карый бу Сафа абзый? Аучы исемен күтәреп йөргән була тагын... Ары карандым, бире карандым – әти казларны урамга ук чыгарып җибәргән икән. Келәне төшереп, урам якка атлауга куркып киттем. Каз гыйгылдый гына түгел, әллә нинди шомлы аваз салып кычкыра, хәтта бала елаган тавышлар чыгара иде.

Күзләрем аны тиз эзләп тапты. Ана каз башын рәшәткә ярыгына тыгып, аларны ике канаты белән кыйный. Җирдә коелган каурыйлар аунап ята, һавада каз мамыклары оча... Чарасыз канатлар авыртуга чыдый алмый башлагач, башын ала да ары китә. Түшләрен сөйрәп, иңнәрен салындырып, алпан-тилпән икенче рәшәткәгә юнәлә. Янә ярыкка тыгылып, шомлы кычкыра. Куәтле җилпегән саен рәшәткәнең барча черекләре, кубырчыкланган буяулары җиргә коела. Ул аларга игътибар да итми. Рәшәткәдән-рәшәткәгә йөргән мескен каз, бәбкәләре бакчадагы куе үлән арасына качып яталардыр дип белә, мөгаен. Бакчаның буеннан-буена шулай үтә. «Менә шунда гына бит минем бәбкәләрем, чирәм арасында гына...» диядер төсле.

Ул, әйтерсең, үзенең ана икәнлеген исбатларга, кешеләрдән бер-бер җавап ишетергә тели. Әйтерсең, дөнья үзе дә тынсыз-өнсез калып, ялгыз каз моңын кайда да булса сыендырыр урын тапмаганга сагышлана...

Икенче көнне дә шул ук хәл кабатланды.

Ата каз аңа минем кебек үк чарасызлыктан, аңгыраеп карап торды.

– Казыбыз җүләрләнде, кызым, – диде әти, тәмам аптырап. – Нишләтик икән инде аны хәзер?

– Абзарга ябыйк мәллә соң? – дидем мин, бу күренештән тизрәк котылырга теләп.

Әтинең болай да хаста җанның иреген чиклисе килмәде кебек, ул аны урамда калдырды.

Таң атканчы урамда каз тавышы тынмады. Аның инде тавышы карлыгып беткән, тәмам аңлаешсыз авазлар гына чыгара иде.

Ә ата каз... Ярсыган ананы тынычландырыр көч тапмам, дип уйладымы, нигәдер янәшәсенә дә килергә кыймады. Ә төн чыкканчы ул, уң як күршеләребезнең бәбкәләрен ияртеп урамга чыккан ана казы янына елышкан, болай гына да түгел, Мәфтуха апаларның бер оя ишле бәбкәсенә хуҗа булып

алган иде. Үзе тудырган бәләкәчләрне дә, ана каз белән парлап биегән көнне дә оныткан иде шикелле ул. Тынычлап та калган сыман.

– Шундый да кыен чакта ташлап китмәсә дә ярар иде инде, гөнаһтан да курыкмый, – дип, башыма килгән уемны кычкырып әйткәнмен икән.

Әти тамак кырып кына куйды.

Безнең әнкә казыбызның хәле көннән-көн кыенлашты. Кайда ярык-тишек күрсә, шунда башын тыгып, канатлары белән җилпенүен дәвам итте. Тавышы чыелдап кына чыга башлады. Хәлсезләнде. Ашамады да, эчмәде дә, йокламады да кебек ул. Күршеләр дә туйды.

– Нишләтеп тотасыз инде, суегыз да котылыгыз моннан, әниегезгә яңа иттән шулпа пешереп барырсыз ичмасам... – дисәләр дә, әтинең пычакка үрелергә кулы бармады. Һәр күзәнәге тоташ әрнүдән укмашкан казның шулпасын әнигә ашату мизгелен күз алдына китералмый азаплана иде бугай, алар белән сүзне башкага борып, кәефсез генә сөйләште.

Мин исә гыйбрәт булып авыл теленә кергән Мәфтуха апаны исемә төшердем. Улын – Хәмит абыйны алып киткәч, ул да бит җүләрләнгән шулай.

«Хәмитем сездә генә, чыгарыгыз! Әле генә елаган тавышын ишеттем», – дип, тирә-күршеләрнең капкасын кагып йөргән.

Ярый ла Казаннан кире кайтарып биргәннәр улын. Табибларга рәхмәт, улын савыктырырлык дарулар тутырып җибәргәннәр. Ананың акыл зәгыйфьлеге таң атканчы беткән. Бөтенләй кыйшаеп калыр инде, дип кот очкан иде, ди әни. Аллам сакласын!

Аннары кем көтәр иде каз көтүен авылда? Бер дигән көтүче бит ул Хәмит абый! Казлар көтүен дә ил өчен дип уйлый белә. Шундый җырлар да җырлый:

Һавада очкан кошларның
Атып алдым сигезен.
Корычтан да нык итәрбез
Коммунизм нигезен...

Сүзләре чит кешеләргә аңлашылып бетмәсә дә, без аларга ирен кыймылдатуыннан ук төшенәбез.

Ә Мәфтуха апа Хәмит абый өчен аеруча өзелеп тора. Сөт сатарга барган җирдән аңа хатынлыкка бер кыз да ияртеп кайтты хәтта. Җитмәсә, шәфкать туташы да икән әле. Мин Сәринә янына кергән чакка туры килде ул. Карлыгандай кап-кара күзле, тулган ай күк ак йөзле кызны күреп, тәмам телсез калдым. Дөнья бәһасе торырлык чибәрне кайлардан тапкан диген? Буе да Хәмит абыйдан бераз гына кыскарак. Үзе умарта кортыдай нечкә билле. Алсу күлмәге дә нәкъ менә билен ассызыклап күрсәтер өчен тегелгән диярсең...

– Менә, улым, сиңа хатын, үземә килен алып кайттым. Бу баланың җир өстендә беркеме дә юк. Әти-әнисе вафат, – дигәнгә, ул түр тәрәзә ягына таба барган җиреннән тукталып, гаҗәпләнеп карап торды.

Аннары адымнарын кызулатып, ишекле-түрле йөренде. Әнисенә:

– Мин өйләнмим, син өйлән... – дип, җитдилек аша тәкрарлавын белде.

– Брачларга мәңге түләп бетерә алмаслык бурычың бар бит, улым, туктале, – дип караса да, Хәмит абыйның исе дә китмәде.

Ул, кызны ошатмыйча, ишекле-түрле йөреп торган мәлдә, без, Сәринә белән аның аяк астында әвәрә килгәнче, чыгып таю ягын карадык.

– Әни дә инде... Абыйның үзсүзлелеген белә торып, әллә нишләп йөри, – дип куйды Сәринә.

– Бигрәк чибәр бит, бәлки калыр әле килен булып... Хет авылда аспирин, цитрамон барып алырга, кан басымын үлчәргә бер кеше булыр иде...

– Калдырмас шул... Ул бит теге очтагы сыер савучы шадра Маһирәне ярата... Иш ише белән, Хуҗа ишәге белән инде... – дип ушымны алды Сәринә. Шундый, көрәшчедәй тыгыз тәнле, ирләрчә алып гәүдәле, дорфа-төкселекне дә яратып була микәнни?.. Гомер йөзендә авызыннан бер җылы сүз ишетмәссең... Әйтәм аны, Хәмит абый су буена казларны бер тыкрык булса да Маһирәләр урамы аша алып төшә...

***

– Әллә соң инкубатордан бәбкәләр алып кайтып карыйкмы, әти? – дидем мин, бер мәсьәләнең чишелешен тапкандай куанып. Чөнки ана казыбыз миңа бик тә, бик тә кызганыч иде.

– Белмим инде, кызым, Тын Күл ягында инкубатор бар дигәннәр иде, иртәгә урап кайтсам да ярар шул. Әниеңнең дә хәле яхшырып бара. Теш төбеннән инфекция таралып яткан, каһәр. Капланган булгач, тиз генә белә алмаганнар. Төзәлгән дип уйлаганнар. Үзе дә оныткан теш алдырганын. «Күктән ни яуса да, җир кабул итәр, диләрме әле... Җирдә без инде ул. Димәк, шулай язган булган. Башкача мондый аерылышулар язмасын иде безгә...

– ...Язмасын иде... – дип кабатладым шыпырт кына әти артыннан.

***

Иртән мин ана каз тавышы ишетелмәгәнгә шомланып урам якка юнәлдем. Әти инкубаторга киткән, каз юкка чыккан иде. Хәмит абый казлар көткән су буена табан атладым. Авыл белән зират арасында елга агып ята. Суны буып куйгач, ул шактый зурайган, дөресрәге киңәйгән. Яр кырыена ук килеп җитсәм, имәнеп киттем: безнең ана каз тыныч кына япа-ялгызы чирәм чемләп йөри... Яхшылык кыләсен каз күңеле дә сизенә, күрәсең...

Хәмит абый көтүне күлнең икенче ярына чыгарган икән.

Мин өянке тирәсендәге ап-ак ромашкаларның сабый тешләредәй таҗлары арасыннан Хәмит абый белән шадра Маһирәнең бәхеткә тулышкан йөзләрен күреп алдым... Маһирәсе чәчкә таҗын йолкып утыра идеме шунда... Әллә тоелды гынамы? Хәтта: «Ярата. Яратмый...» дигәнен дә ишеткәндәй булдым...

***

Әти, ана казга катыргы капка тутырып, эре-эре ун бәбкә алып кайтты. Болар инде шактый ныгыган, тормышка җайлаша төшкәннәр иде.

– Әйдә, терел, рәхәтен күр! – диде ул, казның таушалган ак канатларыннан сыйпап. – Ата казны да алып чыгарбыз аннары. Ату, күршегә йортка керде ләбаса, ояты качкан нәрсәкәй, – дип сөйләнде.

Бер килсә, килә бит! Кайтышлый әтигә хәбәр җиткергәннәр: әниебезне больницадан чыгаралар икән, иртәгә иртән килеп алырга кушканнар. Әмма беребез дә бу куанычны иртәгә кадәрле күтәрлек халәттә түгелбез.

Әнине алырга ай яктысында барабыз. Хәния апа бездә аш-су әзерләп калды. Юл озын. Юл озак. Алдыбызда Сабантуй сөлгеседәй ай юлы сузылган. Атыбыз Сабантуйга ашыккандай күңелле юырта. Тузан, атның тир, дирбия

исе катыш кичнең салкынча һавасы биткә бәрелә. Күктә ап-ак болытлар йөзә, гүя болытлар канат кагына... Арбада әтинең шәм кебек төз гәүдәсе тантаналы чайкала. Уйнак ай үзе якты нурларына чумырып, келтер-келтер генә келтерәгән җырлы арбабызга тагылып, бер тотам да калмыйча, артыбыздан йөгерә. Ул да безнең өчен сөенәдер күк тоела. Безнең генә түгел, ана казыбызның да тормышы көйләнәчәк, димәк... Мин бу уемны әтигә дә әйттем. Ул сабыр гына:

– Һәркем җир өстендә, беренче чиратта, үзен кайгырта шул, кызым, – дип куйды. Бераз кыен булып китте. Әти табиблар хакында уйлап бара икән. – Бу олы йөрәкләре, шифалы куллары өчен ничек рәхмәт әйтербез инде, кызым, – диде ул. – Әллә район газетасына язасыңмы?

– Язармын, – дидем мин, хатның ни рәвешле язылырга тиешлеген дә күз алдына китерә алмыйча. Әнием генә кайтсын, кулга каләм тоткач, сүзе табылыр әле. Болай да бу мәлдә минем бөтен вөҗүдем табибларга рәхмәт хисләре белән тулган иде. Баксаң, дөньяның бар җепләре дә аларга тоташкан икән бит... Гаиләгә катышып, табиблар ярдәм итеп җибәрмәсә, әнә ничекләр чуала икән ул яшәеш җепләре. Мөгаен, Аллаһ илчеләредер алар!

***

Көздә нәни бәбкәләр тупырдап торган казларга әверелде. Урамда тук казлар гыйгылдаша. Аларның да канат ныгытасы, ерак-еракларга очасы киләдер, ахрысы. Хәмит абый каз көтүен куып кайтканда, иң алдан безнең казлар өскә күтәрелә. Әйтерсең, ак болытлар канат кагына. Киң урамыбызны ике яклап күпер сыман шуларның ап-ак канатлары тоташтыра кебек. Әлбәттә, башкалар да алардан калышмаска тырыша.

Шундый көн килеп җитте: алар тау ягына карый башладылар. Биеклек казларны да үзенә тарта, күрәсең... Әтинең дә, әнинең дә сөйләгәне бар: бала чакларында ук булган хәл – казлар, тәпиләп, тау түбәсенә менәләр дә, очып, тирә-күрше авылларга ук таралалар икән. Шуннан кешеләр үзләрен каз җыю мәшәкатеннән азат итәргә уйлашканнар. Җаен тапканнар менә... Тәпиләрен җиргә тидермичә, ерак-еракларга очканнарын белеп алуга, аларның канат очларын кискәннәр...

Көзләр тагын пычрак килде. Яңгыр җир өстен җебетә торгач, тәмам сазлыкка әверелдерде. Хәмит абый да:

– Моннан соң казларыгызны үзегез җыеп алырсыз, – дип, йөзен җыерып, көн дә бер әйтеп  үтә башлады.

– Әниеңнең тау башларына үрмәләп, югалган казларны эзләп йөрерлек хәле юк әлегә, кызым, – диде әти, пычагын үткенләгәндә...

«Кисмә безнең канатларны!» Бу сүзләрне әти әйттеме, әллә казлармы, һич аңлый алмыйча, бер мәл исәңгерәп тордым. Әллә колагыма гына ишетелдеме соң?

Барыбер дә әти Аллаһ һәм табигать теләгәнчә түгел, тормыш кушканча хәл итте: казларның канат очларын кисте...

Һәм казлар кояшлы бер көзге көндә янәдән җиргә төштеләр. Канатларын як-якка җәеп ничек кенә талпынып карасалар да, нибары тәпиләргә мәҗбүр иде алар хәзер...



*Галимҗан Шәрәф (1896-1950) – сәясәтче, тел галиме, язучы. Татар дөньясындагы данлыклы бертуган Шәрәфләрнең берсе. Мөгаен, иң күренеклесеседер. Ул – 1915 елда Петербургта оешкан «Татар учагы» студентлар түгәрәгенең җитәкчесе, Милләт мәҗлесе депутаты (1917-1918), Идел-Урал штатын гамәлгә кертү һәйәте рәисе. Галимҗан Шәрәф 1937 елны «Совет хакимиятенә каршы буржуаз милләтчеләр оешмасы» эшендә катнашкан дигән гаеп белән кулга алына. Үлгәч аклана.*



*Якташлар (сулдан уңга): Мөдәррис Әгъләмов, Аяз Гыйләҗев, Рабит Батулла. 1994 ел.*



*Каләм ияләренең атаклы шахматчы Гата Камский белән очрашу истәлеге. Сулдан уңга: Рашат Низами, Миргалим Харисов, Айрат Садыйк, Ренат Харис, аталы-уллы Камскийлар, Туфан Миңнуллин, Илдус Илдарханов. 1988 ел.*



*Язучылар җыелышыннан соң төшерелгән фоторәсем. Беренче рәттә (сулдан уңга): Нәби Дәүли, Хәсән Хәйри, Гази Кашшаф, Әхмәт Ерикәй, Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир (идарә рәисе), Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Хатыйп Госман, Абдулла Әхмәт, Сибгат Хәким; икенче рәттә: Василий Юдин, Атилла Расих, Гариф Ахунов, Хәй Вахит, Рафаил Төхфәтуллин, Шәүкәт Галиев, Зәки Нури, Галимҗан Латыйп, Госман Бакир, Хәмит Ярми, Әхмәт Исхак, Әхмәт Юныс, Баян Гыйззәт; өченче рәттә: Гали Халит, Рафаэль Мостафин, Нур Гайсин, Шамил Шаһгали, Шаһиморат Зәйни, Габдрахман Минский, Мәрзия Фәйзуллина, Мостафа Ногман, Саҗидә Сөләйманова, Әдип Маликов, Ибраһим Нуруллин, Нил Юзиев, Роберт Бикмөхәммәтов; дүртенче рәттә: Яхъя Халитов, Ибраһим Салахов, Малик Хәмитов, Эдуард Касыймов, Мәсгут Шәрифуллин, Вил Ганиев, Зәет Мәҗитов, Нур Гыйззәтуллин, Мәҗит Рафиков, Илдар Юзеев, Касыйм Фәсәхов, Гөлшат Зәйнашева, Нурихан Фәттах. Казан, Бауман ур., 19. Матбугат йорты, Тукай клубы залы. 1966 ел, гыйнвар.*
*P.S.: Бу фоторәсемдәге илле язучыдан фәкать берәү – Мәрзия Фәйзуллина гына исән-сау.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

# «НӘСЕЛЕМНЕҢ МИН БЕР ТӘРӘЗӘСЕ»

ОЧЕРК

*Бурыч уртак –*
*Җирдә ничек яшәп китсәң дә,*
*Яфрак булып ярыл киләчәккә,*
*Тамыр булып тарал үткәнгә.*
Харрас Әюп

«Бәхет нәрсә ул?» дигән сорауга мең кеше мең төрле җавап бирер иде... Кемдер – акча, дияр, икенче берәү – саулык, мәхәббәт, дип җаваплар. Кайберәүләр әлеге төшенчәнең мәгънәсен башкаларга файда кылып яшәүдә, киләчәккә калыр сүзендә, гамәлендә күрер.

Бу язмамның герое – гап-гади җир кешесе. Хәер, болай диюемә үзем үк каршы килсәм дә, хата булмас. «Гап-гади, җир кешесе», имеш... Алай булса, бүген күпләр үзен күккә чөю яки атлый-йөгерә мал артыннан куу белән мавыккан заманда, ул, мәгарәдәге Әбүгалисина шикелле, китап белән мәш килмәс, республикабызны данлаган шәхесләр турында яхшы сүзем калсын, дип, үз-үзенә эш эзләп йөрмәс иде...

Ике мең ярым еллар элек грек галиме Геродот, үз халкының һәм күп кенә башка халыкларның тормышын чагылдырып, китап язган. Ул үзенең хезмәтен «тарих» дип атаган. Һәркем үз төбәген, туган җирен ярата, күренекле шәхесләре белән горурлана. Ләкин халык бүгенге белән генә яши алмый – «үткәнен онытканның киләчәге булмый», дигән бер акыл иясе. Бәлки шуңа күрәдер дә, язу барлыкка килгәнче үк, кыяларга, тау куышларына рәсем ясаганнар. Соңрак кешеләр елъязма язганнар, килер буынга үзләреннән истәлек калдырганнар.

Бүген дә андый тынгысыз җаннарны очратырга мөмкин. Шуларның берсе – үзебезнең Актаныш Геродоты – СССР, ТР Журналистлар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Йосыф Әхтәм улы Хуҗин.

Журналистлар, язучылар башка кешеләр хакында, аларны зур шәхесләр итеп күрсәтеп, күпме мәкалә, китап язганнар, бүген дә язалар. Әмма еш кына үзләре күләгәдә кала бирәләр. Йосыф Әхтәм улы хакында язарга утыргач, мин моңа тагын бер кат инандым. Бүтәннәрнең хезмәтен күрсәтеп, күпме китап чыгарган, ә менә үзе хакында «үзем турында үзем» дип ярты бит тә язмаган! «Мине язган әйберләремнән эзләгез», – дигән Экзюпери. Йосыф абыйны да язган китапларыннан, аралашкан кешеләреннән «эзләргә» туры килә инде болай булгач...

«Иҗат белән шөгыльләнеп, килгән кеше белән иркенләп сөйләшергә дә вакыт булмады инде минем», дигән Йосыф абыйның, яза башлаган әйберен читкә куйдыртып, ярты көн вакытын урларга да туры килде. Героем хакында тулырак беләсе килә бит, әле бер, әле икенче сорау белән кылларын тартып карыйм. Ә ул, үзе хакында кыска гына әйтеп ала да, татар халкының горурлыгы булган башкаларның матур эш-гамәле турында сөйләүгә күчә. Аның китапларына кергән геройлары арасында Актаныш җирлегендә туып-үсеп, районыбызга, республикабызга, алай гына да түгел, дөньяга исемнәре танылган шәхесләр бихисап, сүз йомгагы тәгәри башласамы...

«Үземнең дә, хәләл җефетем Венераның да шәҗәрәсен эшләдек», – дип, Йосыф абый, ниһаять, рамга парлап куелган нәсел шәҗәрәсе хакында сөйләргә кереште.

– Без – Гәрәй тархан нәселеннән. Тормышлары авырлыктан, әтиебез Әхтәм бик кечкенә килеш, әле буыннары да ныгымас борын, кешегә кулалмаш булып төрле эштә булышып үсә. Шуңа бар нәрсә дә кулыннан килә иде аның. 1935-1936 елларда аз белемлеләр мәктәбен тәмамлап, латинча укырга-язарга да өйрәнгән. Яуга бер түгел, ике тапкыр барган кеше ул. Сугышка 1941 елның 25 августында алына да аннан яраланып кайта. Терелеп, тагын фронтка китеп бара. Шул икенче китүендә, Ленинградны саклаганда, гомерлеккә гариплөнеп кала. Ул балта остасы, пыялачы, тимерче иде. Һөнәрле булгач, безнең күпбалалы гаиләне туендырып тору беркадәр җиңелрәк бирелгәндер: ул чорда киемен, ризыгын юнәтәм, дисәң, ай-һай авыр бит... Әтәйләр хәзерге төп милкебез янындагы чокыр аръягында яшәгәннәр. Әтәй белән инәй 1930 елның 18 гыйнварында никахлашканнар. Әниебез Миңнехәдичә Габделгани кызы 12 бала тапкан, 3 баласы кыска гомерле булган. Ул замандагы башка хатын-кызлар кебек, колхоз эшендә гомере үтә инде, кая кушсалар, шунда риясыз эшли...

Менә шул гаиләдә, 1948 елның 3 июлендә, Актаныш районы Иске Җияш авылында бер малай дөньяга аваз сала. Аңа Йосыф дип исем кушалар. Йосыфка 7 ай чагында, әти-әнисе аны юрганга төреп ала да, атлы чанага утырып, Такталачыкка хастаханәгә юл тота, ниндидер прививка ясатырга кирәк икән... Хәерсез юл була ул алар өчен. Кышкы юлдан юыртып кына кайтып килгәндә, тау төшкән мәлдә нәрсәдәндер өркеп, ат дулап китә. Шул вакытта Йосыфның аягы имгәнә. Шәрип авылындагы бер белекче карчыкка күрсәтеп тә, төрлечә дәвалап та карыйлар, ләкин аяк төзәлми. «Авылда аксаклар җитәрлек иде, җиде айлык чагымда аларның сафын ишәйткәнмен», – ди Йосыф абый.

Аның тормыш баскычларына күз салсаң, беренче карашка, гадәти генә. Авылның башка балалары кебек үк, үзләрендә башлангыч мәктәптә уку. 1949 елны Әлем авылыннан Иске Җияшкә мәктәп мөдире итеп Тәкый Зәкиев җибәрелә, аның хатыны Әскыя ханым – Йосыф Хуҗинның беренче укытучысы була. Аннан инде Теләкәй авылында сигезьеллык мәктәптә укуны дәвам итү. Җияштән килеп укучылар интернатта торалар, көн саен кайтып йөрү юк. Алар янына кичләрен укытучылар килә, балаларның тормышын карап-барлап торырга тиешләр. Йосыф абый мөгаллимнәрнең берсен – Фаил Шәмсуллинны аеруча җылы хисләр белән искә ала. Тарих дәресендә әллә ниләр өйрәнәләр, ә менә рус теле укытучысы, интернатка килсә, татар иленең башкаласы Казан, андагы истәлекле урыннар, Сөембикә манарасы хакында сөйләп, балаларга өр-яңа дөнья ача. Шул рәвешле, үзе дә сизмәстән, Йосыфның күңелендә тарих белән кызыксыну уята ул. Малай, дәреслеккә язылмаган, маҗаралы әкият булып тоелган дөнья белән якыннан танышырга теләп: «Ничек тә шул Казанны, Сөембикә манарасын барып күрәсе иде!» – дип ашкына. Тели белсәң – теләк шул, кабул булуы да ерак йөрми. Беркөнне яхшы укыган укучыларны Казанга экскурсиягә алып баралар. Әкияти хыялның чынга ашкан мәле! Йосыф Казанны күрүгә үк, иртәме-соңмы монда киләчәгенә, биредә белем алачагына чын күңелдән ышана. Әмма хыялны тормышка ашыру өчен, урта мәктәптә укуны дәвам итү кирәк шул әле... Үсмер егет тугызынчы сыйныфка Актанышка бара. Актанышның район үзәге булудан туктаган чорына туры килү, юлсызлык үзәккә үтепме үтә.

– Кыш көне МТСка ремонтка баручы механизаторларны Уразай аша трактор чанасында илтәләр иде. Шулар белән Актанышка барып җиткәндә, мәктәптә дәресләр бетә яки уку ахырына якынлаша иде. Атна аралаш шимбәдә, берничә дәресне калдырып, шул рәвешле кайтырга да кирәк. Шунлыктан сыйныф җитәкчесен һәм үземне җәфалаудан туеп, 1964 елның көзеннән Такталачык урта мәктәбенә күчтем. Монда бик әйбәт укыдым, йөрү ягы да җайланды, игелекле күршебез Фатыйх абый велосипедын биреп торды. Аннан Әнисә апа үземә яңа велосипед алды, кышын товар ташучы Мәгъдәнур абыйга яки хисап китерүче сатучыларга утырып кайта башладым, – дип искә төшерә ул чакларны Йосыф абый.

Кешедә әллә нинди сәләт-талант яшеренеп ятарга мөмкин, кайчагында шул сәләтне «уятып» җибәрү өчен нибары бер этәргеч җитә. 9 нчы сыйныф укучысы Йосыф белән дә шулай була. Туган колхозы «Радио»дагы (хәзер – «Таң») кайбер җитешсезлекләр аның җанына борчу сала һәм ул, күңелендә йөргән уй-хисләрен тота да кәгазьгә төшерә – мәкалә язып, газетага юллый. Яңа Җияш белән Теләкәй арасы – 3 чакрым, әмма ул юл

бик начар булгач, урап-урап, 6 чакрым йөрергә кирәк. Үсмер егетнең күңеленә тигән шушы проблеманы яктырткан язма озак көттерми, «Якын араларны ерак итеп» дигән исем белән басылып та чыга. Безнең яклар өчен район үзәгенә әйләнгән Минзәләдә, соңыннан, район кабат оешкач, Актанышта чыга торган газеталарда, «Социалистик Татарстан»да, «Чаян» журналында Йосыф Хуҗин имзасы куелган язмалар аннан инде еш күренә башлый. Табигатькә саксыз караш, җимерек күперләр, авыллардагы сатучы апаларның дорфалыгы, чишмәләрнең хәле дә борчый егетне – ул шулар хакында язып, каләмен чарлаганнан-чарлый бара. Үз мәкаләләренең матбугатта басылуы егетнең киләчәк язмышын хәл итә дә инде, кем булырга, нинди һөнәр сайларга дигән икеле-микеле уйларга урын калмый. Баш мөхәррир Надил Мөхәммәтовның редакциядән биргән юлламасы да зур роль уйный. Ул чорда авыл кешесенә паспорт бирергә атлыгып тормасалар да, егетнең бу яктан да бәхете була, Актанышка бер баруында ук паспорт алуга ирешә (ә күпләргә укырга кергәнлеккә белешмә алып кайткач кына паспорт алу бәхете тәти). Паспорт һәм юлламаны зур чемоданның кесәсенә салып, Йосыф 1966 елның 12 июлендә җәяү генә олы юлга чыгып китә...

«Дәртле Казан, моңлы Казан, нурлы Казан»ның ничек «кочак җәеп» каршы алганын анда барып төшкәч аңлыйсың... Кайнап торган шәһәрнең үз кануннары, чит-ятларны куенына үз баласыдай иркәләп сыендырырга ашыкмый ул. Ләкин яшьлек хыяллары, куелган максатка омтылу бөтен авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә. Йосыф имтиханнарны тапшырып, шактый зур конкурс узып, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты студенты булу бәхетенә ирешә. Аларның 466 нчы төркеменә Мөхәммәт Мәһдиев җитәкчелек итә.

Сүз уңаеннан шунысын да әйтим: Мөхәммәт Сөнгать улы минем дә укытучым, диплом җитәкчем иде, аның хакында сүз кузгаткач, остазыбызны олылап, яратып искә алдык. Йосыф абыйның коеп куйган артист икәнен белми идем, Мәһдиевнең мәһабәт гәүдәсен, бәрхет тавышын, бармакларын сузып сөйләвен сурәтләп күрсәткәч: «Сезнең артист буласыгыз килмәдеме? Образга бик оста кердегез», – дип сорамый кала алмадым.

– Мин бит татар хорына, театр студиясенә йөрдем. Җитәкчебез – татар театры атасы Галиәсгар Камалның туганы, дөресрәге, туганының кызы – Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Гәүһәр апа Камалова иде. Баш режиссёр Марсель Сәлимҗанов студиядән берничәбезне Камал театры спектакльләренә күп кешеле күренешләргә уйнарга да чакырды, моның өчен безгә 25-26 сум акча түлиләр иде, уку беткәнче, бу минем өчен бик зур файда булды. «Американ», «Зәңгәр шәл», «Кыю кызлар», «Миркәй белән Айсылу» спектакльләрендә күмәк күренешләрдә катнашканымны хәтерлим әле. Спектакльдән соң кечкенә китапчыклар чыгаралар иде, аларның берсендә минем дә рәсемем бар, – дип елмаеп куйды Йосыф абый.

Университетта чит телләрне өйрәтү ул чорда ук үз югарылыгында булган. Йосыф абый француз телен, ә булачак хатыны Венера апа гарәп телен сайлаган. Студент еллары турында күзаллау өчен, 1968 елда чыккан «Игенче даны» газетасына – Хәлил Сәлимовның «Якын дустым» дигән язмасына күз ташлау да җитә дип уйлыйм: «Йосыф һәрвакыт дусларына ярдәм кулы сузарга әзер тора. Шул сыйфатларын истә тотып, беренче курста ук группадашлары аны профорг итеп сайлаганнар иде. Гел «5»кә укый, имтиханнарны «5»кә биреп, югары дәрәҗә стипендия ала. «Бик сәләтле һәм бик тыйнак егет», – ди аның турында студия җитәкчесе Гәүһәр Камалова». Әлеге бәяләмәләр белән килешми мөмкин түгел. Без белгән бүгенге Йосыф абый әле дә шулай. Эшен җиренә җиткереп эшләр, үзе хакында сөйләүгә караганда, башкалар турында нидер әйтергә ашыгыр.

Университетта укыганда, Йосыф Хуҗин «Татарстан яшьләре» газетасының спорт бүлегендә штаттан тыш хәбәрче булып та эшли һәм бервакыт үзе өчен гомерлек сабак ала: «Кеше сүзенә карап, тикшермичә мәкалә язма!» Ә вакыйга болай була. Йосыфтан тиз генә мәкалә язып кайтуны сорыйлар. Студентлар янына баргач, өстәл тирәли җыелышып утырган яшьләр аңа уйный-көлә бер вакыйга сөйләп алалар. Имеш, егетләрнең берсе, йөзә белсә дә, суга баткан. Аны Мөслим егете батырларча коткарган... Шунысы бар: әлеге вакыйганың геройлары булган бу ике егет үзләре дә, мыек астыннан көлеп кенә, шунда утыралар, «алай булды, болай булмады», дип,

кайтарып сүз дәшмиләр. Яшь журналист Йосыф мәкаләлек вакыйга табуына куанып кайтып та китә, бераздан аның шәп кенә язмасы басылып та чыга. «Коткаручы»ның йөзә белгәнен-белмәгәнен тикшереп торырга җай юк, шулай дип сөйләгәч ни... «Мәкалә чыккач, миңа нык кына эләкте, «күрсәм, үтерәм», дип дулап та йөргән әле егетләрнең берсе», – ди Йосыф абый, әлеге сабак турында телгә алгач.

Студент чак – яшьлекнең гүзәл чоры. Бик күп яшь йөрәкләрнең бер-берсен эзләгән, тапкан, кавышкан чоры. Яшь егет Йосыф, Лениногорск районы Үзбәк авылы кызы Венераның озын толымнарын күргәч, күзе түгел, күңеле берегеп калган чор... Башка авыл балалары кебек, кечкенәдән әти-әнисенең кул арасына кереп, җәйләрен күмәк хуҗалык басуында чөгендер чүбе утап, борчак чабып, көзен чөгендер-бәрәңге алып, эшләп, ныгып, чыныгып үскән Венера белән бер курста, бер өстәл янында утырып укый алар. Зәй-Каратайда – сигезьеллык, Карабашта урыс сыйныфында урта белем алып, КДУның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергән, акыллы, тыйнак, оялчан, йомшак сүзле Венера үзенең холык-фигыле белән Йосыфның күңеленә бик якын тоела, бераздан чәчләре чәчкә бәйләнеп тә куя.

Венера ханымның нәселендә – «Мәүлет бабай ягыннан Венераның нәсел агачы» дип төзелгән шәҗәрәдә шактый кызыклы материаллар бар. Әлеге Мәүлет бабай турында «Казан утлары» журналында (соңыннан китапта да) Зәки Зәйнуллинның «Мәүлет гусар» повесте да дөнья күргән иде.

Мәүлет 25 еллык солдат хезмәтенә алына, бик оста җайдак булганлыктан, дворян балалары гына хезмәт итә торган элиталы гусар (җиңел кавалерия) полкында хезмәт итә. 1805 елның ноябрендә Чехиянең Аустерлиц шәһәре янында Австро-Россиянең берләшкән көчләре арасында зур сугыш була. Бу сугышта урыс гаскәрләре җиңелә. Гусар полкыннан егермеләп кенә кеше исән кала. Ләкин алар һаман да сугышуларын дәвам итәләр. Нәкъ шушы бәрелештә Мәүлет, бик каты яраланып, әсирлеккә төшә. Ләкин французлар, аның батырлыгына сокланып, хөрмәт йөзеннән, носилкага салган гәүдәсен урыс дозорына тапшыралар. Дүрт айлап Петербургның хәрби лазаретында ятканнан соң, Мәүлетне дәвалану өчен туган авылы Зәй-Каратайга кайтарып җибәрәләр. Авылда үткән биш еллап вакыт эчендә яралары әкренләп төзәлә, аны яңадан сугышка алалар. Мәүлет гусар Бородино сугышында батырларча һәлак була.

Шушы нәселнең дәвамчысы Камил Мәүлидов – Венера ханымның әтисе.

Венера белән Йосыфка, укуны бетергәч, Казанда урнашу мөмкинлеге дә була – аспирантурада калырга тәкъдим итеп торалар. Тик алар Актаныш ягына кайтуны, балалар укытуны өстен күрәләр. Яшь укытучы Йосыф Чуракай мәктәбендә – француз теле, Венера исә – татар теле укыта башлый.

– Дәресләрне ничек тә кызыклырак итәргә тырыша идем. Француз телен җырлар, күнегүләр аша өйрәттем мин. Ишектән керү-чыгу, исәнләшү кебек төшенчәләрне урыннан торып, практик яктан эшләп карыйбыз. Кайбер укытучылар: «Нишләп сезнең дәрестә класс ишеге бертуктамый ачыла да ябыла; дәресегездә гел җырлап утырасыз», – дип гаҗәпләнәләр иде. Бүген дә горурланам: 4 укучым француз теленнән имтихан тапшырып, югары уку йортына керде. Касыймов Ришат, чит телләр факультетын тәмамлап, француз теле укытты, мәктәп директоры, РОНО мөдире булды, – дип, Йосыф абый укытучы булып эшләгән елларын сагынып искә алды.

Аны бүген «аксакал» дип атаучылар бар. Юкка түгел: Йосыф абыйның дин юлына басуына да шактый еллар инде.

– Кечерәк чакта, хәтерлим әле, өйдәгеләргә әйтәм: Алла юк, дип өйрәтәләр мәктәптә, дим. «Улым, – диде шулчак әти, – яңадан бервакытта да болай дип телеңә алма». Әтинең шул сүзе мине гомер буе озата барды. Бервакыт, Чуракайда эшләгәндә, чәршәмбе көнне класс сәгате үткәрәбез. Дингә каршы дәрес уздырырга кушылды. Шулчак әти сүзе искә төште, андый дәрес үткәрмәдем. «Следопыт» китабын татарчага тәрҗемә итеп, кычкырып укыдым, шулай узды ул дәрес, – диде аксакал, «дингә ничек килдегез?» дигән соравыма җавап йөзеннән.

Мөгаллимлек хезмәтен соңыннан Теләкәй авылында дәвам итүнең дә үз сере бар икән...

– Колхоз рәисе Шәйхразиев: «Чуракай балалары чит тел өйрәнеп ятканда, нигә аны

Teләкәй укучылары өйрәнмәскә тиеш әле? Әйдәгез, үзебезгә кайтабыз. Фатир бар!» – диде дә, әнә шул сүзләре белән «кытыкны китереп», безне Teләкәйгә кайтартты. Кайттык. Фатир дигәне – төзелеп бетмәгән йорт: кухняның идәне җәелмәгән, миче чыгарылмаган... Ярый әле шунда балта остасы малае булуым ярап куйды... Мәктәптә миңа дәресләр булса да, Венерага урын булмады, ул балалар бакчасына урнашты.

Teләкәй мәктәбендәге укытучылык хезмәтен Йосыф абыйның авылдашы, укучысы, бүген «Әнәк» агрофирмасын җитәкләгән Фарис Гаяз улы Фәтхиев түбәндәгечә искә ала: «Йосыф абый безне артык озак укытмады. Хәтерлим: беренче язган иншаларыбызга сыйныфыбыз белән «2»ле куйган иде... Шуннан соң «җиң сызганып» план төзергә, эпиграф сайларга, инша язарга өйрәтергә керешә. Әдәбият дәресендә әсәрне укып сөйләргә генә түгел, һәр сүзгә, һәр җөмләгә игътибар итәргә куша иде. Мин бүген әдәбият белән кызыксынам икән, монда Йосыф абыйның укытучы буларак өлеше зур дип саныйм. Тарихчы авылдашым буларак та дөнья бәһасе кеше ул. «Уртак язмыш кояшыбыз» китабын язу өчен генә дә күпме эзләнде, Иске Җияшнең күпме кешесенең нәсел тамырларын барлады! Без булдыра алмаганны булдырганы, без белмәгәнне белдергәне өчен мин аңа бик рәхмәтлемен. Хуҗиннар – көрәшчеләр нәселеннән алар. Россия беренчелегендә билбау көрәше буенча җиңү яулаган 19 яшьлек Иске Җияш егете Фарис Хуҗин шуның бер мисалы».

Teләкәй мәктәбендә дүрт еллап укыткач, «инде тәмам урнаштык, бүтән күченмәбез», дип дөнья көтеп яткан Йосыф Хуҗинны, үткен каләмле, зиһенле, үзфикерле журналист, дип, имтиханнар бетүгә, Актанышка чакыралар. Эш күләме бернинди үлчәү берәмлеге белән дә бәяләнмәгән, әмма көн саен төрледән-төрле кеше язмышлары, вакыйгалар белән очраштырып торган хезмәткә – районның «Игенче даны» газетасына мөхәррир урынбасары итеп эшкә дәшәләр аны. Тик Йосыф абый, бу урынны үзенеке түгел дип санап, аннан баш тарта, ахыр чиктә җаваплы сәркатип булырга ризалаша. «Ике ел ярым «Ватаным Татарстан» газетасында үзхәбәрче булуымны исәпләмәгәндә, бар гомер Актаныш мөхәрриятендә үтте. Күпсанлы журналистлар, яшь язучылар үстерүгә хәләл өлешем керде», – ди ул, бу еллар хакында сүзгә күчкәч.

Редакция юлын ул елларда үзем дә еш таптадым, шактый күп мәкаләләр яздым: Йосыф абый һәм журналист кызлар утырган бүлмәгә килеп керүгә, үз кеше итеп кабул итәләр иде. (Бүген дә, Аллага шөкер, ул якынлык әле дә сизелеп тора.) Йосыф абый урын тәкъдим итә, «Тукай турында нинди яңа сүз әйттең икән, әллә тапталган җөмләләр тулы язма микән», дигәндәй, мәкаләңә күз йөртеп ала да, канәгать булып, язманы өстәленә куя. Озакламый мәкалә басылып та чыга. Авыл хәбәрчеләре белән тыгыз элемтә булдыруда журналистларның хезмәте әйтеп бетергесез зур. Аларга төрле хатлар килә, кемдер инәдән дөя ясап, шикаять яза, барып тикшерергә, ачыклык кертергә, хатларга җавап бирергә кирәк. Гаделлек тә, тәвәккәллек тә, түгәллек тә таләп ителә журналисттан. Хезмәт хакы түләнми торган җәмәгать эшләрен дә җилкәң күтәрә алган кадәр алып барырга кирәк бит әле, Йосыф абый бу яктан «бик бай» – 15ләп йөк салына аның иңнәренә. КПСС райкомының контроль-ревизия комиссиясе әгъзасы, Актаныш бистәсе депутаты, «Агыйдел дулкыннары» әдәби берләшмәсе җитәкчесе... ТРның Язучылар берлегендә әгъза булып торган кырыкка якын актанышлыларның күбесе әлеге берләшмәдә канат ныгыткан. Җирлектән алтмышка якын журналист үсеп чыккан. Алар арасында бүгенге көндә республиканың мәртәбәле газета-журналларын җитәкләгән мөхәррирләрнең шактый икәнен искәртү дә урынлы булыр.

1986 елда – СССР, 1992 елда Татарстан Журналистлар берлекләренә әгъза итеп кабул ителә Йосыф Әхтәм улы. Эшче-авыл хәбәрчеләренең 5нче, Татарстан халыкларының 1нче корылтае делегаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, РФ Юстиция министрлыгыннан бирелгән көмеш медаль иясенең рәсеме республиканың Мактау тактасына куела (1982).

Йосыф Хуҗинның хезмәте мөхәррият өстәле артында утырып язылган мәкаләләре белән генә чикләнми. 2017 елда басылган китабын кертеп исәпләгәндә, ул – 12 китап авторы.

Фәнүс Моратов белән берлектә 2003 елны Казанда «Актаныш – туган җирем» дигән китап чыгарыла; аннан соң тулыландырылган, районның, Актанышның юбилейлары

уңаеннан өр-яңа итеп яңартылган икенче басмасы бастырыла. 151 авыл, оешмалар тарихын, 2200дән артык кеше язмышын сурәтләгән бу китапка үлчәүләр җитмәслек зур хезмәт салынган. Җирлекнең күренекле улы Роберт Шәкүровның портретын яктырткан «Икмәктә хикмәт», Глүс Шәрипов хакында «Язмышын иярләп тоткан ир» дигән китаплар да – Йосыф Хуҗинныкы.

Хуҗалык җитәкчеләренә багышланган «Алтын баганаларыбыз» китабы ТР Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы министры М.Г.Әхмәтовның фатихасы белән ачыла: «Бу китап шушы фидаи җаннарга, районның алтын баганаларына багышлана. Автор, Актаныш уңганнарының эшчәнлекләрен өйрәнеп, китап каһарманнарының асыл сыйфатларын ачып салган. Төбәкнең үткәннәрен яхшы белүче буларак, ул мәсьәләнең тарихи яссылыгына да басым ясый, күп белешмәләр китерә».

«Район тарихын, чорлар дәвамында район авыл хуҗалыгының үсешен, үткәнен һәм бүгенгесен барлаган, киләчәк буынга зур тарихи ядкәр калдырган елъязма авторы Йосыф ага Хуҗинга... чиксез рәхмәтемне белдерәм», – ди ул чорда ТР Премьер-министры урынбасары – мәгариф һәм фән министры булган Э.Н.Фәттахов.

– Үзем өчен иң әһәмиятле, иң кадерле китап дип, өч елдан артык эзләнүләр таләп иткән, төннәрен йокламыйча, Венера белән икәүләп язган, Иске Җияш авылы тарихын яктырткан «Уртак язмыш кояшыбыз» китабын саныйм, – ди Йосыф абый, аерым бер горурлык белән.

Мәйсәрә һәм Газинур Хәбировлар белән бергә Теләкәй авылы тарихына багышлап язылган китап исә теләкәйлеләр өчен гаять зур бүләк булгандыр.

Минем үземә, шәхсән, Йосыф Хуҗинның «Җирлегебез көзгесе» бик якын. Миңа гына түгел, читтә яшәүче якташларыбыз-авылдашларыбыз өчен дә бу хезмәт бик кадерле. Пермь өлкәсенең Барда районында яшәүче 84 яшьлек Гөлфәгыйзә Юлышева бу китапны «өстәл китабым» дип саный. Китапка сүз башын ул вакыттагы район башлыгы Ф.М.Камаев язган: «Актаныш һәм Калинин районнары газеталары мөхәррриятләрендә, бай үткәне булган җирле радиода һәм хәзерге телевидениедә эшләгән хезмәткәрләр, әдәби берләшмә мәктәбе узып танылган язучылар, каләм ияләре һәм төрле яштәге хәбәрчеләр армиясе турында мондый китап чыгу – зур тарихи вакыйга ул. Күренекле журналист Йосыф Хуҗинга һәм аңа ярдәм итүчеләргә чиксез рәхмәтемне белдерәм».

Район җитәкчеләренең хәер-фатыйхасы белән дөнья күргән әлеге китап чын мәгънәсендә тарихи бер көзге дип аталырга хаклы. Ә ул көзгедә якын танышларыңны, авылдашларыңны, үзеңне дә күрсәң, күңелеңә әйтеп бетергесез сөенеч тула. Кулга газета-журнал алуга, үзең кирәк санаган язманы укырга тотынасың, авторын карыйсың. Ә ул мәкалә сиңа килеп ирешкәнче, кемнәр кулыннан гына үтмәгән дә, кемнәрнең генә көче кермәгән, укучы ул хакта уйламый. Безгә күренмәгән хезмәт башкаручылар турында мәгълүмат бирүе белән дә Йосыф абый бик игелекле эш башкарган.

Редакциядәге эш, нәкъ укытучыныкы кебек, өйгә ияреп кайтадыр, дип уйлыйм. Анда эшләүчеләр өчен дә эш сәгате дигән төшенчә юктыр... Янәшәңдә сине аңлаучы, хезмәтеңнең тәмен-ямен уртаклашучы кеше булса гына, авырлыклары да җиңеләя төшәдер... Бу яктан караганда, Йосыф абыйның янәшәсендә нәкъ менә Венера апаның булуы олы бер бәхеттер. Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау кәгазе белән бүләкләнеп, хезмәт ветераны исеме алып, лаеклы ялга чыкканчы, Венера апа балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Үзенең мөлаемлыгы, йомшак сүзе, ягымлылыгы белән сабыйлар күңеленә кереп калгандыр ул. «Йосыф абый өйдә нинди?» – дигән самими соравыма: «Гадел, игътибарлы, ярдәмчел, башта мине, балаларны, аннан соң гына үзен кайгырта. Ул – дөньяны алып баручы. Таяк белән йөрсә дә, бервакытта да зарланмады», – дип, җәһәт кенә ирен мактап алды. Ике бала тәрбияләп үстергәннәр, үзләренә аларны терәк итеп тоялар.

Кызлары Зөлфия – Актаныш балалар сәнгать мәктәбендә фортепиано укытучысы, инде бик күп еллар шул бүлекне җитәкли. Укучылары ел саен мәктәп, республика, региональ һәм халыкара бәйгеләрдә катнашып, төрле дәрәҗәдәге урыннар яулыйлар.

– Әти – чын гаилә башлыгы, әни белән безнең өчен янып яши. Ул бик укымышлы, тырыш, эшчән һәм таләпчән. Ярдәмчел, туган җанлы, кешелекле. Без аны бик яратабыз

һәм хөрмәт итәбез, – диде Зөлфия, әтисе белән ихлас горурлануын яшермичә. Йосыф абыйның оныклары Азалиягә дә бик кадерле дәү әти булганлыгы сүз сөрешеннән үк аңлашылып тора иде.

Уллары Рәеф чит телләр белгечлегенә укыган. Казанның Яңа Савин районы балалар-яшүсмерләр хәрби-патриотик эзләнүләр клубы директоры вазифаларын башкарган, ел саен Ленинград өлкәсендә, Татарстан районнарында Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалган яугирләрнең язмышларын ачыклау экспедицияләрендә штаб башлыгы булган, «Хәтер» китабына мәгълүматлар туплауда катнашкан. КХТИның кичке бүлеген тәмамлаган. Нәсел шәҗәрәсен Рәефнең уллары Руслан белән Данияр дәвам итә.

Йосыф абыйның «мактанырга» яратмаганын алдан ук искәртеп куйган идем. Үзе турында язарга да, сөйләргә дә атлыгып тормаган героем хакында бер-ике сүз әйтүләрен үтенеп, хезмәттәшләренә мөрәҗәгать итәргә туры килде. Йосыф Хуҗин белән озак еллар бергә эшләгән Филиза Сәлахова: «Йосыф абыйны «аяклы энциклопедия», дип йөрттек. Искиткеч хәтерле, белемле, бик күп укыган. Актанышның бөтен халкын таный. Үзе язган кешесенең туган-тумачасына кадәр белер», – дип бәя бирде аңа.

Газетаның элекке мөхәррире Нурулла Нурлыев: «Йосыф абый – бик принципиаль, үз фикере булган, үзенә дә, башкаларга да таләпчән, төгәл журналист. Тиешле материалны кирәкле вакытка әзерләп җиткерә иде», – дип уртаклашты.

«Актаныш таңнары» газетасының бүгенге яшь мөхәррире Руслан Усмановның да әйтер сүзе бар: «Мин мөхәррияткә эшкә «урамнан» килеп кердем. Мине Йосыф абыйга беркеттеләр. Нәрсә күрәм, ничек бар – шулай язам. Мәкаләне Йосыф абыйга күрсәтәм. Ә ул, уфылдап, җөмләләремне, сүзләремне төзәтә, төзәтә торгач, кай җиренең язарга яраклы икәне дә беленми башлый. Шуңа күрә кызыл яза торган ручка алып килдем. Йосыф Әхтәм улы Хуҗинны зур хәрефләр белән язарлык Укытучым, Остазым дип саныйм».

Үзең эшләп киткән коллективның мондый бәясе һәртөрле Мактау кәгазьләреннән дә артыграктыр...

*Акыл белән гамәл кыла белгән*
*Халыкта тик шәхес табыла.*
*Халык белән шәхес даны үсә,*
*Шәхес белән – халык таныла,*

– дип язган якташыбыз Э.Шәрифуллина.

Ләкин... татар халкының күпме улларын, кызларын республика күләмендә таныткан, күпме тарихи китаплар язган авторның хезмәтләре, ни кызганыч, әлегә тиешенчә бәясен алмаган. «Ике кат яшәми берәү дә, чәчәкләр бирегез кешегә», – дип язган Гамил Афзал бик хаклы...

Бу очрашуда мин Йосыф абыйны Әбүгалисинага охшаттым. Тирә-ягы китаплар белән шыплап тулган бүлмә, өстәлдә компьютер, шулар арасында башына кәләпүш кигән, ак сакаллы Йосыф абый утыра. Мин сорау биргән саен, урыннан кузгалып, таягына таянып, әле теге, әле бу папканы яисә китапны тартып чыгара. Җитмешнең аръягына чыкса да, искиткеч хәтере һәм төгәллеге белән сокландырып, белемен башкалар белән бүлешеп, бүген дә кайсыдыр авылларның тарихын барлап утыруы... Татар халкының менә нинди шәхесләре бар, дип, алар хакында башкаларга җиткерергә омтылуы... Милләтебезнең горурлыгы булырдай тарихлар бар, кешеләр бар: ишетегез, күрегез, килер буыннарга тапшырыгыз, дип җан атуы...

**Зәлифә ӘХМӘТГАЛИЕВА.**
*Актаныш районы Качкын авылы*

*Балалар язучысы Роза Сәет кызы Хафизова (1929-2005) 1929 елның 6 февралендә Татарстанның Бөгелмә шәһәрендә туа. Үз төбәгендә урта белем алганнан соң, 1947-1951 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә укый. Берничә ел Төмән өлкәсенең Тубыл шәһәрендә укытучы булып эшли.*

*Роза Хафизованың шуннан соңгы хезмәт юлы журналистика белән бәйле. Ул 1962-1986 елларда бүгенге «Ялкын» балалар журналының баш мөхәррире була.*

*Роза Хафизова – үзенең иҗатын тулысынча балаларга багышлаган әдибә. Язучының беренче җыентыгы 1967 елда басылып чыга. Шуннан соң аның «Курай-малай маҗаралары», «Кирләмән», «Кашкарыйлар озын гомерле», «Әкиятләр», «Без әле кайтырбыз», «Сак-Сок тавышы», «Киек каз юлы», «Актәпи ник моңая?», «Карурманда ниләр булмас» кебек китаплары дөнья күрә. Аның аерым әсәрләре рус, үзбәк, казакъ, украин һәм башка телләргә тәрҗемә ителгән.*

*Язучының «Сөенечле хәбәр», «Әти кайткан көнне» кебек хикәяләре – балалар һәм яшүсмерләр әдәбиятына керткән зур өлеше. Сугыш елы малайларының күңел халәтен, фронттан гаярь солдатларны – әтиләрен көткән балаларның бар табигатен ачкан хикәяләр әдәби фондта үз урынын алырга лаек.*

*Роза Хафизованың 90 еллыгы уңаеннан, әлеге санда «Әти кайткан көнне» хикәясен тәкъдим итәбез.*



Роза
Хафизова

# ӘТИ КАЙТКАН КӨННЕ

ХИКӘЯ

Бу тавык дигәнеңнән дә әрсез мал бармы икән дөньяда? Иртән инәй пешереп калдырган бәрәңге кабыгын урыпмы уралар. Алларына сибә торасың, тыпыр-тыпыр чүпли генә торалар. Ул гына җитми әле, әтәче, кызыл кикриген кукрайтып, ко-ко-колап өстеңә килә. Авыз ачып торсаң, табагыңа очып кунар. Көш-ш-ш, килбәтсезләр, убырлар!

Мин шулай туймас тамак тавыкларны тирги-тирги ашатып маташа идем, бәрелә-сугыла чабып Солтан килеп керде.

– Малай, яшьләр быел Сабан туе ясыйбыз, дип әйтәләр, ди. Югары оч Ибрай абый әйтә: «Көч җыеп торыгыз, сыбызгы борыннар, Сабан туенда сезне көрәштерәбез», – ди.

Солтан, Ибрай абыйга охшатып күкрәген киереп, тавышын калынайтып сөйли. Киндер күлмәк астыннан очлы кулбашлары тырпаеп тора. Куллары килбәтсез озын, үзе ябык. Хәер, ябык булмый нишләсен, бер дә туйганчы ашаганы юк ич аның. Карт әбисе белән генә тора. Әтисе, Сәгыйть абзый,

сугышка минем әти белән бергә китте. Китте дә югалды. Бер генә хаты килде. Әнисе белән ике энесе кышлаган башак ашап агуланып үлделәр. Солтан мәктәптә булып кына калды. Язын әниләре кырдан башак җыеп кайтып, ботка пешергән дә, өйдәгеләр туйганчы ашаганнар. Әбиләрен сөлек салырга дип түбән очка алып киткән булганнар. Югыйсә, Солтан да, әбисе дә исән каласы түгел икән.

Минем бер дә сер бирәсем килми:

– Көрәштерсәләр, көрәшәбез аны, – дигән булам. Үземнең йөрәк еш-еш тибә. Их, яшьтәшләреңне җиңеп, батыр калсаң! Җиңүче кешене, бер кулын югары күтәртеп, мәйдан әйләндерәләр, аннары аңа бер-бер затлы бүләк бирәләр, диләр. Сугышка хәтле Сабан туйларын күргән зуррак малайлар сөйли.

– Әйдә, хәзер үк көч сынашабыз. Ибрай абый әйтә, күнекмәләр ясый торыгыз, ди.

– Әйдә соң! – Мин бушаган көрпә савытын тавыклар алдына куйдым. Без, ишегалды уртасына, яшел чирәмгә чыгып, чын көрәшчеләр шикелле кара-каршы бастык та бөтен шартын китереп көрәшергә тотындык. Минем чалбар каеш белән буган, әтидән калган каеш. Солтанның чалбары киндерә белән генә бәйләгән. Шуңа күрә аңа мине эләктерүе җиңел. Аннары, ул, ябык булса да, буйга миннән бераз калкурак. Шуңа күрә тиз генә селкеп салырмын димә.

Без мышный-мышный шактый әүмәкләштек. Әле ул өскә чыга, әле мин. Безнең көрәшүне сагаеп күзәтеп торган әтәч, ко-ко-колап, аваз салды, аннары, бөтен тавыкбикәләрен җыеп, лапас астына тирес тибәргә алып китте. Актүшнең генә исе китмәде. Кояшта кызынып, өй нигезендә яткан килеш, әле бер, әле икенче күзен ачкалап, «маташасыз шунда» дигән кебек карангалап куйды.

Ниһаять, хәлдән тайдык. Чирәмдә аунаган җирдән, еш-еш сулу алып, тезләрне кочаклап, торып утырдык. Мин кинәт Фатихның байтак вакыт ишегалдында юклыгын искәреп алдым. Шундук сикереп торып, каударланып, урамга йөгердем. Минем арттан калын тавышы белән һау-һаулап Актүш ташланды. Шайтан малай, кая киткән инде тагы?! Һич өйдә тормас. Артыннан гел ияреп йөрергә генә кирәк. «Фатих! Фатих! – дим. – Фатих!» Солтан да атылып чыкты.

Урамда шылт иткән тавыш, кош-корт, бала-чага юк. Кайдан килсен ди ул бала-чага? Булганы тау астында каз көтә, мал ашатырга әрәмәдән үлән ташый.

Солтан белән чишмә буйларын әйләндек, бакчалар аша гына тау астына, Шушма буена йөгереп төштек. Күктә кояш кыздыра, бөтен җирдә яшеллек. Җылы, рәхәт. Әрәмәлектә кошлар сайрый. Ә Фатих юк. Шушмага баткан булса, әнигә ни җаваплар бирермен?! Утауга киткәндә, миңа ышандырып калдырды ич ул аны! «Тугыз яшеңә җитеп, шул баланы да карамагансың», – дияр. «Фатих! Фатих!» – дим. Бәлки, өйгә кайткандыр инде, дип, җан-фәрман чабып кире кайттык. Юк. Ишегалдында тып-тын! Инде нишләргә? Кемнән ярдәм сорарга? Кайларга барырга?!

– Силсәвиткә заявить итәргә кирәк, – ди Солтан. Тирә-күршеләрдән берсе дә өйдә юк, ичмасам. Әй, Зөлхия апа өйдә ич бүген. Мин, Солтанга берни әйтми, Зөлхия апаларга йөгердем. Сулуым кабып, дөбер-шатыр барып керсәм, ни күрим: идәнгә җәйгән палас өстендә безнең Фатих белән Зөлхия апаның малае Тәлгать шуышып йөриләр. Фатих кәҗә булып Тәлгатьне сөзәргә килә, тегесе шырык-шырык көлә. Зөлхия апа почмак сәкесе өстендә савыт-саба юа. Күрәсең, хәзер генә ашаганнардыр. Фатих миңа игътибар да итеп тормады, уйнавында булды. Мин аны чатыр чабып эзләп йөрим тагы. Үземне үзем

шундый кызгандым, күземә яшьләр килде. Зөлхия апа: «Әйдә, уз, үскәнем», – дигән була.

– Мин аны бөтен җирдән эзләп йөрим...

– Баядан бирле уйныйлар инде алар, уйнасыннар, – диде Зөлхия апа. – Бәрәңге пешереп ашаттым үзләренә... – Ул зур коңгырт күзләрен тутырып миңа карады. Әйтерсең лә аның минем алда да зур гаебе бар. Тәлгатьне ул каядыр урман кисәргә барган җиреннән алып кайтты. «Җилдән туган», – ди аны Солтан. Зөлхия апаның әнисе, Фатыйма әби, Тәлгать туганчы ук дөнья куйды. Исән чагында ул гел безгә керә, әни белән озаклап сөйләшеп утыралар иде. «Язмыш шулайдыр инде, Сәкинә, бу хурлыкларны күрермен дип үстермәгән идем кызымны», – дип кабатлый, әледән-әле күзләрен сөртә иде. Башта мин Зөлхия апаның гаебе нидә икәнен аңламый аптырадым. Бәләкәй булынган. Аннары Солтан аңлатып бирде: «Әби әйтә, ирсез бала тапкан кызларны элек ат койрыгына тагып йөрткәннәр, ди. Аннан да хурлыклы эш дөньяда юк та, ди».

Нихәл итәсең?! Ни генә булса да, яратам мин Зөлхия апаны. Үзебезнең кәҗә белән бергә алар кәҗәсен дә көтүдән юыртып кайтам. Бер-бер йомыш кушса, рәхәтләнеп үтим. Чибәр ул Зөлхия апа, башка хатыннарга охшамаган да. Билләре сыгылып тора. Чәчләре саргылт, толымнары тезенә җиткән, йөзе ап-ак. Ул колхозның яшелчә бакчасында эшли. Тәлгатьне эшкә бәләкәй арба белән тартып йөри. Эшкә бармаганда, өеннән бик сирәк чыга. Үзләренә дә безнең әнидән башка кеше керми. Хатын-кызларның аның белән сөйләшкәнен күргәнем юк, никтер озак итеп артыннан гына карап калалар. Кызганалармы, гаеплиләрме? Өлкәннәрнең уен кем белә?

Уф! Ярый әле, суга батып үлмәгән икән. Фатихны әйтәм. Мин, берни әйтмичә, тиз генә чыгып киттем. Уйнасын әйдә. Озакламый инәй кайтыр вакыт җитә. Минем әле кисмәккә су ташыйсым, утын ярасым, казларны барлыйсым бар. Инәй кайтуга самавыр тергезергә дә кирәк.

Солтан белән Актүш мине урамда көтәләр иде. Фатихның табылуын кыяфәтемнән үк таныдылар. «Без чабулап йөрибез, ул уйнап ята», – диде Солтан, үзе читкә төкереп куйды. Энемә сүз әйттерәсем килмәде: «Бәләкәй бит әле ул, аңламый», – дидем. Солтан, ничек килсә шулай, кисәк кенә китеп барды. Мин шактый югары күтәрелеп, сөйкемле елмаючы кояшка карап алдым. Вакыт үтә, эшлисе эшләр тау чаклы. Озакламый төшке ашка инәй кайтыр.

Мин, тиз генә лапас астына кереп, чыбык-чабык ташый башладым. Лапас асты утыннан бушап бара. Соңгы чыбык-чабыкны ташыйм. Көзгә хәтле әти кайтмаса, ничек тагын утын юнәтәсе булыр. Күптәннән ярылмыйча яткан түмәрләрне ярмакчы булып карыйм. Их, көч җитеп бетми шул әле минем, ни әйтсәң дә, тугыз яшь кенә шул әле миңа. Шундый бер тылсымлы машина уйлап табасы икән ул. Утынны үзеннән-үзе турасын иде. Машинаны ярып булмый торган түмәр янына китереп терәвең була, ул, чаж-чож килеп, үзеннән-үзе ярыла да китә. Уф, арытты, җитәр бүгенгә. Мин, үзем тураган бер кочак чыбык-чабыкны күтәреп, өйгә юнәлдем. Шулчак өнсез калдым, кулымнан чыбык-чабык коелды: бер ир кеше безнең капканы ачып маташа. Капка ярыгыннан аның кояшта ашалган гимнастёркасы күренеп калды. «Әти, әти кайткан!» Мин урынымнан кузгалмакчы булам, кузгала алмыйм, нидер эндәшмәкче булам, телем тотлыга. Ул арада ир кеше, капканы ачып, ишегалдына керде. Як-ягына каранды. Юк, минем әти түгел бу, үзе яшь, буе да озынрак, кап-кара кашлары кылыч борыны өстендә бер-берләренә килеп үк тоташканнар. Җилкәсендә солдат капчыгы. Юк, бу абый безнең авыл кешесе дә түгел.

Кәефем китте. Ымсынуым гына булган икән шул.

Солдат минем белән авызын ерып исәнләште. Аннары:

– Энем, бу Зөлхия апаңнар йортымы? – дип сорады.

– Зөлхия апаларныкы тегесе, абый. Сиңа алар кирәк идемени? Әйдә, күрсәтәм. Безнең малай да аларда әле.

Без солдат белән урамга чыктык. Зөлхия апалар капкасы төбендә солдат абый туктап калды.

– Энем, Зөлхия апаңны чакырып чыгара алмассыңмы? – дип үтенде. Аның тавышы ничектер бик кыюсыз чыкты. Ник чакырмаска, чакырабыз аны!

Мин, ук кебек атылып, Зөлхия апаларга кереп киттем. Керә-керешкә үк: «Зөлхия апа, сине бер абый чакыра!» – дип сөрән салдым.

Зөлхия апаның кулыннан бәйләме төшеп китте. Ул агарынды, зәңгәр күзләрен зур итеп ачып миңа карады һәм ишеккә атылды. Мин аңа иярдем.

Әлеге абый капка баганасына сөялеп тора иде. Зөлхия апаны күрүгә, аңа таба бер адым ясады да туктап калды. Зөлхия апа да, аңа җитәр-җитмәс, никтер туктады. Тик торалар катып. Читтән карап торулары кызык. Ниһаять, солдат абый кымшанып куйды, кочагын җәйде. Зөлхия апа: «Тимербай!» – дип, аңа таба атылды.

Зөлхия апа Тимербай абыйның кочагына капланып үкси-үкси елый иде. Тимербай абый аның чәченнән, аркасыннан сыйпый, тынычландырырга тырыша. «Йә, булды, булды, гүзәлем», – дип, бертуктаусыз кабатлый иде.

Зөлхия апа башын күтәрде, яшьле күзләре белән елмайды, әйтерсең лә кояшлы яңгыр явып узды. «Мин синең килереңә ышандым, Тимербай!» – диде. Аннары, миңа таба борылып, горур тавыш белән: «Бу синең Тимербай җизнәң була, үскәнем», – диде. Мин шунда гына үземнең алар янында кабер өстендәге таш кебек кукраеп торуымны аңлап алдым. Тимербай абый, кесәсеннән яшькелт саплы пәке чыгарып, миңа сузды. «Менә, җегет, Зөлхия апаңнан сөенче алган өчен!» – диде.

Мондый пәкенең әле дөньяда да булганы юктыр. Биш япьле. Мин аларны шундук ачып карадым. Зурлы-бәләкәйле ике пычагы, боравы, чәнечкесе, кашыгы бар. Сабы кояшта елык-елык итеп, әле яшькелт, әле зәңгәрсу булып күренә. Пәкене шундук Солтанга күрсәтәсем килсә дә түздем. Кулыма йомарлап, йодрыгымны чалбар кесәсенә тыктым да Зөлхия апа белән Тимербай абый артыннан өйләренә кердем.

Мин кергәндә, Тимербай абый сәкедә тәгәрәп йоклап яткан Фатих белән Тәлгать янына баскан да бер Зөлхия апага, бер малайларга карап тик тора. Әллә аптырабрак та калган тагы. Шулчак Зөлхия апа оялчан гына елмаеп куйды. Аннары йөзе кинәт никтер кырысланып китте, әйтерсең лә салкын җил исеп куйды. Ул, Тәлгать өстенә иелеп, аның башыннан сыйпады. Мин әле Зөлхия апаны бу хәтле чибәр итеп күргәнем юк иде. Тәлгатькә аның кулы түгел, аккош канаты кагылды, диярсең. Саклык белән генә, ләкин бик горурланып кагылды ул аңа. Тимербай абыйга да астан өскә сөзеп карады. Үз артыннан карап калучы түтәйләргә ул гел шулай карый иде.

Тимербай абый тәмам шашты. Ни әйтергә белми, бер Тәлгатькә, бер Зөлхия апага карады, каушады. Кулын әле кесәсенә тыга, әле ала. Аннары кинәт Зөлхия апага таба атлады да, аны күтәреп алып, идән буйлап әйләндереп йөртә башлады. Үзе аның битләреннән, чәчләреннән үбә. «Зөлхиям, Зөлхиям», – дип кабатлый иде. Зөлхия апа бер үк вакытта елый да, көлә дә иде. Тимербай абый аны сәкегә утыртты да үзе Тәлгать каршына килеп тезләнде. Аның

чәченнән сыйпады. Тәлгать, берни сизми, тәгәрәп йоклый иде. Их, җүләр малай, әтисе кайтуын да сизми калды бит, әй! Һи, ни әйтәсең аңа, бәләкәй ич әле ул, әтисен бөтенләй күргәне дә юк. Мин шулчак Тәлгатьнең нәкъ Тимербай абыйга охшаган икәнен абайлап алдым. Шундый ук борын, кашлар, авыз. Бик көнләштем мин аннан. Әнә, ул нинди бәләкәй булса да, әтисе кайтты. Йокларга ятканда әтисе юк иде, уянгач, бар!

Өйдәге ыгы-зыгыны тоептыр инде, безнең Фатих уянды. Күзләрен ачты, гаҗәпләнеп Тимербай абыйга, миңа карады. Зөлхия апа күбәләк кебек очынып аш әзерләп йөри, үзе Тәлгать алдында тезләнгән Тимербай абыйга әледән-әле карап куя, сөйкемле елмая. Минем аның бүгенгедәй шат, бәхетле чагын башка беркайчан да күргәнем булмады.

Фатихның уянганын күргәч, Зөлхия апа киштәдән ике конфет алып, берсен миңа, берсен Фатихка бирде. «Барыгыз, өегезгә кайтыгыз, наныем, иртәгә тагын килерсез», – дип, аркабыздан йомшак кына сөеп, безне ишектән чыгарып җибәрде.

Күңелне җылытып, кесә төбендә биш япьле пәке ята. Мин, бармакларым белән капшап, аның япьләрен барлыйм, сыйпыйм. Минем әле беркайчан да мондый пәкене тотып караганым юк иде. Фатих кына күрә күрмәсен, «бир дә бир», дип, дөнья куптарыр. Тизрәк Солтаннарга барасы иде дә бит, озакламый инәй кайтыр, минем әле ярты эшем дә эшләнмәгән. Ярый, Солтаннар качмас әле...

***

Сабан туе да килеп җитте. Мин һаман әтинең кайтуын көтәм. Инәй дә: «Бу арада хат-хәбәре дә юк, юлда түгелме икән?» – дип сөйләнә. Колхоз эшенә киткәнче, иртә-кич өйләрне, ишегалларын ялт иттереп чистартып куйды. «Әтиегез кайтуына чиста торсын», – ди. Фатихның гына исе дә китми, чөнки аның әтине бер дә күргәне юк. Көчле икәнен дә, бәләкәй чагымда мине уч төбенә утыртып, баш өстенә күтәрүен дә белми. Батыр Мисбах кушаматлы икәнен белми дә белми инде. Мин энемне кызганам да, кайчакларда ачуым да килә. Теле ачылганнан бирле бар белгән сүзе: «Бир, миңа, мин дә барам!» Һичкая барыр хәл юк, чабуга тагылып йөри, бер тотам калмый. Тукмаклап булса да калдырыр идем, соңыннан инәйдән үземә эләгә. Әләкләвен генә кара әле син: «Инәй, баланы кыерсыта!» Менә шундый инде ул минем энем. Шуңа күрә пәкене аңа күрсәтмим. Ул йоклаган чакта йә әни янында кайнашканда, аннан качып кына уйныйм. Кесәдә пәке булгач, сөлге котлатып йөрүче егетләр артыннан да иярәсем килмәде. Ни кызыгы бар аның, сөлге котлатуның? Берәр йорт янына киләләр дә апалардан күкәй, кызлардан кулъяулык даулыйлар. Солтан белән бер-ике урамда йөреп караган идек, туйдырды, аларга кайтып, пәкеле уйнарга утырдык.

Солтанның да күзләре кызды пәкегә. Үзләренең Зөлхия апалар күршесендә яшәмәүләренә үкенеп бетә алмады. Тимербай абыйның үзләре турыннан узганын да күрә алмый калган. Күреп, каршысына чыкса, пәке аныкы буласы икән. Пәкесе дә бик хикмәтле шул. Сабы елкылдап торгач, Солтан башта аны «фашист пәкесе» дип хурлап маташкан иде дә, әйләндерә-әйләндерә карый торгач, пычак сыртында «Союз» дип язылган җирен күреп алдык. Димәк, үзебезнеке, бернинди дә фашистларныкы түгел. Пәкене күргән саен, Солтан авыр сулап куя. Мин аңа пәкене тотып карарга бирәм, кызганмыйм.

Солтан пәке урынына үзләренең бәрәңге әрчи торган пычаклары белән уйный. Үткен пычак ул. Сугышка киткәнче, әтисе аны чалгы кыйпылчыгыннан ясаган. Үзе бәләкәй генә. Солтан аны гел кесәсендә йөртә. Пәкем юк чакта мин аңа бик кызыга идем.

Солтан, үз чиратында, чалгы пычагын һавада мәтәлчек аттырып, йомшак кара туфракка батырды. Аннары кинәт әсәренеп әйтеп куйды:

– Әгәр дә ки Сабан туена эти кайтса, сөенче алучыга бөтен булган малымны бирергә дә риза!

Минем дә сынатасым килмәде:

– Сөенче алучыга мин пәкемне дә кызганмас идем әле, – дидем.

Солтан очынып китте: «Чынмы, малай, чынмы?!» – дип сөйләнә-сөйләнә, капка төпләренә йөгереп барып, юлга карады. Аларның йорты калкулыкта утыра. Районнан кайта торган юл уч төбендәге кебек ярылып ята. Әтисеннән инде өч елдан артык хәбәр-хәтер булмаса да, Солтан һаман юлдан күзен алмый, аны көтә. «Безнең әти разведчик иде. Разведчиклар бик җитез була алар, исәндер, кайтыр», – дип, мине дә ышандырырга тырыша.

– Чынлап та бирәсеңме, малай, Сабан туена түгел, теләсә кайчан кайтса да бирәсеңме?

– Сөенчесен алганга бирәм!

Солтан пәкенең япьләрен ачып-ябып карады. Кашыгын, чәнечкесен капшады. Кызык, мондый бәләкәй кашык белән ашны ничек ашыйлар икән? Без бәрәңге шулпасын агач кашык белән генә ашыйбыз. Анда да әле эчендә берән-сәрән йөзеп йөргән бәрәңгеләрен башта кашык белән алабыз да шулпасын савыты белән күтәреп кенә эчәбез. Ашау искә төштеме, борып эч авырта башлый, уенның да кызыгы калмый. Мин пәкене кысып тоткан кулны кесәгә тыктым да өйгә йөгердем. Озаграк йөрелде шул биләмдә, инәй мине тиргәп ташлады.

– Көне-төне биләм дә биләм. Кәҗәгә кышка печәнне кем әзерләр дисең соң син?! – Ул, мине тирги-тирги сәкегә ашъяулык җәеп, аш урыны әзерләп маташа. – Ашагач ук Фатихны ияртеп әрәмәлеккә менеп төш, ишетсен колагың. Ярты капчык булса да үлән җыеп төшәрсез. Иртәгә Сабан туе дип көнең узар...

***

Без әрәмәлектән чыкканда, көн кичкә авышкан иде инде. Шушма буендагы таллыкта өзеп-өзеп кошлар сайрый. Үлән арасында чикерткәләр черелди. Сарут исе борыннарны яра. Әрәмәлектә, ышыкта үскән үлән каты булмый, капчыкны Фатих белән уйный-көлә генә бик тиз тутырдык. Энемнең куллары бәләкәй генә булса да, миннән күрмеш, җыепмы-җыя. Тик ул бөкрәеп эшли алмый, тезләнеп шуышып йөри, чалбар балагын пычратып бетерә. Ни әйтсәң дә, бәләкәй шул әле, биш яше дә тулмаган. Кайткан чакта, арбага утырт, дип теңкәгә тиячәк әле ул. Аңа карап-карап алам. Әти кайтса, бер кәҗәлек кенә печән юнәтер иде әле, дип тә уйлап куям. Уф, ярый, булды бу!

Мин капчыкның авызын бәйләдем. Аннары Фатих белән икәүләп аны бәләкәй арбага күтәреп салдык та пар ат булып җигелеп кузгалдык. Әрәмәне чыккач, үр менәсе. Шуннан соң олы юлга чыгабыз, кайгы китә. Такыр юлдан арба үзе үк тәгәрәп барачак. Үр менгәндә, мин алдан тартам, Фатих арттан этә.

Уф, менеп җиттек! Олы юлга чыгуга, хәлебез бетеп, юл читендәге чирәмгә аудык. Мин, кулымны кесәгә тыгып, пәкене барладым. Аны бик алып карыйсым килгән иде дә, түздем. Фатих күрсә, бир, дип теңкәгә тияр. Бирсәң, йә югалтыр, йә кулын кисәр. Әнә, үлән арасыннан нindидер бөҗәк тапкан да, дөньясын онытып, аны күзәтә. Кулымда пәке салкынын тойган хәлдә, чирәмгә сузылып ятып, зәңгәр күкне күзәтәм. Кояш күкнең теге ягына тәгәри. Чикерткәләр тавышын тыңлап ятуы рәхәт, күзләр үзләреннән-үзләре

йомыла. Колак төбендә генә Фатих чыркылдый: «Абый, дим, абый, менә, камка тоттым». Күземне көчкә ачып, торып утырдым. Фатих, йодрыгын ачып, кулын миңа сузды. Камка, шуны гына көткәндәй, башта үтә күренмәле канатларын чыгарды, кара бөрчекле канатларын җәйде дә очып та китте. Аның кайсы якка очканын карар өчен, урынымнан сикереп тордым һәм, юл буйлап безгә якынлашып килүче солдатны күреп, өнсез калдым. Аны Фатих та күреп алды. Солдат, зур-зур адымнар ясап, ашыга-ашыга атлый. Өстендә гимнастёрка. Гимнастёрка өстеннән буган каешының перәшкәсе ялтырап тора. Солдат миңа никтер таныш кебек тоелды. Аяк атлавымы, кулларын селтәвеме? Безнең әти түгелме соң бу?! Мин, үзем дә сизмичә: «Әти!» – дип кычкырып, солдатка каршы йөгердем. Әти, чынлап та әти! Әнә ич, кашлары, күзләре нәкъ әтинеке. Тик, карт ич бу, ябык, безнең әти тазарак иде. Мин кинәт туктап калдым. Солдат та, миңа җитәр-җитмәс, күзләрен зур ачып туктады. Никтер каушады, аптырап, бер миңа, бер Фатихка карады. Аннары кинәт: «Улым, Мансур!» – дип, алга ыргылды һәм мине кочаклап алды. Мин башымны әтигә төрттем һәм күптән онытылган, ләкин бик таныш, тәмле ис, әти исен тойдым. Артык түзәрлегем калмады, шатлыктан үксеп елап җибәрдем. Шулчак Фатих исемә төште. Соң, аның әле этине беркайчан да күргәне юк ич. Мин әтидән читкә тайпылдым. Фатих инде безнең янга килеп баскан, бармагы белән борынын казып, бер әтигә, бер миңа карап тора. Үзе менә-менә елап җибәрергә җыена. Елый башлаганда ул гел борынын казый. «Әти, бу – Фатих», – дидем. Әти үзе дә аңлап алды бугай. (Фатих суйган да каплаган мин ич!) «Кара, нинди дәү булган минем Фатих улым», – дип, аның алдына чүгәләде. (Бәләкәй чагымда ул мине гел баш өстенә күтәрә иде ич, ник Фатихны күтәрмәде икән?!)

Әти Фатихны чүгәләгән килеш кочагына алып сөйде: «Улым, дәү үскән улым минем!» Мин дә әтигә килеп сыендым. Әти ничектер бик авырлык белән генә тураеп басты. Юл уртасында торган бәләкәй арбага игътибар итте, һәм аның ике күзеннән мөлдерәп ике тамчы яшь атылып чыкты. Ул күз яшьләрен кул аркасы белән сөртеп алды да шат тавыш белән кычкырып җибәрде:

– Яле, кайсыгыз арбага утыра?! – Әти, тиз генә биштәрен аркасыннан салып, арбага куйды. Шунда гына мин сугышка киткәндәге әтинең тавышын, үзен танып алдым. Күңелемә рәхәт бер җылы йөгерде, елмаеп җибәрдем. Фатих «әһ» дигәнче печән тулы капчык өстенә менеп атланды. Мин Фатих артыннан арбага менәргә оялдым. Зур ич инде мин, әтинең биленнән.

Без өчәү – әти, Фатих, мин – өйгә кайтып киттек. Әти арба тарта. Мин аның бер алдына, бер артына төшеп чабулыйм. Арба тартмагач, рәхәт, күңелле. Шуңадыр, телгә ни килсә, шуны такылдыйм. «И, инәй шатланыр инде, бүген ул утауга бармады. Иртәгә Сабан туе. Инәйдән үзем сөенче алам!» Фатих бер дә юкка кычкырып көлә. Әти дә, бара-бара да, «алуяу» дип кычкырып, юыртып ала.

Без шулай шау-гөр килеп авылга кердек. Мин ерактан ук Солтанның капка төпләрендә юанып торганын күреп алдым. Ул безнең якка текәлеп карап торды да кирегә йөгерде.

– Солтан инәйдән сөенче алырга йөгерде, йөгерсен, әйдә, – дидем. Фатих күрмәсен өчен, әти алдына чыгып, аңа тиз генә пәкене күрсәтеп алдым.

– Син кайтканны алдан күреп, миннән сөенче алса, мин аңа пәкемне бирәсе идем. Зөлхия апаның ире Тимербай абый аны миңа сөенчегә бирде.

– Солтанның әтисе дә кайтмаган, пәкесе дә юк икән, алайса...

Миңа никтер уңайсыз булып китте. Шулчак безгә таба йөгергән әнине

күреп алдым. Әнине күрүгә, эти никтер туктап калды. Арба тәртәсен җиргә куйды. Әни, кила-килешкә, этинең кочагына ташланды. Алар бер сүз дә эндәшмәделәр. Мин тагын эти белән әнигә барып сыендым. Фатих кына арбада кукраеп утыра бирде. Беләм мин аны, гомер буе да арбадан төшмичә, бездән тарттырып йөрергә риза ул.

Безнең әвәрә килүебезне Солтан бер читтән генә күзәтеп торды да бер дә исе китмәгән кыяфәттә өйләренә таба атлады. Ул ничектер бөкрәеп, кечерәеп калган кебек күренде, күлмәк астыннан калак сөякләре тырпаеп тора иде. Бик кызгандым мин аны: этисе дә сугыштан кайтмады, пәкесез дә калды. Сөенче ала алмады ич!

– Солтан! – Ул минем тавышка әйләнеп карады. Йөзе суырылып киткән, күзләре эчкә баткан, үзе, сер бирмәскә тырышып, ике кулын кесәсенә тыккан иде. – Әйдә безгә!

Солтан, башын селкеп, китеп барды.

Эти кайтуга, ишегалдына шундук ямь керде. Тавыкларга хәтле күңеллерәк итеп җырлыйдыр кебек тоелды. Актүшне әйткән дә юк. Эти сугышка киткәндә, ул әле бәләкәй көчек кенә булган. Шулай да этине таныды. Башта бик озаклап иснәде, һау-һаулап өрде, аннары чиный-чиный өстенә сикергәләде. Койрыгын болгый-болгый куанды.

Өйдә эти булгач, бик күңелле иде. Безнең шундук кадер артты. Ул миңа йолдызлы перәшкәле чын солдат каешы да алып кайткан әле. Минем хәзер этием дә, пәкем дә, солдат каешым да бар. Ләкин никтер күңелемне корт кимерә. Солтанның калак сөякләре калкып торган аркасы, ябык йөзе, ничектер бик ямансу карашы күз алдымда тора. Без өйдә бәйрәм итәбез, күрше-тирә керә-чыга. Инәй өстәлгә табагы белән бәрәңге пешереп утыртты. Эти бер туймас тавыкны суеп ташлады. Үзе: «Ике малайга – ике бот», – дип елмаеп сөйләнә. Фатих аның чабуына тагылган да бер адым калмый тагылып йөри. Кирәксә-кирәкмәсә дә, «эти, эти», дип кабатлый, туйдырып бетерер әле менә. Әнә муенына Тәлгатьне атландырган Тимербай абый белән Зөлхия апа да килеп керде. Тәлгать этисенең муенында патша кебек утыра. Бер Солтан өйләрендә ялгызы. Мин түзмәдем, аларга йөгердем. Бөтен рәхәт миңа гына булса, эчем күбәр!

Солтан лапас астында чыбык-чабык тапап маташа иде. Мине күргәч, балтасын сүзсез генә түмәргә чапты. Мин килә-килешкә аңа пәкене суздым.

– Сиңа булсын, – дидем.

Солтан, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, бер миңа, бер яшелле-зәңгәрле булып ялтыраган пәке сабына карап катып калды.

– Чынлапмы, малай?! – Солтан, кыяр-кыймас кына, кулын миңа сузды. Бит очларындагы, борын яфракларындагы сипкелләре кып-кызыл булып кызарды, күзләрендә нәни очкыннар биеде.

– Ал, әйдә. Сиңа булсын. – Мин үзем, пәкегә карамас өчен, күземне читкә алдым.

Солтан, кире уйлавымнан курыккан кебек, пәкене тиз генә кесәсенә салды.

– Эти кайтканчы гына алам, малай, эти миңа моннан да яхшысын, алты япьлесен алып кайта, менә күрерсең, – диде.

Күңелем тынычланды, рәхәт булып китте. Солтан куанычыннан кәҗә бәтие кебек сикергәли иде. Мин шулчак, кешене куандырсаң, үзең дә куанасың, дигән сүзнең ни икәнен аңладым. Шатлыгыбыз чиктән ашкан иде, без кулга-кул тотыныштык та урамга атылдык. Иртәгә Сабан туе буласы!

*Госман Мохтасар улы Зәйнетдинов (тәхәллүсе – Госман Садә (1949-2014)) – шагыйрь, журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Ул халкыбыз күңелендә матбугат өлкәсендәге фидакяр хезмәте һәм якты шигърияте белән яши.*

*Уйлан, Кешем,*
*Һаман агам*
*Үлән-яфрак арасыннан.*
*Йә мин йотам дәверләрне...*
*Хәтерләрне...*
*Бер төш сыман.*

*Ашык, Кешем,*
*Эшең белән*
*Гасырларны узып кара.*
*Мин бит сиңа бүләк кенә,*
*Тик күз ачып йомган ара...*

*– ди шагыйрь «Вакыт» исемле шигырендә. «Бар да ага һәм үзгәрә» дисә дә, чын шигърият үзгәрми, вакыт агышында үз урынын даулый.*

*1949 елның февралендә Башкортстанның Аскын районы Әмир авылында туып үскән егетне, урта мәктәпне тәмамлауга, Баскын район газетасына эшкә чакыралар. 1967-1972 елларда ул Уфада Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Студент елларында әдәби иҗат белән шөгыльләнә, «Акчарлаклар» дигән әдәби иҗат берләшмәсен җитәкли.*

*Университетны тәмамлаганнан соң, Госман Садә Казанга күчеп килә. «Татарстан коммунисты», «Яшь ленинчы», «Шәһри Казан», «Мәгърифәт», «Ватаным Татарстан» газеталарында эшли, әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли.*

*Шагыйрьнең төрле елларда «Мәхәббәт елы», «Җиләкле тәрәзәләр», «Тайфун күзе», «Ярату ява» исемле китаплары дөнья күрә.*

Госман
Садә

# ҺӘР УЧАКНЫҢ ҖАНЫ, ҮЗ ТЕЛЕ БАР...

## Пилотка турында баллада

Җәйге көн. Эш кызу болында.
Һәркемнең чалгысы кулында.
Дәртләнеп, җиңнәрен сызганып,
Картлыгын тормыйча кызганып,
Гариф карт – гарип карт кузгала:
Егетләр, кайсыгыз узала?

Картлыкның тилергән чагы бар.
Чыңлады, чыжлады чалгылар.
Бар болын, бар алан чайкала,
Чалгылар яшендәй айкала.

И үлән агыла, чабыла...
Чалгыда шат нурлар чагыла.

Егетләр тынгысыз. Кыздылар.
Шунда ук бабайны уздылар.
Янәсе, шаяртма, онытма!
Болгыйлар бабайга пилотка.
Пилотка. Ясалган гәзиттән.
Пилотка. Киелгән яшьлектә.

Киелгән... Хәтердә кырык бер.
Хәтердә болынлык, кырык ир.
Юк чалгы. Автомат кулларда.
Дошманны үткәрмәү уйларда.
Ант итә егетләр окопта.
Башларда – йолдызлы пилотка.

Башлана... бар болын чайкала.
Егетләр һөҗүмгә ташлана.
Егыла, кырыла егетләр...
Чигенми, җиңелми бөркетләр!

Егылды... Кайтмады кырык ир.
Хәтердә каһәрле кырык бер.
Гариф карт караган офыкка,
Егетләр болгыйлар пилотка.
Кабатлый ул шушы минутта:
«Аларны онытма!
Онытма!»

## Ак бүре

(Баллада)

Урмандамы, кырдамы,
Шигырьдәме, җырдамы –
Кырдык кына бүрене.
...Соңгы бүре, ак бүре,
Үлеме син, тереме?

Төркиләрнең юлдашы,
Байрагында кояшы –
Бүре башы, син кайда?
Гасырлар чоңгылында
Югалдыңмы Кытайда?

Таркатып ыруыңны,
Туздырып җир-суыңны,
Монгол явы кудымы?
Муеныңа Чыңгызхан
Чылбыр бәйләп куйдымы?

Мондый җәза-хурлыкка,
Кара төндәй коллыкка
Елый-елый түздеңме?
Әллә зынҗыр-богауны
Чәйнәп кенә өзденме?

Тагын яулар калыкты,
Алар сиңа каныкты,
Буйсынмас рухың күреп,
Соңгы бүре, ак бүре,
Каршыма кил йөгереп.

Афәттән йолып алыйм,
Иркәләп, сыйлап калыйм...
Юк, тарих кире какты.
...Таркалып төште беркөн
Төркиләр каһанаты.

...Килде Явыз Иван да,
Сүнде илдә иман да –
Коелды кан, коелды.
Соңгы бүре, ак бүре,
Күзең кайчан йомылды?!

Йөрәктә әрни яра:
Таркалу һаман бара.
...Әгәр дә булсаң тере,
Үз илеңә кайт кире,
Соңгы бүре, ак бүре!

***

Үзгә бер нур – илһам нуры балкый
Татар гомер кичкән һәр өйдә.
Килеп чыккан татар бистәсенә
Кыен чакта Максим Горький да.

Ул үлемнән үзен саклап калган,
Нурын тоеп шушы бистәнең.
Гәрчә белгән үзе нинди җилнең
Татарларга таба искәнен.

Ул үлемнән үзен саклап калган
Татар җире, татар илендә.
Горький сүзе: «Минем татарларым!» –
Тарихларга кергән легенда.
Сагындыра бүген, сагындыра
Горькийга хас җанга якынлык...
...Татар торган йортта гомер бакый
Балкып тора нурлы яктылык.

## Сандугач

Мөлдерәмә нурлы таң тугач,
Чык тамчысы гөлгә сарылгач,
Сайрамасын ничек сандугач! –
Күңеле тулы ялкын, моң булгач.

Җыры оча иңләп тугайны,
Җыр канаты – алтын буяулы.
Моңнан гына торган шул таңны
Кинәт кызым елап уянды.

«Ник елыйсың болай, чү, кызым?!
Йом күзеңне, йокла, йолдызым.
Сайрасын ла, кызым, сандугач,
Җырны шулай өзелеп сагынгач».

Бишегенә кулым кагылгач,
Пышылдады кызым: «Сан-ду-гач!»
Сабый тынды, елау басылды, –
«Сандугач» дип теле ачылды.

# АДАШМАГАН КАЛӘМ

Тормышымның иң авыр көннәрендә, җанга урын тапмаганда, күршеләргә кереп, телефоннарына үрелә идем дә, кемгә-кемгә…, дип уйланып торганнан соң, Фәнзаман абыйның номерын җыя идем. Алай да без аның белән чыбыклар аша сөйләшмәдек диярлек, чөнки ул шунда ук үзенә кунакка дәшә иде. Миңа ул җитми. Миңа Фәнзаман Баттал исеме белән матбугат мәйданында дан алган, әмма күңелемә туганым кебек кереп калган зат җитми! Ул коточкыч ихтыяҗ хәтта «җитми» сүзенә дә сыеп бетми. Әйе, зур югалтуларым эчендә башка беркемнекенә охшамаган елмаюлы, киң күңелле, мул табынлы, дуслы-дошманлы, утлы каләмле һәм мине бик нык яраткан Фәнзаман абыем да бар.

Фәнзаман Баттал белән якыннан беренче аралашкан көнне үк гомерлеккә дуслаштык дип әйтә алам. Ул үзе дә моны көтмәгән булып чыкты. Бездә бит кайчак кешегә мөнәсәбәтне көнчелләр, ташлап калдырган сөйгән ярың, аерылган ирең, аның шул аерылуны еллар дәвамында көткән «дуслары» да формалаштыра. Фәнзаман абыйда моңа дәлилләр бар иде. Ә менә үзе… Берничә өйләнсә дә, һәр хатынын яхшылык, олы хөрмәт белән, балаларының кадерле әниләре буларак искә алыр.

Бер-беребезгә якын яшәгәндә, Фәнзаман абый белән аена әллә ничә очраша, вакыты белән, тәүлекләр буена сөйләшә, хәтта сөйләшми генә, үзалдыбызга уйланып та утыра идек. Кайчак, милләтең, ана телең өчен борчылып, төннәрен йоклый алмыйсың. Урамнарда йөрүләр дә, балконыңнан төнге шәһәрне күзәтүләр дә тынычландырмый. Шул чакта тагын Фәнзаман абый искә төшә. Инде урам телефоныннан шалтыратасың.

– Үзем дә шундый хәлдә. Кроссворд чишеп утырам. Мен, – ди ул. – Берничә сорау калды әле монда.

Киров районы сазлыкларын турыга гына узып, аның Декабристлар урамындагы җанга да, тәнгә дә җылы өенә йөгерәм. Бөтен йортларда караңгы. Фәнзаман абыйның дүртенче каттагы 99 санлы фатирында гына ут яна. Тәрәзенә карап кычкырам:

– Фәнзама-а-н!

Күршеләре, ут яндырып, аска карый. Ул да, чәйнеген тоткан килеш, тәрәзәгә килә. Аны утка куя да алар йортында гына булган өчпочмаклы ачкыч ыргыта. Үз өеңә кайткандай, мин югында да кереп йөр, дип, яңасын ясатып биргән иде югыйсә. Уңайсызландым. Син югында, ник керим инде, дигән булып, бераздан кире бирдем.

Фәнзаман абыйда лифт юк. Мин менеп җиткәнче, чәйнеге кайнап та өлгерә. Эре бөртекле хуш исле, чөнки – кыйммәтле чәйне турыдан-туры стаканнарга гына ясап эчәбез дә, мөһим эш кыргандай, кроссворд яисә сканворд чишәргә тотынабыз. Фәнзаман абый ахырдан табармын дип калдырган сорауларына да җавапны газетаның соңгы битеннән карамый, ахыргача үзе чишәргә тырыша. Минем дә әле хәтерле, күп нәрсә белгән чак.

– Хатын-кызда да акыл булыр икән, – дип көлә ул. Аннан, тиз генә җавап тапканыма аптыраганга салышып, берәр сорау биреп куя. – Бик акыллы булгач, әйт: кинолог, синеңчә – кем?

Әйтәм. Тагын көлә. Миңа килгән яшь кызлардан сорыйм да, кино белгече, дип җавап бирәләр, ди, кайберләрен, кинолог белән таныштырам, берәр фильмда роль бирер, дип ышандырам, бик сөенәләр. Фәнзаман абый шулай кешеләрне сынарга ярата. Белемдә. Дуслыкта. Иман ныклыгында. Чисталыкта. Тырышлыкта. Мин ул сынауларны иң уңышлы узган кешесе булдым шикелле. Бервакыт ул мине:

– Чисталык генераторым, – дип каршы ала башлады. – Син килгәч, ялт итеп җыештырылган кебек өем дә гөлгә әйләнә. Син җыештырганда, берәр тәмле әйбер пешерим алайса.

Таңгөл белән елын-елга аңа тәрәзәләр юышабыз. Бу эш, кызым Казаннан киткәч, тукталды. Ялгыз калгач, фатирны алмаштыргач, аңа кунакка йөрүем кимеде. Хәзер үкенәм. Бүген барам, дип җыенгач кына, вафат булды. Монысы тагын да ныграк үкендерә. Дуслары күп иде. Аларның да күбесе үлемен белми калды бугай: Фәнзаман абыйны Казаннан бик яраткан кешеләр генә, ясалма нотыклар тыңламыйча, гади һәм ихлас рәвештә озаттык. Ул үзе дә гади яшәде, ясалмалылыкны сөймәде. Фәнзаман абый арабыздан ныклап авырмыйча, хушлашмыйча, әмма якты хисләр, сөйләп бетермәслек истәлекләр калдырып китте. Шифаханә ишегалдына куелган мәрхүм янында хушлашу сүзен дә юньләп әйтә алмадым. Күңелдә яшь иде. Сагыну, ярату, үкенү, югалту яше… Милләт шул көнне әле үзенең туры сүзле олы көрәшчесен югалтканлыгын сизмәде дә шикелле.

Кеше вафатыннан соң бар нәрсә башкачарак мәгънә ала башлый. Таңгөл җитү кыз булгач, ишегалды аша узганда, күгәрченнәр ашатып торганын күреп, янына килдек. Аңа карап, матур сүзләр әйтсә дә, күзендә моңаю чагылды кебек. Гомер узып барганга да, дуслашып-ярдәмләшеп узган көннәрне искә төшерүдән дә сагышлану тоелгандай булды. Фәнзаман абыйның үткен һәм туры теленнән кискенрәк сүзләр ишеткән кешеләрнең бәясе минекенә туры да килмәс, әмма ул – үтә нечкә күңелле кеше иде шул.

Ирләрдәге нечкәлек күзгә күренсен өчен, аны тышка чыгарырлык шарт кирәк. Соңгы елларда Фәнзаман абыйның кызын, оныгын искә алмаган көне булмагандыр. Янәшәләрендә Таңгөлемне дә якын итеп исенә төшерә, акыллы итеп үстерәсең, дип, күңелне сөендерә. Аерылгач та, балалары язмышын кайгыртып яшәгән сирәк ирләрнең берсе иде Фәнзаман абый. Егетләрне шаяртып чеметкәләп узганда да, кызларны авыр сүз белән һичбер рәнҗетмәс, ә ятим балаларга аеруча миһербанлы һәм игътибарлы булыр.

Фәнзаман абыйның иң яратып искә алган кешесе алай да – әниседер. Ул кайвакыт аның бала чагында үзен юатыр өчен ясаган смайликларын исенә төшереп утыра торган иде. Бу төр рәсемнәрнең иң борынгы формасы (б.э.к. 1700 ел) Төркиянең Каркамыш каласында табыла. Аларның заманчаларын исә узган гасырда товар билгесе сыйфатында рәсмиләштерәләр. Тамга хуҗаларының ничек баеганлыгын уйлаганда, Фәнзаман абыйның әнисе дә искә килә. Аның күпкә алдарак иҗат иткән смайликлары 1963 елда америкалы Харви Болл тамгаларына бик охшаган. Кайберләре 1982 елны Скот Фалман эмоткионы белән тәңгәл. Фәнзаман абый исә әнисенең бер үк вакытта елаучы да, көлүче дә булып күренә торган рәсемен ярата иде.

Кемгә дә сер түгел: Фәнзаман Баттал янында яшь кызлар күп бөтерелде. Күбрәк булачак журналистлар. Кызыклы һәм талантлы кеше. Аның белән аралашу танышлык мәйданыңны да киңәйтә. Башка сәбәпләре дә булгандыр. Туксанынчы елларда кемнеңдер ашарына ипие дә югында аның суыткычы тулы иң дефицит ризыклар, урман җиләкләре, итнең-казылыкның, балыкның, кайнатмаларның… ниндие генә юк. Син теләгәне, күңелең төшкәне булмаса, бергәләп барып, базардан теләсә нинди бәягә алып кайта. Студенткалар белән сыйланып яткан чагында килеп керсәң, ул аларга сеңдерерлек итеп әйтә: сезнең өчен зур шәхес, олы шагыйрә килде, инде сез аны сыйлагыз, өстәлне яңадан хәзерләгез, хөрмәт күрсәтегез. Бу – үземне күтәрү өчен китерелгән мисал түгел, ә Фәнзаман абыйның яшьләрдә олыларга мөнәсәбәт тәрбияли алуын исбатлавымдыр. Ул егет һәм кызларда Айдар Хәлим, Фәүзия Бәйрәмова, Гурий Тавлин, Салих Баттал һәм башка олы талантлар турында да хөрмәт уятырлык сөйли торган иде.

Фәнзаман абыйның яшьлегендә аралашкан һәм гомер ахырынача якын иткән каләм ияләренең берсе – якташы, минзәләле Рәшит Гәрәй. Ул аны гадилеге, гаделлеге өчен яратты һәм үзенчәлекле лирик дип санады, бигрәк тә туган җирен, авыл тормышын тасвирлаган әсәрләрен күңелендә йөртте. Ә бит Фәнзаман Баттал үзе дә бер дигән лирик иде, тик иҗатының бу ягын булдыра алганча үстерергә вакыт кына тапмады.Ул, беренче чиратта, заман публицистикасын актуальләштерү, тормышчан итү, милләткә хезмәт иттерү уе белән янды. Алдашмаган һәм адашмаган татар каләме өчен көрәште.

Кызганыч ки, Фәнзаман Батталның шәхси басмаханәдә генә нәшер ителгән һәм лирик әсәрләрне дә үз эченә алган «Соңарган яз» *(Матбугат йорты, 2001)* җыентыгы

киңкатлам укучыларга барып ирешмәде. Әле бит аңа кермәгән әсәрләре дә бар иде. Киләчәктә Ф.Баттал язган сатирик һәм лирик шигърияттне Татарстан китап нәшрияты бастырган калынрак тупланмаларда да бергә күрергә иде дигән теләк-хыял бар.

Вак-төяк нәрсәләргә исе китмәгән Фәнзаман абый глобаль проблемаларны күз уңыннан бервакытта да ычкындырмады. Аның аш бүлмәсендә дуслары белән алып барган гамьле әңгәмәләре тынмады. Аннан соң шул ук темалар ишегалды мәйданчыкларында куера иде. Фәнзаман абый андагы утыргычларга килгән һәркемнән милләтпәрвәр ясарга тырышты. Танышында фатирда торган малайның русча исемен татарчага алмаштыртты һәм үзен мөселман да ясады. Чыннан да, кызык, серле, кешеләргә тәэсир итүчән сүзгә ия кеше иде. Ул күршеләрен, уйнап йөргән балаларны табигатьне яратырга өндәде. Аның йорты тирәсендә һаман да кошлар күп яши, чөнки алар, Фәнзаман абый ризыклары белән нигъмәтләнеп, гадәттән тыш үрчеде, кешеләрдән курыкмаска күнекте.

Фәнзаман абый белән бәхет турында күп сөйләштек. Ул үзен күп яктан бәхетле санады. Язмышына, каләм талантына, йортындагы язар мөмкинлек биргән тынычлыкка, якын иткән кешеләргә рәхмәтле иде. Бәхет – кызык нәрсә, ди иде Фәнзаман абый, күнегелгән җылы суың акмый башласа да кыен, ә инде аны яңадан бирсәләр, үзеңне шулкадәр бәхетле хис итәсең. Әлбәттә, бу – кыска вакыт эчендәге бәхет хисен кичерүләр турындагы фикер. Әле бит милләт бәхете, теге яки бу милләт баласының бәхете дигән төшенчә бар. Милләтеңнең бүгенгесе турында болай гади генә фикер йөртеп булмый, билгеле. Шул милләтнең күпсанлы хокуклары киселгән икән… Димәк, бәхет хисе йортыңа, күңелеңә алар белән бергә кайчан да бер килеп керергә тиеш.

Милләт гаме белән яшәгәч, бергәләп сөйләшкәннәребез дә, нигездә, милләт тирәсендә бөтерелде. Күпчелек мәсьәләләрнең чишелешен бер үк төсле күрсәк тә, мөстәкыйльлеккә ирешүгә килгәндә, Фәнзаман Баттал миннән оптимистрак иде. Ул халкы өчен яшәмәгән илнең алга таба да таркаласына, коллыктагы милләтләрнең якын арада тулы азатлык аласына нык ышанды. Миңа Фәнзаман абый бүген, өметләре чәлпәрәмә килгәнче, арабыздан китәргә ашыкты сыман да тоела… Хәер, авыргалап алса да, йөрәге белән шулай тиз китәр дип уйламый иде ул. Табиблар, өзлексез тәмәке пыскытудан дигәч, тартуын да бераз киметкән иде югыйсә.

Бервакыт Фәнзаман абыйга, аягыгызны сәеррәк атлыйсыз, дидем. Шулай бугай шул, кайвакыт үзем дә сизеп алам, дип килеште. Күптән түгел бер мәкалә укыдым да таң калдым. Тезләрне аның кебек сәеррәк, аксатыбрак бөккәндә, инфаркт куркынычы бик якын, һичшиксез, табибка барырга кирәк, диелгән. Менә сиңа мә! Әйтәм бит, кешене югалткач, сөйләшкән сүзләргә дә яңадан әйләнеп-әйләнеп кайтасың.

Фильмда төшү турындагы сүземнең бер ахыры өзелде, икенче очтан кителде. Фәнзаман абый үзе дә нәфис фильмда төшәргә, теге яки бу тасмадагы хәлләрнең сценаристы булып тарихта калырга теләде. Кызыклы гына сценарий да язган иде ул. Режиссёры да билгеле иде. Без аны төшерү урыннарын безнең яклардан тапкан идек. Мин дә уйнамакчы идем анда. Хыял гына булып калды… Кино кую – кинолог булу, ягъни этләр үрчетү һәм тәрбияләү генә түгел икән шул… Моңа рөхсәт тә, акча да, башкасы да кирәк.

Тормышның кечкенә генә күренешләрендә дә алданучан зур галимнәр була. Кешеләргә вак-төяктә артык ышанучан зур талантлар. Бервакыт Фәнзаман абый базардан йомшак ылыс кебек яфраклы бер үлән алып кайткан да китап киштәсенә элгән. Сусыз, ризыксыз да үсә икән, ди. Баштарак ул, чыннан да, аңа бераз үскән кебек тоелды. Миңа исә, килгән саен, шул унбиш сантиметрлар тирәсе күренә… Әмма яшел, сулмый. Ни вакыт тора алды икән ул гөл? Фәнзаман абый менә бик иртә китте. Ул арабызда юклыкка да шактый икән инде. Татарның Фәнзаман исемле тугры улына 2019 елның 16 февралендә 80 яшь тулган булыр иде. Узса да уза икән бу гомер.

**Рифә РАХМАН**

# СӘГАДӘТ

Гаяз Исхакыйның кызы Сәгадәтнең туган елы мәсьәләсе баштарак бераз бәхәслерәк булды. Төрле елларда язылган анкеталарда ул үзенең туган елын «1907» дип күрсәтә. 1989 елда әнисе Мәрьям Шәрипованың икенче ире Ибраһимнан туган сеңлесе Суфияга җибәргән хатында да «мин 1907 елда туганмын», дип язган иде. Г.Исхакыйның мин төзегән «Зиндан» җыентыгында (1991) шул ук исемдә автобиографик повесть та бар. Анда автор, беренче мәртәбә тотылып, Казан төрмәсендә ике тәүлек утырганнан соң, административ рәвештә туган авылы Яуширмәгә сөрелүе турында яза. 1906 елның 5 ноябрендә ул авылына кайтып җитә. «Менә миңа үземнең кызымны алып чыктылар... Кызымны күрмәгәнемә өч-дүрт ай үтсә дә, ул миннән бер дә ятсынмаенча килде», ди Г.Исхакый. Димәк, бала 1907 елдан алдарак дөньяга килгән булып чыга. Сәгадәтнең туу датасын ачыклар өчен, Татарстан милли архивындагы муллалар тутырып барган метрикә дәфтәрләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк булды. Баксаң, Сәгадәт Исхакый 1905 елның 15 июлендә (яңа стильдә 28) туган икән. Әтисе, Казан төрмәсеннән котылып, авылга кайтканда, балага 1 яшь тә 3 ай ярым була. Бу хәлләргә Ибраһим Нуруллин да игътибар иткән, ул да, метрикә дәфтәреннән карап, Сәгадәтнең туган елын ачыклаган икән. Ә менә метрикәдә Г.Исхакыйның беренче баласы – Сәгадәткә кадәр туган бер улы да булуын И.Нуруллин күрмәгән.

Татар энциклопедиясендә Сәгадәтнең туган елы ике урында ике төрле: 1905 дип тә, 1907 дип тә язылган. Шулай ук Г.Исхакыйның да туган көне 22 февраль дип ялгыш күрсәтелгән. Әдип үзенең «Тәрҗемәи хәлем»ендә: «Мин иске стильдә 10 февральдә (яңа стильдә 23 февральдә) кояш чыкканда туганмын», ди. «Кояш чыкканда» дип әйтүне дә кирәк тапкан.Энциклопедиягә бу бөек затлар турында текстлар язарга алынган кеше даталарны архивтагы метрикә дәфтәрләре буенча тикшерергә тиеш иде. Укучы бит иң дөрес мәгълүматны белер өчен җитди басмага – энциклопедиягә мөрәҗәгать итә. Хаталар энциклопедиядән тизрәк тарала.

Гаяз Исхакыйга мулла таныклыгы 1903 елның 17 апрелендә (яңа стильдә 30 апрельдә) бирелә. Ә шул ук елның 3 ноябрендә (яңа стильдә – 16) Гаяз Исхакый белән Мәрьям Фәтхетдин кызы Шәрипова никахланалар. 1904 елның 3 августында (яңа стильдә – 16) аларның Мәэмүн исемле уллары дөньяга килә. Ләкин бала, 9 атналык булгач, үлеп китә. «Әтисенә бик тә охшаган иде», дип әйтә торган булган әнисе Мәрьям. Тагын бер елдан ул кызлары Сәгадәтне таба. Ләкин, агалары сәбәпче булып (аларга «йорттотмас» кияүләре ошамый), Г.Исхакый белән Мәрьям 1906 елның 26 июлендә аерылышалар. Шул ук елның 28 ноябрендә алар никахларын яңартып, тагын кушылалар. Әмма 1908 елның 21 июнендә Г.Исхакый, Мәрьямнең үтенече буенча, Архангель губернасыннан «...үземнең никахымдагы хатыным Мәрьям Фәтхетдин кызыны үзенең мәһәре бәрабәренә, габде нәфкасы (тияр мал) бәрабәренә хәлгы кылдым (аерылырга рөхсәт бирдем)» дигән документ җибәрә.

Сәгадәт, нигездә, әбисе Камәрия янында тәрбияләнә. Истәлекләрендә Сәгадәт: «Мин әтием белән 1913 елда гына таныштым», – ди. Г.Исхакый төрмәгә эләккәндә бик нәни калып, әтисе 1913 елда сөргеннән кайтканда инде балага 8 яшь була. Аннан соң да әле Казанда яшәргә рөхсәт ителмәгәнгә күрә, Петербургта, Мәскәүдә яшәргә мәҗбүр булган әтисе белән кызына сирәк кенә очрашырга туры килә. Яшь кыз турында «Петербургка китеп, кызлар гимназиясендә укыган, илдә һаман болганышлар дәвам иткәнгә, Петербургтан әбисе янына Яуширмәгә кайткан» дигән имеш-мимеш хәбәрләрне Сәгадәт апаның туганнарыннан еш ишетергә туры килә иде. Мәрьямнең оныгы (Сәгадәт апаның әнисе ягыннан бертуган сеңлесе Суфия кызы) Рәйсә ханым әле дә: «Юк, Сәгадәт апа Смольныйда укыган, дәү әни шулай дия иде», – ди. Татар

энциклопедиясендә дә шул ук версия бирелгән. Баксаң, Сәгадәт апа үзе язганча, әтисе аны 1917 елда Казанда «Мариинская гимназия»гә укырга биргән икән. Бу I разрядлы кызлар гимназиясе Казан шәһәре уртасында, мәһабәт йортта (хәзерге Рәхмәтуллин урамы, 2 нче йорт) урнашкан булган. Профессор Катанов, Терегулов, Апанаев кызлары да шунда белем ала, берара М.И.Ульянова да шунда укый. Аларны Вакытлы хөкүмәт башлыгы Керенскийның әтисе укыта. Кызганыч, Татарстан Милли архивында бу гимназиягә кагылышлы документлар өлешчә генә сакланган. Сәгадәт укыган елларга караган кәгазьләрне күрә алмадык. Ә Сәгадәтнең «Петербург гимназиясендә уку»ына килгәндә исә, бу аның ул шәһәргә чит илгә чыгып китәр өчен баруын яшерер өчен, саклык өчен махсус таратылган булса кирәк.


*Кечкенә Сәгадәт. 1913 ел.*

1917 елның мартында Казандагы «Сәйяр» труппасы куйган «Зөләйха» спектаклен Сәгадәт Мәскәүдән кайткан әтисе белән бер ложада утырып карый. Ә инде 1917 елның августында Г.Исхакый, туган йортында туганнарын соңгы тапкыр күреп, тагын китеп бара. Шул китүдән кайтмый.

Сәгадәт укыган гимназия, Совет власте урнашкач, мәктәп итеп үзгәртелә. 1921 елда ягарга утын булмыйча, балаларны өйләренә тараталар. Шул ачлыкта Сәгадәт әбисе һәм әтисенең энесе Әхмәтхәсән белән бергә Ташкентка китеп, анда торып кайта.

Үзенең автобиографиясендә язганча, Сәгадәт 1922 елда 9 сыйныфлы совет мәктәбен тәмамлавы турында таныклык ала.

Ә өйдә Гаязны югалталар. «Үлгән икән», «төрмәдә икән», «чит илгә китеп котылган» кебек имеш-мимешләр гаиләне бер утка, бер суга сала. 1919 елның җәендә 80 яшенә җиткән Гыйләҗетдин хәзрәт «Мөхәммәтгаяз угылым, Мөхәммәтгаяз угылым», дип, соңгы сулышын ала.

Тагын ни хәбәр ишетербез дип, ут йотып яшәгән туганнары 1921 елның язында гына Гаязның Париждан язган хатын ала. «Әбием елый башлады. Әти хатларны еш язып торуын әйткән, ләкин без аларны ала алмадык. Почталар эшләми иде. Бу хат нинди могҗиза белән безгә килеп җиткәндер. Әбием хатны миннән кат-кат укыта, кәгазь белән битен сөртеп, бертуктаусыз елый иде. Хат алыша башлагач, әти мине үзе янына чакырды», – дип яза Сәгадәт.

Сәгадәт абыйсы Әхмәтхәсән һәм җиңгәсе Нурия белән бергә Казанда паспорт алу артыннан йөри. Сәгадәтнең кем кызы икәнен аңласалар да, паспортны бирәләр, ләкин: «Безгә мөрәҗәгать итүегезне беркемгә дә әйтмәгез», – дип кисәтәләр. Һәм ничек итеп Мәскәүдә илдән чыгарга рөхсәт алу юлларын өйрәтәләр. Сәгадәт үзе язганча, Мәскәүдә дә кем кызы белән эш итүләрен аңлаучылар була һәм аңа рәсми юл белән йөрмәскә, ә Петербургка барып, качакчылар белән Финляндиягә чыгарга киңәш бирәләр.

Туганнары белән бергә Петербургка килеп, Сәгадәт биредә кырык көн уздыра. Килгәндә бу кадәр вакытка исәп тотмаганлыктан, акчалары бетә. Ачыгалар. Кичләрен генә йөреп, көндезләрен йоклап үткәрәләр. Шунысы бар: ачлык йокы бирми. Торган йортлары астында гына кафе-бар була. «Шуннан чыккан тәмле исләр белән туена идем», – ди Сәгадәт.

Бу урында Исхакыйның 1922 елның 16 октябрендә Финляндиянең Хельсингфорс шәһәреннән Садри Максудига язган хатына игътибар итик: «...Петроградка кызым килеп җитте. Ул вакытта Выборгта бик уңайсыз вакыйга булып үткән иде. Ул да Инҗалның энесе Хәсәннең ун көн мәхбүс (тоткын) булып торуы. Шуның өчен аның тирәсендә йөри торган кешеләр куркып-посып калганга, кызымны чыгарту эше чуалып

тора. Бу бик начар тәэсир итә. Тау кадәр вәгъдәләр ясаган Габдерахман аркылыны-буйга алып салмаган икән... Кызым хакында ачыграк мәгълүмат алу өмете берлә бүген Выборгка барам». Бу юллардан Сәгадәтнең ни өчен Петербургта озакка калуы аңлашылса кирәк. Тотылу куркынычы зур булганга, качарга җайлы вакыт һәм озатасы качакчыларның үзен алырга килүләрен көтеп тоткарланган икән ул.

Ленинградта Бакый Урманченың мәдрәсә шәригы, тарихи открыткалар коллекционеры Әхәт Усманов дигән олы галим яши иде. 1986 елда ул өендә миңа Г.Исхакыйның берничә китабын һәм фотоларын күрсәтте. Шунда: «Мин аның үзен дә күргәнем булды, кызын да Финляндиягә озатыштым, – дип куйды. – Чибәрлеге һушың китәрлек иде. Без, яшьләр, аның әтисе янына качар өчен килгәнлеген каяндыр белеп алдык. Көн саен чиратлашып шул тәвәккәл кыз торган йортка барабыз. Хәвеф-хәтәрдән саклыйсыбыз килә. Менә, көне җитте, диделәр. Караңгы төшкәч, аны каядыр озата бардык. Кемдер безне туктатты. Үзен генә алып киттеләр. Соңыннан әтисе белән кавышканын ишетеп сөендек».



*Сәгадәт әтисе Гаяз Исхакый белән. 1926 ел.*

Сәгадәт үзе илдән качуны болай тасвирлый: «Качакчылар кичке алтыда мине алачаклар иде, китергән юрганнарга сарылып яттык. Соңгы көн булганы өчен минем юрганымның кирәге калмады. Тиз генә барып юрганны сатып, ул көнне тамагыбызны туйдырдык. Соңыннан качакчылар килде, мине алганнан соң, һич тукталмыйча, иртәнге алтыга кадәр бардык. Һава яктырганда чик сызыгына килеп җиттек. Бердән, тирә-ягымда халык төркемен күрдем. Ерактан әтиемнең тавышы ишетелде: «Курыкма, кызым, куркыныч артта калды. Хәрбиләргә бирел, алар – Финляндия гаскәрләре». Финляндия хәрбиләренә тапшырылганнан соң, алар мине полициягә китерде.

Бу 1922 елның 10 ноябре иде. Андагы карантин бер айга сузылды. Соңыннан әтиемә тапшырдылар. Гаяз Исхакый бик шатланды».

Әтисе кызын үз янына бик вакытлы алдыра. Күп газаплар кичеп, тырышып-тырмашып, әтисе янына барып сыенырга омтылган 17 яшьлек бу батыр йөрәкле кыз үлемнән качуын ул чагында башына да китермәгәндер. Бөтен нәселен җәзага тартканда, Гаяз Исхакыйның үз баласын, әлбәттә, шундук юк иткән булырлар иде.

Ә Яушырмәдә, Сәгадәтнең әтисе янына исән-сау барып җитүен ишетеп, хәзер инде улының да ялгыз түгеллегенә, оныгының да таянычы барлыгына куанып, Камәрия остазбикә тынычланып кала. Ул 1923 елның 17 мартында тифтан вафат була.

Г.Исхакый кызын, Берлинга алып китеп, гимназиягә урнаштыра. Сәгадәт пансионатта яши. Бер ел чамасы әтисе дә Берлинда була. Ашау такы-токы. Әтисенең дә хәле әйбәт түгел. Исхакый Төркиягә киткәч, Сәгадәт ачлыктан зарланып хат яза: «Әтием мине бик «тынычландырып» җавап бирде: «Очсыз булганга, мин бер карт ат ите пешерә торган ашханәгә йөрим. Ә Фуат Туктар торган өе янында йомырка сатучының ватылган йомыркаларын ашап көн күрә... Әлбәттә, әгәр үзебезнең илебез ачык булса, синең өчен чит мәмләкәтләргә сыенып, мәктәптә уку зарурияте булмас иде. Тагын бераз сабыр ит, син минем күгәрченем». Исхакыйларга иң зур ярдәмне Финляндиядә яшәүче милләттәш эшкуарлар күрсәтә. Алардан посылкалар килеп тора.

1927 елда Сәгадәт Берлин университетына укырга керә. Шул елларда немец телендә

язылган автобиографиясендә Сәгадәт: «Әтием кулындагы документларга караганда, мин 1907 елда туганмын», ди. Бу сүзләр Сәгадәтнең туган елы мәсьәләсендәге «төрлелек»не аңларга ярдәм итсә кирәк. Әтисенә, бәлки, кызын Казан гимназиясенә урнаштыру өчен аның яшен киметеп күрсәтә торган документ кирәк булгандыр. Ул документ 17 яшькә җиткән кызын Берлин гимназиясенә урнаштырганда да ярдәм иткән булырга мөмкин.

Сәгадәт, университетны тәмамлап, аспирантурада укый. 1932 елда үзбәк егете Таһир Чагатайга кияүгә чыга. Икесе дә 1939 елның сентябренә кадәр Берлинда Г.Исхакый оештырган «Милли юл» журналын чыгаруда булыша. 1939 елның сентябрендә Гитлер Германиясе Польшага сугыш ачкач, Г.Исхакый Варшавадан Төркиягә китә. Ә Чагатайлар Берлиннан Төркиягә 1940 елда күченә.

Сәгадәт Чагатай Анкара университетында төрек телен укыта, аның ире профессор Таһир Чагатай (1902-1984) шул ук университетта студентларга социология буенча белем бирә.

Сәгадәт баштарак, хәтта университетта эшләгән елларында да, «Исхакый кызы» гына булып йөри. Югары дәрәҗәләр аңа җиңел генә бирелми. Көндәшләре аның турында: «Ул урысча укыган, төрек телен Әхмәтҗан кадәр генә белә», – дип, еш кына аяк чалалар. Г.Исхакыйның Истанбулдан Анкарага язган хатларында әтисенең кызы өчен бик борчылуы, кызына ярдәм итәргә тырышуы күренә. Сәгадәт үзенең белеме, тырышлыгы белән югары дәрәҗәләргә ирешә. «Исхакый кызы» гына булудан чыгып, профессор-тюрколог исемен үзе яулап ала.

Сәгадәт апа белән мин 1989 елның башында хат аша таныштым. 90 нчы еллар ахырына таба үзгәртеп кору җилләре татарларга да килеп җитте, һәм язучылар, галимнәр исемнәре бездән ераклаштырылган күренекле кешеләребезне барларга кереште. 1987 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры Мирфатыйх абый Зәкиев карары белән «Мирас» комиссиясе төзелде. Шул чагында Гаяз Исхакыйның үзем күп еллар буе эшләп, туплап куйган 4 томлык әсәрләр җыелмасын – әдипнең үз ватанында басылган барлык әсәрләрен өстәлгә куйдым. Боларның кайчаннан бирле һәм ничек эшләнүе – бусы озын һәм гыйбрәтле бер тарих. Анысына кереп тормыйм. Мәскәүдә тыелган фондлар ачылып, аннан Исхакыйның чит илдә басылган әсәрләреннән беренчесен – «Җан Баевич» пьесасын алып кайттым.

Шуннан соң гына мин Анкарага Сәгадәт апага хат язарга батырчылык иттем. Үзем эшли торган институтның грифлы кәгазьләренең берсенә: «Миндә барлар», дип куеп, машинкада басылган бит саннарын да күрсәтеп, тупланган, безнең язуга күчерелгән әсәрләрнең исемлеген, икенче кәгазьгә «Миндә юклар», дип язып, Төркиядә Г.Исхакыйның 100 еллыгына чыгарылган китаптагы исемлектән алып, чит илдә басылган, әмма кулымда булмаган әсәрләрне теркәдем. Сәгадәт апа миңа ышаныр микән, дип борчылдым. Ә Сәгадәт апа миңа ышанган һәм сөенеч тулы хаты белән бергә берничә китап та җибәргән. Бандероль умырып ертылган, соңыннан бик тупас итеп скотч белән ябыштырылган иде. Ул чорда бездә читтән килгән һәр пакетны тикшерәләр иде әле. Сәгадәт апаның хаты Г.Исхакыйның чит илдә язылган әсәрләре хакында без белмәгән, ишетмәгән беренче яңалыкларны алып килгән иде.

Соңыннан сөйләүләренә караганда, Сәгадәт апа миннән алган хатны үбеп-үбеп, битенә сөртеп елаган, әле бер, әле икенче танышын өенә чакырып, хатны кат-кат укыткан. Истанбулга танышларына шалтыратып та хәбәр иткән. «Әтиемнең бөтен китаплары табылган, шул мәхшәрле елларда Советлар Берлегендә аларны укыганнар икән, бер ханым аларны җыеп алып, эшкәртеп өлгергән, бастырабыз, дип яза», – дип кабатлый икән.

Кызганычка, бу вакытта инде Сәгадәт апа бик каты авыру, хәлсез булган. Шулай да, «мин үзем салам», дип, почтага барып, миңа дигән хатны да, бандерольне дә үзе җибәргән. Чыннан да, почтада төрелгән бандероль тышлыгында Сәгадәт апаның кул язуы тора.

Сәгадәт апа күндергән адрес буенча Мәхмүт Таһирга хат яздым. Ул үзенең беренче хатларында ук: «Сәгадәт апа, нәрсә булдыра аласың, шулай ярдәм ит Лена ханымга, диде. Аның высыятен үтәргә тырышырмын», – дип язды. Г.Исхакыйның чит илдә

язылган китапларының байтагын, күп кенә фотоматериалларны Төркиядән мин Мәхмүт Таһир аша алдым. Бик күп сорауларыма җаваплар да яза иде. Мин үзем дә ул сораган һәр китапны яки күчермәләрен аңа җибәрә тордым.

Шунысын да әйтеп китәргә кирәк: Мәрьям белән кызы Сәгадәтнең мөнәсәбәтләре турында төрле сүзләр йөргән. Әмма Сәгадәт бик яшьли әтисе янына чит илгә чыгып китсә дә, Чистайда, соңыннан Казанда яши торган әнисе белән араларын өзмәгән. Алар хатлар алышканнар. Моны исбатлый торган фактлар бар. Мәсәлән, Сәгадәт Чагатайның фоторәсемнәр альбомында Мәрьям белән кызы Суфия төшкән рәсем артына «21 август, 28 ел. Сәгадәт апага истәлек. Суфия. Чистай» дип язылган. 1928 елда төшкән рәсем: «Сөекле балам! Илһамия белән төшкән рәсememне җибәрәм. Сагынганда карарсың. Әниең». Альбомда Суфиянең 1933 елда үзе генә төшкән рәсеме дә бар.

Илләр арасында чикләр ябылгач, Мәрьям белән Сәгадәтнең дә бәйләнешләре өзелә.

1989 елда Сәгадәт апа әнисе ягыннан бертуган сеңлесе Суфия белән яңадан хат алыша башлый. Казанга Анкарадан бүләкләр дә килә. Ләкин бу аралашу бик кыска гомерле була. Сәгадәт Чагатай-Исхакый 1989 елның 24 июнендә 84 яшендә Анкарада дөнья куя. Шул шәһәрдә җирләнә. Сәгадәт ападан варислар калмый.

Мәхмүт Таһир миңа: «Сәгадәт апа тагын бер генә ел яшәсә дә, Г.Исхакый буенча никадәр эш башкарып кала идек!» – дип үкенеп язды. 1991 елның декабрендә Мәхмүт Таһир үзе дә вафат булгач: «Мәхмүт әфәнде, ичмасам, бер генә ел яшәсә дә, күпме мәгълүмат, материал кайткан булыр иде Казанга», – дип мин үрсәләндем....

Г.Исхакыйның Сәгадәт апа хатында телгә алынган китаплары әдипнең 15 томлык әсәрләр тупланмасының 5 нче томында басылып чыкты инде. Хатта: «Локман хәким» – урысча тәрҗемәсе бар, татарчасы юк», дип язылган. Бу әсәрнең татарчасы Анкарада галим Рәшит Рәхмәти Арат архивыннан табылды. М.Худяковның Г.Исхакый төрекчәгә тәрҗемә иткән «Казан тарихы очеркы» турында Сәгадәт апа: «Анкарада Тарих корымында саклана», – дип язды. Тарих җәмгыяте бу китапны Анкарада 2010 елда бастырып чыгарды.

Күңелдә әрнеп торган үкенеч калды. Без Сәгадәт апа белән очрашырга өлгермәдек. Мин Г.Исхакый әсәрләреннән алты китап әзерләп чыгардым. Әдипнең сөекле кызы, өзелеп көтсә дә, аларның берсен дә күрә алмады. Соң, бик соң тотындык без Исхакыйларны кайтарырга... Күңелемне бары бер нәрсә юата: Сәгадәт апа әтисенең барлык китапларының да исән икәнлеген, аларның басарга әзерләнгәнен белеп китте.

Профессор-тюрколог Сәгадәт Чагатай русча, алманча, инглизчә, французча, төрекчә, латинча, гарәпчә, фарсыча яхшы укыган һәм сөйләшкән. Ул дөньяның төрле илләрендә фәнни конференцияләрдә катнашкан, күп илләрдәге тюркология җәмгыятьләренә әгъза итеп сайланган. Аурупа һәм Азия илләрендә аны яхшы беләләр, китапларын да өйрәнәләр. Шуңа күрә, чит илләрдә хатлар аша Г.Исхакый турында эзләнүләремдә профессор Сәгадәт Чагатай-Исхакый исемен атау үзенә күрә бер ышаныч визиткасы булып тора, дияр идем. Беренче хатта ук башланган теләктәшлек һаман дәвам итә, Г.Исхакый буенча башкарган эшләремдә Сәгадәт апа һаман да юлымны яктыртып тора сыман...

Исән булса, Сәгадәт апага быел 28 июльдә 114 яшь тулган булыр иде.

2007 елның октябрь аенда Анкара университетының Сәгадәт Чагатай эшләп киткән төрек теле, әдәбияты һәм география бүлеге Сәгадәт Чагатайга һәм аның остазы Вилли Ванг-Каупка багышланган конференция үткәрде. Анда «Профессор др. Сәгадәт Чагатайның тәрҗемәи хәле» исемле югары зәвык белән эшләнгән, Истанбулда нәшер ителгән китап та тәкъдим ителде. Китапның авторы Һади Шенол бездән соратып алган фоторәсемнәр дә биредә урын алган иде.

Конференциядә чыгыш ясаучылар якташыбызның фәнни эшчәнлеген бик югары бәяләде. Шәкертләре – хәзер үзләре дә профессорлар – Сәгадәт апаның югары әхлаклы, әни кебек йомшак күңелле, хәлгә керә белә торган, мәрхәмәтле, акыллы киңәшче булуын искә төшерде. Күңелне каршылыклы, үкенечле хисләр биләде. Затлы нәселдән булган Сәгадәт, Туган илен бер күрергә тилмереп яшәсә дә, бик күп газаплы киртәләрне үтеп, барыбер үзенең чын асылын саклап кала алган һәм үзенә лаеклы

биеклеккә ирешкән. Әтисе кебек үк көчле рухлы бу татар кызын Төркия үстергән. Милләтебезнең чит илләргә хезмәт итәргә мәҗбүр булган талантлы кызларын, уларын без әле бик аз беләбез.

2008 елда Истанбулда «Профессор др. Сәгадәт Чагатайның басылып чыккан барлык мәкаләләре» исемле ике томлык мәҗмуга дөнья күрде. Аның төзүчесе профессор Айсу Ата. Сәгадәт Чагатай турындагы китап та, мәкаләләре урын алган томнары да 1988 елда Сәгадәт апа үзе төзеп калдырган Айаз-Таһир (Төркестан-Идел-Урал) вакыфы тарафыннан нәшер ителгән.

Сәгадәт Чагатайның үзе исән чакта басылган «Чура батыр» (1935), «Алтын яруктан ике парча» (1945), «Төрек ләһҗәләре үрнәкләре» (I т., 1963), «Казакъча мәтеннәр» (1961), «Төрек ләһҗәләре үрнәкләре» (II т., 1972) һәм башка хезмәтләре бар. Кайберләре Яуширмәдәге Гаяз Исхакый музеена да куелды. Әтисенә җан җылысы, яшәргә көч биреп торган, аның өчен Ватанының бер сөекле кисәкчеге, сагынмалыгы булган Сәгадәтнең, күренекле профессор-тюрколог Сәгадәт Чагатай-Исхакыйның хезмәтләрен тәрҗемә итә башларга иде. Тарихи сәбәпләр аркасында бөтен дөньяга сибелгән талантларыбызны барлау, аларны Туган илләрендә танытырга ярдәм итү ватандашларыбызның бурычы дип саныйм.

Биредә укучыларга тәкъдим ителә торган хатларның икенчесе Сәгадәт апаның соңгы көннәрен тасвирлый. Сәйдә ханым Арсланбәк болар турында әлеге конференциядә сөйләгән иде. Сәйдә Арсланбәк Анкарада Төрек мәдәниятен өйрәнү институтында профессор Әхмәт Тимер белән бергә эшләгән. Аның әтисе Мансур Арсланбәк Ерак Шәрекътә, Мукденда Г.Исхакый нигезләгән «Милли байрак» гәзитендә хезмәт иткән. Гәзиттә аның мәкаләләре, шигырьләре дә басыла. Сәйдә ханым Г.Исхакый архивының Мәхмүт Таһирда сакланган өлешен тәртипкә сала, тасвирлама төзи, башка материаллар белән бергә Казанга кайтарырга әзерли. 1997 елда Сафия Имре-Мәңгәр ул архивны Казанга алып килеп, Президент Минтимер Шәймиев кулына тапшыра. Хәзер ул материаллар Татарстан Милли архивында саклана.

Сәйдә ханым 1970-1980 елларда Анкарада татар телендә «Казан» журналын чыгаруда катнаша. Татар милләтенә күрсәткән хезмәтләре өчен Сәйдә ханым Арсланбәк «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнә.

**Лена ГАЙНАНОВА**

*Сөекле Лена ханым!*

*Хатыгызга күп рәхмәтләр, 27.3 тә язылган, 12.4 тарихында килде. Әтинең мирасы илә мәшгуль булуыгыз мине бик сөендерде. Моның өчен никадәр рәхмәт әйтсәм дә, аз калыр... Табигый, бу эш халкыбызның ярарына булыр. Сез сораган китапларның бер кыйсьме бар, боларны азлап-азлап фотокопияләрен чыгарып юлларбыз, хәзер болар кулымда юк, мин бик картаеп киткәнгә, берсенә сакларга биргән идем, ул Истанбулда. Иншалла, китаплар вә башка әврак (кәгазьләр) саглам торадыр... Алар белән Мәхмүд бәй мәшгуль булачак булды. Бер кыйсьме – Mecid бәйгә дә сөйләдем – «юк»лар арасындагылар Варшавада банк кассасында калгандыр, бу арада без дә, әлбәттә, сугышның зарарларын күрдек. Ул Варшавадан качып чыкты, без дә Берлинда бик күп китап вә әврак калдырып китмәк мәҗбүриятендә калдык, алар бомбалар астында калып янды...*

*2 нөсхә «Идел-Урал»ның французчасын, «Көз» (копиясе) вә 1 нөсхә «Казан» мәҗмугасын бу хат белән сезгә күндерәм. «Тәүбәкәр кадин», урысчасы «Society fon central Asian Studies», №14. Лондон, 1988 дә басылды, татарчасы юк, язылмады. «Юлсызлар» әсәрен 1918-1919 да Сибириядә «соң язган китабым» дип артист Абдулла Карыйга тәслим итеп китүен сөйләр иде, А.Карыйның вә йә Татар театрының көтепханәсе вә йә архивы бар исә, бәлки, табылыр... «Казан тарихы» Худяковтан тәрҗемә, аның әсәре түгел, сезнең өчен бер кыйммәте юк дип беләм, Төркия төрекчәсендә, Тарих корымында, Анкара.*

*Хат белән күп нәрсә сөйләнә алмый. Бу эш бу! Зур көннәр эчендә бу кадәрене саклый белү дә бер казаныштыр. Ни коткарылса, ул коткарылыр, бик зур заман кичте. Сез*

*эшегезгә дәвам итегез, бастырма эшене башлагыз. Сез Мәхмүд бәйгә мөрәҗәгать итегез. Адрес: Mahtud Tahir, Ankara, Balgat 10. Sokak, 10/9. Китапларны алуыгыз хакында хәбәр алмыйча, башкаларын күндерә алмам, хәбәр бирүегезне үтенәм.*

*«Олуг Мөхәммәд» – кулъязма;*

*«Локман Хәким»нең урысча тәрҗемәсе бар, татарчасы юк;*

*Төрекчә «Өйгә таба».*

*Күп сәлам вә хөрмәтләр белән Сәгадәт Чагатай-Исхакый.*

*Мине сораганнарга да күп сәламнәр.*

*Анкара, 17.04, 1989.*

***

*Бөегебез Гаяз Исхакыйның кызы Сәгадәт апа турында байтак хатирәләребез бар. Төрек культурасын өйрәнү институтында эшләгәндә, Сәгадәт апа, профессор Әхмәт Тимер бәй, Абдулкадыйр Инан, Хәмит Зөбәер Кошай, Наилә Бинарклар белән бергәләп, чәй янында, мәмләкәт мәсьәләләрен сөйләшеп, хәсрәтләрен бүлешәләр иде.*

*1987 елның 24-26 апрель көннәрендә «Дөньяда төрекләр» дигән симпозиумга өстәмә буларак, безгә Татарстан мәдәниятенә кагылышлы, аны танытачак күргәзмә әзерләвебезне үтенделәр. Милләттәшләребез кулындагы әйберләрдән матур бер почмак әзерләдек. Беренче көнне Сәгадәт апа килде. Күргәзмәне күргәч, шатланып: «Ватанымны күргән кебек булдым», – диде. Бер сәгать узгач, кулында бер пакет белән тагын килде. Татар милли киемен китерде. «Моны әтием алган иде, аны да күргәзмәгә куегыз», – диде. Җефәк кием, төймәләре көмеш ялтыравыклы иде. Күргәзмә бетемендә күлмәкне һәм шул күлмәкне киеп әтисе белән бергә төшкән фотоны да миңа бирде. «Башка күргәзмәләрдә дә кулланырсыз», – диде. Соңыннан мин ул күлмәкне Казанга музейга җибәрдем. Мәрхүмә үзе бара алмады, ләкин киемнәре китте. (Хәзер ул күлмәк Казан милли-мәдәни үзәге музеенда саклана. – Л.Г.)*

*Сәгадәт апа мәмләкәтнең ризыкларын яратыр һәм аларны үзе дә бик әйбәт пешерер иде. «Казан» культура һәм ярдәмләшү җәмгыяте җыелышларына килер һәм һәрвакыт матди ярдәм калдырыр иде. Шундый җыелышларның берсендә аның авыру кыяфәтен күреп: «Авырыйсызмы әллә, төсегез яхшы түгел?» – дип сорадым. «Хәлем юк, врачка алып бардылар, суык кына тигән, диделәр, витамин бирделәр», – диде Сәгадәт апа. Ә кичен, хәзер мәрхүм инде, Нәҗип Хабләмит углына шылтыраттым. «Синең таныш доктор Нәҗәти бәйнең профессор Сәгадәт апаны кабул итүен оештыра алмассың микән? Үзен бик әйбәт күрмәдем», – дидем. Доктор бәй дә шунда ук: «Мөгаллимәгезне иртәгә иртәнге якта китерегез», – дигән. Телефоннан Сәгадәт апага: «Иртәнге сәгать 8 дә врачка алып барырбыз», – дидем. Сөенде. Иртәнге 8 дә киенгән, сумкасы кулында килеш безгә ишек ачты.*

*Шулай итеп, авыруны тикшерүләр башланды. Доктор безгә начар хәбәр әйтте: «Бавыр рагы. Кызганыч, соңгы стадия. Нигә соңга калдыгыз?» – диде. Үзенә бернәрсә әйтмәдек. Анализлардан соң өенә бик арыган хәлдә кайтты. Мин үзем аны кәнәфигә яткырдым, ризыгын хәзерләдем. Бер көнне башын кочагыма алып, ризыгын ашаттым. Сөйләшкәндә: «Балалар, сезгә бик мәшәкатьләр ясыйм», – диде. Мин дә: «Нишләп мәшәкать булсын, без дә сезнең балаларыгыз саналабыз», – дидем. Аның зәңгәр күзләре яшь белән тулды. «Сезнең кебек балаларым булса иде», – дип елады.*

*Профессор Исмәгыйл Каябалы бәй Сәгадәт апаны медицина факультетының реанимация бүлегенә салды. Үзен ташланган кебек хис итмәсен өчен, көненә өч тапкыр аның янына бара идем. Әмма хәле көннән-көн начарая барды. Бер көнне янында озакка калдым. Аерылганда учыма алкаларын һәм беләзеген куйды. Мин бик борчылдым. Ул үлгәннән соң әманәтләрне Казанга кыз кардәшенә җибәрдем.*

*Сәйдә Арсланбәк*

# ХӘЗӘР КАҺАНЛЫГЫНЫҢ БАШКАЛАСЫ

Татарларның борынгы төрки бабалары тарихында ак таплар да, табышмаклар да аз түгел. Шуларның кайберләрен чишкәндә, әле XXI гасырда да, гаять кызыклы ачышлар ясала һәм тарихи дөреслекне кайтара. Сүзебез Казан археологлары катнашы белән ясалган шундый ачышларның берсе хакында булыр.

Бүре үлемнән алып калган һун баласыннан килә торган Ашин ыруының Алтайдагы күпсанлы төрки кабиләләрне берләштереп, 552 елда көчле Төрки каһанлык төзүе турында беләбез. Әмма шуннан соң Идел буе Болгары оешканга кадәрге тарихыбызда билгесез сәхифәләр дә күп.

Мәгълүм ки, 603 елда бу дәүләт ике: Көнбатыш һәм Көнчыгыш төрки каһанлыкларга таркала. Шуның көнбатыш өлешеннән 650 елларда Хәзәр каһанлыгы аерылып чыга. Ул Түбән һәм Урта Иделне, Кавказның алгы өлеше һәм Азов (Азак) буйларын, хәзерге Төньяк-Көнбатыш Казакъстан, Кырымның көнчыгыш өлешен, Днепр буйларын колачлый. Әмма бу дәүләт хакында элегрәк оешкан төрки каһанлык кадәр дә мәгълүмат сакланмаган.

Хәзәр дәүләтенең төрки телдә сөйләшүче идарәчеләрен Ашин ыруы белән туганлык җепләре бәйләгән дип санала. Дәүләтнең үзәге исә хәзерге Дагыстан җирләреннән акрынлап Идел буена күчә. Якынча 740 елларда хәзәр юлбашчыларының берсе – Булан яһүд динен (иудаизм) кабул итә. Бу факт соңрак ислам чолганышында калган хәзәр каһанлыгының җимерелүендә (969 ел) хәлиткеч роль уйный дип әйтәләр. Әмма әлеге мәсьәләдә дә, фактлардан бигрәк, фаразлар өстен.

Хәзәр каһанлыгының торак урыннары тарихы да озак вакытлар билгесез кала. XX гасыр уртасындагы археологик тикшеренүләр Саркел шәһәрлеген Волгоград һәм Ростов өлкәләре территориясендә су астында калган җирләрдә, Таман шәһәрлеген Краснодар төбәгендә дип билгелиләр. 2008 елда галимнәр каһанлыкның Түбән Иделдәге башкаласы Итил шәһәрлеген Каспий диңгезе буенда, Әстерхан тирәләрендә дип фаразлыйлар. Ике зур шәһәр – Бәләнҗәр һәм Сәмәндәр хакында бәхәсләр бара.

2008-2010 елларда Калмык Республикасы территориясендә гаять зур ике борынгы торак урын табыла. Башанта елгасы буена урнашканга күрә, галимнәр аларны Башанта-I һәм, аннан 8 чакрым читтәрәк соңрак табылганын Башанта-II дип исемлиләр. Мондагы беренчел күзәтүләр бу урыннарда зур территорияне биләп торган таш шәһәрлекләр булганны күрсәтә.

Археологик казу эшләре бары тик 2015 елдан гына башланып китә. Аны Татарстан Фәннәр академиясенең А.Х.Халиков исемендәге Археология институты һәм Россия Фәннәр академиясенең Калмык фәнни үзәге галимнәре бергәләп алып бара.


Соңгы еллардагы казу эшләре вакытында табылган таш торак урыннары, алардагы керамика, таш эшләнмәләр калдыклары мондагы шәһәрлекләрнең Болгар һәм Кырымдагы Херсонес шәһәрлекләре белән охшаш булуын күрсәтә. Башантада, шулай ук, зур мәйдан биләп торган торак урыны табыла. Андагы таш сарайларның зурлыгы, купшылыгы бу урынның идарәче (каһан) даими яшәгән башкала булуына ишарә ясый.

Төзелү вакытын ачыклау өчен, Алманиянең Киль университеты Лейбниц лабораториясендә радиоуглерод матдәләрне тикшерү уздырыла. Аның нәтиҗәсе шәһәрлекнең VII гасыр уртасы – VIII гасыр ахырына (Хәзәр каһанлыгы чорына) каравын әйтә.

Шулай итеп, Башанта Хәзәр каһанлыгына караган иң беренче таш кала – мәркәз дип дәлилләнә. Әлеге ачыш безнең төрки бабаларыбызның VII-VIII гасырлар чигендә үк таш шәһәрләр төзү культурасын үзләштереп, утрак тормыш алып барганлыгын сөйли. Нәтиҗәдә, төрки халыкларда шәһәр төзү культурасының вакыты борынгылыкка чигерелә.

**Айрат СИТДЫЙКОВ, Дания ЗАҺИДУЛЛИНА**

# РӘФЫЙК ШӘРӘФИЕВКӘ 70 ЯШЬ



Журналист, публицист һәм әдәби тәнкыйтьче Рәфыйк Кәләметдин улы Шәрәфиев 1939 елның 13 февралендә Татарстанның Балтач районы Карадуган авылында колхозчы гаиләсендә туа. Авылдагы җидееллык мәктәпне тәмамлагач, колхозда эшли.

1964 елда Балтач урта мәктәбен, ә 1972 елда читтән торып Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Беренче әдәби язмалары – кыска хәбәрләре һәм өйрәнчек шигырьләре «Югары уңышка» исемле район газетасында 1957 елдан күренә башлый. Газетаның ул чордагы мөхәррире Вәгыйз Вәлиев, егетнең язмаларына аерым игътибар итеп, берәр атналык семинарларга чакырып, аны матбугат эшенә тагын да якынрак тартырга тырыша, укуын дәвам иттерергә өнди. Шул тәрбияви чараларның нәтиҗәсе буларак, 1959 елда Р.Шәрәфиевне эшче-авыл хәбәрчеләренең III Республика съездына делегат итеп сайлыйлар. Ул 1962 елда узган IV съездда да делегат булып катнаша.

1965 елда журналистикада инде шактый тәҗрибә туплаган Р.Шәрәфиевне Арчада чыга торган төбәк газетасына әдәби хезмәткәр итеп эшкә чакыралар. Әмма аңа анда озак эшләргә туры килми: шул елның маенда Балтачның үзендә «Хезмәт» исемле яңадан оештырылган газета чыга башлагач, Р.Шәрәфиев үз төбәгендәге шул яңа газетада эшләүне кулайрак күрә. Аның шуннан соңгы журналистлык хезмәте тулысынча шушы газета белән бәйле: тоташтан утыз дүрт ел буе анда бүлек мөдире, бер үк вакытта, 1979 елдан 1999 елга кадәр, ягъни лаеклы ялга чыкканчы, баш мөхәррир урынбасары булып эшли. Журналистика өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа 1984 елда «Матбугат отличнигы» һәм 1995 елда «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Озак еллар дәвамында район газетасы битләрендә һәм республика матбугатында язмалары белән даими катнаша килүе белән бергә, Р.Шәрәфиев узган гасырның туксанынчы елларыннан башлап әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә үзенең каләм көчен күрсәтә. Аның «Казан утлары», «Мирас», «Татарстан», «Сөембикә» журналларында, «Мәдәни җомга», «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан», «Мәгърифәт», «Татар иле» газеталарында дөнья күргән рецензияләре, М.Хуҗин, Р.Сибат, З.Зәйнуллин, Иделбикә, Г.Морат, Р.Газизов, Р.Фәизов, Ф.Сафин, Ш.Маннапов, Р.Вәлиева һәм башка язучыларның иҗатларына багышланган эссе-мәкаләләре, иҗат портретлары, туксанынчы еллар татар прозасы, заман герое, әдәбиятта әдәп-әхлак мәсьәләләрен күтәргән полемик рухтагы язмалары һәм иҗтимагый-сәяси публицистикасы журналистны киң карашлы, кыю фикерле, әдәби процессны даими күзәтеп баручы әдәби тәнкыйтьче һәм публицист итеп таныта. Аның «Сөембикә»дә басылган мәкаләләре ике тапкыр (1998, 2000) «Елның иң уңышлы язмасы» дип бәяләнә, ә М.Фәйзи турындагы мәкаләсе һәм «Үткәннәрдән безгә гамьнәр калган», «Безне кемнәр аңлар?» дигән рецензияләре «Казан утлары» журналының 2000-2001 еллардагы махсус премияләре белән билгеләп үтелә, 2004 елда исә әдәби тәнкыйть өлкәсендәге казанышлары өчен ул ТР Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Җ.Вәлиди исемендәге әдәби премиясенә лаек була.

Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән төп басма китаплары: «Уйлы күңел» (тәнкыйть мәкаләләре, әдәби-публицистик язмалар; 2001), «Татар эзләү» (әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр; 2006).

Рәфыйк Шәрәфиев – 2000 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

---

[*] Сәхифә «Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек» (төзүчеләре: Р.Даутов, Р.Рахмани. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2009) китабы нигезендә әзерләнде.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ТАРИХИ-МЕМОРИАЛЬ ҺӘМ ЭТНОГРАФИК КОМПЛЕКСЫ

1993 елның 20 февралендә Чистай районы Яуширмә авылындагы мәдәният йортында, Гаяз Исхакыйның тууына 115 ел тулу уңаеннан, әдипнең музеен ачу тантанасы җәмәгатьчелек тарафыннан зур яңалык буларак кабул ителә. Әлеге чарада галимә Л.Гайнанова, әдипләр В.Нуруллин, Р.Әхмәтҗанов, Ә.Рәшитов, журналист М.Миншиннарның ялкынлы чыгышын, Г.Исхакыйның туганнары Галия һәм Сөембикә ханымнарның истәлекләрен авыл халкы әле дә сагынып искә ала. Музейга дәүләт статусы бирелә һәм ул ТР Дәүләт музейлары берләшмәсе составына кертелә, фондны баетуда актив эшчәнлек башлана. Галимнәр тарафыннан Г.Исхакыйның бай әдәби мирасы халыкка кайтарыла һәм әдипнең сәяси эшчәнлеге өйрәнелә, «Исхакый укулары»н уздыру традициягә әйләнә.

Музей һәм Г.Исхакыйның шәхесе, иҗаты белән кызыксыну көчле булу сәбәпле, көн кадагына аның мемориаль музеен булдыру проблемасы килеп баса. 1997 елда ТР Министрлар Кабинетының «Г.Исхакый мемориаль комплексын булдыру турында» карары дөнья күрә. Кызганыч, Яуширмәдә әдипнең әтисе Гыйләҗетдин хәзрәтнең йорты сакланмаган, аның нигезендә балалар бакчасы урнашкан. Әмма шуннан ерак түгел, Гаязның эзләрен саклаучы тагын бер бина, тарих-архитектура ядкәре буларак, хәзерге көнгәчә килеп җиткән. Ул – әдипнең бертуган апасы Фәридәбануның ире, беренче гильдия сәүдәгәр Сәйфетдиннең ике катлы таш йорты. Аңа өстәмә агач бина һәм башка хуҗалык корылмалары да салып куялар, эчке экспозицияләр дә өр-яңадан эшләнә.

Шулай итеп, 1999 елның 30 июлендә Гаяз Исхакыйның тарихи-мемориаль һәм этнографик комплексы ачыла. Хәзер исә музейның тимер ишеген ачып керүчеләрне сәүдәгәр Сәйфетдиннең өлкән улының сыны каршы ала. (Нәкъ менә ул 1910 елларда әлеге йорт төзелгән һәм әтисе яшь хатын Фәридәбануга өйләнгән вакытта (беренче хатыны вафат була) биредә сәүдәгәр булып эшли. Эчтәрәк Мөхәммәдгаязның әтисе Гыйләҗетдин хәзрәт һәм әнисе Камәрия абыстайның йортын, гомумән, XIX гасыр азагы – XX йөз башы татар авылы зыялысы тормышын чагылдырган экспозиция белән танышырга мөмкин. Биредәге ядкәрләр булачак әдипнең балачагы турында сөйли. Укымышлы мулла йортында сәкедән кала түгәрәк өстәл, шкаф-буфет, дивар сәгате, бай китап киштәсе дә булган. Мулла-әтинең образы – Коръән, шамаил, хөллә кебек экспонатлар, ә күлмәге, затлы зәркән-бизәнү әйберләре, калфагы һ.б. этнографик детальләр ярдәмендә Камәрия абыстайның эчке һәм тышкы дөньясы ачыла.

Музейда Гаяз Исхакыйның – авыл, 1890-1893 елларда – Чистай, 1893-1898 елларда Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсендә, 1898-1902 елларда Татар укытучылар мәктәбендә укуы, андагы даирә турында бай мәгълүмат бар. Экспозицияләр әдипнең иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге, төрмә һәм сөргеннәрдә уздырган гомере, «Таң йолдызы», «Ил», «Сүз» газеталарын чыгаруы хакында сөйли. Әдипнең үзе исән вакытта басылып чыккан китаплары, фоторәсемнәре һәм шәхесенә, иҗатына бәйле документларның төп һәм күчермә нөсхәләре дә саклана.

Таш бинаның икенче катында Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге чорын (1918-1954) чагылдырган экспозиция урнашкан. Биредәге бай материаллар әдипне Идел-Урал комитеты рәисе, татар мөһаҗирләренең лидеры һәм журналист буларак ача. Шунда ук Г.Исхакыйның эш өстәле, шәхси әйберләре, шулай ук Гали Акыш тарафыннан ТРның Беренче Президенты М.Ш.Шәймиевкә тапшырылган һәм соңрак музейга бүләк ителгән каләм дә бар.

Әлеге музейның экспозицияләрен эшләүгә, аның хуҗалык-утар комплексын булдыруга Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре, этнограф Й.Мөхәммәтшин, Г.Исхакыйның иҗатын халыкка кайтаруга зур көч куйган әдәбиятчы-текстолог Л.Гайнанова, язучының туганы С.Шәрипова һәм ТР Милли музее белгечләре зур хезмәт куя. Татар халкының йөзек кашы, горурлыгы булырдай әлеге тарихи-мемориаль һәм этнографик комплекс хәзерге көндә яңадан төзекләндерүгә, заманча үзгәртеп коруга мохтаҗ.

*Сәхифәне* **Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН** *алып бара.*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Минһаҗ маҗаралары

Мәскәүдән кайтып төшүгә, Казан язучыларын эзләргә тотындым. Аларның Казанда үз өйләре бар икән. Шунда җыелышып тәмәке тарта-тарта ыспурлашалар икән. Берәрсе хөкүмәт турында кыек сүз әйтсә, шуны җыелышып сүгәләр дә икән. Калхуз сыманрак нәрсә икән, үзләренең персидәтелләре дә бар икән. Мине шул персидәтел янына кертеп җибәрделәр.

Сөйләп бирдем мин шуңарга йомышымны. Баштарак бу миңа җүләргә караган сыманрак карап торды. Кайдан килгәнемне сорашты.

– Кама Тамагы районыннан, – дигәч: «Әллә анда бер дә акыллы кеше юкмы?» – дип, озак итеп тәмләп көлде.

Монда инде Минһаҗ абзагыз үзенең кем икәнлеген күрсәтте. Шап мин моның өстәленә Ләнит Илич кул куйган ысправканы. Анда язылган: «Габсаматовка разришается минем турыда писать руман. Никту ни имиет правы мишәйт», – диелгән.

Шуны укыгач, бөтерелә минем тирәдә персидәтел.

– Бөтен талантлы язучылар Кама Тамагы районы белән Арчадан чыга, – ди.

Шунда ук абкумга шылтыратып сөенеч тә алды.

– Безнең арага бик талантлы язучы килде. Ул Ләнит Илич турында руман язган, – диде.– Ярый, ярый, эшләрбез, – диде дә тилифунын куйды бу:

– Кайда руманыгыз, без аны хәзер абкумга алып барабыз, китерергә куштылар, – ди.

– Нәрсәсен китерим, мин әле аны язмаган,– дим. Еларга җитешеп миңа карап тора.

– Мин бит вәгъдә бирдем абкумга. Нишлим инде хәзер,– ди.

– Шылтырат та әйт, – мин әйтәм, – язмаган әле, диген.

– Син әллә абкумның кем икәнен белмисеңме? Бу Кама Тамагыннан җыен мәгънәсез кеше чыга, – дип, тилифунга ябышты. Үзе елмайгандай итә, үзе иелә-бөгелә, үзе тилифунга сөйли, – гафу итегез, руманны карап чыгасы бар икән. Борчыла күрмәгез, үзем мин аңа ярдәм итәм, – ди.

Урынына барып утырып, бераз сулу алгач, әйтә бу:

– Бер атнада язып бетер, – ди.

...Бер атнадан киттем руманны култык астына кыстырып Казанга. Кердем язучылар персидәтеле янына. Руманымны укып чыкты.

– Бик шәп булган бу, күмере төшкән руманның, – ди. Тик менә Маручканың имиләре руманны ямьсезләп тәртеп тора, – ди. – Мин үзем болай имиләргә каршы кеше түгел, – ди. – Әмма да ләкин абкум ни әйтер бит, – ди. – Анда бит хатын-кызлар имисез була, дип уйлыйлар. Әллә соң, «ими» дигәнне бүтән сүз белән алыштырыйкмы? «Түш» дип куйсак, ничек булыр, «күкрәк» дисәк, ничегрәк?

– Түш, мин әйтәм, казда да бар, күкрәк синең белән миндә дә бар. Ими Маручкада гына, – дим.

– Алайса «шалкан», – дип әйтик. – «Маручканың бик матур ике шалканын күреп сокландым», – дип төзәтик.

Кызык икән бу язучылар. Үлә яздым көлеп. Брижнев дигәч тә, дуракмы әллә ул шалкан күреп сокланырга. Мин шалканны ошатмагач:

– Алай булгач, «алма» дип языйк, – ди. – «Ике алма» дип язсаң, килешле чыгачак, – ди. – Үзе матур, үзе тәмле.

Тәки төзәттерде. Хәзер инде минем Ләнит Илич мунча чоланында Маручканың ике алмасына сокланып карап тора.

Ярый әле мунча чоланында Маручка берәү генә. Әгәр икәү булса? Әгәренки унау булса? Ничек итеп язасың инде аннары? Мин Маручкаларның бер яшнек алмасын күреп соклandым, дисеңме?

Ә сез сорагыз, абкумда ни әйттеләр, диегез. Маладис! Шулай, диделәр. Нәкъ менә шулай дип әйттеләр. Мунчаны да, Маручканың ике алмасын да кисеп ташла, диделәр, күмерен генә калдыр, диделәр. Аларча Брижнев көне-төне күмер генә чабарга тиеш икән.

Мин инде болары белән ыспурлашмадым. Киссәгез кисегез, татар инде ул кискәнгә күнеккән дип уйладым.

*(Дәвамы бар)*

**Рабит БАТУЛЛА**

## Һәрхәлдә

Ренат Харис «Татарстан хәбәрләре» газетасы ачып, шунда эшләр өчен язучылар туплый башлаган. Ләкин ни өчендер язучылар аның кул астында эшләргә алынмаганнар, ди. Шулай да бу эшкә Нияз Акмал җиң сызганып тотынган. Рөстәм Мингалим:

– Ата коммунист Ренат Харис янына нигә дип барып кердең?! – ди.

Аңа каршы Нияз Акмал, ачу белән:

– Һәрхәлдә, Ренат Харис коммунист булса да, Рөстәм Мингалим кебек: «Яктыртасың җирне, җылытасың, коммунистмы әллә син, Кояш!» – дип язмады, – ди.

## Хокуксызлык

Азатлык мәйданында ачлыкта утырганнан соң, Заһид Мәхмүди сакал үстереп җибәрә. Озын буйлы Заһидка сакал бик килешеп тора икән. Ләкин ул матур сакалын озак йөртми. Кырып ташлый. Моны күргәч, Батулла:

– Хатының кырдырдымы? – дип сорый.

– Каян беләсең?

– Беләм инде.

– Ие шул, хатын рөхсәт итми.

Батулла кыты-кыты көлә башлый.

– Нигә көләсең, Батулла абый? – ди Заһид.

– Соң, – ди Батулла. – Сакал-мыек үстерергә дә хокукы булмаган ир-егет үз халкына хокук яулый аламы?!

**Айдар ХӘЛИМ**

## «Казанның 1000 еллыгы» медале белән бүләкләнү уңаеннан

Барчасы да лаек булды Меңьеллык бүләгенә.
Бүләксез калдык Тукай һәм мин, – икәү генә.
Барчасы да медаль алган, барчасы да яшәргән.
Бер көнгә тагып торырга медаль алдым Бәшәрдән.

*(«Кырык тартма»дан)*

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Республика җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты Мөсәгыйт Мөдәррис улы Хәбибуллин озакка сузылган каты авырудан соң 4 гыйнвар көнне арабыздан мәңгегә китте.

Күп кенә хикәя, романнар авторы, публицист М.Хәбибуллин 1927 елның 25 декабрендә Оренбург өлкәсенең Абдуллин районы Габдрахман авылында дөньяга килә. Туып үскән авылындагы мәктәптә башлангыч белем алганнан соң, Баулы районы Яңа Шалты авылының җидееллык мәктәбендә укый. Сугыш елларында, уку белән беррәттән, колхозда да эшли.

1944 елда Магнитогорскига китеп, анда һөнәр мәктәбен тәмамлый һәм токарь белгечлегенә ия була. Шуннан соң өч ел дәвамында металлургия техникумында укый. Укуын тәмамлаганнан соң, 1958 елга кадәр Магнитогорск һәм Октябрьск шәһәрләрендә токарь, мастер вазифаларында эшли. 1958-1968 елларда Баулы һәм Азнакай районнары газеталары редакцияләрендә хезмәт куя.

Мөсәгыйт Мөдәррис улы 1969-1971 елларда Таҗикстанда урта мәктәптә тарих һәм җәмгыять белемен укыта. 1971 елда Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының читтән торып уку бүлеген (татар теле, әдәбияты һәм тарих белгечлеге буенча) тәмамлый.

М.Хәбибуллин 1971 елдан 1989 елга кадәр Казанда Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре булды. 1991-1999 елларда – «Мирас» журналы редакциясендә проза бүлеге мөхәррире.

М.Хәбибуллин «Кубрат хан», «Илчегә үлем юк», «Шайтан каласы», «Хан оныгы Хансөяр», «Аллаһы бүләге», «Батый хан һәм Ләйлә», «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный», «Атилла» кебек әсәрләре белән язучы-прозаик сыйфатында халык мәхәббәтен яулады. Мөсәгыйт Мөдәррис улы үзенең романнарында, тарихи чыганакларга таянып, татар халкының узгандагы тарихи үсешенең иң мөһим этапларын сәнгати сурәтләде.

Моннан тыш, М.Хәбибуллин тарихи темаларга, милләт язмышына, әхлак проблемаларына кагылышлы бик күп публицистик язмалар авторы буларак та танылды. Аңа Татарстан һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, Россия гуманитар фәннәр академиясенең мактаулы академигы дигән мактаулы исемнәр бирелде, ул Россия Язучылар берлегенең әдәби премиясе лауреаты һәм Кол Гали исемендәге Халыкара премия лауреаты булды.

М.Хәбибуллин 2003 елда «Кубрат хан» романы өчен Г.Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе белән бүләкләнде, ә 2008 елда Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә аңа «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мактаулы исем бирелде.

1970 елдан М.Хәбибуллин Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Мөсәгыйт Хәбибуллин күпләр өчен үз эшенә тугрылык үрнәге булып торды, аңа гаять зур дәрәҗәдә җаваплылык хисе, изге күңеллелек һәм кешелеклелек хас иде. Аның якты истәлеге күңелләребездә озак сакланыр.

**Р.Н.Миңнеханов, М.Ш.Шәймиев, Ф.Х.Мөхәммәтшин, А.В.Песошин, Ә.Ә.Сәфәров, И.Р.Метшин, И.Х.Әюпова, Р.Х.Гатиятуллин, Д.Х.Салихов.**

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ТӨРКИ ДӨНЬЯДА НӘСИМИ ҺӘМ ВӘЙСӘЛ ЕЛЫ

ТӨРКСОЙ халыкара төрки мәдәният оешмасының XXXVI Даими Шурасы утырышында 2019 ел төрки дөньяда «Имаметдин Нәсими һәм Гашыйк Вәйсәл елы» дип игълан ителде. Бу хакта ТӨРКСОЙ оешмасының матбугат үзәге хәбәр итте.

Нәсими – азәрбайҗан халкының күренекле шагыйре. 1370 елда Багдадта туган. Азәрбайҗан, гарәп, фарсы телләрендә иҗат иткән. Газәл һәм робагыйлар остасы. Бу гыйсъянчы шагыйрьнең шигырьләрен уку, исемен телгә алу озак еллар тыелган була. 1417 елда Сүриянең Алеппо каласында җәзалап үтерелә.

Вәйсәл – Төркиянең күренекле шагыйре. 1894 елда Төркиянең Сивас провинциясендәге Сивриалан авылында туган. Балачакта җил чәчәге белән авырып сукыр кала. 1965 елда Төркия парламенты бу сукыр шагыйрьгә гомер буена айлык хезмәт хакы («Туган телгә һәм милли бердәмлеккә хезмәт өчен») түләү турында карар кабул итә.

## ТАТАРСТАН ЖУРНАЛИСТЛАРЫ СЪЕЗДЫ

Казанда, Татарстан халыкларының Дуслык йортында Татарстан Журналистлар берлегенең XIX съезды узды. Анда медиамәйданның бүгенге хәле турында сөйләшү булды, киләчәккә бурычлар билгеләнде. Алар журналистларның иҗтимагый дәрәҗәсен күтәрү, матди хәлен яхшырту, иҗади активлыкны үстерү максатында бәйгеләрне дәвам иттерү, тарихи ядкәрләрне саклау, электрон технологияләр белән беррәттән, традицияләрне, басма матбугатны саклап калу зарурлыгы, яшь каләм ияләренә игътибарны арттыру, КФУ җитәкчелеге алдында Югары журналистика һәм медиакоммуникацияләр мәктәбе студентлары өчен бюджет урыннарын кайтару, берлек әгъзалары турында белешмәнең электрон базасын булдыру һ.б. мәсьәләләрне хәл итүдән гыйбарәт. Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова үзенең бу эштән китәчәген алдан ук хәбәр иткән иде инде. Әлеге вазифага ТР Дәүләт Советы депутаты, «Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат Әминов тәгаенләнде. Хәзер берлекне ул җитәкләячәк. Делегатлар алдында ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин чыгыш ясады. Съездда «ТАТМЕДИА» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов катнашты.

## РОССИЯ МАТБУГАТЫ КӨНЕ

Россия матбугаты көне уңаеннан Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театрында ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин республика газета-журналлары, радио-телевидениесе җитәкчеләре белән очрашты. Ул каләм ияләрен бәйрәм белән котлады, массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш керткәннәргә Дәүләт бүләкләрен тапшырды. ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, «ТАТМЕДИА» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов, М.Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры директоры Рәүфәл Мөхәммәтҗанов та үзләренең бәйрәм сәламнәрен ирештерделәр.

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ҮСЕШ СТРАТЕГИЯСЕ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Бөтендөнья татар конгрессы бинасында бер төркем язучылар татар халкының үсеш стратегиясе турында сөйләштеләр. Каләм ияләре аның эскизы белән сайт аша таныш иде. Фикер алышуда милли университет, татар гимназияләрен ачу, үзебезнең педагогик кадрларны әзерләү кебек тәкъдимнәр яңгырады. Әүвәл татарның үткәнен анализлау зарурлыгын искәртүчеләр дә булды. Язучылар татар халкының үсеш стратегиясенең эскизы буенча фикер алышу, яңа тәкъдимнәр туплау максатыннан, халык арасында оештырылачак зона утырышларында катнашырга теләкләре барын да җиткерделәр. Сөйләшүне Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары, Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев алып барды.

## ИСКӘ АЛУЛАР

Галим, мәгърифәтче, дин эшлеклесе, тарихчы, журналист, Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте мөфтие Ризаэддин

Фәхреддиннең тууына 160 ел тулу уңаеннан, Әлмәт районы Кичүчат авылындагы мемориаль музеенда «түгәрәк өстәл» утырышы узды. Анда «Татнефть» компаниясе генераль директоры урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев музейның Р.Фәхреддин мирасын халыкка ирештерүдә зур эш башкаруын әйтеп үтте. ТР Милли музее генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова бинаны киңәйтү мәсьәләсенә тукталды, аны хәл итүдә нефтьчеләргә зур өмет баглавын белдерде.

***

Тууына 110 ел тулу уңаеннан татар җәмәгатьчелеге каһарман-шагыйрь Фатих Кәримне искә алды. Язучылар, галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре Казанның Миславский урамындагы 8нче йорт (шагыйрьнең соңгы яшәгән йорты, ул шушыннан фронтка китә һәм кире әйләнеп кайтмый) диварындагы мемориаль тактага чәчәкләр салды. Аннары искә алу чаралары Татарстан Язучылар берлегендә дәвам итте. Катнашучылар «Татарстан» радиосы архивыннан Фатих Кәримгә багышланган тапшыру язмасын тыңладылар, истәлек-хатирәләр белән уртаклаштылар, фикер алыштылар, әсәрләрен укыдылар.

ТР Хөкүмәте каһарман-шагыйрьнең туган ягы – Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында музеен төзекләндерүгә акча бүлеп бирде.

***

Биектау районы Мәмдәл урта мәктәбендә драматург, шагыйрь Хәй Вахитның тууына 100 ел тулуга багышланган «Вахит: шәхес, иҗат, заман» дип аталган республика конкурсы булып узды. Анда дүрт номинациядә («Яшь шагыйрьләр», «Яшь язучылар», «Хәй Вахит әсәрләре – сәхнәдә», «Фәнни-тикшеренү эшләре») җиңүчеләр билгеләнде. Жюри составында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, аның урынбасары Рәмис Аймәт, язучылар Солтан Шәмси, Ләлә Гыймадиева, әдәбият галиме Әлфәт Закирҗанов, Г.Камал театры артистлары Ринат Таҗетдинов, Наилә Гәрәева, Хәлим Җәләлов, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Айсылу Имамиева  һ.б. бар иде. Хәй Вахитка багышланган бу чарада шагыйрьләр Шәмсия Җиһангирова, Рафис Корбан, Рифат Сәлах, галимнәр катнашты. Тантанага килгән кунакларны Биектау муниципаль районы хакимияте башлыгы Рөстәм Кәлимуллин сәламләде һәм Мәмдәл мәктәбенә 50 мең сумлык сертификат тапшырды.

***

Азнакай районы Туйкә авылында шагыйрь, Һади Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты Илдус Гыйләҗевне искә алдылар. Районга каләм ияләренең Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов җитәкчелегендә зур делегациясе кайтты. Аны Азнакай муниципаль районы хакимияте башлыгы Марсель Шәйдуллин каршы алды. Кунаклар Илдус Гыйләҗевнең каберен зиярәт кылды, чәчәкләр салды, шагыйрь истәлегенә мемориаль такта ачу тантанасында катнашты. Туйкә Мәдәният йортында, Азнакайдагы Мәдәният үзәгендә, мәктәпләрдә И.Гыйләҗевне искә алу кичәләре булды.

## ШИГЫРЬ КОНКУРСЫ

Дәрдемәнднең (Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев) тууына 160 ел тулуга багышланган шигырь конкурсы игълан ителде. Аны ТР Мәдәният министрлыгы Татарстан Язучылар берлеге белән бергә уздыра. Ул өч турда үткәрелә. Конкурста 17 яшьтән 35 яшькәчә булган шагыйрьләр катнаша ала. Гариза һәм шигырьләр 2019 елның 20 февраленә кадәр кабул ителә. Аларны электрон адреска (poet2019@mail.ru), Татарстан Язучылар берлегенә җибәрергә кирәк.

## «КАРДӘШЛЕК КИШТӘСЕ»

Башкортстанның Зәйнәп Биишева исемендәге «Китап» нәшриятында «Кардәшлек киштәсе» сериясендә шагыйрь Газинур Моратның «Сөюнең ак тирмәсе» дип аталган шигырьләр һәм поэмалар китабы басылып чыкты. Әсәрләрне башкортчага Фирдәвес Ногманова тәрҗемә иткән. Әлеге җыентыкта шагыйрьнең җан хөрлеге, шәхес иреге турында уйланулары үзәккә алына.

2019 елның 11 гыйнварында 84нче яшендә озакка сузылган каты авырудан соң 1987-1995 елларда ТР мәдәният министрының төзелеш һәм тарихи ядкәрләрне төзекләндерү буенча урынбасары булып эшләгән, Казан Кремлендәге Сөембикә манарасы очына ай куйдыруда зур роль уйнаган, «Семь ступеней минарета Сююмбике» дип аталган фәнни-документаль китапның авторы **Габбас Нурулла улы Мөхәммәтшин** вафат булды.

Чиләбе өлкәсе Троицк шәһәрендә яшәп иҗат иткән язучы-шагыйрь, публицист, СССР Язучылар берлеге әгъзасы **Басыйр Шаһинур улы Рәфыйков** 98нче яшендә вафат булды.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Р.КУРБАНОВА «Родина», повесть Ч.АЙТМАТОВА «Белое облако Чингизхана», повесть И.ДИНДАРОВА «Поле разногласий»; стихи Ф.ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, Д.СУЛЕЙМАНА, Р.НИЗАМИ, Г.САДЭ.*
*«Новые имена»: стихи Р.АБЗАЛОВА, рассказ Ч.ХАЗИЕВОЙ «Моя Асаль...».*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Исцеляющие руки»: рассказ Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ «...не подрезай наши крылья!»*
*«Татарстан. История. Личности»: очерк З.АХМЕТГАЛИЕВОЙ.*
*«Детская библиотека»: рассказ Р.ХАФИЗОВОЙ «День, когда вернулся папа».*
*«80 лет со дня рождения Ф.БАТТАЛА»: статья Р.РАХМАНА.*
*«Наши знаменитости»: Л.ГАЙНАНОВА.«Благоденствие».*
*«Наука»: А.СИТДИКОВ, Д.ЗАГИДУЛЛИНА. «Столица Хазарского каганата».*
*«Поздравляем»: 70 лет Р.ШАРАФИЕВУ.*
*«Наши музеи»: рубрику ведёт Л.ГУБАЙДУЛЛИН.*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: здания историко-мемориального и этнографического комплекса Гаяза Исхаки. Фото Л.Губайдуллина; поэт Айрат Суфиянов.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by R.KURBANOV «Motherland», novel by Ch.AYTMATOV «The white cloud of Genghis Khan», novel by I.DINDAROV «The field of contention»;*
*poems by F.GIZZATULLINA, D.SULEYMAN, R.NIZAMI, G.SADE.*
*«New names»: poems by R.ABZALOV, story by CH.HAZIEVA «My Asal...».*
*«Actual criticism»: section is conducted by D.ZAGHIDULLINA. «Healing hands»: story by F.ZAMALETDINOVA «...do not clip our wings!»*
*«Tatarstan. History. Personalities»: essay by Z.AKHMETGALIEVA. «Children's library»: story by R.KHAFIZOVA «The day when Dad returned».*
*«80th anniversary of F.BATTAL»: article by R.RAHMAN.*
*«Our celebrities»: L.GAYNANOVA. «Prosperity».*
*«Science»: A.SITDIKOV, D.ZAHIDULLINA. «The capital of the Khazar Khanat».*
*«Congratulations»: 70 years old to R.SHARAFIEV.*
*«Our museums»: section is conducted by L.GUBAIDULLIN.*
*«Pages of humor»: section is conducted by M.GALIEV. From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: the buildings of the historical memorial and ethnographic complex of Gayaz Iskhaki. Photo by L.Gubaidullin; poet Ayrat Sufiyanov.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Гаяз Исхакыйның тарихи-мемориаль һәм этнографик комплексы биналары. *Ленар Гобәйдуллин фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь Айрат Суфиянов.